# КАЗАН УТЛАРЫ

8

АВГУСТ

1980

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**8**

АВГУСТ
1980


## Бу санда


**Г. САДӘ.** **Алтын бөртек рәхмәте.** Шигырь . . . 3
**Ә. БАЯНОВ.** **Аргы яр.** Повесть . . . . . . . 4
**Р. ХАРИС.** **Йөрәк белән капшап.** Шигырьләр . . 70
**С. ШӘМСИ.** **Балконда.** Хикәя . . . . . . . . . 80
**М. РАФИКОВ.** **Төрле еллардан.** Шигырьләр . . 87
**Ә. САФИУЛЛИН.** **Гел зәңгәр булмый күкләр.** Хикәя . . . . . . . . . . . . . . . . 90
**Ә. СИНУГЫЛ.** **Дала җаны.** Шигырьләр . . . . 103
**Л. ШАКИРҖАНОВА.** **Атылмыйча калган ук өчен.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 105
**Р. ЗАКИРОВ.** **Шигърияткә.** Шигырьләр . . . . . 108

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**М. ЗАРИПОВ.** **Мәңгелек шәһәр.** Очерк . . . . 111
**М. ГӘРӘЕВ.** **Каһарман.** Очерк . . . . . . . 124

**Р. ФӘИЗОВ.** **Күңелле көн.** Новелла . . . . . 131

МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

**М. МӘҺДИЕВ.** **Шагыйрьнең гомер йомгагы** . . 134
**Р. ӘХМӘТҖАНОВ.** **Мирастан ике энҗе** . . . . 146
**Мәҗит Гафури турында фикерләр** . . . . . . 150

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. ГАЛИМУЛЛИН.** **Идел җырчысы** . . . . . . 152
**Р. ШӘРӘФИ, Р. МИНГАЛИМ.** Эзләнүләр юлыннан 165

**Безнең сафка** . . . . . . . . . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ә. КӘРИМУЛЛИН.** **Культурабыз үсеше елъязмасы** 172
**Н. ХАНЗАФАРОВ.** **Очлы күз, үткен сүз** . . . . 174

**Кечкенә рецензияләр** . . . . . . . . . . . 176



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Язучы Диләра Зөбәеровага 50 яшь . . . . . 180
Кәбир Бәкернең тууына 100 ел . . . . . . . 183
Халик Садриның тууына 90 ел . . . . . . . 184

Мәсәлчеләр мәҗлесе . . . . . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 24/IV-80 ел. Басарга кул куелды 15/VII-1980 ел. ПФ 13141. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94 000 экз. Заказ У-198
Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

## Госман Садә

### Алтын бөртек рәхмәте

Әй, игенче,
Уч төбеңә алып яктыга куй —
Янып торган алтын бөртек мин.
Гәрәбәдәй тезеп түшеңә так —
Нәкъ кояшның үзе кебек мин.

Назлы нурын юмарт өләшкәнгә
Мин кояшны сөям иң элек.
Бар тереклек аңа тартылган күк,
Рәхмәт әйтәм аңа үрелеп.

Кулларыңа алып татып кара —
Миңа сеңгән туфрак, җир тәме!
Ул кадәрле тәмле булмас идем,
Сеңми калса миңа тир тәме.

Үстергәне өчен куенында
Җир-туфракны сөям иң элек.
Тук башаклар гына аска карый —
Рәхмәт әйтәм җиргә иелеп.

Уч төбеңә алып яктыга куй —
Янып торган алтын бөртек мин.
Бөтен йөрәк җылың миңа сеңгән,
Бар нәрсәдән шуңа бөек мин.

Әй, игенче,
Йомыркалар сибеп бураэнага,
Рәхмәт мине иккәнең өчен,
Түм-түгәрәк ипи генә түгел —
Сүнмәс кояш иткәнең өчен!

Әхсән Баянов

# АРГЫ ЯР

ПОВЕСТЬ

*Журналның 1977 елгы декабрь санында «Тавыш — табигать бүләге» исемле әсәр басылган иде. «Аргы яр» шуның дәвамы. Кайбер нәрсәләр аңлашылып җитмәсә, шул беренче повестька мөрәҗәгать итүегезне үтенер идем.*

*Ә бу юлы сүз — бүтән хакта.*

*АВТОР.*

## Сәфәр

Елтыр күзле аю карачкысын кочаклап сөйде дә, Нажар күпмедер елларны сыйдырган тыныч биләмәсеннән киң дөнья буйлата сәяхәткә чыгып китте. Күптән түгел генә реаль чакырып торган Парижгамы, әллә Америкагамы? Юк, туган җиренә. Үзен тудырган һәм кочагында тирбәтеп үстергән тугайларына. Елганың киселгән башын яңадан ялгау нияте белән. Бер тәүлек, ике тәүлек барды—искитмәле үзгәреш күренмәде. Бердәнбер үзгәлек шул, игеннәр биегәя, куера төште. Тагын бер тәүлек узгач, район җитәкчеләре бүлмәсенә килеп керде. Елмаеп каршыладылар, шатланып кунак иттеләр. Урман ышыгына сыенып утырган умарталыкта өр-яңа бал белән чәй эчерделәр. Мәе дә булмады түгел. Мәҗлеснең тәнәфес сыман бер тукталышында рәсми төстәрәк әңгәмә дә булып алды. Район җитәкчеләре үрнәкле һәм гыйбрәтле мисаллар, саннар белән үз уңышлары, хәл-әхвәлләре хакында сөйләделәр. Ә Нажар, бодай шавына сандугач сайравы кушылса гына тормыш җырының гармонияле яңгыравына басым ясап, урманнарда кәккүк тавышларының, бүтән кош моңнарының тынуга якынлашкалын әйтте. Химикатлар белән эшли белү кирәклеген искә төшерде. Аны елмаеп тыңладылар.

Аннары Нажар туган җирнең төп урамы булган Тымызык елгасының аккошлары, чөлдиләре, челәннәре, торналары белән чыңлап торган яшел заманнарны, буасыз вакытларда да ат коендырган чакларны сагынып уфтанды. Бу сүзләрне кызгану кыяфәте белән тыңладылар. Аннары табигатьне саклау хакында нотыкка охшаган сөйләүләр булды. Тиешле предприятиеләр белән бу җәһәттән алып барылган эш-

не туктатмаячаклары турында вәгъдәләр ишетелде. Әмма сазлар һәм күлләрсез калган шәрә болыннарны яңадан терелтү вәгъдәсе ишетелмәде. Шул сәбәп белән Нажарның кәефе кырыла язганны сизгәч, елганың киләчәген хуҗалар матуррак итеп сурәтләргә тырыштылар, әлбәттә. Беркем кушмаган килеш, төп эшенә кагылмаган бу четрекле мәшәкатьне үзенә ирекле рәвештә йөкләгән өчен аермачык мактап, туп-туры соклану тойгылары сирпеп тә карадылар. Тик хәзергә эш шуннан ары уза алмады. Елга башын тергезү өчен гыйфриттәй экскаваторлар, бульдозерлар һәм киракся земснаряд торбалары белән килеп, тирә-як халык арасында шау-шу куптару мөмкин дип исәпләгән Нажар шәрә болыннар буйлап бер үзе генә йөрергә мәҗбүр булды.

Ләкин бу вакытлы тынлык, вакытлы гына ялгызлыктыр. Теге чакта ярдәмче хуҗалыкта тамчылардан ташкын җыелып шаулаган икән, монда Тымызык елга шундый хәлне мәгънәле итеп кабатлый алмасмыни?

Тымызык елга.

Күп еллар элек Нажар әле бик бәләкәй чакта, йөзә дә белмәгәндә, нәкъ менә шушы коры ком саргаеп торган җирдә, төнбоек чәчәкләренә алданып, тирәнрәк керде. Чәчәкне өзеп тә өлгерде, шул ук секундта аяклары су төбен эзләргә дә кереште. Таба алмады. Аннары ни булганын ул яр буенда һушына килгәч кенә төшенде. Тымызык су үзенең бер бөртек чәчкәсен дә жәлләгән иде ахры... Әмма чәчәк — кулда. Нажар да исән —аны коткарганнар. Ул чәчәкне чытырдатып кыскан хәлдә авылына таба атлады...

Бераз үсә төшкәч, язгы бозлар актарылганда, тегермән арты күллегендә каек төслерәк көймәдә йөзеп азаплана иде, артына борылып карады... Бөтен буаны тегермәне-ние белән күтәреп, елга Нажар өстенә ябырылган. Язгы елга зурлыгындагы шарлама астында калачак Нажар. Бер минут, бәлки секундтыр — бетәчәк Нажар. Мизгел эчендә ул көймәдән сикерде дә ава-түнә, бөтен тармаклары белән бутала-бутала, карлы-бозлы суны яра-яра, бата-чума чыгып ярга капланды. Тик анда да тыныч ятарга хут юк иде, котырган аю баласыдай дүрт аякланып, малай биек яр башына үрмәләде. Тагын, тагын секундлар коткарды.

Фаллар ачканда: «Әҗәлең су төбендә ята, сак бул!» дип куркытулар булса да, Нажар судан барыбер аерылмады. Язмыш икән, язмыш, ул аны бүтәннәргә калдырырга тырышып азапланмас, үзенеке үзенә булыр. Һәм Нажар әле дә менә шул суны ярата.

Төнбоек чәчкәсенә яңадан ташланырга, карлы-бозлы суда яңадан бата-чума буталырга әзер ул, тик Тымызык гүзәлнең элекке кодрәтенә яңарырга, кабат кайтырга җыенмый шул. Сай суларда чалбар балакларын сызганмыйча да аръякка чыгарга мөмкин... Аргы яр үзе дә тәбәнәкләнгән, сөзәкләнгән, инде су белән түгел, яшел чирәм белән күмелгән. Су алкынын сагына ярлар, су алкынын сагына.

Еллар узган саен, күргән-кичкән дәрьялар зурайган саен, Тымызыкка булган мәхәббәт тә кинәя, тирәнәя бара, сусауга охшап тилмертә. Гомердә беренче тапкыр аккош күргән дәрья — һаман күңелдә, күңелдә.

Тымызыктан ары Нажар киңрәк сулар күрде — Кама, Бөек Идел... Алар белән дә язмышын бәйләде Нажар. Ул суларда да таныш аккошын эзләде, әмма таба, күрә алмады.

Тымызыкны да, аккошны да гомергә бер күрмәгән кайберәүләр алар хакында җырлар язалар — шома чыга. Әмма кыен булса да әйтик, аккошлы Тымызыкны Нажар аңы, җаны белән генә түгел, тәне белән дә тоеп ярата, шома кешеләрдән көнли-көнли ярата. Сүзсез генә, тын гына. Уйлары да Тымызыкның үзе кебек: «Безгә дә бу изге елгаларны яңадан аккошлар белән кавыштырырга кирәк, шунда гына алар хакында җырларга хакыбыз булыр».

Нажар Тымызыкка шундый ният белән кайтты. Ләкин аның максатын әле житди кабул итмәделәр, елмайдылар гына. Якташлары Нажарны аңламады. Шуңа күрә ул хәзер, аякларын ярдан салындырып, тагын аптырап утыра.

Кичке нурлардан су өсте якты ут сыман кабынмады. Юк, әкертенәкертен тоныклана гына төште. Ниһаять, тора-бара кап-кара төскә керде. Төннең үзе шикелле. Ләкин әле бит кояш батып кына өлгергән. Ник болай бу?

Суны кичке шәүләләр каралтадыр дип, башта тыныч калса да, кара төскә кулын тыгып карагач һәм кул кап-кара чукка әйләнгәч, кара төснең нефть икәне беленде дә Нажарның йөрәге жу итеп китте. Елга астыннан узган торба шартлаган иде. Икенче көнне бульдозерлар белән яр эшереп, бүрәнәләр тутырып, елганың яртысын будылар да жыелган суга ут төрттеләр. Төтене күк гөмбәзенә терәлгән илаһи янгын диярсең, шулай котыра-котыра янды Тымызык елга. Ут белән су кавышканын Нажар беренче кабат әнә шунда күрде. Һәм бүтән елга-күлләрне, Каманы, Иделне күз алдына китерде...

Шул ук көнне промыселлар идарәсенә барып тавыш куптарып караган иде: «Тынычланыгыз, гаепле кешеләр жәзасыз калмас» дип юаттылар. Ләкин су өстендә балыклар ул жәзадан сөенешеп сикерерләр микән? Исән калган вак-төяк ташбаштан керосин исе аңкымый башлармы? Нажар шул сорауларга жавап көткәндә, идарә башлыгы кулына пиджагын алды да гафу үтенде. Ниндидер киңәшмәгә барасы икән.

Тымызыкның чыккан жиренә, бүтән районга баргач та әңгәмәләр шулайрак тәгәлләнде. Юк, киптерелгән жирне яңадан сазлыкка әверелдерүне яклаучы табылмады. Беркемнең бурычына да керми икән бу. Ә катырак сөйләшә башласа аңа тагын сәерсенеп, хәтта кызганып карадылар.

Юк, аңламадылар Нажарны.

Нажар яшел чиксезлектә адашты. Тымызыкның инеш кенә булган жирендә бер ярдан икенче ярга сикерә-сикерә аргач, аяклары кая атласа, шул таба барды, озак, бик озак барды. Атлый торгач бер нәрсә ачыкланды: дөнья Нажарны алдаган икән бит — эштә, хыялда һәм... хәтта мәхәббәттә!

Ләкин нишләргәдер кирәк. Ләкин баш чатнаганчы уйласаң да, тәгаен фикергә килү мөмкин түгел әле.

Көн өйләдән авышкан тирәләрдә елганың буылган бер урынына килеп жителгән иде. Нажар шундагы карт өянке күләгәсенә барып йөзтүбән капланды. Йөрәк ачыргаланып үзе кычкырыр сыман иде. Күз яше чишмәдәй агып, инешне тутырыр кебек иде. Ләкин алай булып чыкмады. Йөрәккә һәм күзләргә өянке ярдәмгә килде — күренмәс кайгы ажгырыпмы ажгырды. «Синең кулыңда нишләп әле агачтан ясалган булса да кылыч юк? Син бит хәзер жил тегермәннәре белән сугышырга тиеш. Тиеш-ш-ш!»

Нажарга бу уйдан бәлки кычкырып көләргә кирәк булгандыр, әмма көлә алмады, чөнки бу эшне аннан уңышлырак башкаручылар бар иде.

— Хи-хи-хи-хи!

Күтәрелеп караса, аргы ярда, мәгъруր карама тирәсендә яшь кенә ике кыз утыра икән. Икесе дә баштанаяк ялангач...

Күзләрен угалады Нажар. Юк, чын иде манзара — теп-тере ике гүзәл нәрсәдәндер шатланып көләләр. Нәрсәдән көләләр икән шушы хәтле чын итеп? Күк зәңгәрлегеннән? Яшеллек чиксезлегеннән? Дөнья хозурлыгыннан? Әйе, күк зәңгәрлегеннән, яшеллек чиксезлегеннән, дөнья

хозурлыгыннан һәм, барыннан да бигрәк, яшьлекнең үзеннән. Яшьлек үзе сәбәп. Һәм көлә чибәрләр, көләләр!

Ә Нажарны күрәләрме икән? Ара күп булса ике йөз метр чамасы гына бит. Бөтен нәрсә күз алдында. Ләкин алар өчен Нажар әйтерсең юк. Тартынырга, ялангач оялчыкларын яшерергә уйламыйлар да. Яшьлекнең мәңгелек тантанасы хакында яшел чиксезлеккә аваз салалар бугай. Алар өчен Нажар кыенсына икән, кыенсына бирсен, алар өчен Нажар күзләрен каплый икән, капласын. Әмма монысы да озакка түгел. Карамыйча булдыра алмый Нажар. Карый да, уйлый да ул. Аргы ярда — кешелекнең бөек тере картинасы. Кайда, нинди галереяда күргән иде Нажар бу картинаны? Хәтерли генә алмый әле. Тик шунысы хак, чынлап та бар мондый сурәт, аның авторы да тел очында гына, тик әллә нишләп, әйттем дигәндә генә телдән ычкына.

Кызларның берсе аягүрә басты да куллары белән күзенә төшкән чәчләрен аралый-аралый суга таба тагын да якын килә башлады. Әнә инде аермачык: таррак иңбаш, чамасын белеп кенә табылган, сирень чәчкәләре сыман пар тәлгәш, аркадан түбәнрәк — калын ук булган тылсымлы тормыш, шул тормышның ышанычлы дәвамы һәм сакчысы шикелле ап-ак аяклар, илаһи уйлар белән яктырган саф чырай һәм хәрәкәтләр — бөтенесе бергә оялуның нәрсә икәнен дә оныттыра. Шушындый да ак, шушындый да тере мәрмәр була икән лә! Шушындый да уңышлы һәйкәл була икән! Моңарчы мәңгелек диган бу гүзәллек жансыз, хәрәкәтсез иде. Ә монысы — теп-тере, атлый әнә, иелеп су чәчрәтә. Иптәш кызына нидер әйтә-әйтә, суга керә һәм... су чәчрәгән тавыш белән көлә дә чирканчык ала.

— Ай, шундый җылы су!

Аккошның үзе — йөзә генә! Күпме еллар сагынып эзләгән хатирә кайтты лабаса? Җитмәсә, ул ерак та түгел, җитмәсә, ул якынайганнан якыная. Су уртасына житкәч, әйе, әйе, Нажарны күрде ул. Күрде дә текәлеп калды. Алай гына да түгел, мөгаен, Нажардан сүз көтә иде. Ә Нажар? Нажар артык сихерләнүдән һәм көтелмәгән бәхетеннән ни дә булса әйтә алу дәрәҗәсеннән ерак иде шул. Нажарның авыр хәлен җиңеләйтү нияте беләндер инде, кыз аңа тел ачкычын үзе ыргытты:

— Сез нишләп коенмыйсыз? Шул кадәр әйбәт лабаса су!

Бу тавышка берсүзсез ышану фарыз иде, бу тавыш бары тик дөреслекне генә әйтә белә һәм бары тик бәхеткә генә дәшә ала торгандыр. Һәм аны Нажар кайчандыр ишеткән дә иде сыман. Кызның үзен дә Нажарның кайчандыр күргәне бар иде шикелле. Кайчан, кайда? Шунысын гына искә төшерергә кирәк. Хыялга ярдәм итәр өчен Нажар:

— Сез кем? — дип, турыдан-туры сораганын сизми дә калды.

Шактый ук мәгънәсез сорау булгангадыр, кыз шаяртып кына җавап бирде:

— Мин аны каян белим?

— Мин сезне таныйм, ахрысы.

— Мин дә сезне беләм.

— Чынлапмы?

— Чынлап, ахрысы.

Кыз шулай диде дә үз ярына таба атлыкты. Су читендә кыюсыз гына чупырдаган иптәш кызы инде аны көтә иде. Алар казлар каңгылдашкан мәгънә белән нидер сөйләшә-көлешә, Нажар ягына күз ташлый-ташлый судан чыктылар да киенергә керештеләр. Кыяфәтләре: «Су тар гына лабаса, егет кеше була торып, шуны да йөзеп чыга алмыйсыңмыни?» дип, сүзсез генә аръякка чакыра иде. Нажар өнсез чакыруны ишетте, ләкин каккан казыктай селкенә алмыйча тик торды. Үзен үзе онытыр дәрәҗәдә сихерләнгән иде ул. Кызлар куак артындагы зәңгәр автомобиль белән гүләп күздән югалгач кына һушына килеп, инде баскан җирендә урын таба алмыйча үрсәләнеп калды. Ел-

ганы йөзеп чык та автомобильне куып җит хәзер. Тик монысы инде бары тик хыялда, аның да бик бәендә генә мөмкин хәл. Әйтелгән ике-өч бөртек сүзенә һәм үзен шактый ук иркен тотуына караганда, кыз аны чынлап та беләдер. Шулай булгач, сөйләшүдән дә баш тартмаячак иде. Әмма Нажар өянке ыжылдавын тынлап, үкенүдән, уфтанудан ары беркая китә алмады. Яр читенә килеп, тагын аякларын салындырып, аргы ярга күз текәп, озак, бик-бик озак утыра гына алды. Уйлана торгач, тагын бер нәрсә ачыкланды: дөнья Нажарны менә шушы рәвешле ымсындырган, шушы рәвешле алдаган икән. Моның бәясен бары тик дөньяның үзен дә алдалау чарасын табып кына кайтарырга мөмкин булачак...

Нажар ничәмә еллык күзәтүләрен, өен калдырып сәяхәткә чыккан. Гомер мәгънәсе булган эше Европада бәхәсләр кузгата торгандыр. Нажар сәяхәтче аюдай адашып ~~йөри, ә исеме һәм тапләсе, бөтенләй~~ юкка чыктылар шикелле. Эш һәм кеше, Сак белән Сок шикелле, бәлки бүтән кавыша да алмаслар. Нажарның иң ышанган кешесе Фәнүзә дә, әйе, башкалар белән буталып, ирнең кешелек дәрәҗәсенә, алай гына да түгел, гомер максатына — көтелгән ачышларына хыянәт иткәч, дөньяда нинди изге нәрсә кала? Шуннан соң туган җиренә тиле өметләр белән кайтып, җил тегермәннәре белән сугышыр хәлдә йөргәннән соң, чын кеше иқәнлеген тоюдан туктап, Нажар үзен тик фамилия итеп кенә тоя башласа ни гаҗәп? Догасыз әрвахлар теге дөньяда шулай кая сугылырга белмичә кубарылып йөрерләр, имеш, исәннәрдән дога килмәсә, мәңге шулай йөрерләр, имеш, дип сөйли иде Нажарга әнисе ерак балалык елларында. Әнисе Нажарга хәзер мондый тирән сүзләр сөйләргә тартына, ләкин Нажар үзе сүз башласа һәм хәлен аңлатса, догасын биреп, улын ач әрвах хәленнән коткарыр иде ул. Ләкин хәзер аның да файдасы тимәс шикелле. Монда хәзер, мөгаен, бүтән төрле дога кирәктер һәм ул доганы әле генә күздән югалган артык та гүзәл кыз беләдер. Үзәкне өзеп, шул кызны күрәсе килү, куып җитү теләге һәм куып җитә алмау әчесе — яңа тойгы борынлап дөньяга чыкты — нәни кош баласымыни. Йөзә белмәгән малайның тирән судагы төнбоекка ташлануымы бу? Әллә язгы ташу кебек өскә сикергән бозлы шарлавыкны көтүеме? Әгәр дә баягы кызны күрү мөмкин дисәләр, әйе, әйе, бары тик тагын бер кабат күреп калу гына булса да мөмкин дия алсалар, Нажар йөзә белмәгән хәлдә су тирәнлегенә, өметсез хәлдә дә бозлы шарлама астына ташланыр иде. Чөнки дөнья һәм аның бер рәвеше булган Фәнүзәдән әҗәт түләтүнең бердәнбер чарасы да нәкъ шул гына була ала. Тырышлыксыз, хезмәтсез-нисез, рәхим ит, менә нинди ачыш: Нажарның күңеле сөю үзгәрешенә, яңа мәхәббәткә әзер, юк, әзер генә түгел, ул аны көтә, юк, көтә генә дә түгел, әзли, ашкынып-кангырып әзли икән ләбаса!

Тик ул, хәзер үк торып яңа хыялы артыннан чабарга тиешле кеше, яшел ярда чалкан ята. Җил дә исми, үлән дә селкенми. Талчыккан уй да, дөнья да тып-тын, тып-тын. Колак тынлыктан нидер эзли, табарга азаплана һәм күпмедер вакыттан соң таба да.

— Зең, зең, зең...

Әллә күптән онытылган черки авазлармы бу? Шушы хәтле дә нечкә, сак аваз! Хәтердәге черки әллә биткә кунган? Әйе, әйе, биттә бу авазлар. Тик битләрен сыйпап карагач, кулга берни барлыгы да сизелмәде. Нәрсә соң бу?

— Зең, зең, зең...

Эзләде, иштте, тапты һәм төшенде Нажар; бу хәтле дә сак зеңләү белән үтә нечкә әйбер генә үсә ала. Бу нәрсә — нибарысы Нажарның сакалы, үз сакалы икән ләбаса. Ә төсе?

Нажар белә: чәче сары булса да, сакалы кара аның. Әгәр ирек куй-

саң, йөзен тиз арада кара сакал күмәчәк. Ялгызлыкта бигрәк тә тиз үсә икән кара сакал. Әгәр ирек куйсаң...

Әмма Нажар тиз генә сикереп торды да ашыга-ашыга атлап китте.

...Шәһәргә кайткач, хатыны Фәнүзә һәм кызы Энжедән башка тора алачагына ышанмыйча өенә кергән иде дә... тик хатыны аны елмаймыйча гына каршылады. «Ахрысы, теге чактагы хата хата гына булмаган...»

Шул уй белән Нажар элегрәк квартирада торган таныш апасына кабат китте. Гәрчә эшкә нәкъ элеккечә йөреп, күзәнәк гаиләсендәге аксым агышын күзәтү-тикшерүне дәвам иттерсә дә, бу җансыз диярлек шөгыльне Нажарның хәзер бары тик фамилиясе башкара шикелле иде. Чынлыкта ул — яңа кеше. Иптәшләре аны, әйтерсең, танымыйлар, аңламыйлар... Бары тик елтыр күзле аю карачкысы моны бөтен тирәнлеге белән тоя, әмма серне чишмәс өчен терелергә, яңадан тавышка, телгә ия булырга гына теләми. Гәрчә ул белә, һәм бөтенесен дә белә... Бары тик ул гына...

Шәһәргә кайткач ничә көн узгандыр, Нажарны аюдан һич ким аңламый торган яңа бер зат барлыкка килде. Яп-якты бер көндә институтка килеп, үзе эшләгән өченче катка күтәрелим дисә, монысы тагы нинди саташу? Әйе, ныклабрак кара, синең алда хыялның үзе. Тымызык су буенда күптән түгел генә күреп кайткан су кызы басып тора бит. Нәкъ үзе, билләһи! Җитмәсә, ул кыз Нажарны таныды, башлап хәтта үзе исәнләште. Моңа Нажар ясалма кыюланып:

— Сезнең исемегез ничек? — дип сораган иде, кыз:

— Онытыбрак торам бит әле, — дип баш уйнатты.

— Ә күптәнме монда?

— Ике ел.

Ничек? Алар бер институтта эшлиләрме? Ә Нажар аны күрмәгән, дөньяда барын да белмәгән? Хәер, Фәнүзә әйткәндәй, ул дөньяның үзеннән үк аерылган һәм күзәнәк чиксезлегенә кереп югалган иде бит. Инде фаразларга мөмкин булганча, Нажар якты дөньяга чыккан икән. Бөтенесен күрә, хәтта менә шушы кызның чибәрлеген дә.

— Шушы ике ел вакыт эчендә сезне бер тапкыр да күрмәү була торган эшме? Әллә сезне яшереп тоттылармы?

— Әһә, яшереп, яшереп тоттылар.

Шулай дигәч, кыз таныш көлү белән көлеп куйды. Бу көлү теге чактагы ялангач гүзәллекнең бүтәнчә сынлануы иде. Үзе сөйкемле, үзе куркыныч... Төнбоеклары белән, яңарыш вәгъдәләре белән чакырып торган тыныч су төбе шикелле, карлы-бозлы шарлама шикелле. Аңардан качып, чабып кына котылып булырмы? Бу юлы бит Нажар инде бүтән кеше — малай чак елгырлыгыннан җилләр искән бит!

Ә секундлар җилдән җитез. Нажар өченче катта үз бүлмәсенә борылырга мәҗбүр. Шуннан соң яшәлгән ел чамасы вакыт исә — бүтән тормыш, бөтенләй бүтән дөнья.

Мөнәсәбәтләрдән, кичерешләрдән, уй һәм вакыт нисбәтләреннән хасил булган бу дөньяда тоя белгәннәр өчен нәкъ гади тормыштагыча мәхәббәт белән сугарылган һава, эфир дулкыннары бар. Күңелләр анда да төрле диапазоннарда бер-берсен эзли, таба, очраша, сөйләшәләр. Хәзер ул дөньяның ике ягында — ике кеше. Бары тик икәү. Вакыт һәм ара ераклыгына буйсына белмичә, ике кеше әллә бәхәсләшә, әллә аңлаша...

## Кыска дулкыннарда

Кадерле кешем!

Син мине бөтенләй аптырашта калдырдың, нидән башларга да белмим. Чыннан да, бөтенесе ничек килеп чыкты соң, нинди хәлдә без — ачыклыйсы килә.

Дөресен әйткәндә, безнең очрашулар бик тә сәер башланды бит. Сәер һәм хәерсез?

Туган якларда сәфәр йөрүнең борчулы нәтиҗәләрен һәм лабораториядә еллар буе барган күзәтүләрнең бер-ике атналык отчетын язган идем. Ашыгыч эш. Күзәтү-отчетларны рәтләп адәм теленә күчерә торган лаборанткабыз ялда булганлыктан, секретарь кыз мине синең бүлмәгә алып керде. Бу вакытта кая барганымны, синең кемлегеңне һаман башка китерә алмыйм бит әле.

Кердек. Институтның гыйльми секретаре белән янәшә япь-яшь кыз утыра... Тукта, бу бит — син, Тымызык су буендагы тере сурәт, берничә генә көн элек таныша язган чибәр зат! Син бит бу!

Секретарь кыз кулымдагы кәгазьләрне алып сиңа сузды һәм шуны гыйльми советка күрсәтерлек хәлгә китерүеңне үтенде. Исемеңне шунда беренче кабат ишеттем — Гөлчәчәк. Ә син, быртыргы Гөлчәчәк, кәгазьләрне кулыңа алдың да тиз арада актарып чыктың һәм кичке диңгез суы төсле яшькелт кара күзләреңне яман да җитди тутырып карадың. Әйе, бу күзләр белән караган кеше бары тик җитди сүз генә әйтергә тиеш иде. Ләкин син?

— Сезнең монда исемегез язылмаган.

— Нажар минем исемем.

— Фамилиягез дә юк.

Синең бюрократлыкны шаярып төзәтмәкчемен:

— Габбасов, әгәр шулай әйтергә ярасa.

— Габбасов? Шул фамилия белән дә дөньяда йөреп буламыни?

— Нишләп?

— Әгәр минем фамилиям шундый булса, мин кеше арасына чыга алмас идем, көн-төн өйдә утырыр идем.

— Ярый соң, бүгеннән мин дә шулай эшләрмен. Тик бит... тик мин бит аның шул хәтле ямьсез икәнен беренче кабат ишетәм. Инде нишләргә соң?

— Габ... габ... фу. Аб... «Аб» — ярыйсы. Аббасов. — Еще хуже. Аббас... Юк, Абба, Абба. Менә кем сез. — Үз табышыннан диңгез суы төсле күзләр яшькә дә манчылган иде шикелле. — Я, ризамы сез шуңа?

— Риза. Сезнең хакка.

— Булды. — Тымызык су буенда очраган кызга бөтенләй охшамаган Гөлчәчәк кулъязманы тагын кулына алды. — Ну что, иптәш Абба, сезнең бу эшегез...

Шаккатып торам, кыяфәтең — иң олы түрәләрчә, аларның да иң олпаты, кырысыныкы. Көләргәме, ачуланыргамы — белмәссең.

— Нишләгән?

— Бик бәләкәй материал бит, тотынсаң бетәргә тора.

— Ә сез уңайсызланмагыз, мин түләү әмәлен табармын.

— Нинди әмәл соң?

— Ну, дискотекага чакырырмын.

— Дискотекага? Анда бит егерме бише тулмаган яшьләрне генә кертәләр. Ә сезгә...

— Ә мин сезгә ияреп керермен.

Әмма сине шаян тонга тәки күчереп булмады. Түрәлек роленнән тәки аерыла алмыйча:

— Сезнең бу эшегезне эшли алмыйм, — дип куйдың.

— Нишләп?

— Мин хәзер авырыйм.

Ышанмадым, әлбәттә. Шаяртасың дип, кул селтәдем дә, чыгып киттем. Ашыгыч һәм кирәкле эш, болай салкын гына карый алмассың.

Ул көнне мин башка йомыш белән институттан бөтенләй киттем. Иртән килгәч исә, күрше бүлмәдәге иптәшләрнең берсе, Хәлим, кичәге

эшләрне тәртипкә салынган, ап-ак кәгазьгә күчереп язылган хәлдә кулыма тоттырды. Телефон аша рәхмәт әйтүне азсынып үз янына югары катка күтәрелгән идем, синең урында бүтән кеше, ир кеше утыра. «Гөлчәчәк авырый, бер атнасыз чыга алмас», — диде ул.

Нишләптер шунда уянып киткәндәй булдым да чынлыкта бүтән кереп йөрмәскә тиешлегем хәтергә килде, чөнки монда бит каршы ишек артында гына киң маңгайлы, шәрә лепкәле бер дус утыра. Кайчаннан бирледер аны исеме белән атаганым юк. Моңарчы иптәш мөдир дисәм, хәзер — иптәш гыйльми секретарь, чөнки лаборатория мөдире буларак үзен акламагач, аны мин кайтуга тагын да югарырак күтәреп куйганнар. Директорга кереп тиргәшә язсам да: «Әгәр без гел үз теләгәнебезне генә эшләп йөрсәк, тормышның кызыгы да калмас иде», — дигән фәлсәфи нәтиҗә генә ишеттем. Димәк, бу бүлмәгә минем аяклар басмаска тиеш. Шулай да... Шулай да, Гөлчәчәк, үз-үземә каршы барырга син мине мәҗбүр итәсең. Бер атнадан соң тагын ачтым ишегеңне. Тик тагын буш иде урының. Каршы ишек ачык булганлыктан, бу юлы сүз катмыйча мөмкин булмады.

— Сезнең Гөлчәчәк атлы кызыгыз бүген эштәме?

Чын галим кыяфәтле гыйльми секретарь:

— Безнең Гөлчәчәк атлы кызыбыз бүген эштә, ләкин ул хәзер ашханәгә төшеп китте, — диде.

Бер атна элек син шушы кеше булып уйнаган идең мәллә?

Ләкин коридор аша узышлый сиңа барыбер тап булдым. Ничектер, каушабрак исәнләштек. Без тукталгач, иптәш кызларың тиз арада юкка чыкты.

— Мин сезгә рәхмәт әйтергә кергән идем.

— Рәхмәт? Сез кем соң? — каушауга охшаган нәрсә тиз арада тагын җилгә очты.

— Ну, ничек инде? Абба мин.

— Әх, Абба! Мин сезне танымый торам бит. Сез ул көнне бүтәнчәрәк күренгән идегез.

— Мин анда әйтермен, бераз акча язарлар.

— Үз эшегезне дәүләттән түләтмәгез әле.

— Соң... алайса... — дип, сүз таба алмыйча, акча чыгарам.

Син бәлки, тиеш булмаганны түләмәс өчен сатулаша башлар дип, мыскылларга җай эзләгәнсеңдер, әмма кешесенә туры килмәдең — гафу ит.

— Юк, ул хәтле тиеш түгел! — дисең дә читкә тайпыласың.

— Бүтәнчә нишли алам соң?

— Белмим.

— Алайса, әйдәгез, көндезге ашка ресторанга керәбез.

Шул рәвешле без — ресторанда.

Хәтерем ул көнне сәгатьләре, минутларына чаклы тәгаенләп саклый. Минем хыялда ул сәер һәм якты утрау сыман кала бирер шикелле — очраклы сүзләрдән, елмаю, шаярулардан — уеннан башланды. Шаярып кына, юри генә син йөзем шәрабы сайладың, мин—бераз коньяк. Юри генә, ирнәп кенә эчкән булдың һәм, шуңа күрә бугай, исермәдең. Ә мин аз гына коньякны чынлап эчтем һәм бераз кәефләнә төштем. Коньяктан гынамы? Шулай булса икән. Хәмердән тиз ук айнып була, ә мин һаман да, менә шушы көнгәчә айнып бетә алмыйм. Ә син моны әллә сиздең, әллә юк. Хәер, бу хакта уйлап та карамагансыңдыр әле. Уйламыйча, уйнап кына:

— Әллә нигә битләрем яна, — дигән булып, чынлап алсуланган битләреңә, яңакларыңа шәрабтан түгел, күзләреңнән, үзеңнән шәүләләнеп күчкән алсу-зәңгәр төсләр белән уйнаган бокалны назлап терәдең дә: — Ә сезнең куллар ерак шул, — дип шаярттың.

Әмма мин нәрсәнедер чынлап тойдым, нәрсәгәдер чынлап өметлә-

нергә кирәклеген аңладым. Син эшләгән бүлмәдә беренче очрашуда ук без бу уенны башлаган булганбыз икән. Ул очрашуда ук шаяртып, сүз җаеннан: «Безнең каннар бергә кушылып яши ала», — дип ычкындырганым хәтергә килде... Беренче сөйләшүдә!

Бокалны назлаган кулың түбән төшкән арада сак кына минем кул сузылды, әйтерсең, кабат исәнләштек, әйтерсең, ни хакындадыр килешеп кул кысыштык. Чынлап та, килешү иде бугай бу. Аң белән булмаса, тән белән аңлашу булгандыр. Ә аң — икенче дәрәҗәдәге көч кенә ул. Мәхәббәт беркайчан да акылдан башланмый. Акылдан башланганы исәп дип атала. Безнең килешү барлык исәпләр һәм аңлы эшләргә каршы килеп башланды һәм, әлбәттә, нинди кодрәттер безне чакыра, тарта иде. Тау өстендәге ташны упкын төбе шулай дәшә торгандыр. Тагын шунысы бар, әгәр биеккә, биек йорт балконына менеп җиргә карасам, минем сикерәсем килә, нәрсәдер тыелгысыз тарта — кош сыман канат җәеп, шул рәвешле түбән мәтәләсе килә. Чынлап торып очып китмәс өчен, гадәттәгечә тагын да югарырак карыйм яки өйгә үк кереп китәм. Ә синең яннан, синең яннан китә белмәдем шул, уйлап та бирмәдем.

Уйсыз шатлык урамга чыкканда тагы да үсте. Киң баскычлардан җитәкләшеп төшкән чакта, инде берничә ел элек үк яшьлек белән мәңгелеккә саубуллашкан булуым хәтергә килсә! Яисә моны пышылдап кына, белмәгән сабак өчен югары билге алырга ярдәм иткәндәй әйтеп куючы табылса! Юк, булмады, безнең куллар, әйтерсең, аерылмас өчен тотышкан иде. Табигать нәрсәдер ымлады шикелле. Көтмәгәндә коярга керешкән август яңгыры безне кинәт кенә телефон будкасына куып кертте. Безнең эшкә табигатьнең тыкшынуы аркасында, кысан будкада бер-беребезгә мәҗбүри сыланып тордык һәм кысышкан куллар безне тагын да якынрак тартканга буйсынып... Тукта, монысы ничек булды соң әле? Юк, ул чакта түгел, хәзер дә әйтә алмам моны: безнең ирennнәр әллә шаярып, әллә чынлап бергә кушылдылар...

«Безнең каннар бергә кушылып яши ала!..» Әллә шул уен сүз чынга әйләнәме? Будкадан чыккан чакта күңелгә кереп калган сурәт шул: күрше будкада малайлар торган һәм безгә карап шаркылдашканнар икән. Аларны абайлагач та ояла белмәдек, ахрысы, монысы хәтердә сакланмаган. Кызара алмасак та, сагая язганбыздыр, чөнки урамны аерым-аерым чыктык, чөнки син өйләнең инде узганлыгын, эшкә шактый соңлавыңны әйткән булдың һәм ашыгып йөгергән булдың. Әйтерсең, мин соңламаган. Әйтерсең, шушы кәеф белән нәрсә дә булса эшләргә мөмкин!

Бер-ике сәгать кем керсә шуның белән сөйләшеп, вак-төяк нәрсәләр хәл итеп утыргач та, сиңа шалтыраттым һәм озак көттермичә төштең дә, без — тагын бергә. Нәрсәләр хакында сөйләшкәнебез хәтердә калмаган, димәк, телдә юк-бар гына булган. Ә менә озату...

Дөресен әйткәндә, гадәттән инде чыккан, онытылганга күрәдер, сине озата ук бару нияте юк, теләгем сине троллейбуска утыртып кына җибәрү иде. Шул уй белән тукталышта бераз торгач та, урамның аръягында алма сатканнарын күреп, син мине шунда алып чыктың, алманың рәтсезлеген күргәч һәм минем кабат троллейбус янына чыгарга чамалавымны сизгәч:

— Әйдә, шушы урамнан бераз гына бергә узыйк инде, — дидең.

Мин исә, көндез башланганча, уйсыз иярдем. Сине өеңә якынайта, мине күнегелгән тормышымнан ерагайта торган юнәлеш белән атладык. Икенче тукталышка җиткәч, кире борылу нияте башыма килеп өлгергәнче үк, син мине ары алып киттең — урамны җитәкләшеп чыктык, әле транспорт керә башламаган урамның тап уртасыннан атладык — урамның түгел, шәһәрнең генә дә түгел, әйтерсең, дөньяның уртасыннан!

Шәһәр уртасындагы тынлык утравы, мәхәббәтнең үзенә охшаган кичке иркә җил — җиңел. Күңел аннан битәр. Әмма бераз гына баргач та, һәр даим сагалаган куркыныч кебек, каршыбызга бозау хәтле эт килгәне күренде. Безгә җитәкләшергә, бер-беребезгә сыенырга тагын бер сәбәп. Караңгы төшеп килгәндә, мондый җан иясе белән очрашканда, сагаю — табигый хәл. Ләкин без моны куркыныч урам дип кабул итмәдек һәм ялгышмадык та. Тиз арада эт артыннан йөгереп малайлар килеп чыкты һәм безгә бер сәбәпсез ниндидер әйбәт сүзләр әйтеп калдылар алар. Тик хәтер генә ул сүзләрне санга сукмаган. Куркынычның күңелле нәрсә белән алмашынуы сәбәбеннән без тагын шатланып кочаклаштык һәм тагын үбештек. Көтмәгәндә килгән шатлык сәбәбеннән хәтта мин сине күтәреп алдым һәм, әйтерсең, инде күптән оныткан бәхетемне табып, синең белән бергә аны да киң урамның, юк, урамның гына түгел, шәһәрнең, юк, шәһәрнең генә түгел, дөньяның тап уртасыннан үзем белмәгән төбәк тарафына алып киттем.

Мин үземнән моны ук көтмәгән идем, әлбәттә. Гомумән, бөтен гомеремдә ике-өч кенә кабатланган шатлыклы онытылу булгандыр бу. Һәм мин шунда үземнең дөньяга кабат туганымны, икенче яшьлек белән яши башлаганымны сиздем. Тагын ук дөресрәге — тоемладым. Ә аңлавым — соңрак.

Алда нәрсә?

Алда — тагын да тынрак, караңгырак урамнар. Бу шәһәрдә гомеремнең яртысыннан күбесен кичереп тә бер кабат та күрергә туры килмәгән ят урыннарда күңелгә шом килә. Инде хушлашырга вакыт икәнен чамалап, сине тагын кочакладым да:

— Үп мине! — дидем.

Әмма көтелмәгән хәл.

— Ярамый.

Нишләп?

— Монда минем егетем тора. Күрсә, сугыша башлар.

— Ә мин әле бер дә куркыныч барын тоймыйм.

— Шул килеш калсын.

Шул килеш калган теләкне күңелдә алып китәргә туры килде. Ә эшкә ашмаган хыял теләкләрне җилкетә...

Август җиле чәчләрне, битләрне сыйпаган, муеннарга ук уралып иркәләгән чакта, күз алдында — синең куллар, синең күзләр, синең түс. Әйе, синең түс, синең сурәт барлыкка килде — елмая, көлә, шаяра, иркәли, иркәләнә. Инде сине күз белән генә түгел, матурлык итеп, хыял белән тоям. Тик сәбәбен генә аңлый алмыйм.

«Безнең каннар бергә кушылып яши ала!..»

Өйгә кайтып салкын су белән юынгач, кылган эшләремә үзем ышанмыйча, үзем шаккаттым. Ләкин күз алдында — һаман синең сурәт.

Нишләргә миңа? Мин болай яши белмим, мин аңа күнекмәгән, житди эш, житди тормышка күнеккән мин. Ничек котылырга бу сурәттән? Ничек котылырга ялган белән сулый торган тилелектән, уеннан ничек котылырга?

Ничек айнырга?

Бәлки диваналык иртәнге томан белән бергә күккә очар. Тәндә, җанда бәлки иртәнге зәңгәрлеккә охшаган, онытылырга гына торган якты, җиңел хатирәләр генә калыр...

Ә чынында?

Чынында, киресенчә, исемнәре табылып җитмәгән буталчык сызлануларны ап-ачык үкенү, оялу алыштырса да, яңа түс, яңа кеше, яңа сурәт һаман елмая, көлә, шаяра бирде.

Нишләргә мөмкин, ни чара моңа, кайда котылу чарасы? Юк. Аны эзләү урынына, мин сурәтнең оригиналын эзлим! Сине эзлим, Гөлчәчәк,

ишетәсеңме, сине! Син кирәк миңа: сусап су эзләгән кеше сихерләп минем җанны алган да үзенекен миңа салган булырга тиеш.

Бәхетем — бер айга син ялга китәргә тиеш — еракка, чит илгә. Тик бер ачылган сәләт тиз генә томаланамыни ул: бүгенге матурлыкны иртәгә дә саклау мөмкинлеге кала, бүгенге тилелек иртәгә дә үзенә шөгыль табар...

Синең белән саубуллашканда, Гөлчәчәк, ышанмым, мин үземне аламаның аламасына чыгарып тиргәдем, тик тиргәсәм дә, барыбер тилелекне киметә алмадым. Кочаклашу, үбешүләр, онытылмас сүзләр.

Бергәлекнең соңгы минутлары.

Мин синең янга кердем. Хушлашачакбыз.

Ишетелер-ишетелмәс кенә «эһе» дип баш кактың да, күзләрең иркә йомгалап, янәшә ишекне шактый ук кыю ябып куйдың. Гыйльми секретарь хәзер безне ишетмәс.

Гадәти һәм табигый кабатланулардан соң йомгаклау көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты:

— Бөтенесен киләчәктән көтәбез, — дим.

— Әйе.

Күзләреңдәге шаянлык җепселләрендә миңа таныш булмаган хәвеф ялтырап куя. Сүзең төгәлләнгәнче, коридор ишеге ачылып, аннан тагын чибәр генә кыз керә дә, син аның белән таныштырасың:

— Иптәш кызым.

Иптәш кызыңның башы авырта икән, дару сорый. Синдә дару булмауны сәбәп итеп, безнең сүз төгәлләнмәгәнне белгәнгә, ашыгып чыгып китә. Син тагын нидер әйтмәкче, шулай да ходай язмаган аны миңа ишетергә, мин тик ымсындым гына. Бәлки ул сүз әйтелмәскә тиеш булгандыр һәм шуңа күрә күңелеңнән чыгу җаен тапмагандыр. Ә тиеш теләк әйтелә ул, җаен таба барыбер. Ә син әйтә алмадың, чөнки, иптәш кызың чыгып киткәнне генә көткәндәй, телефон шалтырады да, син, чак кына уңайсызланып, трубканы алдың. Аермачык сизелгәнчә, мәгънәләре аңлашылмый торган сүзләр генә әйттең: «Әйе, юк, күп, түгел». Ләкин ахырда мәгънәле бер сүз барыбер ычкынды: «Ярый, кайткач, как-нибудь загляну». — Трубкада кызлар тавышы түгел иде.

Каушамасам да нәрсәдер сизендем. Инде соңгы сүзләр әйтелгән һәм бөтенләй үк чыгып китәргә баягы кыз һәм хәзерге телефон шалтыравы гына комачау иткәнне сәбәп итеп, кул изәдем:

— Бетте, хуш.

Бу ике сүзгә «Бүтән очраша алмабыз» дигән өч сүзле өстәмә мәгънә салынган иде салынуын, тик, моңа дикъкать үк итмичә, елмаеп кына калдың. Димәк, яңадан күрешү булырга мөмкин һәм булмаска да мөмкин. Синең бая тел белән тәгаен әйтеләсе вәгъдәң әйтелмичә калу—икебез өчен дә тиешсез бурычны өскә алмау кебек иде.

Ныклабрак уйлый китсәң, мондый гына танышу-очрашулар элегрәк тә булмагандыр түгел, булгандыр. Булган да, вак-төяк үпкән-коч-кан тиз арада җилгә дә очкан. Табигый хәл. Монысы да шулай булыр. Шулай тиеш.

Башкалар эше булган ашкыну һәм онытылулардан бер ай микъдарлы ераклыкта синсез яшәп, үз өлешем белән канәгатьләнергә карар кылдым. Ә син ФРГ дигән ят ил кояшы астында кызын...

«Бетте, хуш!»

«Ярый, кайткач, как-нибудь загляну», — диген. Якында безне бик җиңел килешү көтә...

«Хуш, бетте!»

Ләкин бу сүзләрне кабатлаганда ник йөрәк ашкына, җилкенә башлый? Көтелмәгән фаҗига кешене шулай сәбәпсез җилкендерә...

Исәпләр мондый мәгънәдәге очрашуларның бүтән булмаячагын исбатласа да, тора-бара мәҗбүрияткә күнел күнеп, инде тынычлана яз-

са да, мәгәр син кайтыр көн якынайган саен исеме табылмаган кодрәт исәп ташының башта очлырак мөешләрен, аннары исә үзен үк кимерә, шомарта торды. Син кайтыр мәл житкәндә, ул инде тәсбих урынына йөргән таш мисалында шоп-шома хәлгә килгән иде.

Кайтсаң да сине каршыларга, күрергә ашыгыр идемме, юкмы, йөгенә керү читен, әмма шәп сәбәп чыкты — миңа каты гына грипп эләкте дә, атна чамасы өйдә чирләп яттым. Тик шул ук вакыт киресе аңлашылды: синең исәнлек мине кызыксындыра, яшермичә әйткәндә, синең тавышыңны үлеп ишетәсем килә икән. Алай гына да түгел, рәхәтләнеп бер туйганчы сөйләшәсем килә. Ләкин колакта һаман бер үк сүзләр: «Ярый, загляну...»

Бар, бар, чит илләрдә күңел ач. Ә мин... Ә мин тотам да трубканы алып, саннар җыям.

— Алло!

Я хода, синең тавыш! Теләсәң ничек чыда, җавап бирмә.

— Алло!

Синең тавыш ямансу, хәтта елыйсы килгән кешенеке сыман. «Сагынган!»

— Пип-пип-пип! — кыска гудоклар.

Түздем, эндәшмәдем. Исәнсең икән, хәзергә шул бик житкән. Ә калганына... калганына түзәрбез. Болай булгач, мөмкин әле ул. Тилелекне оныта төшеп, зур кеше булып йөрү мөмкин төсле хәзер.

Терелеп эшкә чыккач, үз кабинетыма кереп тормастан, директор бүлмәсенә кердем. Секретарь кызның исән-саулыгын сорашкан арада (кай арада!) син кердең дә... Инде чү, ни хәл бу? Ялдан кайткан кеше шушындый хәлдә, караңгыда үскән үлән хәлендә буламыни? Синме соң бу? Һәм шуннан, артык гаҗәпләнүдән булса кирәк, шактый ук рәсми исәнләштек. Син килеп кул сузсаң, торып басачак идем, әлбәттә, ә син «Исәнмесез», дип кенә куйдың да, кыенсынуыңны җиңәр өчен секретарь кызны кочаклагандай иткәч, чыгып та киттең.

Бу катта минем якын кешеләр байтак. Аларның да хәлләрен кереп белештем. Берсе — Хәлим дус, синең хактагы хәбәр белән шаккатырды. Син, имеш, канцелярия кызларына минем белән булуың хакында Германиядән кайтып төшкән көнне үк мактанып сөйләгәнсең. Ә алар, имеш, чыш-пышны тарата белә.

— Син аңа әйт, сөйләнеп йөрмәсен, — диде Хәлим.

— Булды, рәхмәт, әйтермен.

Димәк ки, Гөлчәчәк, синең белән сөйләшмичә барыбер ярамый.

Үз бүлмәмә кайтып вак-төяк эшләрне тәртипкә китергәч, лабораториягә кереп таныш күзәнәкләрнең хәлен белгәч, өйлә дә житте. Аннан соң да директорга тагын ниндидер йомыш бар иде, күпмедер сөйләшкәч чыксам, тагын син очрадың. Әмма минем белән, директордан башка, Хәлим һәм тагын бер-ике кеше булганлыктан, сүзсез генә узып китмәкче идең, бу юлы үзем туктаттым:

— Гөлчәчәк, нишләп исәнләшмисең?

— Исәнләштем ич... бая.

— Ә-ә.

Кутәрелеп карасам, директор тукталмаган, егетләр кай арададыр таешканнар. Безгә шарт тудыралар!

Сүзсез генә сезнең ишек төбенә җителгән икән. Тик син аны ачарга ашыкмыйча:

— Ә мин сезне шалтыратыр дип, исән кайтуым белән котларсыз дип уйлаган идем.

Чын рәнҗү белән карыйсың.

— Авырдым бит.

— Беләм инде, телефон трубкасын да ала алмаслык булмагандыр.

Төш вакыты узса да коридорлар нишләптер тынычланмаган. Әле

бу, әле теге ишек шакылдаң, кешеләр тыз-быз йөрүдә дәвам иткәнлектән, мин сине бинаның икенче башындагы баскыч ягынарак чакырдым. Бу төштә тынычрак иде. Бәлки әле бая Хәлимнән ишеткән сүзләрне ачыклый алырмын.

Ничек башларга белми торганда сүзне бөтенләй көтелмәгән яктан, үзең башладың.

— Ә мин сине шул кадәр сагындым!

— Сагындың? — Гаҗәпләнүемнең чамасы юк.

Мин бит андый ук хискә исәп тоткан кеше түгел. Ике-өч кенә тапкыр очрашкан кешене ничек сагынырга мөмкин? Тик үзем соң? Ә үзем?

— Ә син мине бар дип тә белмисең.

— Мин шалтыраттым, Гөлчәчәк, тавышыңны да ишеттем.

— Ә минем синең тавышны ишетәсем килүне уйламадыңмы?

Тагын аптырабрак калдым. Кулларым күз тирәсендә буталганда синең куллар белән очрашты да шул рәвешле без, аерылып торганнан соң беренче тапкыр, исәнләшкән булып чыктык. Синең куллар шул хәтле дә назлы, үз иде ки, бу күрешү кинәт күңелдә өр-яңа шатлык тудырып, ике кулым белән синең яңакларыңны кыстым да чәч төшеп торган маңгаеңнан үптем.

— Алайса, дәвам итәбез.

— Әһә.

Күңел тагын беренче мәхәббәт кичергәндәгечә яктылык белән тулды. Һәм мин тагын әйтәсе сорауларны шунда калдырып, синсез яшәлгән елларымны, оятымны таптый-таптый, үз бүлмәмә төшеп киттем. Ләкин артык дулкынлануданмы, әллә грипптән калган хәлсезлектәнме арына алмыйча, ул көнне синең янга бүтән менмәдем дә, яңадан шалтыратмадым да. Сәбәпнең иң зурысы — минем хатын-кыз белән дус булу тәҗрибәләренең шактый сай булуы белән аңлатыла иде булса кирәк. Бу институтта инде җиде ел эшлим. Шул елларның берсендә дә гүзәл җенеснең күзләренә күтәрелеп карарга вакыт таба алмаганмын икән. Менә башны күтәреп, күзләремне ачыбрак карасам... шаклар катарлык — матурлык хәтта күзләрне чагылдыра һәм мин аннан шактый ук куркам да бугай.

Бер көн, ике, өч көн.

Эшкә килеш.

Ишек ачылуга, анда — син! Син — бер үзең!

Кузгаласы идең бугай, әмма мине күргәч тукталдың.

Икәүдән-икәү менеп киттек һәм нигәдер шактый баргач кына кул бирештек.

— Сезнең мине бер дә күрәсегез килмимени?

Сүзне, әлбәттә, син башладың, чөнки мәгълүм сәбәп аркасында, инициатива күрсәтү миңа оят, син моны сизә идең бугай. Ә син чын мәгънәсендә азат кеше, ничек тә килешә, беркем алдында да җавап бирәсе юк, хәтта — вөҗдан алдында да. Ә миңа шаярып котылу да бик житкән:

— Мәңге карап торсам да туймас идем.

— Шулай булгач? Неужели без бер җирдә дә очраша алмыйбыз?

— Минем бит әле грипп һаман узмаган, йоктырырмын дип куркам.

— Йоктыр, бергә чирләрбез.

— Каһәрләрсең дип куркам.

— Беркайчан, беркайчан.

— Бүген мине университетка кафедра утырышына чакыртаннар. Озакка сузылмаса, шалтыратырмын.

— Көтәрмен.

Тагын кул кысышмакчы идек тә, тиешле катка житеlү сәбәпле, «пока» белән саубуллаша торырга мәжбүрбез.

Кафедра утырышы сәгать бишләргә бетсә дә, университеттагы хөрмәтле бер профессор юбилеена багышланган гыйльми совет утырышына калырга кирәк булып чыкты да, шул хакта сиңа шалтыраткан идем, ахрысы, хәтерең калды.

— Ә мин көтеп утырам тагы, — диден.

Һәм мин синең балаларча бүлтәйгән иреннәреңне күрәм, очрашырга чынлап тырышуыңны чамалыйм һәм үзем дә сизмәстән:

— Әйдә алайса, ял көнне очрашабыз, — дип тәкъдим ясыйм.

— Кайда?

— Белмим шул.

Минем тәжрибәсезлектән, булдыксызлыктандыр инде, син трубканың теге очында мыскыллагандай көлеп куясың. Шуңа күрә, тәгәлрәк әйтмәкчемен:

— Әйдә, алайса, Кремль сәгате янында.

Онытыла язган элекке очрашулар күз алдыннан узгандай итә.

— Сәгать...

— Сәгать дүрткә.

Мин ул көнне чак кына алдарак килдем дә, тирә-юньгә күз ташлагач, күрешүне монда билгеләүнең ялгыш икәнен чамаладым. Чөнки монда һәйкәл янына язылышкан яшьләр килә. Ә син ак күлмәкле кызларның берсе урынында үзеңне күрергә теләмисеңмени? Минем белән исә бары тик кара күлмәк кенә киярга мөмкин. Шул уй белән автобус тукталышында каршыларга тиеш таптым. Үзең төшкәч тә һәйкәлгә таба түгел, ә урамга таба алып киттең.

Акрынлап атлый торуга «Ял» кафесына жителгән — шунда кердек. Безнең ашханәләрнең хәле мөшкел икәнлеге миңа да билгеле. Ләкин анда начар гына йөзем шәрабының дә булмавы барыбер кәефне кырмый калмады. Кызларны ничек итеп каты эчемлек белән сыйларга?! Гаеп миндә түгеллектән көч алып:

— Коньяк эчәбез инде алайса? — дим.

Ә син бу сүздән сискәнеп үк киттең:

— Юк, юк!

— Рәтле вино юк. Алайса, акны...

— Әйе, бераз булышырмын.

Кәефең китмәве һәм шул «бераз» эчкә чак кына жылы кертте шикелле. Чырайлар ачыла төште.

— Әйдә, тост әйт, Гөлчәчәк.

— Әйтә алмам шул.

— Алайса, телдән әйтелми торган теләгең өчен эчәбез — чынга ашсын.

— Әнә бит сез ничек матур әйтә беләсез.

— Эчә дә беләм.

Беренче тәэсир күрсәткәнчә, икенчесе раслаганча, катыны да эчә белгәсең икән. Кыстарга куркып торуым юкка булып чыкты. Шунысы гына бераз жайсыз, күтәрелгән кәефең янадан төшә куйды, нигәдер моңая калдың, хәтта уфтана башладың. Моның аракыдан икәнен сизгән килеш, сәбәбен сорыйсы иттем, хәерсез. Ә син телгә килгәнне тыеп торырга һич уйламыйча әйттең дә салдың:

— Әгәр мөмкин булса, син азат кеше булсаң, без әйбәт кенә тормыш корыр идек, — дип мине берьюлы телсез калдырдың.

Менә ни уйлыйсың. Менә нинди икән синең телдән әйтергә ярамаган теләгең: минем узганнарны сыза төшү! Ләкин нишләргә мөмкин?..

— Безнең очрашулар менә шушылай утырудан гына гыйбарәт булачак, — дим.

Официант кыз ягымлы булды. Без чыгарга жыенгач, хәтта «Урам-

да яңгыр бит» дип кунакны кыстагандай итсә дә, калырга риза булмадым. Кәеф тоту өчен миңа вакытның аз бирелүе сәбәпле (синең белән мондый бәхәсләр алда иде әле) официанткага һәм сиңа:

— Яңгыр булса да, анда кочаклашырга мөмкин, ә монда ярамый бит, — дип шаярткан булдым.

Шаярудан чынга адымнар күп түгел, әлбәттә. Теләкләр — күбрәк.

Син икенче көнне тагын очрашу ягында идең. Вакыт кысан булганга күрә, төгәл вәгъдә бирә алмасам да, син барыбер килгәнсең һәм мине вәгъдәсезгә чыгаргансың.

Иртән эшкә килгәндә, вахтадагы кара кучкыл егет янында басып тора идең, мине күргәч, аның белән елмаеп-көлеп үк сөйләшә башладың. Ай, бу садә беркатлылык! Мин бит сине күрми дә уза беләм! Хуш!

Ләкин бүлмәгә таба күтәрелгәндә, кеше арасында булса да, безне баскычлар барыбер очраштырды. Рәнҗүле карашыңны гына булса да күрү, һич югы, күзләр белән гафу үтенешү ләззәтле иде.

Язмышларны оныттык — узганын, киләчәген. Күңелдә тик — көннәр, сәгатьләр, минутлар. Бәлки алар безнең өчен булган һәм үзебез кылган барлык гамәлләрдән кыйммәтлерәк, мәгънәлерәк һәм татлырак булгандыр. Халык җырларында мәхәббәтне җир җиләк, пешкән кура җиләге дип атыйлар — тәти сүз генә дип йөри идем мин аларны. Гомер буе шулай булды. Ә хәзер халык беркайчан да ялгыш әйтмәгәнне тагын бер кабат аңладым бугай.

Шушы хәтле дә кайнар була ала икән кочаклашулар. Мин сине әллә ничек үзем белән бер тән, бер җан, бер ашкыну, бер теләк итеп тоям. Иреннәр талгач, куллар аргач читкә тайпылганда, үзең дә сәеррәк тел белән: «Син вкусный!» дип куясың. Соңыннан исә бу сүзләр «минем сине эчәсем килә, минем сине ашыйсым килә» дигән сәерлекләр белән алмашынды.

Мин — егет, син — кыз.

Еллар ялгышкан!

Язмышлар саташкан!

— Әгәр минем бер ялгышым булмаса, без очраша алмаган булыр идек, — дисең син.

— Нинди ялгыш?

— Мәңге онытылмый торган — минем язмышны харап иткән.

Минут эчендә күзләреңдәге шаян яктылык гөлт итеп сүнә дә ике кулың белән чигәләреңне тотасың.

— Нәрсә булды? Ник?

Аркаң белән борылып, тынасың. Ә мин нәрсә дә булса аңларга, фаразларга тиеш. Уйлап та, фаразлап та карыйм, ләкин барыбер төгәен фикергә килә алмыйм.

Гөлчәчәк, акыллым, дустым, син үзең генә аңлат, зинһар — шулхәтле дә кыен эш түгелдер бит?

*
* *

Кадерлем минем, Аббам!

Ничек аңлатыйм — мин ул нәрсәгә бүгенге көнгәчә үземнең дә дөрес кенә бәя бирә алганым юк бит. Мин ул чакта артык яшь, хәзергегә караганда да җүләррәк идем. Совет районына, сезнең гыйльми институтка барып эшләү уе әле башка килгән нәрсә түгел, шулай да баргалый идем, чөнки анда минем якташ кызым эшли.

Якташ дигәннән, туган җирем — Кама буе. Туган өем елга ярыннан күп дигәндә ярты чакрым гына. Шулай да без, бәләкәйләр, анда еш булмыйбыз, әти-әниләрнең үзләре белән генә баргалыйбыз — җәй бусна ни бары өч-дүрт тапкыр. Үзебезне генә җибәрмиләр. Яр буенда-

гы куакларда, имеш, безне бүреләр сагалый, ә елганың үзендә усаллыкта бүреләрдән һич калышмый торган җәеннәр посып ята. Әти-әнисез балалар суга төшмәсме дип, авызларын ачып, йотарга торалар.

Без, өч кыз, гел бергә уйныйбыз. Кап-кара ихата, сап-сары, сикәлтәле урам туйдыра. Бакчада исә бөтенләй уйнарга кушылмый. Анысы кушылмаганга бик аптырамыйбыз, тик менә елга буена җибәрмәүләре иребезне кыса, безне бүреләр, җеннәр, бөтерелеп аккан су, аждаһалы чоңгыллар кызыктыра.

Бер яктан:

— Юк, ярамый!

Икенче яктан:

— Рөхсәт ителгәннең аръягында, тыелган белән ике арада иң ләззәтле сөенечләр җанны иркәли ул. Ышанмасагыз, үзегез килеп күрегез. Дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, җәенле, аждаһалы чоңгыллар аша үтә-үтә, елга аръягына чыгыгыз: анда сезне зәп-зәңгәр киңлекләр, үзегез дә ышана алмаслык матур үзәннәр, әрәмәләр — әкиятләр көтә.

Әти-әни сүзен тыңлап, син түзәсең, ике ел чыдап торасың, өч ай, ике, бер ай газапланасың, өч, ике көн интегәсең һәм түземең бетә дә син иптәш кызларыңны котырта башлыйсың.

— Бүре дә бүре диләр, куак арасында яшеренеп ята диләр. Әйдәгез шуны еректан булса да карап киләбез, ә?

— Ул безне куса?

— Ул безне тотса?

— Тиз генә суга сикерербез.

— Ә суда җәен эләктерсә?

— Суда чоңгыл йотса?

— Дулкынга утырып, аръякка чыгарбыз. Анда бүре дә, җәен дә, чоңгыл да юк — анда җәй дә, кыш та чәчкә ата торган әрәмәлекләр, карлыганнар, шомыртлар, тагын, тагын әллә ниләр. Анда без аккошлар белән танышабыз, бергәләп чумышлы уйныйбыз, качышлы уйныйбыз. Әйдәгез, киттек!

Чабыша-чабыша куаклыкларны үтәбез. Анда безне бүре куса да без аңардан шәбрәк чаба беләбез—тиз генә дулкыннар арасына ышыкланырга дип, суга сикерәбез.

Әти-әниләр белән су керүләрнең файдасы шул: безгә инде, сигезтугыз яшьлек кызларга, йөзәргә өйрәнәсе калмаган — дулкыннарны колачлый-колачлый, агып та китәбез.

Тик аз гына баргач та, бер кызыбыз кире борылды:

— Аръякта да шушындый куаклар, анда да әле җимеш пешмәгән ди безнең әти. Мин аргы ярга чыкмыйм, мин кире киттем.

Һәм китте дә — куркам димәде.

Икенчесе, елганың яртысына җиткәч, куркуын туп-турыга әйтеп бирде:

— Гөлчәчәк, мин кире борылам, әллә кая агып киттек, адашырбыз, әйдә кире үзебезнең якка, Гөлчәчәк, әйдә. Гө-ө-өл-чә-ә-чә-ә-к!

Ул кирегә таба йөзә башлаганда, мин инде аңардан ким дигәндә йөз метр түбән агып киткән, әмма куркырга кирәген чамаламый идем. Артка борылып карамыйча, йөзүемне белдем — шатлыктан сулыш кысыла, төпкә китәрмен сыман, калтырап куям, тик шушы калтырауның ләззәте аңлата алмаслык татлы. Аръякка шушы рәхәтне татыр өчен генә дә чыгарга мөмкин икән. Анда тагын да көчлерәк шатлык — ят яр. Мин зурлар да йөзеп чыгарга батырчылык итми торган суны кичеп чыктым, мин куркуны җиңдем! Мин рөхсәт ителгән киңлекне уздым да, рөхсәт ителмәгән якның бәлки үзендә үк йөрмәсәм дә, һич югы, ике арада, рөхсәт ителгән белән тыелган арасында йөрдем. Миңа хәзер кем нәрсә әйтсә дә барыбер, мин чын мәгънә[illegible] азат! Әрәмә-

ләр, сез гади сыман тоеласыз гына. Бу—икенче төрле җир, чит җир, бу — әкият!

Берүзем булса да яр буеннан чабам, әрәмәләр аралап йөгерәм — якында гына кошлар чыркылдаша, аккошлар җилпенә — барысы, барысы миңа сәлам бирә. «Исәнме, тылсымлы аръяк! Мин — синеке!» Бүген монда бик озак тора алмам, чөнки әниләр югалтыр да эзләп интегерләр. Мин бит башсыз ук кыз түгел, дулкыннар үземне өч чакрымга түбән алып төшкәнлекне бик яхшы беләм, мин үзебезнең якка кабат чыгар өчен суга бу төштән төшәргә тиеш түгел. Бөтенләй төшмәскә дә мөмкин — моннан ике генә чакрымда паром бар дип күрсәткән иде бит әти — шунда барам мин. Анда ялындырмыйча гына утырталар. Кояш баеп өлгергәнче, мин инде кайтып та җитәм.

Шатлыктан тыным-көнем бетеп кайтып керсәм, әни: «Әй, балам, син исәнсең икән!» дип, әй елый, әй коча, әй үбә! Әй шатлана минем кадерле әнием. Аны бары тик мин генә шушы хәтле шатландыра алдым, моңарчы беркайчан да бу хәтле каушап сөенгәнен хәтерләмим. Мин әниемне гел сөендереп яшәячәкмен — хәзер моның олы серен ачтым, беләм, бик, бик яхшы беләм.

Әнием кулыннан бушагач, әтием кочагында, аннары дәү әнием кочагында рәхәт чиктем. Тик караңгы төшкәч кенә икенче иптәш кызыбызның әнисе шашкан кешедәй килеп керде:

— Сезнең кыз белән бергә киткәннәр икән, су кергәннәр. Кызыбыз әле булса юк.

— Безнеке кайтты, исән, аллага шөкер.

— Ислам кызы да кайткан, безнеке генә юк.

Эшнең ничек булганын миннән сораштыргач та җыйнаулашып су буена чаптылар. Ярты төнгә хәтле йөрсәләр дә таба алмаганнар. Иртәгесен дә, аннан соңрак та эзләп карадылар, тик минем иптәш кызым бөтенләйгә юкка чыкты. Шул хәлдән соң үзем өчен гомерлек бер фикер туганын сиздем: я бик куркак булып, үз өеңнән чыкмыйча, читкә борыныңны да чыгармыйча тыныч ят, я куркыныч диган, күзгә күренми торган сызыкларны чынлап та күрмичә һәм курыкмыйча уза бел, ә урталыкта — хәтәр. Тыелган белән рөхсәт ителгән арасында — шулай ук хәтәр, әмма монысы әйтеп аңлата алмаслык шатлыклар белән бизәлгән, тылсымлы ара. Анда куркуны җиңүчеләр генә тантана итә ала.

Дәү әнием бик карт — үзе дә, фикерләре дә. Ул шушы заманда да, остабикә булып, авыл буенча кунакка, ашка йөри, догалар укый, тагын әллә нәрсәләр. Мин бәләкәй чакта да шулай йөргән — әти белән әни үзенә ышанып тапшырган бер яшьлек баланы Мидхәт исемле тугыз яшьлек тумача абыйга калдыра да көннәр буе үз догалары артыннан йөри икән. Мидхәт абый мине карамый — арбага яткыра да үзе дөнья гизә — җәйге рәхәт сахрада дөньясын онытып чаба, уйный. Ә мин арбада юешләнеп бетәм, буялам, елыйм, кычкырам, әрним, үксим, ярсыйм да сыныма катам. Бу хәл еш кабатлана. Мин моны, Абба, сиңа сөйләп күрсәткәч, син үзеңчә хөкем чыгардың: имеш, минем артык хисле, кайнар һәм тиз җәрәхәтләнә торган булуым шушыннан килә. Бәлки шулайдыр да. Ялгызлык юньлегә китерми инде ул, бала чакта бигрәк тә шулайдыр. Акыллы кеше баланы ялгыз калдырмый. Ни булмас аның белән — нинди куркынычлар белән очрашмас ул?!

Ихтимал, син хаклысыңдыр — минем өметсез кычкыруларым шунда ук башлангандыр... Мин: «Әни, әни, әни!» — дип өзгәләнсәм дә әни еракта, урман-сулар артында иде. Мине ишетмиләр, ишетергә кешесе юк иде, ә хәзер син ишеттең, син тыңлыйсың, аңлыйсың. Аерма зур бит, Абба!

Калага килеп беренче курста укыганда мин сине башка берәү белән бутаганмын... Ә ул бөтенләй бүтән кеше булып чыкты. Аерма — җир белән күк!

Ул да сезнең институтта эшли. Сиңа хәтле — моннан биш ел элек— мин аның белән очраштым...

Институтка Алсу исемле якташ кыз янына килгәләвемне әйткән идем бугай. Менә аның белән аскы катка, ашханәгә төштек. Көндезге аш вакытында чират шактый була икән. Өстенә гөл-үләннәр үрмәләгән юка дивар арасыннан аш алып чыксам, бу якта ким дигәндә кырык-илле кеше тезелгән. Ашый башлар алдыннан мин шул якка таба карап утыра идем, Алсу әллә шаярып, әллә чынлап: «Минем шунда күзем төшкән бер егет тора иде, чиратын ташлап, танышлары янына, алга узып китте дә, шуның белән мәхәббәтемне тагын да көчәйтте», — дип куйды.

Бу миңа кызык тоелды да сәбәпсез көлеп:

— Минеке чиратсыз керсә, минем хисләрем сүнәчәк! — дидем.

— Синең монда танышың бармыни?

— Әле килеп җитмәгән. Бераз гына көтсәк, күрсәтермен.

Чиратка бер яшь кенә, чибәр генә кеше килеп басты.

— Шушымы?

— Түгел.

Тагын, тагын килеп баса тордылар — Алсу сорый, мин «ул түгел» дип торам. Арада берсе минем чынлап та күз төшебрәк йөргәне килде. Анысын бигрәк катгый рәвештә «Что син, түгел!» дип, кабул итмәдем. Алсу исә сабырсызлана ук:

— Син нәрсә, алдыйсың? Синең монда беркемең юк. Инде столовойга керер кеше дә бетте.

Әмма керер кеше калган икән әле. Бөтенләй «өлешсез» калмас өчен соңыннан кергән бер кешегә тоттым да ымладым:

— Әнә ул!

Алсу да карый, үзем дә «күз төшкән кешемнең» ниндилеген тикшерәм: кызыл куз кебек янар күзләр, кап-кара сакал...

— Син моның кем икәнен беләсеңме соң? — дип сорый Алсу минем зәвыкка, мөгаен, исе китеп.

— Мефистофель.

— Мефистофель? — Алсуымның күзләре шат! — Ну син дә... Тапкансың шаярыр нәрсә.

— Ә мин чынлап.

— Ул да яратамы?

— Белмим.

Алсу рәхәтләнеп көлде генә:

— Ярый, алайса, без белербез, бик кыен булмас дип уйлыйм.

Шаярдык та бетте дип, мин бу сөйләшүне онытткан ук идем инде. Ләкин бер атнадан соң Алсу янына килсәм, анда күпмедер вакыттан соң телефон шалтырап Алсу трубканы миңа сузды:

— Сине сагынганнар.

Калага килгәннән бирле телефоннан беренче сөйләшүем. Бу институтта Алсудан башка танышым юк. Кем булуы мөмкин?

— Алло.

— Алло, Гөлчәчәк, сезме бу?

— Мин. Ә сез кем?

— Минме? Сез мине беләсез, хәтта яратасыз.

— Кем соң сез?

— Мефистофель.

Куркуымнан трубканы шап итеп куям да, ватылмадымы дип, тагын да ныграк каушыйм.

Телефон тагын шалтырый, Алсу миңа трубканы тагын суза, мин исә, котларым чыгып, куш кулларым белән күренмәгән адәмне тибәрәм:

— Юк, юк! — Баш та чайкыйм бугай әле.

Әйе, мин аның белән сөйләшә алмадым, чөнки ул миңа чынлап та ят, чынлап та куркыныч, чынлап та Мефистофельдер төсле иде. Коридорда очрашырга мөмкин булганда, әллә каян читләтеп узам, исәнләшергә, күзгә карарга да җай бирмим. Ләкин язмыштан узмыш юк диләр, һәм ул минем язмышым иде бугай. Нихәтле генә курыксам, карышсам да мин аннан кача, котыла алмадым. Хәтта үзем үк эзли башламадыммы икән әле?

Шулай бер ел узды.

Икенче көз башында — махсус курсларның берсе буенча дәрес. Үз группабыз белән генә кечкенә аудиториядә утырабыз. Укытучы керде. Укытучы кем? Кызыл куз кебек яна торган очлы күзләр, кап-кара чәч, кап-кара сакал...

Мефистофель!

Исәнләште дә үзе белән таныштырды:

— Шамил Шәрифуллович Сәмигуллин.

Минем колак моның фамилиясен һич тә кабул итәргә ашыкмады. Исеме, атасының исемен әйткәндә дә бик затлы тавышлар ишетелми, күзләре дә артык кадалып карый. Юк, Мефистофельнең укытучы кыяфәтендә килеп керүе аның файдасына булмас.

Бер дәрес, ике, өч дәрес — өстәлләр аша күзләр белән көрәш. Сизәм, ул инде мине күрде... теге куркыныч мәгънәдә. Сизәм, ул инде үзе дә каушый, үзе дә сабырсызлана. Шуны күрү миңа кызык — үз көчемнең тәэсирен күзәтү ниндидер канәгатьлек бирә кебек.

Көннәрнең хәерсезе, тәнәфесләрнең берсе. Аудиториянең эчке ишеге төбендә, кызлар белән җыелышып, яңа пластинка, яңа җырлар хакында мәгълүмат алмашабыз. Мин туган чорда, син һәм мин туган җирнең икенче ягында, тезләрен бутый-бутый, ботларын боргалый-боргалый һәм вакыт-вакыт җилкәсендә асылынып торган гитара кылларына бармакларын саксыз ыргытып, моңарчы һичкемгә билгеле булмаган, Элвис Пресли дигән яшь шофер истерикалы тавыш белән микрофонга кычкыра:

Я хочу поторчать на этом свете
И чувствовать острый вкус жизни,
Танцуя рок.

Тавыш җирнең икенче ягына да килеп җитте — әчкелт тәм җырчы ирләрнең оеткыч мыгырдауларын, ясалма сагышка баткан апаларның татлы пышылдауларын кинәт күмеп китте дә шул рәвешле музыканың яңа стиле аваз салды:

Разве ты не понимаешь,
Что я хочу сказать?
Разве ты не чувствуешь страха,
Что испытываю я?
Стоит кнопку нажать —
И спасенья не будет,
Некого будет спасать...

Эчке ишек төбендә шушы сүзләрне кабатлап рок ритмына биеп торганда, кинәт иптәшләремнең тынып калуына гаҗәпләнеп карасам, Шамил Шәрифуллович дигән яшь укытучы кергән дә исе киткәндәй миңа текәлгән. Ике кулым белән чигәләремне кыстым да уттай яну ымны сизә-сизә, үз урыныма чаптым. Дәресем дәрес булмады, нидер сөйләп азапланса да, укытучының ярты сүзе дә колагыма керергә азапланмады. Илтифатсызлыгыма җәза бирер өчен дип торам — дәрестән соң ул минем фамилияне атап:

— Сез бераз гына чыкмый торыгыз, пожалуйста... — диде.

Партлар арасыннан аның өстәле янына узам. Дәреснең булуы хакында группа старостасы китергән журналга кул куйгач һәм вак-төяк

кәгазьләрен сумкасына салгач, мине култыклауны имитацияләп, ишеккә ымлады. Хәрәкәтендә һичнинди шелтә галәмәте юк, киресенчә, ярарга тырышу хикмәте сизелә иде. Бергә коридор буйлап киттек, аннары урам буйлап та.

Күпмедер баргач, Шамил Шәрифуллович бая аудиториядә мин башлаган беркатлы, ләкин ритмик яктан гаҗәп җырны дәвам итте:

Когда мир станет темной могилой,
Оглянись вокруг, приятель.
Пойми же, пойми,
Что мы накануне гибели.

Укытучымның тел төбен төшенмәү аркасында мин бер сүз дә әйтмәгәч, ул татарчалап көйләгәндәй итте:

Килер көнгә дип калдырма бүгенгене,
Иртәгәнең булмавы бар үзенең үк.

Лобачевский урамыннан бакчага төштек. Чама белән тынычрак урыннарның берсенә утыргач, укытучым үзенең рәсми булмаган лекциясен дәвам итте. Тик ул яңалык итеп сөйләгәннәрнең барысын да мин белеп онытткан шул инде.

Яңа музыка аркасында булмаса да, аның тәэсире белән, мода гына түгел, вакытлы мавыгу гына түгел, тормышның ук яңа стиле туган, мин туганмын — Гөлчәчәк. Ә хәзер исә бу сүзләрдән елмая гына алам:

— Артык көчле әйтелде! — дим.

— Рок — сабыйлар музыкасы гына түгел, олылар музыкасы да була бара.

— Үсәбез!

— Вакыт белән бергә атлыйбыз. Ул безгә промышленность дигән держава аша яңа техника бирә, ә бездән — яңа җыр, яңа гадәтләр, яңа хисләр.

— Байыйбыз!

— Карт җырлар — бүгенге тормыштан, рәхимсез көрәш аренасыннан чамасыз ерак. Алар сентименталь мәхәббәт, абстракт изгелекләрне мактадылар, ул көйләрнең җегәре бүгенге нервылар киеренкелегенә, көн ритмнарына, безнең таләпләргә туры килми, җавап бирмиләр. Яшьлек эч пошуга, бертөрлелеккә дөньяны үзенчә күрү сәләтен каршы куйды.

Сөт тә, ит тә, он да мулдыр гәрчә,
Җитми ләкин һава, мин шуңа ач.
Интегүне үртәү тантанасы —
Бу дөньяга кирәк менә нәрсә!
Бу дөньяга һич тә җитәр булмас
Хак мәхәббәт, саф мәхәббәт.

Шамил Шәрифуллович ни өчен сөйли бу сәер сүзләрне? Нигә дә булса мине күндерергә уйламыйдыр бит?

Ул үзенең төп эш урынында һәвәскәр ансамбль җитәкчесе икән. Атнага ике тапкыр репетициягә җыйналалар, бернинди кыенлык юк. Әгәр мин теләсәм, ике куллап кабул итәчәкләр, имеш.

— Минем бернинди дә сәләтем юк бит, — дип, баш тартып карыйм.

— Ә-ә, тыйнаклык — заман билгесе түгел.

— Мин чынлап.

— Ә мин үзем күрдем, тавышыгызны үз колагым белән ишеттем. Имтиханның беренче турын уздым дип исәплэгез.

— Нинди предмет буенчадыр бит.

— Җыр, әлбәттә җыр. Ә танцевать итүче бөтен зал булачак. Шуның өчен дә самодеятельность бит ул. Без уйнаганга, без җырлаганга масса кушыла. Булды что ли, килештек?

— Белмим шул.

— Иртәгә — беренче репетиция. Калганын шунда хәл итеп бетерербез. Булды, килештек. Шулай? Эндәшмәү — ризалык. Иртәгә кичке сәгать җидегә. Көтәм. Ә хәзер сезне кая озатырга?

— Что сез, көпә-көндез курыкмыйм бит.

— Алайса, бигайбә. Покага хушлаштык.

— Хушыгыз.

Ул беренче мәртәбә сузган кулымны бик бөгелә-сыгыла кушучлап кысты да китеп барды. Мин исә Яшьлек урамындагы ашханәгә юнәлдем. Үлеп ашыйсым килгән, арганмын икән. Җирле, укытучым белән керпелерәк тордым.

Ашханәдән соң кәеф күтәрелер дисәм, юк, күңелдә — һаман Шамил Шәрифуллович. Ни өчендер, үзе юкта да гел үртәп тора. Шулай да ул чакырган көнне химия институтына барасы иттем. Беренче катта, вестибюльдә үзе көтеп тора иде. Әллә чынлап та миннән җырчы чыгар дип өметләнә?..

Иң югары бишенче катка күтәрелдек. Клубта инде миннән башка тагын ике кыз, өч егет бар иде. Тәртипләре әллә ни түгел, күрәсең — оркестр дигәннәре квинтет кына булып чыга.

— Кабул итегез һәм яратыгыз, менә сезгә яңа талант табып килдем, — дип тәчеләнде Шәрифуллович, гүяки аның өчен күптән бөтен нәрсә хәл ителгән. Мин үзем генә дә хәл ителмәгән мең проблема төенедер әле, бәлки.

— Гөлчәчәк, сүз — сезгә. Соңыннан безне тыңлый башларбыз. Я, нәрсә башкарабыз?

— Бер дә башкарганым юк бит, җырлаганым гына бар.

— Ну, нәрсә җырлыйбыз? Я? Оркестр, әзер бул. Гөлчәчәк, киттек, нинди әсәр?

— Ну, алайса...

— Алайса, так...

— «Не пой, красавица, при мне...»

Оркестр кинәт көлеп җибәрсә дә, Шәрифуллович мине бирмәде:

— Шәп, аккомпонемент — гитара, син аны әйбәт беләсең. Әйдә. Тональность? Ре минор. Гүзәл! Дикъкать!

Дирижер ымы белән гитара телгә килгәч, аны тыңлау үзе үк бәхет иде дә, тик дирижер мине дә тиз буйсындырып, сизмәстән, ияргә киттем.

Не пой, красавица, при мне
Ты песен Грузии печальной.
Напоминают мне оне
Другую жизнь и берег дальний.

Яңа тактка күчәм дигәндә, дирижер кул чәбәкләде:

— Стоп! Монысы булды. Зачтено. Тагын нинди әсәр?

— Тагын? Бәлки җиткәндер?

— Сабыр, түзәргә — тагын бер әсәр. Нинди?

— «Тәфтиләү» булса?

— Булса соң? Безнең ни эшебез бар анда? Атладык, ары.

Әмма гитарачы бу көйне белми икән — дирижерның үзе кебек үк сакаллы сабый кулбашларын селкетте:

— Аккомпонементсыз гына булмыймы соң?

— Нишләп булмасын, була, — дим, үземнең мөстәкыйльлеккә, роксыз да яшәп булганлыкка басым ясап.

Һәм нindiдер үҗәтлек белән, әмма чын күңелдән дала, болын, урманнар көен, гомер чиксезлеген тар клубка сыйдырырга тырышам. Максатыма ирештем дә дип уйлыйм, чөнки бер куплет җырлап баш игәч тә һавалы оркестр үзе үк кул чапты һәм тиз арада карар да чыкты:

— Сезнең алдыгызда — пешмәгән, юп-юеш материал, рәхим итегез, но да шәп материал. Башка фикерләр юкмы? Юк. Гөлчәчәк Галимова бертавыштан безнең ансамбль члены итеп раслана. Бүгенгә җитеп тә торыр. Ә без сүзсез әсәр өйрәнгәндә әнә тегендәрәк утырырга мөмкин. Вообщем, җаныгыз кайда тели. Рәхмәт.

Оркестр дигән квинтет чираттагы эшенә керешкәндә, мин арттагы урыннарның берсендә утыра идем инде. Тавышлар моннан бигрәк тә матур ишетелә.

Төп инструмент — электр гитарасы. Анда ерак прерияләрдәге ковбой гитарасы чакыруларының кайтавазы һәм төнге паровозның ямансу сызгырулары ишетелә бугай. Сак кына, кыюсыз гына булса да, гавай гитарасының гөнаһлы авазы да хәтер шикелле булып каяндыр килә. Тагын да ераграк җирләрдән төнге учак яктылыгын, һәм акылдан яздыргыч чегән биюләрен эченә алган кыргый моңнар килеп кушыла һәм үз кыргыйлыгын әкрен-әкрен сиңа да йоктыра. Үзе рәхәт, үзе гөнаһлы үзе куркыныч чир — әйтерсең, татлы шәраб алдавычы...

Аңа бирешмәс өчен сәеррәк уйларга күчәргә тырышам. Әгәр дә хәзер кинәт ут сүнсә, дим, әгәр бу залда кинәт ут сүнсә, дөнья тып-тын калыр иде. Тавышсыз-тынсыз залда боргаланып, чайкалып кара? Капкараңгы...

Борынгы кыргыйлык безнең заманның электр көче белән кушылгач телгә килә ала?..

Әгәр яңа тавыш килеп чыкмаса, моңарчы тавышсыз-тынсыз яткан инстинктлар да дөньяга чыга алмаган булыр иде. Музыка яңа тавышларга электроника ярдәмендә ия булды. Күптән яшәгән электр дигән көч әле генә тавышка иреште, кычкырырга өйрәнде. Син дә өйрәнерсең, Гөлчәчәк! Шамил Шәрифуллович дигән укытучың өйрәнгән кебек. Ул күп нәрсә белә: укыта, фән үстерә, музыкада яши. Бер кеше — өч улчәүдә! Бу кеше үзен кызганмыйча исраф итә — ахыргача! Син дә өйрәнерсең, Гөлчәчәк!

Һәм мин тырыштым — репетицияләрнең берсен дә калдырмыйча йөрдем. Шамил Шәрифуллович белән очрашу атнага өч тапкыр — клубта, университетта... өченчесе хәзергә сер икән. Әмма шунысы көннән-көн ачыграк сизелә: безнең мөнәсәбәтләр укытучы белән студент мөнәсәбәтләре рамкаларына сыймый башлады бугай.

Керфек араларыннан гына иптәш кызларымның безгә кызыксынып, хәтта бераз көнләшеп карауларын тоям. Гаҗәп хәл: укытучы белән әлеге мөнәсәбәт иптәшләрем алдында миңа ниндидер өстенлек — престиж бирә түгелме соң? Ләкин иптәшләрем арасында җәмәгать эше, уку белән бәйләнмәгән өстенлеккә мин мохтаҗ түгел. Шамилгә тартылуымның сәбәбе икенче — ул гадәти түгел, көн дә бергә йөргән, яшәгән студентларның берсе түгел ул — ерактагы кояш, яктырак... Ләкин укытучы белән йөрергә ярамый, бу — бер чик. Үз ишләрең белән бер тормышта яшәргә тиешсең, монысы — икенче чик. Берсе рөхсәт ителми, икенчесе рөхсәт ителә. Уртада — нечкә генә сызык. Юк, уртада — тимер аркан. Син шуннан атлап бар, син шунда бие, сикер, ләкин егылма. Миңа шулай язган. Мин моны бүгенге көнгә чаклы тоеп киләм. Бөтен максат — егылмаска, харап булмаска. Ә биеклек төрле чакта төрлечә — егылып баш тишелү, бил, аяк сындыру белән котылырга мөмкин булса, кайчак сөякләреңне дә җыя алмас хәлгә килүең бар. Төрлесен күтәргә кирәк. Тимер арканда йөрергә яратсаң, барысына да әзер бул. Һәм мин әзер. Әзер генә дә түгел, бу куркынычны тоеп яшәү минем тормышны мәгънәле итә, ялгызлыктан, эч пошудан, бушлыктан коткара:

«Нарасый чактагы өметсез кычкырулар, ялгызлыктан куркуларның дәвамы — хәзерге яшәвең» дип аңлатачаксың син моны, Абба дустым.

Шулай булгач, каныма салынган программаны мин ничек читкә ыргытыйм? Бүтәнчә яши алмавымда минем ни гаебем? Бүтәнчә мин нишли алам?

Бер сүз белән әйткәндә, Шамил Шәрифуллович Сәмигуллин озак та үтмичә, просто Шамилгә әйләнде. Беркемнән курыкмыйча, без аның белән каланың үзәгеннән — Яшьлек урамыннан узабыз. Яшьлек бакчасына кереп утырабыз, кино, хәтта театрларга йөрибез. Яз азакларында аңа бер бүлмәле булса да квартир бирделәр. Шамил миңа аны да күрсәтте һәм өстәлгә шампанское шешәсе бастырып, үзе кухня ягында йөренгәләде. Язу өстәлендә аның паспорты ята иде — рәсемен карыйм дип кенә алсам (рәсеме — сакалсыз, гади, хәтта артык ординарный авыл малае!), кулым, хәерсез, бүтән битләрне дә актарды... Корт чаккандагыдай, кинәт үртәлеп, мин аның янына атылып кердем дә үзенә паспортын суздым. Ул исә кычкырып көлде генә:

— Ә-ә! Язуда гына ул. Чынында, мин — ялгыз.

— Кайда соң алар? Хатының, улың?

— Авылда.

— Озакламый киләчәкләр. Квартир булгач.

— Килмәячәкләр. Без аерылган.

— Аерылгач паспортта үзгәрмимени?

— Белмим. Ну, без әле суд белән аерылышмаган. Вакыт житми, шул гына. Син нәрсә, син... ник әле болай сытыласың.

Чәчләремә буталып, абына язып залга чыккан идем, ул да иярде һәм кочаклап, күз яшьләремне, бугазга тыгылган рәнҗүемне авырттыра-авырттыра кочаклап, үбә-үбә тыннарымны буды. Мин аның белән бер дә үбешергә яратмый идем. Ул үзе генә үпкәч тә мин тиз арада читкә борылам да еш кына хәтта иреннәрне сөртеп куям. Гомумән шулай буладыр дип уйлый идем, гомумән сиңа хәтле яраткан кешенең иреннәре хәзергечә тәмле була алуын башыма китерә алмый идем. Син бөтенләй бүтән, Нажар, син — минем өчен бердәнбер! Ул чакта моны белгән булсам, мин икенче төслерәк җавап биргән булыр идем, ләкин ул юлы мин аның иркәләү, каушаулары, ялынуларыннан тиз арада тынычландым. Шампанское шартлап ачылгач һәм стаканнар да «Шамил Шәрифуллович» дип чыжлагач, мин аңа, мөгаен, елмаеп та караганмындыр әле. Сүзләре шактый ук ягымлы ишетелде.

— Шушы квартирадагы уртак бәхетебез хакына — әйдә, күтәрдек.

Әйтерсең, ул миңа үзенең тормышын тәкъдим итә, мин исә аны йөз проценты белән үз кулыма алам, югыйсә, болай ул бернинди мәгънәсез, чип-чиста эчемлек кенә булган икән бит. Күп дигәндә, минутлар шатлыгы гына күбекләнгәндер анда. Син әйткәнчә, минем тормышка дәгъваларым артык бәләкәй икән, шул шатлык житә алды — көлдем, шаярдым, кочаклаган кулларга карышмадым, иреннәр әрсезлегенә дә түздем. Өметсезлек өнсез торды. Хәзерге көннәр генә синең сүзләр белән: «Син «юк!» сүзен әйтә белмисең», дип кабатлый. Әллә чынлап та хак сүз микән бу? «Юк!» дию өчен билгеле күләмдә зирәклек, ныклык, батырлык кирәк. «Юк» дияр өчен болар миндә юк — аларның буш урынын бары тик ашкыну, ашыгу, тиле ярату биләгән. Шамилне мин шундый ихтыярсыз ярату белән яратуымны яшермим.

Без аның белән көн саен диярлек очрашабыз, әмма, сессия вакыты житкәч, сирәкләмичә хәлең юк. Һәр китап, һәр дәфтәрнең юл араларында Шамилнең кызылланып янган күз нуры җемелдәсә һәм күләгәле һәр почмакны аның дөм-кара сакалы тутырып торса да, күзләреңне уып, хәрефләр, сүзләр, аннары исә әллә күзне, әллә миләрне интектерә-интектерә, әчеттерә-әчеттерә мәгънә, фикерләр җыясың. Һәр имтихан тапшырылган саен — ашкынулырак яңа очрашу. Ләкин мин ай азагына якынлашкан арада дустымның күзләрендәге кызыл утның сүрелә төшү-

ен, сакалның исә тагын да карарак, зуррак була баруын сиздем дә эчем жу итеп китте. Үзенә шушы хакта әйткәч, ул: «Элеккечә үк яратам, син мине шик белән не оскорбляй!» дип, үпкәләсә дә, мин барыбер аның тавышында ялган катнашмасын ишеттем. Бәлки чынлап рәнжетәмдер дигән уй белән (үзеңнең начар тойгыларыңа ышанмаска тырышасың, шуларны инкарь итәрдәй фактлар табасы килә мондый чакта) Алсуга, синеңчә әйтсәк, секретарь кызга киңәшкә киттем. Алар бергә эшлиләр, көн-төн дигәндәй бергә, һәр кайсы һәркемнең уч төбендә — күрми, белми булмас. Ә Алсу? Минем якташым, минем сердәшем исә, һич кызганып тормыйча:

— Син аны ташла, бәгърем, ул синең кисеп ташлаган тырнагыңа да тормый — бабник, коеп куйган, — дип ярып кына салды.

Егылып китә язганмын, Алсуның чак тотып калганын, кинәт өстәлгә бөгелеп төшүемне хәзер дә күксел вакыт пәрдәсе аша күреп торам. Алсу юата, акыл бирә, тынычландыра:

— Юк, җаным, ул хәтле түгелдер ул, миңа шулай тоелган гынадыр. Яратадыр ул сине, бәлки башкалар белән юри генә буталадыр.

Уф! Бу хәтле тиз бирешергә, коелып төшәргә ярамый лабаса. Ачыклап, уйлап кара, нәтиҗә соңыннан үзе чыгар. Кая ашыгасың? Сиңа унсигез генә яшь бит әле!

Чәчләремне җыештырам, күзләремне сөртәм дә, ни өчендер кофта һәм итәкләремне тарткалап куйгач, Алсуга туп-туры текәлеп:

— Кем белән? — дип сорыйм.

Алсуның да йөзе үзгәрә — баягы кызгану, юатырга тырышу галәмәтен ниндидер өнәмәү, читләшү, хәтта мыскыллау билгеләре алмаштыра.

— Яшермә, Алсу, бу минем өчен бик важно.

— Әйтә алмыйм, Гөлчәчәк. Үзең күрерсең әле.

Кинәт аның салкынлык сипкән ят күзләре мине усаллаштыра куйды:

— Синең белән түгелдер бит?

— Что син, Гөлчәчәк, акылыңдамы? — Күзләрендә: «Үз дустыңа, үз якташыңа ничек оялмыйча ялган бәла ягасың?» дигән сорау төсмерләнеп ала. Шуңа күрә, вөҗдан хисе кузгалудан, сүзләрем йомшара төшә:

— Ачуланма, Алсушка, мин болай, аптыраганнан. Чынлап та, үзем белермен, ачыклармын.

Аннары юк-бар сөйләшеп кенә утырдык. Алсу машинкасын шакылдаткан арада аның машинкасыннан чыккан кәгазьләрне караштырып утырдым. «Микробиологиядәге соңгы экспериментлар». Авторы — Габбасов Нажар. Габ, габ... с-с-с... Шундый фамилия белән дә дөньяда йөрүче бар бит әле әнә. Миңа ник боегырга?

Телефон шалтыравы, тагын, тагын. Шалтыратуларның берсеннән соң Алсуым туры мәгънәсендә алсуланып каушады да сүзләре шифрларга яшеренде.

— Әйе, әйе, аңладым, булды, шулай шул, юк, аңладым, обязательно.

Әмма шифр минем өчен артык җиңел шикелле сизелде, чөнки трубкадагы тавыш миңа таныш сыман, Шамил тавышы сыман тоелды.

— Алсуш, Шамил кайсы бүлмәдә эшли, әйт, пожалуйста.

— Нәрсә, үзең керер идеңме әллә?

— Ә нәрсә? Мин бит аның өендә булган кеше.

— Өендә? Сөйләмә лә. — Йөзендә тагын курку галәмәте.

«Минем өчен курка — якташ бит!»

— Лицом в грязь не упаду, курыкма. Кайда аның бүлмәсе?

— Бездән аскы катта гына. Язылган анда, табарсың.

Шул сүздән соң, гаҗәп, миндә аның телефон номерлы барлыгы хәтеремә төште. Моңарчы шалтыратып караганым юк иде. Сынап карарга булдым. «Ялган номер түгелме икән?» Трубканы алдылар. Аның тавышы «Алло! Мин сезне тыңлыйм, Алло! Мин сезне тыңлыйм!»

«Җавапсыз телефонга күпме сүз әрәм итә болтун! — дип уйлыйм. — Тыңлый тор әле, бабник!»

— Хуш, Алсушка, рәнжемә, не обижайся.

Бу вакытта мин инде сау-сәламәт һәм кабат уенчак. Сәбәбен аңламасам да — күңел көчле, җитез. Елмаюларым — бернинди тырышлыксыз, чын. Шамил булмәсенә кергәч, тагын да шуклана төштем шикелле.

— Сәлам, Шамилек, как поживаете? — Гафу ит, Нажар минем тел культурасы шул чама гына бит. Бу яклап та мин тимер аркан өстендә... син аңлыйсың инде. Шулай бит?

Шамил мине күрүгә аягүрә басып, янында утырган кешедән һич тартынмыйча, миңа кулын үзе сузды һәм кочаклап та алды. Хикмәт, кырысланмыйча, рәхәтләнеп басып торам. Дөресен әйткәндә, кеше барын соңыннан, Шамилнең кулларыннан арынгач кына күрдем. Сакаллы... Юк, сакалсыз гына, озын мыеклы, Волкенштейн дигән кеше икән. Танышкач ук чыгып китте — әрҗә хәтле елмаеп.

Ул чыккач тагын кочаклаштык, тагын үбештек, иреннәремне тагын сөртеп куйдым. Әмма очрашу мине чынлап шатландыра. Алсу белән баягы сүзләрем инде тупаслыкка әверелә һәм Шамилдән үзем сөенче алгандай әйтәм:

— Бүген тагы бер экзамен белән покончено, инде соңгысы. Аннары...

— Син просто молодец, Гуля, поздравляю үзенне, — дип ул тагын бер үбеп куя.

— Бүген кич — безнеке, дөнья гизәргә мөмкин. Я, ник тындың? — дим, тәкъдимгә шатланмавына гаҗәпләнеп.

— Юк, болай гына. Дөньяны без синең белән иртәгә әйләнербез. Ә бүген...

— Бүген синең свидание — Алсу белән!

— Гөлчәчәк, что син, Гуля!

Туп-туры йөзенә карасам, кузлы карашы ялган сөременннән тоныкланган, чырае ватык, ямьсез.

— Иртәгә хәтле, Шамил.

— Юк, җибәрмим, озатып куям. Что син, ярыймыни шулай!

Әле генә кыза төшүем тагын мәгънәсен җуя, тагын тиз бирешәм — ул мине озатасы иткәч, бәлки мин юкка гына гөнаһлы буламдыр? Тагын кайнар өметләр, вәгъдә, ышандырулар һәм шулар яктылыгында туган кояшлы тойгылар.

— Хыянәт итсәң, мин сине яшәтмим — белдеңме?

— Белдем, Гөлчәчәк. Беркайчан хыянәт итмәячәкмен — син ул сүзне белмә. Ярыймы?

— Ярый.

— Хәзергә хуш.

Кольцодан сигезенче трамвайга утырганда ул мине шул сүз белән озатты. Сөйләшеп тору булмады, мөгаен, ашыкты, каядыр ашыкты. Кая? Хәзер ул мине Идел буе районына, өйгә кайтып китте дип, үз күзе белән күреп ышанды һәм Мефистофель тыныч кына кичке аугa чыгып китәчәк. Күзләрендәге ут дәрәҗәсенә караганда, урамда күп йөрмәс, өенә кайтыр. Күп булса берәр кино-театрга кереп чыгарлар да...

Каян шушы хәтле тәгаенлек? Нишлим мин, ник көнләшәм үземне дә, аларны да мыскыл итеп? Тагын, тагын «алар»! Уф, беттем мин — көнлим, көнче күбәләк мин — утка кунaчакмын. Кунсам кунам, ләкин шәмнәрен дә сүндереп янaчакмын.

Әйе, өйгә кайтмадым мин. «Татарстан»га килеп берүзем кино карадым да, Ленин районына юл тоттым. Алар кайтып кердeләр инде, чөнки сүз куешып баргач, билетлары көндез үк алынгандыр бит. Кич чират торып вакыт әрәм итмәсләр.

Тәрәзәдән мин килгәнне күрмәсләр — караңгы төшкән. Якты булса да күзләрен мәхәббәт томалаганлыктан, берни абайламаслар. Алар — бәхетлеләр! Әмма бәхетләре — минем исәпкә, мине рәнҗетү, миңа хыянәт итү исәбенә.

Ишек төбендә звонокка басаргамы, юкмы дип торам. Өйдә адымнар, кухня белән зал арасында. Шамил тырыша!

Звонок.

Аяклар дөпелдәүдән туктый.

Звонок.

Квартир йоклый.

Звонок!

Квартир үлә!

Мин җиңелдем, мин алдандым, мин тапталдым! — Нәтиҗә шундый, ләкин ул ашыгычрак ясалган булып чыкты. Бу катгый сүзләрне әйтер вакыт алдарак көткән әле. Сабырсызланганмын.

Иртәгесен, соңгы имтиханга әзерләнер өчен китаплар дәрьясына чумасы урынга, Арбузов урамына, Алсушка янына ашыктым. Исәнләшүгә, миңа бөтенесе дә ачыкланды. Аның чыраенда дуслык димәстән, якташлык яктылыгы да сүнгән иде.

— Мин кичә сезнең янга килгән идем, — дим.

— Әллә тагы, мин сине күрмәдем.

— Бәхетлеләрнең бәхетсезләрне күрергә вакыты җитми.

— Синме бәхетсез?

— Өч тапкыр звонок биреп тә ачмадыгыз.

Мәгънәләрен аңлап бетерә алмаслык сәер елмаю. Шуның белән сүз тәмам.

— Ярый, Алсушка, мин моны не прощу.

Машинка шакылдавы. Ишеккә хәтле һәм бераз аннан соң да мине шул гына озата барды. Дүртенче кат. Ишек ачам. Керәм. Аның янында фырт мыеклы озын егет исәнләшкәч үк чыгып кача. Кара сакал аның артыннан иярми, миңа ябыша:

— Гөлчәчәк, ни булды? Нишләп болай бик иртә?

— Минем бөтенесе в порядке. — Күкрәгенә капланып елап җибәрәсе килә.

— Ярый, алайса, болай гына. Бик әйбәт, как раз сине сагынып утыра идем әле.

— Рәхмәт.

Ни хикмәттер, аның кайнар сулышын тою күңелдә укмаша башлаган бозны бер өрү белән эретеп агыза — мин аның кочагында сабый шикелле иркәләнә башлыйм. Үпкәләүдән бигрәк көязләнеп:

— Сез нишләп миңа ишек ачмадыгыз, ә? — дим.

— Ничек ачмадык, кем белән?

— Алсушка белән.

— Җүләр син, тилергән! Юк иде беркем. Тик мин бераз гына салган идем дә, үземне начар күрсәтмәс өчен ачмадым. Ә син икәнен белгән булсам, теләсә нинди хәлдә ачкан булыр идем. Үзең дә инде — миннән тавыш көтмичә «Шамил ач, бу — синең бердәнбер мәхәббәтең!» дип, шушы матур тавышың белән эндәшсәң, минем өчен нинди зур бәйрәм китергән булыр идең. Шулай да хата төзәтелмәслек түгел. Аны төзәтергә мөмкин, кирәк, бүген үк. Син әш бетүгә монда килерсеңме? Үзем берәр җиргә барыйммы? Миңа ничек тә бата.

— Килермен, шушында.

Әле көннең башы гына, кабат китеп, кабат килү шактый вакытны

әрәм итәчәк иде. Әмма монда килеп, юри Алсуга икәүләп күренү өчен, тиешле әҗәтне кайтару өчен андый гына җайсызлыкка түзәргә мөмкин. Шулай, Шамил, акыллым, без кичкә таба дүртенче этаждан беренче катка бишенче кат аша төшәрбез...

Һәм мин максатыма ирештем дә. Шамил Алсуның ишек төбеннән тавыш-тынсыз гына узмакчы иде дә, мин ишекне юри киереп ачып, әдәп сакладым:

— Алсушка, без киттек, хәзергә!

Елмаерга азапланып башын күтәргән иде, янымда Шамилне күргәч, секунд эчендә елыйсы килгән җимерек иреннәре иләмсезләнеп, үзе бюст шикелле катты да калды. Шул кирәк сиңа! Бүтән минем белән ярышмассың. Хыянәтне суд та, дус та ярлыкамый. Ямьсез чыраең тиз генә чибәрләнмәс.

Мәхәббәттә зур җиңү менә шушындый кечкенәләрдән җыела торгандыр ул. Минем өмет тагы яңарды. Шамилемне ятларга тиз генә бирмәскә тырышу тойгысы, көрәш хисе барлыкка килде. Мин аның янына көн аралаш үзем килсәм, көн аралаш ул университетка килә торган булды. Ялгыш күрешми калсак, караңгы дип тормыйча, квартирына киләм дә, хәзер ишек тиз ачыла, һәм ул анда гадәттә ялгыз, яки иптәш егетләре (дөресрәге — ирләр, барысы да өйләнгән кешеләр) генә була. Мине күрүгә аягүрә басып шаулашырга, мактарга, чибәрлегемне, батырлыгымны зурларга керешәләр. Радик исемле күк күзлесе — шактый чибәре — бигрәк тә чын күңелдән сөенә. Аспирант, булачак зур кеше — минем кебек кечкенә студентның кулын яшертен мәгънә белән кыса.

Гадәттә, алар мин килгәндә инде ярыйсы ук кызмача булалар һәм мин килгәч, тагын да кайнарланыбрак бәйрәм итәргә керешәләр. Тик Хәлим исемлесе күзләремә астыртын гына карый да җай чыкканда йодрык төя. Мин аны аңламаганга сабышканга күрә, икенче вакыт урамда үземне генә очраткач, дусларча тупасланып: «Әгәр тагын бер кабат безнең мәҗлесләрдә күренсәң, бөтенесе алдында тотып кыйныйм», — дип чынлап тиргәшә.

Университетка Шамил үзе килсә, минем өчен җайлырак. Шул ук вакытта — уңайсыз. Ул — укытучы кеше, иптәшләр миңа көнләшеп карый һәм мин, алар белән булган хәлдә, үземнең чак кына ераграк икәннемне күрәм. Алда — укытучылар, галимнәр дөньясы, артта — иптәшләр. Мин — ике арада... әллә тимер аркан сузыла торамы?

Яшьтәшләрдән аерымлану үз үчен тиз алды — көнләшү һәм Шамилне ычкындырмау көрәше күңелемне тулысынча биләгәнлектән, соңгы предмет буенча белемем өчледән артмады. Икенче курста ярты ел стипендиясез көн күргәндә мәхәббәт өчен артыграк түләгәнем һәрвакыт хәтердә торды. Ләкин Шамилдән аерым булу — минем өчен стипендия алмаудан мең мәртәбә ачырак иде. Уйлап карасаң, үзе бер гаҗәп, сагынудан ничек йөрәгем ярылмады икән: җәй буе аннан башка яшә дә, аннары тагын бөтен сентябрь буе кайдадыр олагып йөр. Ерак Астрахань далаларында кояштан, эсседән, мәхәббәттән көй, ян, суса. Монда яшьләр, иптәшләр күп күбен, ләкин тәгаен генә дус юк. Шаян сүзләр, күзләрне мактаулар еш ишетелә ишетелүен, әмма берсенең дә күкрәгенә капланып, дөньяны оныта алмыйм. Урталай ярылган карбызга бөтен бит белән чумып, татлы сыеклык чөмерсәк тә, барыбер ул мәхәббәт түгел. Аны күп эчә торгач, ул да ачыга әйләнә — сагыну, тилмерүнең нәкъ үзе шикелле. Шамил, Шамилем, бәгырем, бу хәтле интегүемне белсәң, күпмедер вакытыңны минем өчен әрәм итеп, минем белән шушы тәмугта бер генә көн, бер генә сәгать янсаң, көйсәң, син мине ахыргача аңлар һәм мәңгелеккә тугры дусым, аерылмас юлдашым булып әверелер идең бит. Ә син шул уйламыйсың

бугай, мөгаен син ялваруларымны ишетмисең, килмисең, һәм син килмәдең, минем белән бергә көймәдең, ярылырга житеп өлгергән кып-кызыл карбыз мисалында синең бәйрәм өстәлеңә мин үзем килеп тырдым.

Сулышым белән тартып, үз яныма сине мин үзем китердемме, әллә сагынуың белән, Шамил, очыртып үзең мине кайтардыңмы? Таныш урам. Менә син торган мең бизәкле гүзәл йорт, синең исемең, синең тавышың бәрелүдән бәхетле дивар, ишек һәм баскычлар. Синең куллар көн саен кагылган ишек тоткасын сыйпыйм — йомшак, бәхетле.

Звонокка тотынсам... Әллә электр агымы, әллә яман хатирә очкынланып бармагымны этеп кире кайтарды. Бармактан башланган курку ялт итеп башка менеп житте:

«Алсу? Монда ул булса?»

Ишек катында озак торырга шулай да ярамый — түз, бармагым.

Түзде бармагым, ишек катында — минем өчен әйтеп аңлата алмаслык кадерле булган, бөтен хәвефләрне берьюлы юклыкка очырган кеше, аның аяк тавышлары, ачкычны чыңлы итә белгән ягымлы куллар.

— Кто? Кем?

— Мин, Шамил, ач!

Ачкыч йозакны ашыктыра, йозак карышмый, буйсына, ишек ачардан калышмый һәм мин әйтерсең юклыкка сикерәм — күпердән суга атылган кебек. Мин сөйгән кешем кочагында юкка чыгам. Мин инде үземнеке түгел, мин — аныкы, тулысынча — аныкы, үткәнем, бүгенгем, киләчәгем белән. Юк, мин аннан инде бүтән аерылмаячакмын, аның яныннан бер адымга да читләшмәячәкмен — китмәячәкмен бу өйдән беркая! Мин синең тормышыңа мәңгелеккә килдем, Шамил, сине бәхетле итәр өчен, бүтән бернинди максатым юк, ишет, бел, сөеклем.

— Аһ!

Күңелдәге бөтен ашкыну, тилерү, сагыну, ярату һәм барлык теләкләрем шушы ымлыкка сыйды. Бүтән сүз әйтерлек хәлем калмагандыр инде. Әмма ишетерлек көч шулай да калган иде әле.

— Син күктән төштеңме әллә, Гөлчәчәк? Мин бит нәкъ сине сагынып, сине көтеп кенә тора идем. Килмәсеңне белэм, тик барыбер кетэм. Һәм менә син килдең, әй молодец! Бүген — безнең көн, кич — безнеке. Аны бездән беркем дә тартып алмас.

— Мин ашыкмыйм, Шамил, борчылма, тынычлан.

Сүзнең ни хакында икәнен аңлап елмайгач, шунда шешәгә ябыша:

— Салют син кайту хөрмәтенә! — Бөке түшәмгә атачак диярсең, ә үзе нибарысы коньяк ача.

— Хәзер, хәзер, Гөлчәчәк. Кич — безнеке. Ә үзебезгә мәхәббәт хуҗа, ни теләсә, шуны кылсын.

Күз алдымда һаман өлгереп ярылган карбызлар. Кояшны эчкәндәй, шул татлы кызыллыкка иреннәрем белән кагылам да кыстатмыйча коньяк эчәм, чөнки тост — безнең шушы өйдә булачак бәхетле тормыш хакына. Мин аны үзем моңарчы беркайчан да татып карамаган ачылыкны җиңеп расладым.

— Уф, тәмсез, нәрсә бу?

— Что син, бу самый настоящий — әрмәнский.

Шулай булса да тәмсез минем өчен, бигрәк тә үзеннән соң кабар ризык булмаганда. Табадагы әллә кайчаннан калган, көйгән бәрәңге күңел кайтаргыч тәмне көчәйтә.

Бәхет дөньяның чите кебек үк ерак, мин анда барып житә алмам, чөнки минем инде кузгалырлык хәл дә калмады, диванга барып сеңләм. Ләкин Шамил һич гаепкә алмый, ачуланмый, әдәпсез, тәрбиясез, характерсыз дип тиргәү урынына, әле кочаклый, сөякләрне эретеп сый-

пый, кайнарлыктан болай да кысылган тынны исәпсез-сансыз үбүләре белән буа.

— Шамил, тукта!

Шамил башын күтәрә, тын кала. Мин исә ниндидер бушлыкта чайкалам — кукто, биектә кичке болытларда бугай. Баш әйләнүе кими, басыла. Әкертен-әкертен тәннең рәхәт оеганы сизелә башлый. Күңелдә тагын ай буе тоткынлыкта интеккән тойгылар терелеп кузгала, җыйнала, бөтерелә, айкала башлый һәм мин аны инде үзем кочаклыйм — җилкәсеннән кысам, чәчләрен сыйпыйм, карбызга чумгандай, аның иреннәрен тойган хәлдә юкка чыгам.

Вакыт көчен җуя, мин — бәхетле, шушы бәхеттән башка бүтән берни дә кирәкми. Ләкин Шамилгә болай гына җитми; күрәсең, аның куллары ераккарак сузыла, күбрәкне эзли, таләп итә... сикереп торам да киенергә керешәм.

Сәгать угы биебрәк алса да, көч куебрак карагач, тынычлана — сәгать нәкъ унике! Төн уртасы! Без чынлап та бәхетле булганбыз, ахрысы — сизелмәгән бит — күпме утырганбыз. Шамил шул бәхеттән дә туймаган:

— Хәзер мин сине беркая да җибәрмим, менә шушында ят та йокла, курыкма, кагылмыйм мин сиңа.

Бүтән чакта төнге өчтә дә чыгып китәр идем бәлки, чыкмасам да үземне икенчерәк тотар идем, мин моны беләм, әлбәттә. Ләкин ул кичтә кечкенә җилкәләремдә мәхәббәттән яралган пар акканат җилпенә, болай да ихтыярсыз йөрәгемне каты эчемлек буйсындырган, җитмәсә, Шамил шундый өзгәләнә:

— Әгәр ышансаң, хәзер менә шушында урын җәясең дә ятасың. Теләсәң караватка, теләсәң шушы диванга. Менә урын-җир.

Диванга да, караватка да, баягыча чуала-чуала, урынны ул үзе җәйде. Кухнядан чәй алып чыкты да рюмкаларга тагын коньяк койды:

— Әгәр төнебез дә бәхетле булсын дисәк, менә шушыны эчәбез дә, аннары — чәй. Айныга ул чәй, курыкма. Исерсәң дә, без — үз өебездә, аңладыңмы?

— Аңладым, Шамил, любимый, мин сине яхшы аңлыйм, һәр сүзеңне.

— Менә молодец.

Рюмканы ничек эчкәнемне беләм, әмма чәйне эчтемме, юкмы, бөтенләй хәтерләмим, хәтта ничек ятканымны да уйлап кайгыра алмыйм. Иртән уянып китсәм, мин — караватта, Шамил дә шунда...

Ул рәхәтләнеп йоклый бирә. Ә мин коелдым да актым:

«Нишләдем?!.»

Баш әйләнә, косасы килә — өстәлдәге коньякны Шамил өстенә сибәсе, ыргытасы килә. Үземне мыскыл иткән кешенең чын йөзен фаш итү өчен өстендәге юрганны ачып атасы килә. Әмма ачсаң, тагын бер оят өстәләчәк...

— Шамил!

Ярым елап, ярым ялынып, ярым яратып, әмма тулысынча куркып һәм ярсып шулай кычкырганымны хәтерлим.

Сикереп торды да битләрен, җилкәләрен угалады — ялангач булуыннан... юк, оялмады һәм ашыкмыйча гына киемгә үрелде. Мин битемне учлап кухняга ашыктым, өлгереп ярылган карбызны эчкәндәй, күз яшьләремне чөмерергә, кухня өстәленә күкрәгемне куеп үксергә керештем. Шамил кабаланмый, чуалмый гына чыкты да ирләрчә көчле, тыныч тавыш белән:

— Гуля, хәерле иртә! — диде.

Аптырадым да калдым. Бу каян килгән тынычлык? Дөнья үзгәрмәдеменни, ул кичәгедән дә хәерлерәкме?

Юк, монда миңа нәрсәдер аңлашылмый. Мин шаккатып бераз тор-

гач, тиз генә юыну бүлмәсенә кереп салкын су ачам — яшьләремне суга кушам, юынам, чыгам да:

— Туйга синең әйбәт кара костюмың бармы? — дип сорыйм.

— Бар, булмаса, табарбыз.

— Миңа күлмәк...

— Булыр, барысы да булыр.

— Кайчан?

— Тиз арада.

Һушыма килеп, газ кабызам, чәй кайнатам, инде икенчерәк, тынычрак хәлдә мәҗлес яңадан башлана. Рюмкалар яңадан тула. Тик, мин аны ирнәмәкче булып карыйм да, бүтән бүлмәгә чыгып йөгерәм, кешегә әйтергә оят — укшыйм! Бер-ике көн элек кем дә булса: «Син шушындый түбәнлеккә төшәчәксең!» дисә, мин ул кешенең яңагына суккан булыр идем. Бүген исә, күрәм, үземне үзем күрәлмыйм, ә Шамилне кызганам: «Шушындый тәрбиясез хатын белән ничек яшәр икән?!» Ләкин бирешергә ярамый, бүген кулдан ычкындырганны бары тик шушы квартир белән, туй белән генә кайтарырга мөмкин.

Бер-ике йотым чәй фикерне терелтә:

— Шамил, хәзер без нишләргә тиеш инде синең белән? Ник бер сүз дә әйтмисең?

— Без синең белән яшәргә тиеш, Гуленька.

— Кайда? Ничек?

— Әүвәлгечә.

Чәй чәшкәсе чатнап төшә дә кайнар тамчылар икебезнең дә кулларыбызга чәчри. Ярсудан сүз буыла. Кичәге кебек диванга барып утырам да бөкшәеп калам. Күпмедер вакыттан соң гына Шамил үзенең баягы ялгышын аңлап, мине тынычландырырга, көйләргә, өстәмә вәгъдәләр коярга керешә: мәхәббәттә, имеш, оят нәрсә юк, мәхәббәтнең иң югары биеклеге менә шушы, ләкин яшәү тукталмаячак, киресенчә, тагын да мәгънәлерәк дәвам итәчәк — икәү булгач анда безгә җиңел булачак. Туй да ясаячакбыз, бер нәрсә дә бездән качмаячак, тик моның өчен, бераз әзерләнергә вакыт, түземлек кирәк булачак. Ватылган чәшке кыйпылчыклары да — бәхеткә ул, барысы да, барысы да — безнең гүзәл киләчәк хөрмәтенә икән.

— Ышанмасаң, менә сиңа ачкыч, өй — икебезнеке, теләсәң кайчан кил.

— Синсез монда нишлим?

— Соң... бергә булырбыз инде.

— Бергә ачарбыз ишекне дә.

— Булды, вакыты җиткәч күчәрсең, үзем барып алырмын, туй алдыннан.

Ярты елга якын вакыт эчендә туй бәйрәме безгә килергә ашыкмады. Сессия узсын инде, дип килештек. Ә аннары... Аннары Шамилне командировкаларга еш җибәрә башладылар. Болай, карап торсаң, аның эше командировкалар белән бәйле түгел сымак, шулай да аны җибәрәләр. Кайткач исә, үтәлми калган плановый эшләрне үтәү өчен аңа нык тырышырга һәм мәхәббәт назыннан мәҗбүри рәвештә баш тартторырга туры килә. Шулай итеп, без сирәгрәк очрашабыз. Билгеле, элегрәк дикъкать итмәсәм дә, соңрак яман нәрсә сизелә башлады. Чөнки моңарчы гел өенә килүемне ашыктырган кеше, бөтенләй чакырмас булды. Менә шунда инде мин теге чакта ачкычны алмавыма, сүзгә ышануыма үкенә башладым. Ниндидер үзгәреш бар, монысы көн кебек ачык, кем беләндер тагын бутала Шамил... Кем белән?

Мин хәзер барсам, анда мине Алсу каршыласа?

Әйтерсең, үлемемә ашыгып, Шамилнең квартирына килам. Таныш, якын баскычлар. Пәрәк дөп-дөп тибә, әйтерсең, күз күне көньяктан кайтып килешем. Сагыну бәлки нәкъ шул чамадыр, ләкин аңа шик,

шом буталган, теге вакыттагы коньяк исе дә бәрелеп китә. Укшымасам гына ярар иде.

Звонок.

Өйдә — аяк тавышлары, кемнәрдер сөйләшә. Әллә балалар инде? Ишек ачыла да... миңа утыз яшьләр чамасындагы бер хатын күзләре текәлә. Карашында — аптырау, танырга тырышу. Ә мин — телсез.

— Сезгә кем кирәк? — Хатын янында алты-җиде яшьлек малай.

— Ә-ә, гафу итегез, мин подъездны бутаганмын икән, гафу итегез.

Оятымнан егылып үләрдәй булып, чаба-чаба төштем дә, тиле кешедәй урам буенча да шулай йөгерә бирдем. Бутадым, подъездларны бутадым. Һәм кешеләрне!.. Ә ник дөресен әйтмәдем? Хатыны алдында Шамил кызарып кайбер нәрсәләрне аңлатып интекмәсен, борчылмасын өченме? Ә минем нервларны кем сакларга тиеш? Ә ник бөтен авырлык минем өскә?

Менә сиңа хата!

Башта ул уртак сыман иде, ә хәзер аны мин үзем, бары тик үзем генә күтәрәм. Шамил өчен ул бер дә яман нәрсә түгел. Ә ник ул аңа бәхет, матурлык, ләззәтле хатирә булып кына кала?

Үләм, бетәм, беттем мин!

Икенче көнне иртә үк эшләгән җиренә барып хәлне аңлатуын сорагач, Шамилем:

— Килде дә керде, нишләтим инде мин аны, язылган хатын бит, бала белән. Закон алар ягында, мин ничек җиңим? — дип, гаепсез күзләр белән карап тик тора.

Әй, ансат та инде! Минем кебек диваналардан менә ничек кенә котылалар! Мин — законсыз, мине беркем якламаячак!

Көндәлдә яңа әче тойгы туды, үземне, әллә ничек, гарип кеше итеп сиздем, әйтерсең кыйнап ташладылар... Нәрсәнедер югалттым мин. Нәрсәне? Төгәл генә әйтә дә алмыйм бугай. Шунысы хак, ул көннәрдә беренче кабат: «Кайда син минем тыныч намусым, кайда син минем гөнаһсыз шатлыкларым, кире кайтыгыз!» — дип кычкырасым килде.

Җитмәсә хурланган, алданган, тапталган мәхәббәт үлеп калырга теләмичә, егылган җиреннән торып баскан көрәшче мисалында, үзенең юк хокукларын дәгъвалагандай, һич бирешмәде, һич сүрелмәде — киресенчә, үҗәтләнеп кайнарлана гына бирде. Ояты, гарьлеге белән бергә — мәхәббәт! Бу ни дигән сүз була икән, моны хәзер дә аңлый, аңлата алырлык хәлдә түгелмен. Шамил үзе дә ныграк ярата башлады шикелле — сирәгәйгән очрашулар тагын ешайды — күз яшьләре, бәхәс, тиргәшләр дә аларны киметә алмадылар. Бер көнне мин аңа:

— Ташла квартирыңны, калсын анда законлы кешеләр, исән булсак, квартирын бергәләп алырбыз, — дигән идем, ул моңа да каршы килде:

— Алай да ярамый... Хәзергә ярамый. Соңрак... Эштәгеләр бәйләнми башларлык ныгыйм әле.

Җандагы актык өметләрне тузгыткан бу гарьләндергеч җөмләләрдән соң элеккедән дә яманрак әрнү, ачу кузгала, үч укмаша.

— Ярый, Шамил, бу хакта сүз бетте.

«Хуш, бәгырем, исән бул! Квартирың имин булсын!» — көндәлдә калганы шул уй гына.

Шамил юкка чыккач, миңа инде бәхет тә, мәхәббәт тә, дөнья үзе дә кирәкмәс. Шушы зур дөньяда мин тагын бер үзем. Мин Шамилгә кирәкмәгәч, бөтен кешелеккә дә кирәгем бетә икән. Әйе, кем минем белән үз булып сөйләшә ала? Кайда андый кеше? Әни белән эти, бүтән беркем юк. Димәк, мин алар янына кайтырга тиеш. Ләкин алар да бит элекке саф Гөлчәчәкне көтәләр, бүгенге Гуленьканы түгел!

Дәресләрне, университетны, очрашуларны, гарип мәхәббәтне, яшь-

лек бөтенлегән-сафлыгын калдырып — туган өйгә, авыл шикелле тыныч шәһәремә.

Туган йорт.

Әти башымнан сыйпый.

Әни елмаеп эш куша.

Бары да элеккечә, моннан ел ярым гына булган тормыш — нәкъ мин калдырып киткән көенчә. Үзем генә икенче кеше. Әгәр әйтсәм? Алар мине асып куярлар да, үзләре дә муеннарына таш бәйләп, Камага сикерерләр төсле. Ләкин мин үзгәрешне әйтмим — ялган каплап тора минем чынлыгымны. Төсем, кыяфәтем үзгәрмәгәч, шул җитә. «Әй, әнием, әй, әтием, нишләп мин сезне кызганам соң әле? Сезнең тормышыгыз нык, бөтен, элеккечә тулы бит — сез үз эшегездә, Рамил энем мәктәпкә йөри бирә, мин дә өйдә...»

Аерма кечкенә: элек мәктәпкә укырга йөрсәм, хәзер мин анда, бәләкәй булсам да — укытучы.

Калган, каргалган кышым яртысы шулай үтте: мин янадан бишектә тирбәлә алмадым. Ә җәй көне тагын вакыт күплектән генә түгел, елга агымына карап, үз җиремдә җирсәгәндәй уйланам, каядыр агып китәсем килә иде. Агып барасың, барасың да... сине кемдер коткара. Бу урын нишләптер Казан турысы була, ә коткаручы — Шамил исемле егет. Һушыңа киләсең дә, коткаручының муенына асылынасың: «Рәхмәт, сөеклем, рәхмәт! Хәзер мин — тулысынча синеке. Теләсәң нишләт, кадерле коткаручым!» — дисең.

Үз уеңнан үзең оялсаң да, фикер ачыклана төшәргә тиешлегән аңлыйсың: Шамилгә мәхәббәтең зурмы синең, нәфрәтеңме. Икесе дә бер тигезме?

Әле мин бары тик нәфрәтләнәм генә, дип уйлый идем. Алай гына түгел, яратам да икән. Мин аны үлеп сагынам, янадан күрәсем килә. Ул калдырган мәңге терелмәс җәрәхәт татлы сымак сулкылдый. «Яши алмыйм, яши алмыйм синсез, яши алмыйм мин Казансыз!»

Күз җиткәнне дә көтмәстән юлга чыгам.

Тагын күрешү...

Читтән торып укуга күчкәнгә күрә, сезнең институтка эшкә керим дип килгән идем, борып чыгармадылар—теләсәң-теләмәсәң дә хәзер син миннән ерак китә алмассың, Шамил дустым.

Шунысы гаҗәп, хәзерге нәфрәт янында элекке ярату кечкенә булып калды, олы нәфрәт мәхәббәтнең дә үз масштабына туры килүен дәгъвалап, шуңа көннән-көн ныграк иреш барды. Мәхәббәт хокукы буенча сөйгән кешем минем белән булырга тиеш — ә яратышмаган кешеләрнең бер бүлмәдә ялганлашып яшәүләре — әхлаксызлык, гаделсезлек. Гаделлек өчен көрәшү тиеш һәм мин шул юлны сайлыйм.

Шамил Радик дигән кеше белән дус һәм аларның хатыннары да дуслар иде. Мин шул дуслыкны эшкә кушарга кирәк таптым. Радик хатынына үземнең серләремне бушатам. Хатын-кыз өчен мондый сер— олы табыш, аны ул үзенең сердәшләренә, балаларга конфет биргәндәй, сөенә-сөенә өләшә. Радик хатыны аша җибәргән хәбәрләремә беренче җавап: алар өйдә бик тату яшиләр икән, мин, имеш, юкка гына гаилә бозмакчы булып яшим. Шамил артыннан үзем чабам, очрашулар дәгъвалыйм, ә Шамил миннән кача, минем белән күрешми һәм күрешмәячәк. Шамил — тугры ир.

Болай булгач, исбатларга кирәк аның тугрылыгын!

Шамил әле ике көн элек кенә бер дустының командировкага киткәнлеген һәм түшәмнең кешеләр сагынып зарыгуын берничә кинаясез әйткән һәм чакырган иде. Ул көнне нәфрәтем җиңү сәбәпле, баш тарттым. Хәзер чакырса, мәхәббәт җиңәчәк...

Көндезге сәгать өчләрдә телефонда — Шамил тавышы. Йомышын шулай гына хәл итмәкче тагы, юньсез, юк, үзең кереп сөйләшсәң дә таман булыр. Эш сәгате беткәч керде һәм туп-туры теге «түшәме зарыккан» өйгә алып китмәкче.

— Бүген без иптәш кызым белән сүз куешкан идек — концертка барабыз. Ныклап килешсәк, синең белән иртәгә мөмкин.

Шамил шат:

— Ярый, бик кыен булса да түзәрмен.

Бернинди дус кыз һәм аңа бирелгән вәгъдә юк, концерт — бигрәк тә. Радикның хатыны гына бар, минем аңа, тик аңа гына әйтә торган йөрәк серем бар.

— Без бүген Шамил белән үзебез генә бер квартирда булабыз, адресы менә шушы, — язып кулына тоттырдым. — Кичке сәгать җиделәргә килсә, ирен бик матур кыяфәттә күрә алачак.

— Кит инде, малайкаем, менә кызык! — ди Радик хатыны, рәхәтләнеп көлә. — Әллә мин дә барыйм микән?

— Син үз ирең янына шулай барырсың, яме, ашыкма.

— Кеше өлешенә кул сузма дисеңме? Ярый, только бер шарт белән — ни булганын чәчми-түкми сөйләп бирерсең. Алардан сорашып булмас бит инде — яхшы түгел, үзең беләсең. Шулай бит?

— Мин риза, әҗәтемне бөртеген дә калдырмыйча үзеңә кайтарырмын.

Сөйләшкәнчә, икенче көнне биштән соң унбиш минут үткәч, Шамил керде. Ул инде мине кулындагы кош итеп тоя һәм ялгышмый. Эчтә дөрләп янган үч әллә кайчан ургылып чыгар иде, әгәр дә аның юлын каплап таш сыман авыр мәхәббәт ятмаса. Бәхеткәме каршы, бәхетсезлеккәме, ул — бар, бөтен усаллыкны җиңеп шушы хәлдә дә аның кочагында ләззәт кичерергә ярдәм итә торган, аңлашылмас көч бар. Нәфрәт артка чигенә — мин Шамил чакырган тыныч оҗмахка сөенеп диярлек барам.

Без әйтерсең беренче уйсыз вакытлардагы кебек — икәүдән-икәү. Мин инде аның хатынын көтмим дә, аның килмәсенә, куркачагына ышанам һәм, хәйләм чынга ашмаганнан һич кайгым артмый, киресенчә — мин мәхәббәтемнең гөнаһсыз вакытларына кайттым шикелле, бөтен гомергә калачак җәрәхәт, әйтерсең, төзәлгән, әйтерсең, без киләчәге һичнинди караңгылыкка бирешми торган якты утрауда.

— Мин сине теге вакыттагыга караганда да көчлерәк яратам, Гуля. Синең белән курыкмый очрашу җае беткәч, бөтенләй әллә нишләдем. Ахрысы, түзә алмам мин — җиңелермен. Син бөтен нәрсәне җимерәчәксең, менә күр дә тор.

— Киресенчә, безгә нәрсәнедер рәтләп корырга кирәк, яңаны, әйбәтне. Ә яратмаган кеше белән бер минут та тора алмас идем мин, тик синең икейөзле булуың гына сезне бер семья итеп асрый.

— Әйе, аңладым. Бетте. — Һәм шешә ачарга керешә.

Әйтерсең, миңа шул кирәк.

— Шамил, менә шушылай кара-каршы, күзгә-күз карашып утырсак, минем өчен шуннан да зуррак бәхет юк.

— Минем өчен дә шулай гына, — дигән булып, үз ялганы аңлашылып торганны тоеп, елмая.

Алдыма рюмка куя. Тост дигәне тагын килер бәхетләр хөрмәтенә булгач, рюмканы чәкешеп, ирнәп карыйм, ләкин яман ис гайрәтне чигәрә — кире куям.

— Булдыра алмыйм, Шамил, үпкәләмә.

Үзе генә ике-өч рюмканы бушаткач, каршы як урындыктан туеп, минем якка чыкты да урындыгымны чәүмәлдерде.

— Хәзер син — минем кулда, ни теләсәм, шуны эшли алам.

— Тырышып кара, көчең җитсә.

— Гуленькам! Үкенечле бәхетем минем! Нишләргә миңа, әйт, нишләргә!

— Берни дә эшли алачак түгел син, үзебезне үзебез алдамыйк. Мин инде беләм.

— Белмисең, белмисең!

Һәм кара сакал минем ак күкрәгемә каплана. Мин тагын юкка чыгам — ерактагы хәерсез кичтәге кебек. Һушны, акылны коньяксыз да җуярга мөмкин булуга тик соңыннан гына гаҗәпләнеп ышанам. Шулай да кай мизгелдәдер тән авыртып сызлануым, елыйсы килүем хәтердә кала. Димәк, һушымнан бик үк язмаганмын, димәк, мин үземне бераз алдыйм, җан тынычлыгы вөҗдан хакына икән. Вөҗдан ул шундый уңайсыз нәрсә, аны кая куярга белми аптырыйсың...

Тойгылардагы аң яктыртып өлгермәгән тынычсызлыкның нәрсә икәнен чамалый алмыйм әле. Моның сәбәбе Радик хатынына әйтеп калдырган сүзләр мәгънәсеннән куркып калтырый башлаган минут һәм секунд укларында дип беләм. Ачудан шашкан апа килер дә ялган идиллия пәрдәсен бер селтәнү белән һәм бер алама сүз белән йолкып ыргытыр...

— Шамил, вакыт бетте, җыен, — дим, каушый биреп.

— Кая? Яле, кыланма.

— Тизрәк бул, киттек, я инде.

— Курыкма, көн — безнеке.

Шамил борчылырга җыенмый — гадәттәге саргылт чыраена бәхет алсулыгы кунган.

— Син үзең кара, алайса, — дим аптырагач.

Өс-башны рәтли-рәтли биш-ун минут ялынсам да ул кыймшанмады — ялгызым гына чыгып китә алмаячагыма ышанган хәлдә, үзенең тынычлыгын хаклыктан ышыклап торган түшәмгә карап ята бирде.

— Дөп-дөп!

Түшәм селкенеп куйды. Мин, сискәнеп, тордым да ишек катына килдем.

— Дөп-дөп-дөп!

Ә Шамил куз сыман кызарып янган күзләреннән ярсулы очкыннар чәчә, кулларын бутый-бутый, мине үз янына килергә боера.

«Ачмыйм, курыкма!» дигән ишарәләр ясап аны да, үземне дә бераз гына тынычландырам да, ихлас күңелдән рәнҗетәсем килмәсә дә, күз ачып йомган арада ишекне ачып та карыйм:

— Сезгә кем кирәк?

Ишектә — моннан нәкъ бер ел элек мине шушы сүз белән каршылаган апа. Аның җавап бирерлек хәле калмаган, чырае — Шамил сакалы сыман кап-кара, күзләре Шамил күзләреннән дә куркынычрак — аларган, урыннарыннан купкан.

«Нишләдем?!»

Шамил ялангач килеш ике кулына берьюлы таянган да шундый ук аларган күзләре белән миңа карый. «Хатыныңа кара, хатыныңа!»

Хатыны әкрен-әкрен караватка якынлашты да Шамилнең урындыктагы чалбарын эләктергәч, үксеп тә җибәргәч һәм чалбар белән Шамилнең ялангач тәненә шапылдатырга керешкәч, «Менә, кабәхәт, менә җир бит, пычрак таракан!» дип тәкрарлый башлагач, мин, шул тирәдәрәк калган сумкамны эләктердем дә, тизрәк урамга ташландым. Өйдәге чыйкалаш ни белән бетсә дә минем файдага булмаячак, әлбәттә. Үч кайтаруымның бик көчсез, минем югалтуларым белән чагыштырганда гаять кызганыч икәнен сизәм, бик, бик сизәм. Ләкин шуннан артык нишли алам соң? Кулдан килгән кадәресе шушы гына лабаса!

Шамилнең мине тынычлыкта калдыруы җандагы моңарчы булган җәнҗалны бетерер дип көтсәм, чынлыкта киресенчә булды бугай. Чынлыкта мин, Шамилне үземнән тибәреп, ялгышлык кына эшләдем ши-

келле: аның белән очрашканда йөрәктәге кара боз чак кына эреп, әрнү кимегәндәй тоелса, хәзер ул үскәннән-үсә генә, чөнки аңа минем күз яшьләрем өстәлә һәм өстәлеп туңа бара. Ялгызлык дигән кара кодрәт тыштан басса, түзәлмәс хата салкынлыгы эчтән тутырып шул ук бердәнбер йөрәкне кыса. Хәлемне аңлатканда, син, Нажар, киләчәк көннән: «Бәләкәй арбада туып тәрбияләнгән ялгызлык тойгысы автомобильгә, трамвайга, самолетка утырган чакта да дәвам итә», — дисең.

Хактыр ул. Әмма Шамил белән очрашканга тикле мин мондый өянәкне белми — рәхәтләнеп сәбәпсез көлә, шаяра идем бит. Шул гадәт буенча, дөрес, мин әле дә көләм, әле дә шаярам, ләкин аерма — җир белән күк арасы лабаса. Көлгәндә җандагы кара боз чак кына эресә, ул күз яше булып атылырга тора.

Шамил белән аралар беренче тапкыр бозылгач ук мин ул җитәкләгән ансамбльне дә ташлаган һәм җыр белән араны өзгән идем. Әмма Шамилдән дә, җырдан да азат хәлдә, буш вакыт дигән төпсез дәрья мине суыра башлады. Көчсезлек гарьлегеннән мәңгелекнең үзенә охшаган төнге һәм кичке бушлыкта дөньяга ишетелерлек итеп үксисе килә. Җаным минем, дөресен әйткәндә, кычкыра да, тик ул тавышны бүтән тавышлар белән томаларга тырышам, шуңа өйрәнеп киләм: кинотеатрларга, төрле очрашуларга барам, алардан соң ниндидер күңел ачу кичәләре була, ә күбесенчә танцыларга, дискотекаларга йөрим. Ашыгам, чабам, сулыш алырга да вакыт җитми, янәсе артымнан ниндидер куркыныч нәрсә куа — кешеме, җенме — кара сакаллы... Ул куа, мин качам, тыннарым кысканчы йөгерәм. Янәшәдә кемнәрдер тагы йөгерә — елмая, хихылдый, сикерә, бии. Әллә бу шундый сәер дискотека инде? Әллә кайсының йөзе таныш та, түгел дә, ягымлы да, чирканыч та, ә мин аларның чыраена карамыйм, исемнәрен атап әйтсәләр дә истә калдыра алмыйм, тырышмыйм да. Бу чакта күргән-кичергәннәрне ходайның үз каршында да сөйләрлек булмады шикелле. Ләкин дөнья ул хәтле үк киң түгел. Шулай күпмедер вакыт яшәгәннән соң кичке бәйрәмнәрнең берсендә Шамил белән очрашырга туры килде.

Иптәш кызлар белән институт клубына мендек. Бер-беребез белән, аннары кем чакырса шуның белән танцевать иткәч, шул ук залда Шамил белән Радик барлыгы күзгә чалынды. Аларны күргәч, нишләптер, түгәрәкне калдырып, тынычрак почмакка барып бастым. Тик күзләрем керфек асларыннан гына булса да аларны күзәтә, ә колакларым музыка тыңлый.

Хендрикс җырлый. Ул — бөтенләе белән өметсезлек кычкыруы. Наркотиклар парыннан яралган көйләр. Кеше азаккача ялангач — улояттан да азат,. сабый шикелле, кыргый җан иясе кебек. Хендрикс миңа уйламаска куша. Уйлау — үзеңә сораулар бирү дигән сүз, ә аларга миндә җавап юк. Кичәләрне генә түгел, бөтен гомерне фикерләр белән тутырырга мөмкин һәм шул кичтә өйгә кайткан чакта ук ялгыз булуың ихтимал. Фикер файдасы кайда?

Фикерләрдән синең уңышсызлыкларың җиңүгә әйләнми, шуңа күрә шайтаныңа озат син ул уйларны. Әйдә, өстеңә гайбәт булмагае, ташлар ыргытсыннар, ә син вакытны барыбер әйбәт, күңелле уздыр, шушы мизгелдә сиңа бүтән һичкем бирә алмаган рәхәтлекне кемдер бирә ала икән, шуны сайла — түкер барча шартлы нәрсәләргә!

Ә ул кеше — монда, син аны яхшы тоясың...

Ләкин беренче булып, танцыга мине Радик чакырды. Иске танышлар белән кабат очрашуданмы, тиз хәрәкәтләр нәтиҗәсе булуы да бик ихтимал, тик шунысы хак: мин үземне каядыр очып баргандай хис иттем — язгы иркенлектә, гүяки сагышсыз шатлык кичергән Радикның бөдрә чәчләре уйны чуалтмый, соры күзләр чаялыгы башны әйләндерми — күңелдә саф яктылык, залдагы нурларны көчәйтә торган хис.

— Синең белән кайчан да булса уртак сүз табарбыз әле без, әйеме? — ди Радик әрсезләнеп.

Ләкин шул да мине рәнҗетми, тора-бара үзем дә оятсызландым, әрсезләндем, ахрысы. Әнә бит, елмаям бит!

Әкертен танец музыкасы яңгырый башлауга... Әйе ул! Мин сүз кушмаска да тиешле Шамил килде:

— Исәнме, Гуля.

Минем нәрсәне дә булса ахырынача уйлап эшләгәнем бармыни? Җил каян иссә, шул таба бит! Колбашыма яткан кара сакалны сыпырып төшерү уе килми башыма, киресенчә, ул минем муеннарымны, колагымны кытыклап рәхәтләндерә. Алама уйларны музыка дөбердәве куа, бөтен тавышка: «Бетсен дөньясы, җимерелсен иртәгә үк, ә без шуңарчы бу нык түшәм астында һич нидән курыкмыйча йөри торыйк әле!» дип җырлыйсы, кычкырасы, шашасы килә. Шамилнең пышылдавы барыбер ишетелә һәм баягы теләкләрне тагын да котырта, аздыра гына:

— Мин сине оныта алмыйм, Гуленька, оныта да алмам. Миңа карата эшләгән усаллыкларыңнан соң да сагынам. Нәрсә икән бу, нинди мәхәббәт икән бу?

Мәче ихтыярындагы тычкан булудан туктап адәм буласы килгән көе дә һаман шушы купшы сүзләргә ышанырга тырышам.

Әгәр ул чакта ук синең белән танышкан булсам, кадерле Абба, мин аңа бу вакытта «мәхәббәт түгел, тимер аркан өстендәге бию!» дияр идем. Ә мин һичничек тә җавап бирмәдем шул, зал тутырып тетрәнгән рок шикелле колак пәрдәләрен ярырдай ишетелгән сүзләрне рәхәтләнеп тыңладым гына.

Озата да барды. Анда да шундый ук сүзләр кабатланды.

Мондый чакта, син, Абба: «Иреннәр алдаша белмиләр», дисең. Ул чакта да шулай булды микәнни соң? Ничек алай була ала икән? Нишләп бер үк җан, бер үк тән алдашмыйча капма-каршы мәгънәле җырны җырлый ала?!

Ә ник күптән бөтенесе аңлашылган, кабат-кабат укылган китапны яңадан кулга алырга? Искергән көйнең яңа яңгырашын ник эзләп азапланырга? Акыллы, тирән кичерешле әсәрләр белән шулай мөмкин дә бит, ләкин... Ләкин җитәр, үз дустыңны яманлап ташлавың бар. Ә ул әнә, теләсәң, хәтта синең өеңә үк барырга риза. Өйдә беркем дә юк. Һәм ул шуның белән куркыныч та. Дөресен әйткәндә, бүген мин анда кайтып, ишекне ачып керә алмам шул. Өйдә әйтеп аңлата алмаслык шом, хуҗабикә апаның өрәге кетә...

Куркуым сәбәбе аңлашылсын өчен кечкенә генә чигенү (бәлки ул лирик булмас, юмористик чигенү булып чыгар, гафу итәрсең) ясарга тиешмен.

Өч елдан артык мин квартирада торган апа күптән түгел генә пенсиягә чыккан иде. Икәүдән-икәү яшәсәк тә, бүлмә бәләкәй булгач, пропискага керә алмадым. Алай да яшәргә мөмкин иде дә бит, тик апа бик каты чирләп, озак вакыт түшәктә ятты. Үз әниемдәй күреп карадым аны. Бөтен теләге үз түшәгендә җан бирү иде, ләкин хәле бик авырайгач, ашыгыч ярдәм коткарыр дигән өметне өзә алмыйча, шалтыраткан идем, килеп алдылар. Ә ике көннән вафат диделәр. Күрше-тирә, аз-маз туганнары белән җыйнаулашып җирләдек.

Ул апаның якын туганнары юктыр дип йөрсәм дә (чөнки хастага калгач килеп хәлен белүче булмады), җирләгән генә идек, бер көтү кыз туганнары (кайберләре әзмәвердәй ирләре белән) килеп керделәр дә өйне туры мәгънәсендә тентергә керештеләр. Сандыкларны актарып аттылар, әллә нинди матур киемнәр, затлы бизәнү әйберләре табып (ә мин белмәгәнмен!) сатулаша-сатулаша бүлештеләр. «Бусы әнидән

калган, ул аны миннән алып кына торган иде, хәзер мин аны кайтарып кына алам. Монысы — минеке, биреп кенә торган идем, кире китермәде ач күз», — дигәнрәк сүзләр ярты көн буе колакларымны тондырды. Анысына түзәр дә идең, комод тартмасыннан сберкнижка табып алгач, «шушы хәтле акчасы булган!» дип, тел шартлата-шартлата бот чаптылар һәм анысын ничек алырга, ничек бүлешергә белмичә кычкырыштылар. Кычкырышып аргач, яннарында мин, чит кеше, барын абайлап, инде миңа ташландылар. Имеш, әле апаларының кассага салмаган акчасы да булгандыр, табып бир, янәсе. Үлемтегенә тотканнан соң калган өч-дүрт сум чынлап та бар иде, шуны биргәч, колакка сыймас орышулар белән ырлашырга тотындылар. Дөньяда мондый кешеләр белән очрашу үзе үк күңелне рәнҗетә. Тик алар бар. Үземнең чемоданнарым, портфельләремне тентеп күрсәткәч тә тынычланырга ашыкмадылар: «Хәйләкәр, укыган башы белән уборщица апаны имеп яткан икән», — дип, берсе хәтта корсак киереп каршымда аяк типкәч, сизмәстән нәкъ үзләренчә: «Заразалар, паразитлар!» — дип, чирканчык алган идем, ни хикмәттер, кайнарлыклары бераз басыла төште. Шулай да «Хәзерге яшьләр бозык» дигәнрәк сүзләрне тагын бик озак һәм пычрак су сымак туктаусыз сибә тордылар. Аптырагач, проигрывательне тоташтырып, бөтен көченә диярлек җибәргәч кенә колак тынычлана язды. Үзләре шаулаганда матуррак тоелгандыр, күрәсең, монысын да яратмыйча сукранып туктатмакчылар иде, тагын баягы шикелле кычкыруымның файдасы тиде. Озак та тормыйча, чыгып китәсе иттеләр. Тәрәзәдән караган идем, гаҗәп матур тезелеп кенә атламаслар диген! Ирләре белән култыклашып, шундый әдәпле атлауларына сокланырсың. Менә нинди матур, тату гаилә корганнар! Ә мин? Мин дә шундый семья хакында уйлыйммы?

Тумача апамнарга дип чыгып киттем дә шуннан соң бу өйгә бик озак кайта алмый йөрдем. Аларның өйләре кысан булганлыктан, кайсыбер көннәрдә иптәш кызларым янына, тулай торакка бара торган булдым.

Йортсыз-җирсез яшәргәме шулай? Нишләргә? Әлбәттә, киңәшкә үземнең турыдан-туры башлыгым булган гыйльми секретарьга (син элегрәк аны мөдир дип кенә йөрткәнсең икән) махсус кердем. «Минем райбашкармада танышым бар, сөйләшеп карармын», — дип тынычландырды. Ә бер-ике көннән исә шул кешенең үзенә — коммуналь бүлек мөдиренә барып керсәм, абзый әрҗә хәтле елмаеп каршылагач, әчкә җылы кергәндәй булды. Начальник буларак түгел, гыйльми секретарьның дусты сыйфатында, ачык сөйләшә, үз кешеләрчә. Ә мин түзәм, чөнки сәбәп җитди. «Шулай, дөрес, — ди абзый. — Законча эшләгәндә, сезне ул квартирда калдыру мөмкин түгел. Ләкин кешелекле булсак... Шулай бит? Уйларга ярый. Сез дә уйларга тиештер.»

Абзыйның күзләре майлана. Ул сихерле мәхәббәт сирпеп карый да беләгемнән тота, тик мин бүтән урынга күчеп утыргач, сөмсере тиз коела.

Хәтере калды абзыйның...

Елмаймыйча сөйләшүгә күчкәч, эшне шулай да тикшереп карарга вәгъдә бирде һәм әгәр мин нинди дә булса әйбәт фикергә килсәм, шалтыратырга тиешмен...

Маҗараны кайтып сөйләгән идем, гыйльми секретарь рәхәтләнеп көлде: «Кызык икән, кызык. Менә нишли безнең братлар. Ә соң ничек, син нәрсә дә булса югалтасыңмы соң?»

Күзләремне учларыма яшереп чыгып киттем. Берничә көннән хәбәр итүләренчә, квартирга ордерны бүтән кешегә биргәннәр.

Шамил белән әлеге кичәдә очрашканда хәлем шундый иде. Трамвайда барышлый: «Соңгы тапкыр ул өйдә бәйрәм итсәк тә хәләл икән», дип куйгач, һәм мин гаугалы, өрәкле өйдә йоклый алмыйм, дигәч, Шамил: «Үз өлешеңне талап, каерып алсаң да таманга килә бу дөньяда, ә син көязләнеп маташасың», — дип хәтта битәрләде үземне. Кая кайтасымны белмәсәм дә, саубуллашып китеп бардым. Озак уйламастан, тумача апам ишегеп шакырга тиеш таптым.



Эчке бер сизенү авазы очрашуларның бу инде азаккысыдыр дисә дә, алай ук булмады. Озак та үтмичә, звонок — Мәскәүдән. Шамил иртәгә үзен каршылавымны үтенә. Хатыныннан мине якынрак күрүе күңелне тагын җылыта кебек...

Вокзал. Мәскәү поезды. Үз кешеләрчә кочаклашу. Такси. Таш кебек җиргә береккән чемодан. Мин кузгата алмагач, елмайды да Шамил аны багажникка урнаштырды. Ишекне үзе ачып чакыргач, алгы утыргычка утырдым.

Кайтышлый Яшьләр үзәгенә тукталдык. Шамил кемнедер бик ашыгыч күрергә тиеш икән. Тукталыр-тукталмас ишекне ачты да:

— Син бер биш минут көтеп тор, озакламам, — дип, йөгерә атлый китеп барды. Ни уйларга белми утырам. Ә шофер нәрсә уйларга кирәген тиз төшенгән икән. Шамил күздән югалу белән миңа автомобильдән төшәргә кушты.

— Ник? — дим аптырап.

— Анысы сиңа нәрсәгә?

— Минә тагы...

— Ә ну! Кемгә әйтәләр?

Шул хәтле акырды ки, кот очып, бәреләсугыла төштем. Ә ул бөтен тизлегенә гөрләп китеп барды һәм юкка да чыкты.

Багана шикелле басып тик торам. Шамил күренгәч, нигәдер, аның каршысына ашыгам. Килә-килешли:

— Ни булды, кайда машина? — дип кычкырды ул.

— Китте дә барды.

— Ә чемодан?

— Ул куркытып төшерде мине, акырды да каушап...

— Уфф, дура!

— Ә?

Шамил ике кулы белән колакларын каплап таш барьерга утырды һәм сынына катты.

— Машинаның номерын истә калдырдым мин, курыкма, беркая китә алмас, милициягә хәбәр итәрбез, — дип һушына китермәкче булам.

Кая ул! Биш-ун минуттан соң гына торып басты:

— Милиция! Милициягә хәбәр итмәкче! Ах, дура!

— Ә ник? Ни булган?

Монысын ул миңа аңлатып тормады, әлбәттә. Озакка сузылган сүзсез газаплардан соң кузгалып киткәч, һәм бераз баргач, мәсхәрәле елмаеп:

— Анда сиңа тиешле джинсы да бар иде, — дигәч кенә бөтенесе берьюлы аңлашылды.

Минә ни өчен кирәкми икән таксиның номеры! Минә ни өчен генә чакырган ул мине — машина саклап торырга! Сөекле хатыны намусына кер кундырмас өчен! Һәм чалбар бәрабәренә тагын нинди эш кушар иде? Сәүдә белән күңел ачарга?

— Шамил дустым, син минем кемлегемне бөтенләй белмәгәнсең

икән бит. Мин дә сине... Мефистофель икәнеңне сизенсәм дә, өч кенә үлчәүдә яши дип йөрдем. Дүртенчесе дә бар икән ләбаса. Һәм монысы иң основноедыр. Молодец, котлыйм, дустым!

Юлдашым күзләремә текәлде дә шып тукталды. Кибет янында булып чыктык. Аның да аракы бүлеге каршысында. Халык чират тора. Шул фонда остаз миңа иң кыйммәтле, иң соңгы дәресен бирә:

— Әнә, күрдеңме, абзый нинди бәхетле. Огромный толпа арасыннан чиратсыз аракы алып чыкты. Эләктерде! Тизрәк һәм күбрәк — минә аның бәхете нәрсәдә.

— Синеке дә шулай.

— Шула-ай! Организм үзе шуны сорый — табигый хаҗәтем бу минем, табигый хокукым.

— Ә мин аннан баш тарткан...

— Шуңа күрә дә машинадан төшеп калдың бит. Һәм тормыштан.

— Ашыкма, кем төшеп калыр, күрербез.

— Яшәү — мәҗбүрият патшалыгы. Кем өлгер, кем оста, бөтен нәрсә шуңа буйсынган. Хәтта синең мәхәббәтең дә.

— Синеке!

— Хәтта ул да аракы кебек үк — әйбер, булмый ансыз! Кем күпме эләктерә. Ишеттеңме? Бөтенесе — необходимость!

— Мәҗбүрилек патшалыгыннан чын азатлык киңлегенә күчә бара кеше. Күреп торасың.

— Синеме? Һа, син! Син, Гуля — минем икмәгем, суым, син минем тәнем, каным өчен кирәк һәм күбрәк, күбрәк! Әйе, мин — синең кулланучың, потребителең!

Сатулашу мөмкинлеге бетте. Чемодан югалту фаҗигасе бәндәне тәмам шәрә хәлгә чишендерде. Теге вакытта, аулак урында, хатыны килер алдыннан ул болай ук шәрә булмагандыр. Менә бүген ичмасам! Бүген! Җан порнографиясе дигәннәре шушы икән. Моңарчы еллар ача алмаганны ничә генә минут ачты да ташлады. Дустым минем нинди ямьсез кыяфәттә басып тора. Ямьсез, ялангач һәм... кирәксез. Инде соңгы сүзләрем:

— Ә син минем суым да, икмәгем дә түгел. Яшәвем өчен хәтта кирәк тә түгел идең. Синең дөньяда барлыгыңны тою бик җиткән иде. Син миңа җаннар кушылу ләззәтен татыр өчен кирәк идең. Ә хәзер...

— Кирәгем бетте.

— Хәзер ачыкланды: минем күңелгә кушылырлык тойгылар синдә юк. Рәхмәт, укытучым, болай ук беркем дә аңлата алмас иде. Хуш.

Шушы аңлашудан соң ярты ел чамасы вакыт узгач, без синең белән таныштык, Абба.

Боларга үч итеп, синең янга килдем мин. Кабул итмәслек сыйфатың бер генә — син болар кебек актив түгел икәнсең. Белүемчә, чын яхшылык йодрыклы да булырга тиеш.

Безнең бүлмәдә каушап торасың. Гыйльми секретарьдан оялыпмы? Ул синнән дәрәҗә белән дә, эш һәм төс ягыннан да күпкә кайтыш бит. Ә син, нишләптер, булган өстенлегеңне күрсәтә белмисең...

Мине күргәч, әлбәттә, төсең-кыяфәтең үзгәрде: чибәр, ягымлы-матур елмаясың. Карашыңда бернинди ясалмалык юк — күңелеңдә ни булса, бөтенесе үтә күренмәдә. Шуңа күрә рәхәт — шик, курку кинәт юкка чыга, сагаюдан арган күңел синең белән ял итә.

Каршымда торасың: көнбагыш чәчәге сыманрак аксыл сары чәч, зәңгәр күлмәк, күкле-сарылы галстук, җәйге күксел костюм... Күктән төшкән кебек. Үзем түзә алмыйча:

— Аh, минә сез нинди! — дип сокланып куйдым.

— Нинди?

— Элегантный!

— Кызык.

— Чибәр.

— Җитте, ышандыруың бар. Кеше сүзенә ышана торган гадәтем бар минем.

— Ә бу — хак, валлаhидыр.

Ләкин шушы вакытта — телефон... Хәтердә калган сүзләрең: «Как-нибудь загляну...» Гаепле идем мин, гөнаhлы идем, тик кем шалтыратканын әйтә алмыйм бит инде: «Хәлим шалтырата», дигән булдым... Хәер, бу чакта безнең танышлыкның кая таба китәсе билгеле дә түгел иде бит әле!

Мин турист путевкасы белән чит илдә йөргәндә дә бүтән очрашмабыз дигән уй белән яшәдем. Шулай тиеш булганга күрә. Сезнең лабораториядә эшләүче бер апа безнең ресторанда булганны ишеткән дә оялтырга тырыша: «Аның эше бик авыр чак — күзәнәкләр бүленешендә яңа ачыш алдында тора, кагылма, борчыма син аны.» — дип үтенә. Дөрес булса да ялган! Мин бит Нажар дигән кешене беләм инде, очраштым: аның иң зур ачышы мин булырга тиеш. Минем өчен ул үзе дә яңалык: мондый кешене бүтән күргәнем юк, ул — бердәнбер.

Шулай да күңелләр ул хәтле берекмәгәнгә күрә, башта алар сүзенә буйсынырмын кебек иде. Алай гына да түгел, шушының белән бетәр дип уйлаган идем, шулай хәл кылган идем. Ләкин чит илдән кайтып, очрашыр көн якынлашкан саен, акыл сүзләрен тойгы күмеп, күрешүнең нинди булачагы хакында сабырсызланып уйлана башлыйм.

Ә үзең мин кайтканны белгән килеш берничә көн буе телефоннан да шалтыратмагач, хәтта ачу кузгалды — беренче сүз итеп, тиргәшә башлармын кебек иде. Булдыра алмадым. Директорга узышлый, кем беләндер исәнләшкән тавышың ишетелгәч, йөрәгем урыныннан кубып, очып китмәсен дигәндәй, түшне кулым белән капладым. Секретарь кыз бүлмәсенә ашыктым. Син шунда идең әле.

— Исәнмесез.

— Исәнмесез.

Хәзергә шул җитә — ут булып дөрләгән гәүдәмә бензин кебек сибелгән карашыңнан тиз генә котылырга кирәк. Ничек янганымны күрдең, калганын үзең бел.

«Нишләрсең», дип ярты көн интектем. Калганы инде үзеңә билгеле. Шалтыратмый аптыратуың өстенә, эшкә килгәч тә сөйләшмичә гаҗәпкә калдырдың. Болай булырга тиеш түгел иде бит — беренче көнне үк кочакларга ташланган кешеләр болай очрашамыни? Тагын бер-ике көн сөйләшмәсәң, тәмам үпкәләмәкче, сине хәтта күрми дә узарга тырышмакчы идем. Әмма ничәнчедер көнне коридорда очрадың да, бер-ике сүз алмашкач, баскычка хәтле озата бар әле дип үтендең. Менә шунда инде мин беренче көнге Нажарны — Сине таныдым. Сүз арасында ике яңагымнан тотып маңгаемнан үпкәч, рәхәтлектән, ләззәттән күкрәгеңә егыла яздым. Синең куллар! Тылсымлы, көчле, назлы куллар. Мин мондыйны беренче кабат тоям әле.

Очраша башладык. Болай булгач, дөнья тигезләнде, бәхеттән башка тойгылар онытылды дип йөргәндә, көннәр безнең өчен гел аяз гына тормады шул. Берсенә берни сөйләмәсәм дә, кешеләр әллә каян белә дә безнең арага кермәкче була. Каршы бүлмәдә эшләгән иптәш кызым Тәнзилә үзәгемә үтеп

— Син аның белән булырга курыкмыйсыңмы? — дип көлә.

— Минә тиле, аның янәшәсендә басып тору да минем өчен дәрәҗә генә.

— Ялгыш, күгәрчен дип белеп, йөрәгеңне, бавырыңны, бөереңне актарып ташласа?

— Син аны әллә үз танышларың дип беләсеңме?

— Бавыр итеңне кисеп алып, центрифугасына утыртыр да, зыр-зыр әйләндерер. Шунысын да дәрәҗәгә исәплярсең, әйеме?

— Син просто котырган.

— Ул бит үз дөньясына бикләнгән кеше, бүтәннәрне тере яки җансыз организм итеп кенә күрә. Бар белгәне күзәнәкләрдәге аксым агышы...

— Ә ул тойгылар агышын да бездән шәбрәк күрә.

Бәхәсләшүнең файдасыз икәнен аңлап, Тәнзилә үз шөгыленә керешә һәм: «Аңа бездән ни кирәк, ник тыкшынадыр?» дигән уй калдырып, каядыр китеп бара.

Чит илгә барганда без Тәнзилә белән бер делегациягә туры килдек. Ләкин юлдаш була алмадык. Тиз арада аның башкалар юлдашы икәнлеге ачыкланды. Берәр мәйданда тукталдыкмы, ул шәһәр күрү, архитектура, музей могҗизаларына соклану мәшәкатеннән үзен тулысынча азат итеп, бөтен вакытын яңа бер танышы белән кибетләргә чабуга багышлады. Бөтенләй үк кибетсез дә булмый, әлбәттә. Бер көнне боларга ияреп мин дә кердем...

Урамга чыккач ук:

— Нигә кирәк сиңа шул хәтле сумка? — дип сораган идем. Тәнзилә беркатлылыгыма шаккатып:

— Минә тиле: берсе-берсе ун тәңкә тора бит аның бездә, ә монда— бушлай... — диде.

Үзенең күпме түләгәнен тәки белмәгән икән. Моңарчы да чит илгә йөрүчеләр тирәсендә сырпалануына гаҗәпләнсәм, хәзер аңлашылды: ул кешеләр елмаюы да бик үк бушлай эләкмәгәндер аңа... Шамил белән бәйләнеше бармы, юкмы — әйтә алмыйм, тик барыбер, икесе дә бер төркемнән... Шамил кебек ачыктан-ачык лекцияләр укымаса да, бу кыз да мине сафлыкка чакыра... Мине, Абба, синнән коткарырга азаплана. Колакларга эштә дә тынгы юк — үзебезнең бүлектәге лаборант апалар үзәкне өзепме өзәләр. Үзләре һәртөрле шикләнүләрдән өстен булгангамы, аларның сүзләре бәгырьне чынлап кисә. Бер көнне үпкәләгәндәй карап утырдылар-утырдылар да, синең белән телефоннан сөйләшкәнне сәбәп итеп, икесе ике яктан минә керештеләр, минә керештеләр битәрләргә! Имеш, мин юри бәхетле кешеләр гаиләсен җимерер өчен йөрим — Шамилне бәхетсез иткәнем җитмәгән, хәзер монысын...

Уф алла, мине беркем дә бәхетсез итмәгән, мине гүяки беркем алдамаган, гүяки ул кешеләрне мин үзем харап итәм. Хәзер сине! Каян беләләр, Тәнзиләме, кем әйткән аларга? Җаваплары: сүз иясе белән йөрми! Шулкадәр гарьләндем, шулкадәр хәтерем калды, моңарчы булган барлык рәнҗүләрем, барлык югалту, алдануларым бергә җыйналып, күз яшьләренә әверелделәр дә минә керештем үксергә, минә керештем үрсәләнергә. Икесе дә — Суфия апа да, Сәлимә апа да хәтта куркып калдылар. Берсе салкын су эчертә, икенчесе яшьләремне сөртә — бәләкәй баланы көйлиләрмени. Тагын бераз үртәсәләр: «Әйе, әйе, мин аны яратам, я, шуның белән мин сезнең кайсыгызга начарлык эшлим соң? Безгә бит беркемнән берни кирәк түгел, без сездән бернәрсә сорамыйбыз лабаса. Ә сезгә бездән нәрсә кирәк соң?» — дип кычкыра-

сы идем. Берничә тапкыр сынап, тыңлап карадым: йөрәкнең болай ачыргалануын бөтен куәтенә куелган рок музыкасы яңгыравында гына ишетергә мөмкин һәм аны шул гына томалый ала.

Мин тагын шуны тыңлыйм.

Хуш.

*

* *

Гөлчәчәк!

Дөньяда, тормышта чик дигән нәрсә барын оныттыңмыни? Аның аръягына чыга башласаң, нәкъ менә шушындый нәрсә килеп туа: кемнәрдер шаулаша башлый, әйтерсең, син аларның шәхси дәрәҗәләрен мыскыл иткәнсең...

Тыныч кына атла-атла да, ил чигенә җит — аның аша җиңел генә узып булыр дисеңме? Тавыш тизлеге дигән чикне узу өчен күпме газап чикте миләр, күпме кеше егылып төште? Син әйткән яңа музыка, электрон тавышы нинди газаплар кичерә-кичерә генә үз хокукларын даулады?

Ә син көйле генә атлап узмакчы...

Каршылык булмаса гаҗәпләнергә тиеш булыр идең. Болай исә — бөтенесе табигый, түз, кычкыр, җырла, бие, талап ит, ләкин түземсезләнеп хәлдән тайма, егылма. Мин гомерем буе үз хәрәкәтләремне тыеп яшәдем һәм күпме авыруларымның бөтенесе булмаса да, күбесе шуның аркасында. Кычкырасы килгән килеш кычкыра алмау, тыелу яки үзеңне тыю — бөтен фаҗигаләр шуннан башланмыймы? Ә син кычкыр! Син чын мәгънәсендә азат бит!

Ләкин идиллия көтмә, Гөлчәчәк, — булмаячак, синең бәхетеңә тиешле киңлекләрне бары тик узган заманнарның үзләренә тарту көчен җиңеп кенә үтә аласың. Тик бер нәрсәне онытма: үзеңә үзең комачау итмә. Югыйсә, кешеләрдән бигрәк, без үзебездән күбрәк күрәбез зыянны. Синең аркада мин моны шактый тирән аңлый башладым шикелле.

Балаларчарак кылансак та, безгә инде алай гына булмый: урамнар, бакчаларда көзге пычракны таптау, кафе, рестораннарда сөйләшеп утыру, син котылу чарасы дигән колак яргыч тавышлар, моңнар гына җитми, безгә тыныч, интим тынлык та кирәк икән бит. Минем күңеләмә кунакка килеп, син ял итәсең икән... Беләм, минсез булмый сиңа. Ләкин аларсыз — шау-шуларсыз да яши алмыйсың.

Алтын бизәкләрең белән ялтыра син,
Елмаюлар белән йөзең капла.
Күзләреңә сөрмә тарт син, ки син маска,
Тик чын йөзең яшерермен димә,
Күңелеңдә гәрчә тирән ятса,
Гариплегең күмелеп калмас әста.

Бу җыр белән сине рәнҗетәм бугай да, нишлим, кызгануга карап кына дөреслектән котылып булмый бит.

Без танышканнан һәм син авырып яңадан эшкә чыкканнан соң, лаборатория мөдире буларак, минем соңгы экспериментлар хакында кайбер нәтиҗәләр ясыйсым, аннары, бөтен фикерне туплап, аннары тагын отчет язып, гыйльми советка тапшырасым бар иде. Мондый чакта яшьлек тә, мәхәббәт тә читкә тайпыла, рәнҗеми, үпкәләми. Син моны аңларга тиеш идең. Ләкин «тиеш» ул әле «бар» дигән сүз түгел. Синең эш җиңел, бүтәннәр биргән материалларны тәртипкә китереп, теркәп кенә барасы — вакытны кая куярга белмәгән көннәрең күп.

Әкертенләп бушлыктан коткару башы, имеш: сиңа задание бирәм.

Гажәеп перспективалы яңа ачыш — мидә эндорфиннар синтезы. Шул хакта булган күзәтүләр, фикерләр белән танышырга, ә кирәк булса, лабораториягә кереп (мин рөхсәт итте дисәң, кертерләр), экспериментлар яса. Кызыксына калсаң, өр-яңа чиксезлекләр анда, хәерле юл теләргә мөмкин. Ә син? Тәкъдимем бер колагыңнан керде, икенчесеннән чыгып та сызды, үзем күреп тордым.

Нишләрсең икән дип, телефоннан шалтыратып торам. Бер, ике, өч көн. Дүртенче көн җомга иде — хәтерлим, сәгать икеләрдә шалтыраттым — сөйләшүең гадәттәгедән салкын. Мин моңа күнекмәгән һәм сүзне сузмыйча: «Ярар, соңрак шалтыратырмын әле», дип куймакчымын. Тик син катгый рәвештә: «Сәгать өчтә мин китәм!» — дисең. «Кая?» — «Бер җиргә».

Шактый пошаманга төшкәнемне күрмисең, сизмисең һәм бу синең мәнфәгатькә туры да килми. Мең сорау, мең газап белән дүшәмбе көнне эшкә килүем, вестибюльдән баскычка борылуым булды, аннан син килеп чыктың. Юк, мине каршылау өчен түгел иде бу юлы, шуңа күрә каушадың.

— Исәнме? Нишләп болай? — дим аптырап, гаҗәпләнеп.

— Ничек «болай?»

— Төсләрең качкан.

— Температура, ахрысы, баш авырта.

— Минем дә күңелдә авыр нәрсә...

Син баягыдан да ныграк каушап:

— Нишләп алай? — дип куйдың.

— Синең аркада.

Шул вакыт янибызга танышлар килде дә син китеп бармакчы.

— Китәсең дәмени? — дим, тагын гаҗәпсенеп.

— Әйе.

Киттең дә. Ә минем хәлнең ниндилеге бары тик үземә генә билгеле. Ярый әле отчетларны тапшырасы гына калган иде. Югыйсә — бутап бетерәчәк идем.

Ярты көн. Ул да узды. Утырам, сиңа шалтырата алмыйм — йөрәк җитми, җан карыша. Бүтән вакытта үзең ешрак шалтырата торган идең — хәзер син дә лим-мим. Нәрсәдер булганлыгы көн кебек ачык. Кемгә бәйләндем мин, кемгә?!

Инде бишләр тулып килә. Бүлмә буйлап йөренәм — ул тар, урын җитми. Мондый хәлдә бүлмә генә түгел, җир йөзе ямьсез, җир йөзе тар. Кеше белән сүзгә килешкәндәй ярсынам. Номерлар җыям. Таныш тавыш. Нечкәрәк, ләкин ягымлы, ямансу тавыш.

— Синме? — дип сорыйм шул тавыштан.

— Әйе.

— Син тереме?

— Ничек алай?

— Минем өчен, дим, тереме син?

— Тере. Ник алай дисең? Иртән дә мәзәгрәк әйттең...

Сезнең катка менеп ишек ачканда, гыйльми секретарь үз бүлмәсеннән чыгып килә иде. Гаҗәпләнеп тора:

— Ни булды, иптәш... кем... берәр «чп» юктыр бит?

— Юк. Менә отчетларны укып карар кеше таба алмыйм. Ашыгыч бит, үзең беләсең. Килешеп булмасмы дип, тагын Гөлчәчәккә килеп егылмакчы идем. Мәхәббәттә дә аңлашасы бар бугай, — дип елмаерга тырышам.

— Соң, сөйләшегез, алайса, сөйләшми генә килешә алмассыз.

Икәү генә калдык. Хәзер инде синнән сүз көтәм. Һәм башлыйсын да шикелле:

— Бая әллә ничек әйтеп куйдың.

— Нәрсәдер бар кебек бит.

— Син Радикны күрдеңме әллә?
Монда, кем әйткәндәй, сине «на пушку» алырга, Радик бөтенесен сөйләде дип алдарга мөмкинлек бар. Тик бусы — минем стиль түгел, мин дөресен генә әйтә алам:
— Нәрсәдер тоям.
— Радик наверно әйткәндер. Теге көнне кергән иде.
— Шуннан?
— Бер җиргә барырга үгетли, аңлыйсың бит инде.
— Аңлыйм. Бардыгыз да?
— Юк. Ул шуңа күрә ачулана. «Кем дип беләсең үзеңне» ди.
— Синең белән килешкәнче үк бүлмә тапкан?
— Әйе, ул минем белән плохо поступил.
Менә сиңа караш! Шайтан алгыры, шушы хәтле түбәнлеккә төшәргә, шушы хәтле мыскыллауга ничек түзәргә мөмкин? Ничек син аны миңа көн буе сөйләмичә түзә алдың? Шауламасам, тыныч кына үткәрер дә идең!
Бу — синең хакта беренче алама сигнал. Шуңа күрә әллә ни ашыгу дөрес булмастыр. Һәм минем холык артык тәвәккәл дә түгел бит — тиз генә хәл итә белмим. Аптырап кына калдым тик. Ишекне шапылдатып ябарга һәм сине мәңгегә ташлап чыгып китәргә көч җитмәде. Ике-өч көннән соң ук миңгә теткәләнгән кәеф белән өеңә хәтле озатып куярга тиеш таптым әле хәтта.
Институттан чыккач та, безнең кечкенәрәк бакча бар. Шуның аша үткәндә, гадәттә, без балаларча көлешә-көлешә атлыйбыз һәм кочаклашабыз һәм... ник сүздән куркырга, үбешәбез. Монысы — гадәттә. Ул көнне болай булмады. Шаярдык, көлештек, әмма... бер омтылыш, ике, өч... Шаярдың да читкә тайпыла тордың, ә мин исә көлүне дәвам итеп: «Син әллә бүген чит кеше белән үбештеңме?» дип сорадым. Шуның белән бетте дә онытылды. Ләкин берничә минуттан соң кабат хәтергә килер өчен генә онытылды.
Трамвайда куллар бер-беренә тотынышкан — нидер сөйлисең. Кайсын ишетәм, кайсын юк. Ләкин бер урында сагая калдым.
— Кичә минем янга Алсу кергән иде.
— Керсә соң?
— Шамил Мәскәүгә китә бүген, ди.
— Ник?
— Үз шөгыле беләндер инде. Тагын китә, имеш, кемнәрдер озата төшә, ди, Алсу әйтә.
— Барасың калган, — дим юри генә үртәргә тырышып.
— Ә мин бардым.
— Ни-че-е-е-к?
— Бүтәннәр белән түгел. Болай, соңгы кабат, сынар өчен — якынлык калдымы, юкмы икәнен белер өчен. — Мин ни әйтер дип көттең булса кирәк, ләкин мин эндәшмәгәч, дәвам иттең. — Күңелдә берниндә хис кузгалмады. Димәк, беткән. Радик та, Алсу да озата килгәннәр. Ник бер сүз дә сөйләшмисең, ник эндәшмисең? Я инде, что син? Я инде, юләрләнмә!
Яндагы кешеләр игътибар итә башлагач кына:
— Соңыннан, соңыннан, — дип куйдым һәм алдагы тукталышта төшеп тә калдык. Син исә, әйтерсең, берни белмәгәндәй, һаман ни булды да ни булды дип, кабатлый-кабатлый нярәсең.
Бер атна эчендә ни хәтле үзгәреш! Бер атна вакыт эшемнән аерыла алмаганым аркасында Радиктан үзеңне мыскыл иттерергә дә, киткән поездны озатып үзеңне үзең тере мәет хәленә куярга да өлгергәнсең. Җитмәсә, мине култыклыйсың да кискен тартып туктатасың:
— Бернәрсә дә аңламыйм, аңлатуыңны сорыйм, — янәсе.
— Син миңа бөтенесен үзең аңлаттың.

— Шуннан ни булган? Ул бит мине күрмәде.

— Мине анысы кызыксындырмый. Син баргансың — шунысы хак. Ярый, бетерик, хуш.

— Нәрсә, китмәкче буласыңмыни? Шәһәр уртасында ташлап?

— Көн иртә — зыян юк.

Кузгалгач та син тагын эләктереп аласың:

— Тукта, хәзер... бит... бер дә юктан. Бөтен нәрсә бетәмени? Бөтенләйгә? Акылыңдамы син? Син мине подводишь.

— Ну син мине үзеңчә подвела, шундый шәп!

— Ничек, ничек итеп?

— Аңламый!

— Мине беркем күрмәде, мин эштән апаларга кайтышлый, читтән генә уздым, озату дип уйларлык та түгел.

— Барыбер, барыбер анда булуың факт. Гафу ит, калдык-постык мәхәббәткә мохтаҗ түгел мин — вокзал алкоголигы түгел, бишәр тиен акча теләнә алмыйм.

— Сабыр ит, зинһар! Тукта!

Шулай дип, син минем тирәдә ике-өч тапкыр әйләнеп чыктың. «Нишләдем мин, нишләдем мин!» дип шыңшый-шыңшый, башта кулбашыма башыңны куеп иркәләнмәкче, аннары җитәкләп каядыр алып китмәкче, килешү сүзе ишетмәкче булып шактый азаплангач:

— Әгәр син мине ташласаң, мин сине үтерәм! — дип кычкырасы иттең дә, мин беркатлы интегүләреңнән ясалма рәвештә булса да көлгәч, бүтән юл сайладың:

— Мин сине не подвела, монысы дөрес. Бөтенләй икенче төрле булды, мин сине бая алдадым.

— Карале, Гөлчәчәк, ник әле син шул хәтле өзгәләнәсең, син бит бернәрсә югалтмыйсың. Ну, нәрсә ул мин? Нинди өмет, нинди вәгъдә? Куй, тынычлан да бар, кайтып кит. — Сүзләрем чын күңелдән.

— Беркайчан да болай булмаячак. Мин сине калдырмыйм, калдырмыйм.

Елап җибәрәчәгең көн кебек ачык булганга күрә, юатмакчымын:

— Берни югалтмыйсың ич!

Моңа каршы тагын бер сүз дә әйтә алмыйча:

— Нишләдем мин, нишләдем! — дип уфтанасың һәм моның да чын күңелдән икәнен күреп, бераз йомшара төшәм, ни өчендер, баштан: «Мин үзем әле кем соң шушы хәтле чибәрне санга сукмыйча интектерергә?» дигән уй ялтырап куя. Ләкин җиңелүнең башы бу түгел әле.

Без синең апаларың торган урамнан барабыз икән. Син урамның икенче ягында барган ике кешене күрдең дә сөенеп куйгандай иттең.

— Ә беләсеңме, мин бит кичә вокзалга кермәдем. Ышанасыңмы? Ышанмасаң, әнә апа белән җизни бара, туктатабыз да сорыйбыз. Кичке җидедә мин аларда идем инде. Әйдә, туктатабыз да сорыйбыз.

Безнең танышлык — синең барлык туганнарыңнан сер. Әгәр без хәзер барып сөйләшергә керешсәк, бу синең иң якын апаң каршында үзебезне ачу булачак һәм моның өчен үзеңә шактый каты шелтәләр эләгәчәк. Дөрес, алар бу очрашуда сине яклап калулары бик ихтимал, ләкин мин югында... мин югында нинди сүзләр буласын күз алдына китерү һич тә кыен түгел.

Ихтимал булган җәнҗаллар бәрабәренә минем белән килешергә тырышуың күңелне йомшарта төште. Ялганлавыңны күреп торган килеш, чынлап өзгәләнүең, нишләргә белми газаплануың күз алдында торганлыктан, бу алдашу миңа гөнаһсыз, матур алдашу, батыр алдашу сыман тоелды. Кичереш — хәрәкәтнең бер төре. Бу чаклы газаплана алгач, бәлки әле мин теләгән якка да борылырсың, үзгәрерсең? Рәтле, саф кешегә әйләнерсең? Кем белә?! Менә шушы фикер иде минем җиңелүемнең башы. Ә дәвамы: «Сине акылга буйсынмаган мәкерле

тойгы шаярта, ахрысы», — дигән фараз. Елларга сузылып гадәткә әйләнгән мөнәсәбәт кабатлау таләп итә. Күңел үткәнне тагын, тагын һава төсле сулап, тоеп карарга тырыша. Һәм моның иң көчле ярдәмчесе — вакыт күплеге, эшсезлек... Тәндәге һәр күзәнәк вакытны ычкындырмаска тырыша...

— Әйдә, киттек.

— Кая?

— Күпме торырга мөмкин?

Тукталыш якын иде, тиз килеп җиттек. Трамваймы, троллейбусмы туры килде дә утырып та киттек — синең өй ягына. Чыраем солых вәгъдә иткәндер, күрәсең, кеше арасында инде син кулыңны минем билгә ук куйдың. Гәрчә юл буе бер авыз сүз алмашмадык. Төшкәч тә авызга су кабып барылды. Өеңә килеп җиткәч кенә сәгатькә карап:

— Бик иртә бит әле, кич буе мин нишләрмен икән? — дип уфтандың.

Үзең генә калу, бигрәк тә кичке ялгызлык сине гел куркыта. Бүтән көн булса, мине тиз генә җибәрмәгән булыр идең. Ләкин бүген азмы-күпме газаплансаң да була. Син моның белән бәхәссез ризалаштың. Иртәгә безнең гыйльми совет — теләгән хәлдә дә очрашып булмас иде. Өй анализы ничек әйтер, анысы да билгесез, бүген исә шулай килештек — берсекөнгә хәтле.

Ә кичен кирәкме, юкмы, керләнгәнме, юкмы — барыбер, төнгә хәтле тирләп-пешеп, дөбер-шатыр син кер юачаксың...

Берничә көннән соң урамда без өчәү: Хәлим, син, мин — бергә туры килдек. Башта бернинди максатсыз йөрдек, кибетләргә кердек. Берсендә әйбәт коньяк туры килгәч, кирәге бер чыкмаса бер чыгар дип, Хәлим белән без, шуны алып, сумкага салдык. Шул ук кибетнең икенче бүлегендә синең күз төшкән вак-төяк ризыкка да күз ташладык. Аннары, инде аяклар үзләреннән-үзләре тиешле якка атладылар: тиз арада без Хәлимнең кунакларына әвереллек. Әмма юк-бар сүз белән ярты сәгать чамасы утырылдымы, Хәлимнең почтага барып кемгәдер телеграмма сугарга тиешлеге исенә төште дә, кунакларны ялгыз калдырып һәм үзе кайтканны сабыр гына көтүебезне үтенеп, китеп тә барды.

Бер өй эчендә яратышкан ике кеше калса, бу хактагы хәбәрләр дүрт стена арасыннан читкә чыга аламы? Бу хакта нәрсә булса сөйләү яки язу әхлакка сыямы? Белмим, белмим. Бары тик шунысын, гаҗәпләндергән ике нәрсәне генә телгә алам, берсе — кара сакал, икенчесе — коньяк...

Яныңа утырып, бераз кочаклашып торганнан соң, син минем аркаларымны, җилкәләремне, аннан исә, күзләремә туп-туры карап, иркәләнә-иркәләнә, битләремне сыйпадың. Рәхәтлеккә талып, күзләремне йоммадыммы икән әле. Мәгәр синең шул арада әйтелгән сүзләреннән алар бик тиз ачылдылар. Битемне сыйпауда дәвам итеп, шул ук ягымлы тавыш белән:

— Син сакал үстерергә җыенмыйсыңмы? — дип сорадың.

— Нишләп?

— Сакал сиңа килешер иде.

— Син минем кемгә дә булса охшавымны телисеңме?

Кыенсынып, елмайдың гына. Ул вакытта әле мин моңа ныклап дикъкать итмәгәнлектән, сүз шуннан соң бүтән таба борылды.

— Синең чәчең сары булса да, сакалың кара бит. Ә чәч белән сакал төрлелеге — нәсел гади түгел дигән сүз. Син — дворняшка түгел, выведенный...

— Овчарка.

— Һам-һам.

Бераз тагын шундыйрак юк-бар сөйләшеп утыргач, чират коньяк-

ка житте: бу өйдә булачак мәгънәле минутлар өчен эчкәч ничә генә минут үткәндер, син залдан чыгып йөгердең дә мин ишек аша синең укшыганыңны шәйләдем һәм кайчандыр синең бүтән кеше белән булган бүлмәне күз алдына китердем. «Моныcы әйбәт: әхлаксызлыктан табигатең баш тарта...»

Вакыт соң инде — саубуллашырга кирәктер. Эмма Хәлим дусның адымнары ишетелми генә бит, — кая куясың ачкычны һәм ярыймы өйне ташлап качу? — Кунаклардан без шулай тиз арада әсирләргә әйләндек. Утыра торгач, диванда син ойый да төштең бугай. Ләкин үзем барын да тоям: син минем күкрәккә башың куйдың да кичке яңгыр сымак тыныч кына, үткәзеп кенә озак-озак яшь түктең. Сине тынычландырырга, юатырга тырышу артык иде. Бу күз яшьләрендә тынлыкта очрашу шатлыгы һәм язмыш сүзе дә, минутлык ләззәт һәм мәңгелек җәрәхәт тә, аннан соңгы табышлар һәм югалтулар да, безнең танышу һәм аерылыша язулар да, ниһаять, бүгенге бәхет һәм киләчәктәге яшьле бәхәсләр, үкенечле, кайтарып була алмаслык татлы якынлыклар да — барысы, барысы үз мәгънәләрен, яшәешләрен тапканнардыр. Күз- галмыйча чәчләреңнән генә сыйпап тын торырга мине синең кичәге көнең һәм иртәгәге язмышың өчен кайгыру, кызгану әчесе һәм йомшаклыгың, дөньяга, тормышка, кешеләргә җиңел караганың өчен әйтеп аңлата алмаслык үпкә, йөрәкне сагыш кебек үк кыса торган әрнүле ачу бәхәсе мәҗбүр итте.

Күз яшьләреңә минем тын әрнүем дә кушылып ага иде, ахрысы: «Ела, бәгърем, ела. Елый аласың икән әле, димәк, күңелең кипмәгән. Хәлең әлегә начар ук түгел, өметең исән диген сүздер бу. Тик бер нәрсәдән куркам, елый алмый башларсың дип. Менә шунда инде сине беркем сөймәс, корыган агач кебек, өметсезлектән туган үз усаллыгыңнан үзең агуланып утырырсың. Ашыгырга, яшел килеш нгырга ашыгырга кирәк».

*

* *

Биш катлы корабль сыман, бер кварталга сузылган озын йорт — безнең фәнни институт. Вестибюльне узам да баскычтан югары күтәреләм. Икенче катта ак чырайлы, кап-кара чәчле, түгәрәк йөзле, яшь, чибәр кыз очрый.

Ул текәлебрәк караганлыктан:

— Сезгә кайсы бүлмә кирәк? — дип сорыйм.

Ә чибәр уйлап та тормыйча:

— Без ничек килешсәк, шулай! — дип көлә.

Ләкин мин аңа караганда алдарак борылам. Инде бүтән туры киленмәс дип уйласам да, шул ук төштә (ничә көн үткәчтер) шул ук кыз.

— Сезгә ничәнче кат кирәк? — дим тагын.

— Ничек килешербез бит!

Ә килешү мөмкин түгел, Гөлчәчәк, чөнки мин синең белән күрешкән инде... Күзләрем синнән башканы күрми, колакларым ишетми.

Бу кыз белән шушы кысан юлда, тар баскыч төбендә ел буе ничә кабат очрашканбыздыр, ләкин моңарчы, ул минем күзгә, мин аның күзенә күренмәгәнбез. Сине генә ярата башлаган идем, башкалар да күрә башлады. Дистәдән ашкан еллар буе беркем күрмәде — тыныч яшәдем. Ә хәзер...

Ләкин күп тә үтмәстән, син тагын күздән югалдың...

Ни булды? Бу ни диген сүз: уйламаган-нитмәгәндә, чирлә дә кит, имеш. Җитмәсә, үзебезнең шәһәрдә түгел — Яшел Үзән диген кечкенә чит калада. Син анда туганнарыңа кунакка киткән идең бугай. Суфия апаң, ашыгыч ярдәм машинасы белән алып киткәннәр, дип хәбәр итте миңа. Җай чыккач та барып җитәрмен.

«Яшел Үзән» сүзе чыкканга күрәме, сине ак япмаларга төренгән хәлдә түгел, ә биек үлән үскән, исемендәй матур гөлчәчәкләр чуарлаган җирдә дип күз алдына китерәм. Җир өсте дә ап-ак кар белән капланмаган, кар бөртекләре урынына — күбәләкләр...

Ерак аралардан син мине күрмисең, ишетмисең, шуның өстенә, мин тагы тавышымны югалттым. Инде бөтен ышаныч синең тоемлавыңа: хәзер минем ниләр сөйләргә тиешлегемне син белергә тиеш. Уйла, уйла һәм...

Һәм менә, инде син мине ишетә дә башладың!
Барысы, барысы да — күптән әйтеләсе сүзләр.
Барысы, барысы — чын йөрәктән.
Ә бүтәннәре? Тагын да җитдирәкләре?
Алары — соңрак.
Исән бул!

*
* *

Кадерле Аббам!

Минем өчен аеруча яғымлы булган рәсемеңне үзем белән алып өлгергәнмен. Белсәң икән, редикюльдән шушы кечкенә кәгазь килеп чыкканга шул чаклы сөендем, шул хәтле куандым, мин аны кулларымнан ычкындырмыйча, битләремә, яңакларыма куеп, синең назлы һәм көчле кулыңны тоеп, озак, озак уйланып яттым. Һәм, әлбәттә, мин сине ишеттем — сүзләреңне озак, бик озак тыңладым.

Хәзер син тыңла: мин сине шул дәрәҗәдә яратам, хәтта үзем өчен иң авыр булган, үлем белән кавышырга тырышкан минутларымда да күз алдымда синең сурәтең торды һәм хәзер дә бөтен фикерләрем сиңа тоташа.

Авырып ятканда вакыт күп, шул хәтле күп, аны кая куярга да белмәссең. Ә мин, күргәнеңчә, ул вакытны синең белән тутырам. Ләкин шулай да син — барыбер моң, сагыш дигән сүз. Минем бөтен барлыгымны билэгән, күкрәкне, үңәчләремне һаман катырак кыса барган тере сагышны кая куярга? Ул нишләп китми, таралмый, каян туктаусыз килә тора? Үзебез, әйтерсең, шундый камалган хәлдәбез. Кая да булса чыгар, котылыр җай бармы, кайда ул?

Чыннан да, кызык бит, безнең мөнәсәбәтләр киләчәктә нинди булыр? Без якын арада хушлашырбыз шикелле. Шулай тоела. Уйласаң, безне гөнаһсыз мәхәббәтебездән башка бер нәрсә дә бәйләми бит. Ә ихлас сөю беркайчан да хәерлегә китерми диләр. Ләкин бу мәхәббәт синең тормышыңда эзсез югалсын өчен без икәүләп тырышлык куярга тырышырбыз. Шулай бит?

Күпме каршылыклы тойгылар! Моңарчы беркайчан да мәхәббәт белән нәфрәт янәшә яши алмыйлар дип, болар тик матур (әгәр шулай әйтергә яраса) сүзләр генә дип йөри идем.

...Салкын көзге көн һаман узмый, юкка чыкмый!?

...Ә хәзер мин сине яратам һәм үзеңне шул хәтле дә яраттырган өчен күралмыйм. Һәм шул чаклы авыр! Әмма бернишләр хәлем юк, үземә һичничек ярдәм итә алмыйм. Мин бөтенләй беткән кеше. Һәм, ахрысы, инде һичкайчан да чынлап бәхетле була алмам, бөтен нәрсә ярты-лаш булыр яки бөтенләй булмас. Киләчәктә мине нилэр көткәнне уйлау да куркыныч, ихтимал, анда бүгенгедән дә яман бушлыктыр һәм бүтән берни юктыр? Сәбәбе шул: анда син булмаячаксың!

Сизгәнсеңдер, яшәү хакында башладым да, үлем турында тәгәллим. Чынлап әйткәндә, безнең хәл үзе шундый бит. Син — минем бәхетем, син — минем бәхетсезлегем. Фаҗигам — син. Бөтен нәрсә шул хәтле буталган, ялгыз түгел, икәүләп тә һичкайчан очына чыга алмабыз, һичкайчан. Бердәнбер юаныч — хисләребезнең суыначагына өметләнү.

Уйларыбыз, тойгыларыбыз, хәлебез буталчык булганга күрә сүзне

тәртипле, мәгънәле төзү кыенлашты. Ләкин үземне яклау нияте белән әйтелгән бу искәрмәсез дә син мине аңлар идең, дип уйлыйм.

Синең кайчандыр шигырь укыган кебек кенә әйткән: «Ерткалама язмышымны минем, сөюемне минем вакламa!» дигән сүзләреңне кабат-кабат күңелемнән кичерәм. Башта аларның мәгънәсен төшенмичә генә кабатласам, соңыннан, нишләптер, аларның нәкъ үземә төбәп әйтелгәнлеген уйлый башладым. Шунда инде үзебезнең бу танышлыкның гади уен янсә вакытны күңеллерәк уздырырга тырышу түгеллеген аңладым. Мин сине йөрәгемнең бөтен көче белән яраттым, шуңа күрә ул сүзләрең дә минем өчен изге булып һәм синең хакта уйлау, хәтерләү үзең юкта бердәнбер юанычым булып әверелде.

Сүзләрем йогыш килеп чыкмый, әйеме? Дулкынланам бугай. Күз алдымда һаман беренче танышкан көн бутала. Болай мин аны бик томанлы итеп күрәм — мин анда да авыру идем бит. Бары тик тупасрак сөйләшкәнем истә. Инде кайчан булган хәл, әле генә булган кебек үзе, бер карасаң, инде айлар түгел, еллар узгандыр шикелле. Шуннан соң нинди генә хәлләр булмады: үпкәләшү, бер-беребезне газаплау һәм чигенә чыга алмаслык мәхәббәт, мин гомер буе интегергә риза булган сәер мәхәббәт.

Тиздән яңа ел. Бу көннәрдә кешеләр бер-берсенә бәхет, иминлек телиләр. Мин дә теләкләрне әйтәм — бәхетләрең минем белән килсен. Тик нәрсәгәдер өметләнү, безнең хәлдә — салкын кыш икәнен белмичә, җылы өйдә елмаеп утырган яшел яфраклар хәлендә — бигрәк тә зур тилелек бит. Хәтта кызың Энҗе аңласа һәм кичерсә дә, син үзеңне һичкайчан гафу итә алмассың, һәрвакыт мине гаепләячәксең, мине шелтәләячәксең һәм, ниһаять, барыбер мәхәббәтнең азагы күренер... Юк, мин моның белән килешә алмыйм, әйдә минем бәхетемнең азагы җитсен, ләкин синең мәхәббәтең яшәргә тиеш, чөнки мәхәббәт бит үзе — яшәү дигән сүз. Бүтәнчә яшәүне күз алдына китерә алмыйм, теләмим.

Безнең очраша алмавыбыз ихтималы күңелгә килгән чакта, мин очрашырга тиешле булуыбыз, моның законлы хәл икәнлеген уйлыйм. Соң булса да синең өчен мин туганмын икән, табигать үзенең олы хатасын төзәткән, барыбер төзәтергә тиеш булган. Ә бу тормышта кем дә кем без белгән мәхәббәтен таба алмыйча китсә, ул кешене мин яшәмичә үлгән дип исәплим. Андыйларны үземә караганда да ныграк кызганам. Сине, дөресрәге, бер-беребезне табарга ярдәм иткән язмышка рәхмәт әйтәсе иде.

Исеңдәме, мин сине эссе итеп ратам дип көлә идем? Чынлап та көлке. Ләкин менә синең хакта уйласам да миңа чынлап та җылы һәм рәхәт. Хәзер уникенче ярты, тиздән — тәүлек азагы. Шунда минем ут сүнәчәк, гәрчә баштагы уй тиз генә сүнмәсә дә. Ә син бу вакытта төшләр күрә-күрә йоклыйсың микән? Кызганыч, төшеңдә мине күрмәсәң. Ә менә мин, йоклап киткәч тә, тагын сине күрәчәкмен — хәзерге кебек үк: күзләреңне һәм (иң гаҗәбе) кашларыңны акыртын-акыртын гына, йомшак кына, сак кына итеп сыйпыйм.

...Берничә көн узды. Әйтәсе килгән фикерләремне һаман төгәлли алганым юк. Вакыт җитми бугай. Яңа ел алды ыгы-зыгысы, шуңа өстәп өем-өем күңелсезлекләр, җитмәсә, бик зур үзләре. Ә барысын бергә җыйганда, безгә, мөгаен, аерылырга туры киләчәк.

*
*   *

Гөлчәчәк, исәнме!

Синең атап әйтергә базмаган күңелсезлекләреңне мин беләм.

— Мәхәббәт — гаепле, гөнаһлы эшмени? Җинаятьмени ул? — дисең син, нәрсәнедер төшенә алмыйча. — Без беркемнең бәхетенә кул

сузмыйбыз, ник безгә бәйләнәләр, кемнең нинди эше бар бездә? — дип сорыйсың, нindидер тәртипләр, нигездә көнләшүдән килеп чыга торган тарлыкларны кабул итәргә теләмичә. — Кемнәр, кемнәр алар? Шундый сәер адәмнәрнең күзләренә карыйсым килә — алар бер вакытта да яратып карамадылар микәнни? Кемнәр алар? — дип сорыйсың.

Гыйльми секретарь сине үз бүлмәсенә чакырып кертә.

— Кемдер югары оешмага шалтыраткан...

Сүзнең нәрсә хакында барачагын шунда ук сизеп, тагын да:

— Кемнәр алар? — дип кабатлыйсың.

— Исемсез кешеләр.

Әйе шул, исемсезләр белән бәхәсләшү җайсыз, көрәшү куркыныч. Тынычланмасаң да, тынасың, тыңлыйсың.

— Анда синең хакта... Һәм тагын бер иптәш фамилиясе телгә алынды.

Бу сүзләрне ишеткәч, нинди кыяфәткә кердең икән, Гөлчәчәк? Күзләреңне чытырдатып йомгансыңдыр, башыңны үңәчеңә терәп, куллары астына качмакчы булып бөрешкәнсеңдер. Тик барыбер кача алмыйсың шул.

— Зур скандал булуы мөмкин. Булмавы да ихтимал, әгәр дә без дөрес хәл итә, килешә алсак. Нәрсә дә булса эшләргә кирәк.

— Миңа бу шәһәрдән китәргә үк туры килер микәнни?

— Нишләп алай, шәһәрдән үк... Впрочем, күрше калада минем бер танышым бар — шушындый ук эшкә урнаштыруын сорый алам.

Уф, секретарь абыең явыз ук түгел икән — яхшылык белән сөйләшә белә. Әмма бер кабат аның телефон шалтыратуы буенча райбашкармадагы танышына баргач артык олы җиңүгә ирешмәгәнең кылт итеп кенә искә төшә дә:

— Мин бит бу юлы бигрәк тә берни югалтмыйм, — дип, киная ыргытканыңны сизми каласың.

Начальник абыең елмаймый, ишетми. Болай булгач, бүтәннәр белән дә киңәшми ярамас. Теләгеңне сизгәндәй, гыйльми секретарь телефон аша Суфия белән Сәлимә апаңны чакырып кертә.

— Син болай башта кешеләрдә әйбәт тәэсир калдырасың бит. Уйлабрак эш итәрсең, чит җирдә...

Монысы — Суфия апаң фикере. Сәлимә апаң шуны куәтләгәч, син инде әллә нишли алмыйсың:

— Ярый, гариза язам, алайса. Кайчаннан?

— Начальство белән кичә сөйләштек. Мин аларга гариза инде минем кулда дидем. — Секретарь абыең шулай ук йомшак тавышлы, бөтен кыяфәте кайгырту белән сугарылган.

Гаризаны язасың да ул секретарь сейфына барып керә.

— Хәзергә эшләп тор. Бүтән урын тапкач, яки китәм дигәндә, кул куярмын.

— Китү хакында тагын бер кеше белән киңәшәсем бар.

Иптәшләр елмаеша. Гөнаһларына кермик, алар хәерсез бу гариза һәм аның сәбәпләре хакында күп сүз таратмадылар. Мин синең үзеңнән генә ишеттем.

— Курыкма, сиңа берниндн зыян китермәдем мин, — дип башладың сүзеңне.

— Юк, курыкмыйм, һич тә.

— Эш сиңа барып җиткәнче, миңа китәргә кирәк. Бүтән шәһәргә — хәерлерәк.

— Мин — каршы. Урнашкан, ияләшкән, яраткан шәһәрдән шушындый гына сәбәп аркасында китү — җиңел уйлау дигән сүз. Эшкә бүтән җиргә урнашырга мөмкин. Бу калада бүтән химик-биологик лабораторияләр бетмәгән. Үз тормышыңны тәртипкә салу да ирешмәслек хыял түгел — яңа урында уйлабрак яшәрсең. Репутация хакында кайгыр-

тыбрак. Сине яратырлар, бераүне табарсың... Җиңел булмас, билгеле, ләкин синең кыләчәгең хакына мин үз җанымның барлык каршылыклы карышуларын җиңәрмен, чөнки мин сине чынлап яратам.

— Юк, юк, тиз түгел әле, — дидең син курыккандай, — мин ашыкмыйм, ким дигәндә, тагын бер ел синнән китмим әле.

— Ашыгырга кирәк.

Ләкин барысының без теләгәнчә барып чыгачагына ышаныч зур түгел, һәм аның сәбәпләре белән, кызганычка каршы, шактый еш очрашырга туры килә. Алар — хәтердә. Уйландырган сәбәпләрнең берсен безнең ишек төбендә вахтер булып эшләүче егетләр аңлата тора.

Без эштән кайтышлый баскычтан күп вакыт аерым төшәбез бит. Ләкин аерым төшсәк тә, күбрәк мин сине барыбер куып җитәм — вахтерлар янынннан аллы-артлы гына диярлек узабыз. Бер көнне вестибюльдә вахтер яныннан ерак та түгел Радик һәм тагы берничә таныш кеше басып тора иде. Вахтер — төскә карарак кына егет. Син шунда ачкыч калдырмакчы булып килгән идең — кинәт кулыңдагы ачкыч идәнгә шалтырап төште китте. Вахтер: «Нәрсә син, ни булды тагын?» — дип өзгәләнә. Мин дә ни булганын белмим бугай. Мөгаен, Радикны күрүдән каушагансыңдыр, дип уйлыйм. Әллә син артисткамы? Каушауны, алайса, менә дигән итеп башкардың — аңа ышанмау мөмкин түгел иде.

Гомумән, монда вахтер булып шактый егетләр эшли һәм алар гадирәк кызлар белән шаярырга яраталар. Сине дә шундыйлардан итеп тоялар. Ачуың килмәгәнгә җенем котыра.

Бервакыт вестибюльдә кем беләндер сөйләшеп тора идем, гөнаһ шомлыгына каршы син килеп кердең дә саргылт йөзле вахтер сиңа авыз ерып:

— Нишләп болай соңга калып йөрисең? — ди. — Кичә иртә киткән идең.

Синең урында бу урынсыз бәйләнүгә җавап итеп: «Сез үз бурычларыгызны аңлап җиткерәсезме?» — дип кенә сорарга кирәк тә бит, ә син:

— Хатыныңны болай ук тикшереп тормыйсыңдыр әле,— дип шаяртасың.

— Минем хатыным юк бит, так что...

«Так что» — кайбер нәрсәләргә өметләнергә мөмкин...

Икенче юлы без аерымрак төшеп килгәндә, төсе белән теге карарак вахтер тора иде. Анысы тагын, әрҗәдән киңрәк елмаеп:

— Ник болай озак утырдың? — дип сорады. Ә син әллә мин юк дип иркенәеп, әллә чынлап иркәләнеп, кәкре-бөкре тавыш белән:

— Менә хәзер китәм инде! — дип, отчет биреп көязләндең.

Ә егет үзеңнән дә женсирәк иркәлек белән:

— Китмә инде! — дип ялварды.

Тавышындагы: «Китмәсәң, төн — безнеке!» дигән мәгънәне ишетмәү артык кыен иде.

Үзем ирексездән шаһит булып чыккан бу уеннар инде кызыгын җуйганлыктан, сиңа кинәт минем каным катты.

Сиңа туры килгән җәзаның бер дә юкка түгеллеген төшендем. Үзең генә түгел, безне бергә иткән минутлар бәясен без бергәләп түли киләбез. Ләкин аерма: син миннән тиешсезен түләтәсең.

Шулай да кем арбасына дигәндәй утырганмын икән, ул бөтен көченә каядыр тәгәрәгән вакытта караңгы бушлыкка сикерә алмыйм бит. Сикерсәң, ни белән бетәсе билгесез. Аннары, болай да авыр чагың.

Ничек сине юлда ташлап китим? Мәхәббәт арбасы (заманча әйтсәк, мәхәббәт поезды буладыр) чаба, чаба, оча гына. Янныбызда — очраклы юлдашлар. Әйдә, аларның берсен сакаллы ир кеше, икенчесен хатын-кыз дип күз алдына китерик. Юлда вакытны ничек үткәрергә

мөмкин? Мәсәлән, чәй эчкәч, син кроссворд чишә башлап, бераздан барыбызны да шул шөгыльгә тартасың. Читләр белән дә тартынмыйча сөйләшерлек хәлгә киләбез. Ятар алдыннан без синең белән, әйтик, купе ишеге төбендәге тәрәзәдән карап барган чакта, эчке яктан хатын-кыз тавышы ишетеп сагаябыз:

— Юк, сез джентельмен була алмыйсыз. — Сакаллы адәмгә, очраклы юлдабышызга бәя бу...

Икенче көнне эш юклыктан өстәлгә карта чыга. Ничек утырсак, шулай пар булып: мин хатын-кыз белән, ә син сакаллы ир белән туры киләбез. Гади «дурак»лы уены. Җиңүләр, әлбәттә, алмашына тора. Сезгә бер булса да алтылык чәпәлгәч, көләбез. Синең белән уйнаучы сакаллының да алтылык белән җавап бирәсе килгәнне сизеп, мин ана ахырда алтылыкларны юри бирәм. Уен сез теләгәнчә булсын өчен ниндидер «мәгънә» белән ул сиңа күз кыса. Ә син? Син аның үзенчә үк җавап бирәсең — күз кысасың! Шул минуттан алып таныш түгел кеше сиңа «син» дип эндәшә башлый.

Уйнап бетергәч, мин купедан чыгам да сине дә чакырам. Бераз көткәч һәм син тиз чыкмагач, вагонның икенче башындагы буферга китәм. Ә үзебезнең якка кире килүемә — сез сакаллы кеше белән тәрәзә янында басып торасыз... Ниндидер ярамаган нәрсә күрәм... тик ышанмыйм күзләремә: ул синең биленә кулын куйган лабаса! Мин күренгәч тиз алса да, ләкин инде соң.

— Мин сине аңламыйм, — дип, купега кереп китәм.

Артымнан иярәсең һәм тиз генә бөкшәеп утырасың да:

— Мин ул хәтле нишләдем? — дип шыңшырга керешәсең.

— Син үзең әйбәтрәк беләсең, минемчә,—дим, тыныч булырга азапланып.

Бу вакытта кем дә булса бәлки яңакларыңа чалтлатырга тиеш табар иде, һәм ул хаклы булыр иде. Ә мин, болай да язмыш тарафыннан рәнҗетелгән дип, сине кызгана һәм тынлый бирәм:

— Мин берни эшләмәдем, сөйләшмәдем дә. Үзең чык дигәнгә генә чыккан идем.

— Ни өчендер мин киткәч чыктың? Кочаклашыр өчен?

— Ни сөйлисең син?! Каян килеп?

— Син булмасаң, ул...

— Ә ник, алайса, миңа әйтәсең? Кеше өчен мин җавап бирәммени.

Начар төш күрәм бугай: хаерсез поездан төшә, ычкына алмыйм. Күпме көннәрдән соң: «Нишләп җитмәде көчем?» дип сорыйм да, җавапсыз калам. Бер карасаң, уйга да кермәскә тиешле юньсез ваклык, ләкин ул, бәйләнчек чебен шикелле, төннәр буе биткә куна-куна, төн сәгатьләренең йокысын куа.

Ә поезд чаба бирә. Хатын белән ир-ат адәмнәр — төшеп кала. Без хәзер икәүдән икәү. Ләкин бәхетебез өстенә баягы алама хәл күләгәсе барыбер төшә. «Акыллым, бәгърем! Синең арттан кара сакал һаман иярә бара лабаса!» — дигән уй такылдый.

Синең элекке мәхәббәтең артыннан барып, вокзалда ялгыз басып торуыңа Радикның чакыруы өстәлә. Вахтер егетләр алдында кулыннан чылтырдап идәнгә ачкычың төшә һәм... кара сакал килеп чыга — кирәк хәтле кара нокта төшә безнең мәхәббәт аклыгына. Минә моны инде төзәлә алмый, хәзер бөтенләйгә нәрсәдер үзгәрде, малайларча беркатлылык өстенә, беренче кар төсендәге хисләргә корым яуды, кала урамы сыман ул хәзер — алалы-колалы. Күкрәктә гаҗәеп саф, якты сирпеп торучы ниндидер күзәнәкләр үлде, җанымның иң нечкә хисле күзәнәкләре мәңгелеккә, яңармас өчен юкка чыкты. Бүтән алар кабатланмас, яңармас, чөнки бит син — минем соңгы тукталышым, соңгы җырым!

Ләкин тукталышның исеме юк, ә җырның ертыгы бар шикелле...

Өстәл өстендә йөзем шәрабы, төнге ут, шәм рәвешле лампалар. Алар мисалында янган апельсиннар, алардан мең мәртәбә яктырак күкрәкләр... Шуларның барысын бергә җыйган музыка — электр гитарасы тавышы. Кичке караңгы дөньяда кемдер кемнедер эзли, кемдер кемнедер таба, кемдер кемнедер югалта, кемдер кайдадыр сагына, кемдер нәрсәгәдер өметләнә, кемдер кайдадыр өметен җуя, кемдер...

Юк, кемдер түгел, без үзебез... үзебез моңаябыз. Узган бәхетләрнең азагын тоеп, бүгенгесенең чиген күреп, киләчәк билгесезлегеннән аһ итәбез: иртәгә, иртәгә ни көтә безне? Ә поезд ашыга. Ник ашыга ул — аңа кайда да барыбер түгелмени?

Күзләргә яшь килә. Башым синең чәч арасына яшеренергә, качарга, күңелем синең рәхәт җилкәңне сулап ял алырга тырыша. Ә синең баш минем күкрәктә. Күз яшьләрең дә күкрәгемә, йөрәгемә тама...

Электронның җанны айкаган тавышы белән берләшеп, күз яшьләрең, сүзләрең җаныма тула. Чиләккә яңгыр җыелгандагы шикелле тулып түгелергә тора. Ә үзем сине юаткан булам, киләчәк көннәргә ышандырырга азапланам:

— Дөньяда яхшы кешеләр күп ул, менә яңа эшкә күчәрсең, яңа кешеләр белән танышырсың, яңа мәхәббәт табарсың...

Әмма үзең күбрәк ышандырасың:

— Мин әйбәт кешеләр беткәндер дип тә уйламыйм, үземне ярат тыра алмам дип тә курыкмыйм. Минем бөтен куркуым шул: бүтән болай ярата алмам мин. Бөтен ярату сәләте янып беткәндер дип куркам. Җанга ниндидер салкын тынычлык үрмәләвен инде хәзер үк сизгән төсле булам. Әгәр чынлап та шулай булып чыкса, гомер буе хатирәләр белән генә яшәргә кала. Бу уй үзе үк бөтен тәнне калтырата.

— Яшәү дәвам итә икән, мәхәббәт тә дәвам итә.

— Мин бит хәзер синең кебек кеше эзләрмен, ә ул син — үзең генә, син — берәү, икенчесен каян табыйм?

Өстәлдә шәрабсыз буш шешә һәм татлы җимешеннән аерылган апельсин кабыклары.

Урамда караңгы, ямансу вокзал.
Ары табан мин үзем генә китәргә тиеш.
Вагон ишеге төбендә хушлашабыз.
— Чак кына, чак кына, тагын чак кына...
Башың иягем астында калтырый.

Кулларыбыз аркалардан кысыша, иреннәр бер-берсен эзләп таба. Ләкин бу инде бәхетнең соңгы тиберченүе, аннан соң...

Яшьле күзләреңне, битләреңне сыйпыйм да кузгалам, вагонда үз урынымны табам. Ә син каршымда, тәрәзә янында басып торасың.

Күзләрең сөртелгән, озакламый бөтенләй кибәр. Ләкин карашың!.. Бу караш минем хәтердә мәңгегә калыр өчен шулай яратып та, китмәскә ялварып та, язмышка буйсынып һәм буйсынырга теләмичә дә газапланадыр...

Безнең уйларны сизгән поезд гадәтидән озаграк кузгалмый тора. Аякларың талгандыр инде. Ишарәләп китәргә кушам, ә синең хәрәкәтләр кискен: «Юк, юк!» Күңелдәге сурәтең тирәнрәк уелсын өчен юри шулай тордыңмы? Шушы сорауны тоепмы елмаеп куйдың?

Кузгалдык, син инде артка шуасың, кул болгыйсың. Мин дә.

Ераклашкач, ике кулыңны алгарак сузасың да нәрсәдер әйтәсең. «Китмә, китмә!» дип ялварасың бугай. Шул рәвешчә басып калдың хәтеремдә — гомергә, мәңгегә онытылмас өчен калдың.

Хәтердә кичке вокзал, күңелемдә син: ике кулыңны сузып, кемгәдер, нәрсә хакындадыр ялварып басып торасың. Тик шунысын гына ачык аера алмыйм — үзебезнең каладамы син, әллә бүтән шәһәрдәме? Төштәме, әллә өндәме?

Вокзалларнымы, кем беләндер үземнеме — мин һаман бутыйм бугай...

Кичке караңгыда син мине каршыларгамы, әллә кемнедер алып киткән поездның соңгы вагоннарынмы карап калыр өчен ашыгасың?

Кичке караңгыда, утлар яктылыгында, синең арттан кичке караңгылык төсле кара сакал ияреп бара... калмый.

Үзем хакында уйламыйм, юк, синең киләчәгеңне уйлыйм мин: ни булыр, алда нәрсә көтә, дөньяда һаман шушылай кичке вокзалдагы төсле каңгырып йөрмәссең бит?!

Йөрәк җавап таба белмәүдән сулкылдый.

Кара сакал. Аны, аны нишләтергә?!

*

* *

Хушлашканнан соң беренче өч көн: өстәлемдә — синең портретың. Син — минем кулда... Сагышлы караш. Портретыңа карамаган чакта да барыбер елмаясың, моңаясың, елыйсың. Битләремдә кулларың жылысы, иреннәремдә синең иреннәрең тәме. Дөньядагы барлык татлы әйберләр алар каршында көчләрен җуя.

Дүртенче, бишенче, алтынчы көннәр: портретың конверт эченә керде, конверт — тумбочкада. Сагынган саен аны конверттан алам да озак-озак текәлеп торам, бигрәк тә кич, йоклар алдыннан карап ятам.

Ә күңелгә күләгәләр үрмәли. Ничек килеп чыкты соң әле? Бәхет каплап торган вак бөҗәкләр кыштырдаша башлый — үрмәлиләр, кырыкмаса кырык аяклары белән жанда тырмашалар, күбәйгәннән-күбәя баралар. Ничек булды соң әле? Ничек?

Динле кеше аллага бары тик ышана, аны тикшерми. Тикшерә башласаң, аның барлыгына ышаныч кими. Ә мин тикшерәм, тере күзәнәкләр тикшерү гадәте мине диннән яздыра. Син, минем аллам, акрынакрын юкка чыгасың.

Хатирәләрең белән кушылып, бүлмәгә «Пинк Флойд» музыкасы тула. Тавышлар, стерео-эффектлар — колак моңарчы ишетмәгәнчә, күнегелмәгәнчә — өр-яңа. Колакның ишетү киңлеге арта. Бу тавышлар әле яшьләр арасында гына таралган, олылар дөньясына уза алмый әле ул, һаман көрәшә, мәйдан даулый, кычкыра...

Шартлы челтәрләр, тыю мәгънәсенә ирешкән сызыклар кеше хисләренә ихтирам арткан саен ватыла, кими, бетә тора. Әле кайчан гына синең кебек чибәр кыз үзенең гүзәллеген, битен каплаган пәрәнҗәяулыкны ачып ташлар өчен ачыргаланып көрәшкән? Ә синең территория мәгълүм чорлар белән чагыштырсаң, чамасыз киң. Әмма син шуңа да риза түгел, яңа иркенлекләр даулыйсың.

Белмим, яшәү мәйданнарын кешелек дәрәҗәсен рәнжетү исәбенә киңәйтү үзен аклый микән. Һич югы — бәхәсле дер бу. Сафлык белән Ирек мәңге бәхәсләшер, мәңге килешә алмас.

Синең яшәү рәвешең, Гөлчәчәк, мине мыскыл итә, мин аларга күнегә алмаячакмын. Моңа кадәр булганнарын чикне таптап чыккан өчен җәза рәвешендә кабул иттем. Ә арысына көчем җитмәячәк. Хәтереңдәме, бераз элегрәк син: «Әгәр мин башта ук сине очраткан булсам, узганнарым белән дә яхшы кеше булыр идем», дигән идең? Мин шуңа ышанып яшәдем. Тик, кызганыч, син ышанычлы, тотрыклы юлдаш була алмадың. Бәлки үзеңчә хаклыдырсың, шулай да мин дә үзем чә генә яши алам, үзгәрә алмыйм.

— Мин элеккечә түгел, синең белән очраша башлагач, мин бөтенләй бүтән, үзең дә сизәсеңдер, — дисеңме?

Бәлки сине үзгәртергә тырышу — үзе үк җинаятьтер? Дәвамлы тотрыксызлык — үзенә күрә бер тотрыклылык бит. Мәхәббәт хакында сайрамый дип, яшәү биләмәсен киңәйтү өчен генә сайрый дип, сандугачны сайраудан тыярга кем дә уйламый лабаса. Адәм баласының дөньяны күбрәк белергә омтылышын ничек тыясың? Телескоплар галәмгә һаман тирәнрәк үтеп, кешенең күрешен үткенәйтә, киңәйтә, озайта — аларны тыю дөресме? Төнге күкнең, галәмнең, табигатьнең караңгы почмакларына прожектор сыман көч, акыл һәм күз карашы һаман ераграк үтеп керә — яктылык көлтәләрен кулга җыйнап упкынга ыргытыйкмы? Кеше тойгылары үзе өчен яңа киңлекләр даулый икән, шуның барлык омтылыш-хәрәкәтләрен әхлаксызлык дип бәяли килик ме? Юк, булган җәзаны тыныч кына кабул иткәнсең икән, мин моны икенчерәк сыйфаттагы батырлык дип исәплим. Ә үзем, ахрысы, көчсезрәк булып чыктым...

— Син мине шушы авыр көннәрдә бер үземне калдырасың да, шуның өчен гафу үтенеп, вөҗданыңны тынычландырасың. Молодец, рәхмәт, — дисеңме?

— Мин сине ялгыз калдырырга җыенганым юк.

— Логикаң сизелми.

— Мин синең дустың булып калам. Ә мәхәббәтнең бүтәнен тап. Анда бәлки, ничек теләсәң, шулай булыр.

— Эх, җүләр син, җүләр син.

Карап карыйк, сыныйк, бәлки алай ук тиле дә түгелмендер. Эксперимент — бәхәстә иң оста арбитр. Без хәзер синең белән очрашырга тиеш түгел, репутация — өр-яңа, ныклы, шиксез. Булдымы?

*
* *

Нажар!

Шалтыратмыйсың да, үзең дә күренмисең...

Күңелгә салкын үрмәли — җыйналып бөтен сүзләрне, тойгыларны туңдыра. Түзә алмыйча, сүзсез генә ыңгырашам, ә син инде ишетмисең.

Син мине тиз онытырсың, мин дә онытырмын — бу шаулы шәһәр безне мәңгелеккә аера...

Коточкыч. Күз яшьләре. Алар да күңелдәге әрнеткеч бозны эретә алмый. Җан сызлый. Бүтәнчә түзә алмыйм. Яратам сине. Мин елыйм, ләкин син ишетмисең, күрмисең. Миңа беркайда да урын юк — нишлим мин хәзер, кая барыйм? Шушы зур, шаулы шәһәрдә нишләп мин ялгыз? Тик син генә мине коткара аласың. Коткар! Ташлама мине. Синсез яши алмыйм мин. Хат та яза алмыйм, күз яшьләре ирек бирми. Болай булуга мин ышанмыйм — бөтенесе шулай тиз үтте дәмени?

Бәхетле якты айлар белән хушлаштык та нинди хәерсез бушлыкка килеп кердек соң? Бер-бер көне шушы хәтле авыр, озын булгач, мин бу елны, бу озын гомерне ничек кичеп чыга алырмын?! Булдыра, түзә алмам.

Куркыныч көннәр. Уйларым шундый таркау — гаҗәпләнмә, күз яшьләре аша карыйм. Актык сүзләрем минем хакта, мәхәббәтемнең бәхетле мизгелләре һәм олы кайгым турында истәлек булып калсын, күңел шуны тели. Син инде күрергә теләсәң дә мине бүтән күрә алмассың, шунлыктан бөтенесен ачыктан-ачык әйтәм. Сүзем шул: ахрысы, безнең балабыз булыр. Мин аны ир бала булыр дип юрыйм, шулай булсын, дим. Ул булачак, чөнки моннан алда безнең өчен искиткеч матур ай булды бит. Ул да шундый ук матур, сокландыргыч булыр, ләкин син аны беркайчан күрмәячәксең, беркайчан аның хакында

ишетмәссең дә. Шундый вәгъдә бирәм. Мин синең тормышыңнан бик ерак китәчәкмен, шәһәрдән генә түгел. Сиңа нәрсә өчендер, дөресрәге, үзең өчен куркырга, газап чигәргә туры килмәс. Син бит үз эшең, дөресрәге, үз тынычлыгың өчен һәрвакыт калтырап яшәдең. Синең иминлегең өчен мин үземне корбан итәм һәм шул җитәдер дип беләм.

Элегрәк сүзләремне уйлап әйтергә тырыша идем, ә хәзер болай эшләргә туры килми, бөтенесе шулкадәр күп җыйналды, хәтта кайсына тотынырга белмим — үзем хакындамы, әллә икебез турындамы?

Исеңдәме, безне әле мәхәббәтебезнең иң башында ук аера язган, искә алырга да курыккан бер көн хакында мин сиңа сөйләгән идем? Бүген дөресен әйтәм, чөнки хәзер ни уйласаң да барыбер. Мин бит сине шул чакта ук ярата идем, ләкин ул вакытта моңа үзем ышанып бетми идем. Ышангач, бу минем өчен әллә нинди тетрәндергеч хәл булды.

Теге көнне бармадым дип, баш тарта башласам да, шулай да мин вокзалда барыбер булдым бит, ләкин поезд инде кузгалып киткәч. Мин тик соңгы вагоннарны гына күреп калдым һәм бу хәлне яхшы галәмәткә юрадым, чөнки күңел шундый тыныч иде, күңелдә син идең. Моңарчы бит мин аның хакында, үзем өчен күптән чит булган алама кеше хакында уйлаудан котыла алмый йөрдем. Котылырга син, синең яратуың ярдәм итте. Мин синең белән моңарчы һичкайчан булмаганча бәхетле булдым. Син мине үпкән чакта һуштан язардай булып иреннәреңне эзләдем, күзләреңне, кашларыңны сыйпадым. Мондый якынлыкны, мондый бәхетне үз гомеремдә беренче татуым иде. Бәлки бүтән болай булмас та. Йөрәк урыныннан куба да каядыр төшеп китә... Һәм чынлап та бу кабатланмас микәнни?

Гүя син мине чынлап та ишетеп, тыңлап торасың: шулкадәр ашыгам, сүзләр шул чаклы күп җыйналган, кайсын да булса әйтми калырмын дип куркам. Барысын әйтеп өлгерә алмам да, ахрысы, ләкин син мине барыбер ишетерсең, аңларсың. Моңа хәтле аңлый идең бит. Шулай да кызганыч, аерылышуыбыз шул чаклы мәгънәсез, кечкенә нәрсәләр аркасында. Ләкин, тегеләйме, болаймы, бу хәл барыбер килеп чыгарга тиеш иде шул.

Бер-ике көннән соң мин каядыр китәм. Кая икәнен әлегә белмим. Ләкин ничек булса да еракка китәрмен дип уйлыйм, нәрсәгә булса да өмет калмасын өчен. Чөнки мин бит: без бергә ук була алырбыз дигән нәрсәгә һәрвакыт өмет саклап яшәдем. Өметне югалту шулкадәр авыр, шул кадәр!

Иртәгә, мөгаен, миңа шалтыратасың килер, ләкин син моны эшләмәячәксең. Телефон шалтырамаса, икебез өчен дә хәерлерәк булачак. Мин моны беләм. Синең дә минем белән хушлашуыңны беләм. Дөрес эшлисең. Ләкин сиңа мине барыбер искә төшерергә, чөнки миңа шушы җырны ишетергә туры киләчәк.

> Күңел тынды, дөнья буш калды,
> Ташландык өй, җимерек өй сыман.
> Йөрәк бөреше — әче төтендәй
> Каплый күзне сагыш һәм томан.
>
> Сукмагымны ник син югалттың?
> Шушы бөркү караңгылыкта,
> Ябышып мин сынган ботакка,
> Нишләп карыйм син киткән якка?

Бу җыр минем барып чыкмаган тормышыма бик охшаш. Хәтергә ул шуңа күрә килгәндер дә.

Ә хәзер хушлашам бугай. Соңгы тапкыр синең иреннәреңә кагыласым, күкрәгеңә сыенасым һәм шулай оеп, югалып каласым, кулларың җылысын, кочагың кайнарлыгын соңгы тапкыр тоясым килгән иде, бу

теләгем коточкыч көчле иде. Әйтә алмыйм әле, мин синнән башка яши алырмын микән? Ләкин тырышып карыйм.

Шулкадәр йөрәк сызлый, аңлата торган түгел. Нишләп болай килеп чыкты соң әле? Моннан берничә көн генә бөтенесе әйбәт иде ләбаса.

Миңа инде безнең буласы улыбыз хакына гына яшисе кала. Аны харап итмәскә тырышырмын. Сиңа булган бөтен сөюемне аңа бирермен, аны яратырмын.

Сау бул.

Сине үбәм.

Яратам. Хуш.

*

* *

Абба!

Соңгы ике-өч көндә үзгәреш килеп чыкты. Ике-өч көн элек уйлаганнарым коточкыч төш сыман тоела. Ләкин төш шул гына: безнең балабыз булу өмете акланмады.

Ләкин белмим, аклана калса, мин мондый җаваплылыкны үзем генә күтәрә алыр идемме икән? Синең өчен, аның өчен һәм үзем өчен дә булган җаваплылыкны минем көчсез гәүдәм күтәрә алыр идеме? Һич башыма сыймый.

Бүген урамда кайтып баруыңны күргәч һәм син исәнләшкән кебек булгач та күңел хәлсезлеге үтмәде. Апатия. Ешаеп киткән аңлашылмаучанлыклар безне барыбер аерылышуга якынайткан икән.

Гаризага бүген виза салдылар! Обходной кәгазьгә дә куллар куйдырып бетергәч, шул килеш саубуллашмакчы идем, тик гыйльми секретарь монысын килештермәде — бүлмәдәшләр җыелып чәй булса да эчик инде дигәч, мин буфетка төшеп конфет, печенье кебек ризыклар алып мендем. Чәй кайнады. Зур бүлмәдәге бер өстәлгә биш кеше җыйналдык.

Яңа урында миңа уңыш, бәхет теләүләр, әлбәттә, булды, ләкин, гаҗәпкә каршы, минем хакта сөйләүгә караганда, күбрәк синең турыда сөйләделәр.

Минем өчен шатлыкка сәбәпләр күп түгел, һәм кыяфәт, чырай да шуңа тәңгәл килгәндер. Аларга кушылып сөйләшә, көлә алмый интеккәндә, телефон шалтырады да үземнең якка бәреләсугыла чаптым. Ялгышмадым — син идең. Болай хәлләремне генә сораштың. Очрашулар хакында ым да юк. Әмма күңел күтәрелергә тавышыңны ишетү җитә калды. Болар ягына тыела алмыйча елмаеп чыккач, кинәт үзгәреш аларга сәер тоелды, ахрысы.

— Аңлашыла, — дип куйды Суфия апа.

Һәм сүз тагын сиңа күчте. Гыйльми секретарь шунда:

— Нинди әйбәт кызны харап итте! — дип куйган иде, мин сискәнеп киттем:

— Ничек «харап итте»?

— Ну, эштән китүең аның аркасында бит.

— Ә-ә. Бәлки шулай хәерлерәктер.

— Сиңа заводта бәлки мөстәкыйль эш бирерләр — сәләтең ныклап ачылырлык. Мин ышанам, син анда тиз өйрәнерсең. Ә кабат кайтасың килсә, пожалуйста. Тилелекләреңне онытсаң, бу эшләреңнән арынсаң иртәгә үк сине каршыларга әзербез.

— Рәхмәт, сезнең кебек үк саф булачакмын.

— Эшткән киткән кешегә һич тә охшамагансың, шул кадәр бойкая, — дип куя Сәлимә апа.

Ә чәй тәмле, чөнки аңа синең хактагы уй кушылган. Секретарь абый сүзләре дә аның татлылыгын киметерлек түгел:

— Анда үзеңнең Аббаңа әйт, сине югалтуыбызны кичерсеннәр дисә, бәхилләшергә бер шешә коньяк белән керсен.

— Юк, бу югалтуга бер генә шешә җитми, бер әрҗә кирәк булачак, — дип көлде безнең белән эшләүче икенче бер ир кеше.

— Сезне алкоголик ясатыр хәлем юк, көтмәгез, бер сүз дә әйтмим, — дип көлдем.

Шушындый юк-бар белән күпмедер гомерне калдырып киттем. Алдагысы, хәтта иртәге көннең нинди буласы ук билгесез. Башта һаман бер уй: «Ни өчен? Ни өчен?»

Ә үзем әле елмаям...

*
* *

Кадерле кешем! Абба!

Теләкләреңә, тәкъдимнәреңә, аларның чынлыгына күңелем белән ышанып җитмәсәм дә, дөньяга, тормышка күз йомарга тырышмыйм мин. Күзгә чалынучы кешеләр дә булгаламый түгел шикелле. Очрашмый башлагач килгән беренче бәйрәмдә туганнарыма кунакка баргач, алар, кайсысы беләндер таныша алыр дип өметләнеп, ахрысы, кичәгә шактый гына егетләр чакырганнар иде. Пианинода уйнадым, зал бетереп тыелгысыз чегән биюен биедем — барлык күзләрнең үземә текәлгәнен тойдым. Танцыга чакыручыларга карышмыйча чыга тордым. Тик күзләрем берсенә дә без уйлаган мәгънәдә карый алмадылар. Танцы вакытындагы якынлашу да күңелгә тия — теге коньяк исе сыманрак...

Тулай торагыбызда үзгәреш: Асия исемле дус кызым кияүгә чыкты. Яңа Кузнецк шәһәреннән кайткан шахтер егет белән танышып, бер атна эчендә Загска гариза илттеләр дә, вакыт җитмәү аркасында, блат буенча язылышып та кайттылар. Егерме дүрт яшендә егетнең чәче коелган. Тасмалы автомобильләр күренгәч йөрәгем дертләп китә торган кеше, иң якын дустым бәхетеннән көнләшә алмадым.

Туйда тагын биедек, җырладык, көлдек, ләкин истә — һаман син.

Соңыннан әйтүләренчә, миңа шунда бер егет игътибар иткән икән. Асияне озатырга аэропортка баруымны белгәч, ул да килгән һәм Асия:

— Чиратта син хәзер, кара аны, — дигәч, яныма шушы егетне дәшеп китерде. — Танышыгыз әле, я.

Көлгән була Асия, шаярган була.

Мин аның шаянлыгына иярәм дә, танышырга кул сузган кебек итеп, Асия кулындагы чәчәкне сыйпыйм. Егетнең кулы һавада асылынып кала.

Егетнең исеме Ришат иде.

Күңелем аңа төшмәсә дә, миннән бизгәнең өчен җәза булмасмы, котыртмасмы дип, ул егетне кумадым. Егетнең сиңа бөтенләй охшамаган булуы да аралашуның өзелмәвенә сәбәп булды. Ул, әлеге дә баягы, әрсезләр нәселеннән. Мәхәббәтен дә шулайрак игълан итте: «Мине күргәч, читкә борыласың килмиме? Әйбәт, димәк, без бергә була алабыз. Сиңа да вакыт, миңа да. Союз?»

Тәкъдиме сорау хәлендә калган килеш тә өмет җуймады. Синең нинди караштагы икәнеңне сорашып белгәч исә, бигрәк тә еш күренә башлады. Хәтта үзең белән дә танышып өлгергән икән...

Троллейбуста Ришат миңа артык елышканга түзә алмыйча (имеш, җәяү барсак, сөйләшү уңайрак — әйбәт сылтау), беренче тукталышта ук төштек. Синең белән без генә белгән тын урамнан киттек — киң, тыныч урамнан. Янымнан баручыны син дип, онытылып, кайчак чит кешегә елышканым өчен оялып куя идем.

Синең белән минем өчен генә салынган трассаның уртасына җитәрәк, таныш маэмай килеп чыкты. Аның туп-туры безгә килүеннән сагаеп, Ришат туктап калган иде, мин аны җитәкләдем, хәтта:

— Курыкма! — дип куйдым.

«Егет кеше, хәзер каушап кара!»

Эт минем өскә аякларын ук күтәргәч, Ришатны күреп иләмсез ырлап куйды. Менә шунда Ришат егет булып кала алмады —барыбер кинәт читкә тайпылды. Бу очракка нинди бәя бирергә белмичә, һаман аптыраудамын. Бер уйласаң, егет куркаклыгы кыз кешене рәнҗетә, икенчедән, аны якларлык сәбәп бар — этнең безгә иялашкән, инде таныш ук икәнен ул белми бит.

Маэмай артыннан йөгерешеп килгән малайлар да аптырап калдылар, Ришатка гаҗәпләнеп, танырга тырышып карадылар һәм аның син булмавын минем сиңа хыянәтем дип кабул иттеләр дә усаллаша-усаллаша китеп бардылар:

— Икенче юлы без аларга Ярусны өстерәбез.

— Һи-һи-һи!

— Фас, Ярус, фас!

Эт аптырап тора. Ләкин кая, кемгә «фас» икәнен аңламый һәм малайлар да хәзергә аны конкретлаштырмыйча, ары йөгерәләр.

Алар киткәннән соң бүтән беркем дә очрамаячагын тоеп, син мине күтәреп ала торган идең. Хәзер дә, ахрысы, шуны көтәм, ә Ришат моны башына да китерми...

Әйтә алмыйм: әгәр ул мине күтәреп китсә, аны син дип кабул итәр һәм карышмас идем микән? Аннан соң инде эшнең ничек буласы томанлы. Үзең гаепле, Абба дустым, үзең!

Үкенерсең, соң булыр.

Үзебезнең урамга чыгар алдыннан сиңа беренче көннән үк таныш булган караңгырак почмакта тукталдык. Синең кебек булмаса да, Ришат та чак кына кочаклау галәмәте сиздергән иде, шуннан да файдаланып:

— Ярамый, минем монда егетем тора, күрсә сугышырга керешәчәк, — дидем.

— Егетең? Нинди егет?

— Менә инде. Үзеңә хәтле беркем белән дә таныш булмагандыр дип уйлыйсыңмы?

— Юк синең бүтән.. Абба гына бар.

— Нажар? Без бит аның белән болай гына дус, ул просто минем киңәшчем.

— Моңа ышаныр өчен круглый идиот булырга кирәк.

— Ни сөйлисең син, Ришат! Безнең арада — бары тик тойгылар гына бит. Бүтән берни юк.

— Монысына ышанам, ул артык тәрбияле кеше, герметичный. Бәхетсезлеге дә шунда.

— Ул сиңа бәхетсез сыман тоелдымыни?

— Күзләре соң... Яшь атылып чыгарга тора лабаса.

Җайсыз хәл, Ришаттан нәрсәне дә булса яшерү кыен, ахрысы.

— Ну, син мине вряд ли ярата алырсың. Монысы да каты сизелә,— диде ул.

— Менә сынагыз инде, алайса, сәләтегезне.

Мин дә синең эздән, турыга киттем бит, Нажар, хәерле булсын. Түзмәсә китсен дигән, котыласым килү теләге көч бирде микән? Тиз арада капланып төшмәүнең тылсымлы нәрсә икәне дә беренче кат шунда сизелде. Беренче кыенлыклар егетне куркытмады гына түгел, аны үчектерде булса кирәк. Чөнки ул минем янга килүдән туктамады. Ә син исә күзгә бөтенләй күренмәс булдың.

Әйе, моннан соң тыныч яшәрсең — рәхәтләнеп эшләрсең, үзеңнен

иң олы мәхәббәтеңнән — үле һәм тере күзәнәкләрдән — яшәү сереннән — сине беркем дә аермас хәзер. Сиңа үч итеп теге чакта икәүләп сайлаган маршрут буенча Ришат белән атлауда дәвам итәбез. Беркөнне хәтта синең белән икебез генә белгән кафега кердек. Киемне алып торучы апа да, официантка да, гаҗәпләнеп хәтта рәнҗеп карадылар. Бу карашлардан мин үземне карак итеп тойдым, оялдым, кызардым.

Мондый да буталчык хәлдә калганымны хәтерләмим. Син мине утка салдың, Абба, инде күңелемә су сип!

*
* *

Бөтенесе хәерлегә булыр, Гөлчәчәк.

Кайбер галәмәтләр инде шул хакта сөйли.

Моңарчы минем янга еш керә идең, хәзер сирәкләдең. Моңарчы миңа көненә биш тапкыр шалтыратып, бергә эшләгән иптәшләремнең сукрануына дучар була идең: «Һич маза бирмәде бу сиңа!» диләр иде. Хәзер атнасына бер шалтыратасың. Анда да озак сөйләшүләр кабатланмый. Эшләгән җиреңнән сөйләшкәндә, кем аркасындадыр, кычкырып көлүләрең ишетелә. Син бит кәеф кешесе — язгы көн. Кояшың, күкрәвең, яңгырларың мул була да тиз алмашына. Тыныч җәй ерак түгелдер инде, ул Ришат белән икегезгә атап килер, минем өчен килмәс.

Шулай да, сезнең белән гомерлеккә саубуллаштым дип йөргән көннәрнең берсендә Ришат минем янга килгән иде, юк кына бәхәстә җиңелеп өч шешә йөзем шәрабы оттырды да мине ресторанга чакырды. Мин вәгъдә бирсәм дә көнен онытkan булып чыктым.

Лабораториядә артыграк мавыгып, агудан исән калган күгәрчен бавыры күзәнәкләрен карап утыра идем, яныма Фәнүзә килеп:

— Анда сине сорыйлар, — диде.

— Кайда?

— Коридорда. Үзләре керергә кыенсына.

Чит кешеләрнең монда кереп йөрүләре мөмкин кадәр тыелган нәрсә — берәрсе аларга шулай әйткәндер. Коридорга үзем чыктым. Карасам, син — Гөлчәчәк, ә янында Тәнзилә атлы кыз белән Ришат.

— Ә нәрсә, бик әйбәт, — дип, чынлап шатланам. — Менә ачкыч — минем кабинетта бераз сөйләшеп утырыгыз. Кара сакал әйткәндәй — кич — сезнеке. — Син тагы үпкәләп ирennәреңне бүлтәйтәсең.

Пробиркаларны тиешле язулар белән урнаштыргач, өстәлләрне җыештырып, центрифуганы ычкындырдым да (боларның бөтенесе күп дигәндә ун-унбиш минут вакыт алгандыр) Фәнүзәнең сәер карашын абайлап, туктап калдым. Ул нәрсәдер әйтергә җыена иде шикелле.

Соңгы көннәрдә безнең аралар җылына төште. Сәбәпнең башы авылдан килгән хат иде. Өйдән үзе китергән конвертны кулыма тоттырды да «нәрсә язганнар?» дигәнрәк сорау белән тукталып калды Фәнүзә. Хәбәр күңелле иде: җәй көне кайтып сөйләшүләремнең кайтавазы буларак, безнең районда үле елганы — Тымызыкны терелтү өчен яшьләр махсус комиссия оештырганнар.

Дулкынланып хатны Фәнүзәгә суздым. Укып чыккач, аның да күзләре балкып китте:

— Котлыйм, молодец!

— Рәхмәт.

— Болай булгач, өмет тә терелә түгелме соң? Көрәшне өр-яңадан башлыйбыз, шулай бит?

Уянып киткәндәй булдым. Димәк, ул безнең эшне гел уртак дип исәпләгән, хәзер дә көрәшнең дәвам итәчәген тоя һәм минем янда бу-

лырга әзер. Димәк, теге вакытта хыянәт булмаган, һәм мин кайбер нәтиҗәләрне дөрес ясамаган булып чыгаммы?

Беркемнән курыкмыйча, үзенең яшьлеге белән бәхәскә керүе элекке мәхәббәт белән ара өзү өчен генә кирәк булган түгелме соң? Чынлап та, хәзер Вәкил белән бернинди мөнәсәбәт, хәбәрләшү юк лабаса. Ярты ел аерым яшәп, кемгә дә булса елмаю кадәресе дә сизелмәде. Киресенчә, тагы да катгыйләшә төште. Эш-мәнфәгатьләре беткәч, элек мөдир булган гыйльми секретарь белән хәтта сөйләшми ук башлады. Кайда соң монда хыянәт? Тәрәзәгә таш аткан малайлар? Минем иң ышанычлы дусларым! Без ашыктык, без ялгыштык бугай лабаса!

Фәнүзә минем Гөлчәчәк белән аралашуымны белеп, күреп торды. Мин дә үзем теләгәнне дөнья яктысында, курыкмыйча эшләдем. Фәнүзәнең рәнҗүләре чыраена сары булып коелса да, юк, ул үпкә сиздерергә мөмкин дип тапмады. Башта моны яратмау галәмәте дисәм, хәзер икенче уй: минем киңәйгән территориям шулай законлы төскә керде — аны минем хатыным таныды...

Фәнүзә күзләреннән мин менә шушындый фикерләр укыдым. Шулай да инде вәгъдә бирелгән һәм мине көтәләр. Иртәгә хәтле хушлашып, югарыга, кабинетка менеп киттем. Яңа хәлдә үземне ничек тотармын? Анда — син, Гөлчәчәк!

Хәтәр экспериментка тотындык — күзәнәкләрнең агулымы, түгелме икәнен тикшерү генә түгел бу. Хисләр агулымы, түгелме — менә нәрсәне белергә туры киләчәк, ә моны тикшерү өчен төгәл приборлар хакында сүз йөртмәстән, аларның бөтенләй юклыгын әйтергә туры килә. Башка махсус белгечләрне әйтмим, үземне генә күздә тотам, әлбәттә.

Түрә булып өстәл артында утырырга тиеш тапмыйча, дивар буйлата тезелгән урындыкларның берсенә, син утырган якка (арада берике урындык калдырып) урнаштым. Каршыда — Тәнзилә белән Ришат.

— Я, ничек хәлләр? — дип сораштырган буласың. — Ничек яшәп ятасыз?

Молодец, Гөлчәчәк! Валлаһи син миңа караганда мең кабат зирәгрәк. Нишләп соң син нибарысы кече гыйльми сотрудник? Монда ниндидер хаксызлык бар, билгеле.

— Рәхмәт. Безнең бер көй. Сездә ниләр? — дигән булам.
— Безнең дә болай — тәртип.
— Ә сезнең, Ришат?
Егет тыныч кына:
— Зыянсыз, — дип куя.

Бу егет миңа инде шактый таныш. Горбунов берләшмәсендә эшли. КАИ бетергән. Тумышы — авылныкы да, шәһәрнеке үк тә түгел. Бар җәһәттән, Гөлчәчәк, сиңа бик туры килә: тәрбия, уку, биография, яшәү кагыйдәләре — дискотекалар, шәраблы кичәләр, очрашу һәм ташлашулар һ. б. һ. б. Шулай утыз елы узганны сизми дә калган. Хәзер өйләнергә йөри — рәхим ит, Гөлчәчәк!

Тышкы кыяфәте белән шулай: гөнаһсыз караш, тыныч, кара күзләр — мишәр егете дә димәссең. Тик теле генә үзен бераз фаш итә — авазлар әдәби түгел... Теләк булса, әдәпкә, шул җөмләдән тел әдәбенә дә өйрәнә торырсыз. Яшәү дигәннән, менә мин үзем дә шушы көнгәчә яши белмәүчеләрнең иң беренче категориясеннән булып калам бит. Ярый әле исән йөрим! «Бер хәйләсез яшәп, ничек шушы көнгә килеп җиттең!» дип син гәрчә гаҗәпләнсәң дә, Сент-Экзюпериның бәләкәй принцы: «Гел турыга барсаң, ерак китә алмассың», — дип кисәтүгә дә карамастан, сукмагымны үзгәртә алганым юк, нишләтәсең.

Соңгы вакытта көннәремә ялган катнаша башлаганга күрә генә килде бу хәерсез әңгәмәләр. Бүген дәвам иткән комедиянең авторы

мин бугай. Безнең арада, гомумән, һич тә роман түгел, фельетон килеп чыкты...

Сүз эшләрнең ничек барышыннан «буш вакытның» ничек узуына күчә. Ришатныкы, безнекенә караганда, баерак төсле. Институт кичәләреннән аерылып бетмәгән, завод тормышына да ияләшеп өлгергән. Шул ук вакытта, Гөлчәчәк, ул синең принцип белән: «Хочу растратить себя всего, без остатка!» дип яшәгән кешеләрнең берсе. Менә ичмасам тапкансың үз ишеңне — берегезгә дә үпкәләр урын булмаячак! Шуның нәкъ үзен раслап, безнең алфавитта билгесе булмаган калын «г» авазын үзенчә нечкәртеп:

— Мин сезне базарга чакыра алам, — ди Ришат.

— Базарга? Анысы ни?

Егет көлеп куя:

— Мәхәббәт базары.

Мин тагын шаярырга җай эзлим:

— Кызык, я, анда күпме тора мәхәббәт? Бәясе бик түбән түгелме?

— Киресенчә, бик биек. — Ни өчендер, «югары» түгел. — Дефицит, надо сказать.

— Анда да блат?

— Пожалуй. Ну, алай да булмасын. Ну, чын хисләр хәзер аерым бер элитага гына хас.

— Без, алайса, шул элитага керәбез инде, ә? Гөлчәчәк, син ничек карыйсың?

— Базарның үзен күреп карамыйча әйтү кыен бит, — диден син, шаян сүзгә катнашып.

— Без аны карыйбыз, әлбәттә, барабыз — чакыра бит Ришат.

— Чакырам. Беренче базарга ук. Башта белешергә туры килер, кайчан булырын.

Шушы минутта мин, ни өчендер, Ришатны да сакаллы, кара сакаллы итеп күрдем... Сакал аңа килешәчәк. Тора бара, әгәр дә мәгәр Гөлчәчәк белән дуслаша калса, сакал йөртә башлаячак ул. Миннән булмады. Ә Ришатның холкы моңа рөхсәт итәр шикелле.

— Ярый, килештек, туганнар — базарга без барабыз. Ә хәзер, Ришат, тыйнак булмаган бер сорау: сезнең сакал йөрткәнегез бармы?

— Гафу итегез, монда... как сказать, сакалның ни катнашы бар?

Каушап калырга ярамый, югыйсә, шаярудан узып кешене рәнҗетү була, ихласрак кыланырга тырышып елмай да дәвам ит, Нажар.

— Безнең бер танылган галим апабыз: «Сакалы, мыегы булмаса, мин кешене иргә чутламыйм аны», ди.

— Үзегезнең сакалыгыз да, мыегыгыз да юк ич. — Монысы синең сүзләр иде, Гөлчәчәк.

Син нәрсә, миңа каршы сөйләшә башладыңмыни инде? Димәктән, шулай дөресрәктер дә ул — күчә башла, үзгәрә башла!

— Мин, димәк, чын ук түгелдер инде. Сезнең затка билгелерәктер анысы, — дип елмаерга тырышам да Ришатка борылам. — Сакал сезгә килешәчәк — кара, җете кара сакал. Гөлчәчәкне гашыйк итәсегез килсә, тиз арада сакал җибәрергә киңәш итәм сезгә.

— Бәлки ул болай да гашыйк булгандыр?

«Оһо! Егет син көткәннән дә кыюрак бит!»

Йөрәккә эләккән беренче йодрыктан соң чыраем җимерелгәндер, мөгаен, син тиз үк эшне төзәтергә тиеш табып:

— Әйдәгез, тойгыларга бүген кагылмыйк! — диден.

Күзләрең шактый җитди караганлыктан, мин тындым. Егет тә сагаерга мәҗбүр иде шикелле.

Сөйләшмичә диярлек, кәгазь, газета актарган булыбрак шактый вакыт уздырдык.

Тышта инде — караңгы. Бозлы тәрәзә аша ай интегеп карый. Ул

да ниндидер күңелсез нәрсә, буталчык хәл сизеп, безне кызгана сыман. Ришат кына тыныч: өметләре, теләкләре — бөтен, йөзе — ак.

Бүлмәдән чыгышлый, кинәт мине тагын алама хисләр әләктереп алды: «Кая барып чыгарбыз?» Барысы да шушы бүлмәдә калсын, иярмәсен иде.

Чыктык. Урамда боз кристаллары безнең кәефләр сыман шыгырдап тетелә. Аяк баскан саен, баскан саен җир сызлый, ыңгыраша. Йөрәкләр шыңшуын ишеттермәс өчен, табигать юри шулай эшли — рәхмәт әйтик, ләкин эчтән генә: Ришат ишетә күрмәсен.

Һәм оттырган шәрабны түләсен.

Сүзләр ресторанда да интегебрәк ялгады. Урыныбыз эстрада төбенә туры килгәнлектән, музыка яңгырый башлагач, нишләрбез дигәнрәк темага, аннары кемдә нинди пластинкалар бар, шул хакта, аннары хәтта һава хәлләре хакында әңгәмә коруга хәтле барып җиттек. Официантка килеп, ашамлыктан тик бер генә нәрсә — гуляш кына булуын ишеткәч, ресторанның фәкыйрьлеге хакында зар башланды. Шәрабның да кызларга тәкъдим итәрлеге табылмагач, официантка:

— Кызлар өчен әйбәт коньяк бар, — дигән иде, син котың очып:

— Юк, юк, — дип кулларыңны бутап куйдың.

Башкалар моның мәгънәсен аңламый, әлбәттә... Синең Шамил белән булган хәерсез кичеңне алар белмиләр бит.

Сез аракыдан да баш тарткач һәм «Эрети» дигән очсызлы шәрабтан рәтлерәге табылмагач, нәзберекләнер җай калмады. Кырыла язган кәеф аркасында сүзсезлектән интекмәс өчен мин үзебезнең башсыз калган елга хакында кыйтга сөйләдем дә шушы көннәрдә генә авылдан килгән мәгълүм хатны сиңа суздым. Һәм ялгышмадым —сызылган шырпы кебек тиз кабынып киттең.

— Менә шәп! Поздравляю! Болай булгач, теге аю да терелә инде.

— Терелә, Гөлчәчәк, терелә.

— Без аны терелтәбез, шулай бит? Икәүләп. Бергәләп.

Синең кайнарлануыңа гаҗәпсенгән Тәнзилә:

— Менә тиле, үлгән аю тереләмени? — дип, аннары әллә миңа, әллә Ришатка ымлады. — Шушы беркатлы кызны ничек җитди яратып буладыр.

— Бәлки тилелегендәдер аның бөтен зирәклеге? — дим, сүзне шаянга бору нияте белән.

Тик тырышлыгым урынсыз, чөнки Ришат бу сүзләргә бөтенләй илтифат итмәстән, хәтта сак кына иснәп тә куйды. Нинди мәгънәләр кызыклырак тоелачагын чамалап, көн тәртибен тагы үзгәртергә булдым.

— Сез, Ришат, безнең янда бердәнбер интеллигент: джинсовый костюмда. Чит илдә еш булырга туры киләме?

Ришатның чырае сизелерлек яктырды.

— Юк, еш түгел. Дуслар ешрак була. Кирәк булса, табарга мөмкин. Сезгә нәрсә? Велюр? Дубленка? Джинсы? Сез дә бит интеллигент, шунсыз ярамыйдыр.

— Әйе шул, — дип, син, Гөлчәчәк, баягыча ук җанлылык белән Ришатны җөпләргә керештең. — Кыяфәтең гади булса, үзеңне дә простой дип уйлыйлар. Модный киенүчеләр синнән хәтта затлырак сыман тоелалар. Ә үзләре... Аларны каян белсеннәр, киемнәрен салдырып караучы юк бит.

— Бәлки кайчакта бардыр?..

Астыртын мәгънә кабул ителә — син елмаясың һәм дәвам итәсең:

— Ну, синең аларга бирелми торган чын байлыгың бар, әлбәттә, талант дигән хәвефле нәрсә. Тик анысын бит сирәк кешеләр генә белә, белгәне дә күп вакыт күрмәскә тырыша.

— Киметмә, Гөлчәчәк, минем өстенлегем бүтән нәрсәдә.

— Чынлап ярата беләсең. Шулмы?

— Әһе, шулдыр.

Ришатка бу борылыш, әлбәттә, тагын ошамады. Ул хәтта үртәлүен сиздерә язып:

— Ихлас тойгы — анысы инде анахронизм, — дип куйды.

Кинәт колакларга шау-шу кереп тулды да күзләребез белән генә елмаеп сүзсез калдык. Һушыбызга килә, күнегә төшкәч, син миңа:

— Сине танцыга күтәрәбез әле, — дип куйгач, Тәнзилә кинаяле карап куйды.

Ришат игътибар итмәде.

Бер мәлне солист ватык-җимерек теле белән инглизчә җырлый башлаган иде, син миңа елмаеп:

— Тәрҗемә ит әле, зинһар, нәрсә хакында җырлый ул? — дип, минем тел белүем белән мактангандай иттең.

— Бер нәрсә дә аңламыйм, — мин әйтәм.

— Нишләп? Син инглизчә әйбәт сөйләшәсең ич. Ә-ә, бу үзе җырлый белми. — Миңа күләгә төшерергә һич риза түгел идең син.

Башкаларның безне һәм оркестрны гына тыңлап утыруларын килештермичә, Ришатка тәкъдим ясадым:

— Бәлки, кызларның танцыга талпынуларына күз салырсыз, ә? Ничек уйлыйсыз?

— Ә-ә, әйе, — дип, егет сиңа карады.

Ярый торып бастың — югыйсә кәефе китәчәк иде.

Сез өстәл янына кире кайтканчы, Тәнзилә белән бер сүз әйтешә алмыйча һәркем үз уен уйлап утырдык. Сездә генә икән тотка, шул беленде, һәр хәрәкәтнең башы — син бугай, бөтенебезнең күзе синдә генә. Тик син бераз гына утыргач та, өстәл янында кулларың белән бер дә юктан буталып куйдың да, алдагы бокал салат тәрилкәсенә ауды.

— Син нәрсә? — дип борчылды Ришат.

— Алай гына була инде ул, зыян юк, — диде иптәш кызың.

Ә мин:

— Синең хәрәкәтләр бүтән вакытта бик салмак бит, оркестр аркасында бу, — дип якладым.

Ләкин үтенеп сорыйм, гел миңа гына карап утырма, егетең, киләчәк өметең — каршыңда, үпкәли күрмәсен, кара аны.

Тагын оркестр. Тагын тиз ритм. Озакламый, тагын кузгалдың да, синең карашка буйсынып, мин дә күтәрелдем, ләкин тизрәк иптәш кызыңа якын килдем, ләкин без чынлыкта бер дә икәү түгел, дүртәүләп танцевать иттек. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты.

Өстәл янына кабат килү, тостлар һәм оркестр ихтыяры буенча залга чыгулар кабатлана һәм ешая барган саен безнең дә буталулар, елмаю, көлүләр, чуалышулар арта тора. Гомуми настроение мине дә үзенә ияртеп каядыр алып китте, мин дә көләм, мин дә танцевать итәм. Синең белән бергә ешрак туры килә башлау гына уйны күктән җиргә кире кайтара. Бигрәк тә шунысы хәтердә калган, әкрен танецта бер генә кабат Ришат белән булдың да, аннары тиз танецта гына аның белән, ә акрын ритм ишетелдеме, гел минем янга килә башладың. Хәвефле якынлык зиһенне шәрабтан бигрәк чуалта, музыка белән союздаш булып, мине әллә нинди ашкындыргыч дөньяга очырып китә — зиһен таркала. Бу минутларда дөньяда тик син генә бар, кулбашымда синең иркә башың, рәхәт, гомерлек бәхетләргә биргесез татлы сулышың бар. Калган бөтен нәрсә — Ришат та, иптәш кызың да, ресторан үзе дә юклыкка таба шуыша, бөтерелә-бөтерелә ага, кайчандыр без белгән дәрья сулары шикелле. Без алар агышын җиңеп, үзебезне җилкелдәтеп торган күксел томанга, аръякка, аръяктан да арыракка таба йөзәбез. Инде кайдадыр адаштык, үзебез дә юкка чыктык, хыял белән, бәхет белән, максат белән һәм икебез бергә кушылып, онытылдык. Оркестр гы-

на, хәерсез, тукталмаса ни булган! Ник безне бирге ярга, хәтта аннан да якынрак, — менә шушы дүрт кыр белән чикләгән өстәл янына чакыра, дүрт ягы да кыйбла булган киңлектән ник аера ул безне?

Дөрес, син моннан соң Ришат белән дә танцевать иттең, Тәнзилә белән генә дә чыктың. Ләкин сизәм, бары тик әдәп хакына, минем фикерне аяк астына салып таптамас өчен генә чыга идең алар белән. Ә без синең белән булганда, бөтен шартлы нәрсәләр — кыенсыну һәм оялулар, тыю һәм тыелулар, җанны кыса торган чик-киртәләр — барысы, барысы, әйтерсең, таптала, барысыннан да югарырак күтәрелеп, күңелләр бернинди мәҗбүриятсез кушыла, дөньяда бернинди күләгәсез яктылык, кер дигән мәгънәне белмәгән сафлык, бөтенлек тантана итә...

Өстәл янына узышлый официантка безнең янга туктала да:

— Сез шулкадәр матур танцевать итәсез, — дип, миңа комплимент ясый, гомерен лаборатория киңлегенә сыйдырган кешегә. Һәм үзенчә серле, кинаяле елмая. — Бөтен зал сезне күзәтте. Ләкин сез ир белән хатын түгел.

— Нишләп алай дисез?

— Бер-берегезне артык көчле яратасыз.

Бәхәсләшерлек җай да, көч тә калмаган иде инде. Ришатлар сизмәс диген шуннан соң.

Читтән, мөгаен, яхшырак күренә, кешеләр үзебез белмәгәнне дә белә — килешик алар белән, рәнҗетмик аларны — житәкләшик...

Ришатның кәефе шактый кырылган кырылуын, әмма монысы да әйбәт билге ләбаса — димәк, битарафлыктан колак каккан ул — долой гамьсезлек! Димәк, ул да яратырга өйрәнә!

Сүз бирәм — тәүбә, тәүбә, бу — соңгысы, сиңа болай ук якын килмәм, Ришатны рәнҗетмәм. Күптәнге хокуксызлыгымны, ниһаять, таныр чак житкәндер.

*

* *

Гөлчәчәк!

Синең исемең йөз кабат язылган кәгазь белән бергә бөтен тилелекләрне, соңгы талпынышларны учка кысып, корзинкага аттым. Телефон трубкасын көненә өч тапкыр күтәрсәм, биш кабат номерлар җыйсам да, соңгы санны әйләндермәскә көч табып, трубканы яңадан шап итеп куям. Кайвакыт тавышыңны ишетеп ял алам.

— Алло, алло! — Тавышың ямансу, ләкин тере, җәйге су белән яшел су ефәге берләшкән кебек.

Эшеңнән аерган булсам, кичер.

Шалтыратмавың буенча хөкем йөрткәндә, эшең дә күп, Ришат белән очрашулар да дәвам итә. Исемә төшсә, бөтен гәүдәм көзән җыергандай бөрешә дә, яман өянәк, тәмам хәлдән тайдыргач кына, яңадан ычкындыра. Тере күзәнәкләрен үзләреннән дә кечкенәрәк бүленешләренә һәм актык серләренә төбәлгән караш күңел күзәнәкләрен онытырга мәҗбүр. Күңел дә, тән дә үзләренең соңгы серләренә хәтле ачылмыйлар — күкле-сарылы төсләргә әверелләләр дә юкка чыгалар, билгесезлеккә качып китәләр. Шуңа күрә мин үземне дә, сине дә, гомумән, адәм баласын яхшы аңлыйм, беләм дип һич әйтә алмаячакмын. Моны әйтер өчен тулы мәгънәсендә томана булу фарыздыр. Бөтен нәрсә бөтен галәм табышмакка әйләнә...

Шушы хәл белән килешеп, инде тынычлана да язган көннәрнең берсендә Ришат шалтыратты. Вәгъдәсендә торган, «базар»га чакыра.

— Анда кемнәр була соң? Үзегез генәме?

— Үзем генә түгел, Гөлчәчәк тә... Аның өчен дә шулай бергә булсак әйбәтрәк сыман.

Килешенгән сүз — һәркем үз юлы белән атлап, КАИның ишек төбендә очрашканны көтә. Башта риза булгач, хәзер баш тартсаң җайсыз. Болай да нишләптер барасы килми, җан карыша, килештерми.

Ләкин барыбер билгеләнгән сәгать сине үзенә буйсындыра — мәҗбүри рәвештә. Хәтта ишек төбенә беренче булып килгән кеше үзем булдым әле. Икенчесе — син, өченчесе... Баскан җирдә авам дип торам — Ришат! Кул кысышканда гына таныдым — сакаллы! Әйе, әйе, кап-кара сакал!

Инде бөтен нәрсә аңлашылды димәсәк тә, бер нәрсә көн кебек ачык — сез килешкәнсез, якынлаша алгансыз. Инде син, Гөлчәчәк, бу сакалга чатырдап ябыш та аны бу юлы әллә нинди очракларда да ычкындырма. Мин сине бераз беләм бит. Нәкъ шулай булачак та ул!

— Мин сине котлыйм, Гөлчәчәк.

— Ни белән?

— Кара сакал белән!

Ришат моны гади шаярту дип кенә аңласа, син икенче төрлерәк кабул иткәнсеңдер. Елмаюын елмайдың, ләкин ниндидер үпкә белән — иреннәреңне кыскалап. Тик сүз озайтырга вакыт беткәнлектән, тиз генә эчкә уздык.

«Базар, әлбәттә — нисбәти базар. Башта «ник алай атадылар икән» дип, гаҗәпләнәсең хәтта. Чынлыкта ул гадәти концерт, һәвәскәрләр чыгышы. Тагын да дөресрәге, Мәскәү телевидениесе оештыра торган «КВН» шаукымының әдәбият һәм музыка белән кушылмасы. Тагын шуны өстәргә кирәк, безнең шәһәр өчен боларның бөтенесе яңа, джаз, рок. Халык музыкасы ишетәм дигән кеше монда йөрми торгандыр. Концерттан соң шул ук музыкаль кычкырулар, уфтану, чакыру, эзләү-югалтулар, чуалулар арасында конкрет кешеләр бөтерелүе, сикерү, ыргулар, көлү, шаярулар, елаган булып кылану һәм чынлап, ләкин яшьсез елаулар — бөтенесе бергә. Кешеләрнең бәясе бу «базар»да тышкы кыяфәт белән билгеләнә: велюр яки джинсы костюм — беренче категория, калганнары исәпкә алынмый. Үзеңне кыйммәткәрәк бәяләсеннәр дисәң, шуны истә тот. Синең элекке дусларың Шамил белән Тәнзилә, мөгаен, шушындыйрак җирләрдә чыныгу алганнардыр.

Базар минем өчен мәҗбүри түгел...

Көткәнемчә, син танцыны Ришат белән башладың. Синең белән мин күп дигәндә ике-өч тапкыр чыкканмындыр. Эшнең үзем теләгәнчә, ә дөресрәге — теләмәгәнчә баруын сизеп шатланырга тиешле кеше — ярым үлек хәлгә төштем. Күз алдында — төштәгечә — тик сурәтләр буталышы. Күңелгә тынычлык биргәне шул гына — әкертен танецларга тагын минем белән чыктың...

Үзем өчен соңгысы дип исәпләгән танецтан соң икенчесенә чыкмыйча, без синең белән тукталып калгач, Ришат килеп житте дә, мин үзем өчен балалар вакытының инде беткәнлеген әйтеп, саубуллашырга кирәшкәч, Ришатка матуррак сүзләр әйтү өчендер:

— Монда сез һаман үз кеше икән әле, студентлардан аерылмыйсыз ук, ә миңа инде бераз уңайсыз, — дип куйдым. — Бары тик сүз куешканга күрә генә килдем. Тәүбә, бүтән булмас, начарлыгым тигән булса, гафу итегез, хушыгыз, — дидем.

— Студентлардан сез дә аерылып тормыйсыз! — дип җавап кайтарды Ришат.

Шуннан соң кул кысыштык, ә сиңа... сиңа нишләптер баш кына кактым да киенергә чыгып киттем. Гардеробтан болонья куртканы кулга тоткан килеш, аркага салып кына чыктым. Аннары бөтерелгән кешеләргә, чайкалган, дулкынланган, чуар массага карап бераз торгач, әкрен-әкрен атлап (әйтерсең, кемнедер көтәм!) чыгып киттем. Нәрсәдәндер, чынлап та, аерыласы килми, нинди көчтер, йөрәкне өстерәп чыгарырдай үзенә тарта, ләкин яшертен көчтән мин өстен чыгарга ти-

еш, мин аны ерып үтәргә, мәңгелек иркенлеккә чыгарга тиеш... һәм жиңдем, һәм чыктым — баскычтан көч-хәлгә төшеп, асфальт урамның тап уртасыннан атлап киттем.

— Нажар!

Кемдер эндәшә, ишетәм, таныйм, ләкин колакка, зиһенгә ышана алмыйм, ышанмаска тырышам. Инде тавыш елаудан яман ачыргаланып эндәшә:

— Абба, ишетәсеңме, тукта!

Артка борылам. Син! Ни уйларга, нәрсә эшләргә белмичә каттым да калдым. Син, шашкан кешедәй, кулларыңны бутый-бутый йөгереп килдең дә... күкрәгемә ташландың. Еларга, үксергә керештең. Мин исә, үземнең баягы көрәшемнең жиңелү белән төгәлләнүен, жиңелүнең әйтеп аңлата алмаслык татлы икәнен, нәрсәгәдер әзерләнүем — теләсә нинди фажига, теләсә нинди жәзага әзер булуымны тойган хәлдә, синең чәчләреңне сыйпап торам, урамның нәкъ уртасында!

Ә баскыч өстендә — Кара сакал! Кем, кем соң әле бу? Әй, барыбер түгелмени, сакал булгач сакал лабаса. Хәзер ул шунда калачак, хәерсез кара сакал моннан ары сине һичкайчан эзәрлекләмәячәк. Әнә ул моны үзе дә аңлады, безгә кул селтәде, ләкин китте дигәч тә, яңадан баягы урынына килеп басты. Мин аның ни теләвен әллә нинди бик зәгыйфь тоемлау белән генә тоям да сиңа ялынып эндәшәм:

— Син — молодец, Гөлчәчәк, син — акыллы, искиткеч син! Тик бүтән болай ярамый, ишетәсеңме? Тагын да акыллырак булырга кирәк. Әнә Ришат сине көтә, ачулана күрмәсен, бар син аның янына. Ә безгә икебезгә беркая да юл юк. Без болай да чиктән ашып, шактый ерак киттек. Адашып йөрдек. Бөтенләй югалмыйк дисәң, бар син Ришат янына.

— Юк, аның белән булмый, булмый!

Тавышың шулкадәр кискен иде ки, миңа кулымны тартып алып, ары атларга гына калды. Ялгызың бераз торырсың да, аптыраудан гына булса да, берүзең калудан гажизләнеп кенә булса да аның янына кире борылырсың дигән актыккы өметемне дә таптап, яңадан мине куып життең һәм без сүзсез генә такси тукталышына таба киттек. Дөресрәге, шунда таба атлаганбыз. Мин моны машина килеп, шунда утырып барганда гына абайладым. Әйе, без барабыз. Кая?

— Мин сездән тәки ишетмәдем — кая барырга соң?

Шоферга мин кая икәнен аңлата алдым шикелле — син торган өйгә һәм аннан соң — минем өйгә.

— Өйгә түгел, зинһар, кая булса да бүтән жиргә — дип, син кулларымны тотмакчы буласың, ә мин аларны яшерәм, кире алам. Болай да ярсынган нечкә күңелгә, шушы кечкенә нәрсә дә житә кала: нишләргә белми үрсәләнә, үртәләсең.

— Син нәрсә инде, бөтенләй... Соңгы кабат. Аңлыйсың ич — икәү генә калырлык жиргә, жир читенә!

— Алай тиеш түгел... — дим. Күңелдә: «Ришат янына китәргә тиеш», дигән уй.

Аңлата алдыммы, юкмы, белмим. Күңелдә: «Мин сине хәзер алып китсәм, коточкыч ялганчы, синең киләчәгең каршында хәтта жинаятьче булыр идем. Ә син һаман бүгенге белән канәгать, бүген, бүген, менә шушы сәгать, шушы минутлар гүзәл булса, шул житсә, калганы башыңа да керми, шушы мизгелләр хакына елларны корбан итәргә әзер син. Сиңа хәзер ярдәм кирәк, булышчы. Ә миннән дә якынрак кемең бар соң синең?!»

Әллә уйлар белән мавыгып, әллә артык көчле каушаганга күрә, күзле бүкән булып катканмын да калганмын. Шул хәрәкәтсез бүкәнне тегеләй дә, болай да тарткалап уята, кузгата алмаганыңны сизмичә, инде син миңа бөтенләй аңлашылмас сүзләр пышылдыйсың:

— Барысын да аңладым бүген, син ялгышасың, мин сиңа беркайчан хыянәт итмәдем, беркемгә дә иярләшә алмаячакмын. Сиңа өметләнү — барыннан да олырак тилелек. Инде бер генә нәрсә кала — син аны беләсең, була язды дип әйткән идем. Тик юкка өметләнгән булып чыктым. Хәтерлисең бит?

— Хәтерләмим, аңламыйм, Гөлчәчәк.

— Синең дәвамыңны алып китәргә кирәк миңа — соңгы өмет шул гына.

— Мин үләргә җыенмыйм, үзең беләсең — ашыктырма зинһар. Аннан соң бит, беләсең — минем инде дәвамым бар.

— Ул инде үз көнен үзе күрерлек... Ә бусы озаграк, арырак алып китәчәк сине, тагын да арырак.

— Мин үз балама, Энҗемә, хыянәт итә аламмы? Ул бит үзе генә булуга күнеккән. Ул мине кичермәс иде. Юк, Гөлчәчәк, син мине җинаятькә этәрәсең. Ә җинаятьче синең яратуга да лаеклы булмас иде. Гафу ит, Гөлчәчәк.

— Син үзең мине гафу ит.

Сискәндереп, кискен, ят тавышың колагымны авырттырды:

— Туктатыгыз, зинһар!

Машина чарылдап туктады да, минем башка ни буласы килеп җиткәнче, чыктың да ишекне ачу белән шакылдатып яптың һәм каядыр йөгереп тә киттең.

Ә мине машина үз юлым белән ары алып китмәкче. Ләкин ике-өч минут узгач та ниндидер каты нәрсә сугылгандай, кинәт баш чатнап китте: «Төнге урамда берүзен калдырдым бит!»

Машинаны мин дә синең кебек капылт туктаттым, синең кебек үк чыгып та йөгердем. Каядадыр еракта шәүлә, син булырга тиеш, ә мин куып җитәргә тиеш. Ләкин ул да булмады, аркама тупас тавыш бәрелде:

— Әй! Әй! Тукта! — Тукталам. — Сезнең өчен кем түләр! Акча! Акча! Ә?

Менә нәрсә — беттем мин болай булгач, синең кебек тиз генә китә алмыйм икән. Нинди минутлар кесә кабалап, акча эзләп үтә. Ә син бит ераклашасың!

Шоферга күпмедер акча бирдем дә юләр кешедәй тагын торып йөгердем. Ләкин бу вакытта инде алдагы ерак шәүлә бөтенләй юкка чыккан иде. Йөгердем дә йөгердем, чаптым да чаптым, маэмай шикелле телләрне асылындырырлык хәлгә җитеп алҗыдым, мәгәр сине таба алмадым. Атлап кына да ары сугылдым, бире ыргылдым—эзләрең калдырып китмәгән идең. Күккә ашкандай юкка чыктың.

Аякка уралырга азапланган кылка күлдәвекләрне өстери-өстери, үкенүләр һәм уфтануларның, хәерле һәм хәерсез хатирәләрнең өсләренә баса-баса, һәм, ахрысы, төнге утлар сыман юлга яткан уйларны, өметкә охшаган тойгыларны таптый-таптый, төн карасы шикелле куе, дөнья хәтле зур кара сакалны йолкып атарга тырыша-тырыша һәм максатка һич ирешә алмыйча, хәлдән таеп, вакытлыча гына дип яшәгән фатирыма кайтып аудым. Ләкин монда мин — чит кеше, квартирант кына. Кем нәрсә әйтсә дә төшенер, җавап бирер хәлем юк... Миңа тизрәк үз өемә, гаиләмә кайтырга, таңга, якты иртәгә чыгарга кирәк.

*
* *

Хөрмәтле Нажар!

Инде миннән хәбәрләр көтмә. Үземне дә эзләмә, барыбер таба алмассың. Гәрчә син мине ишетсәң дә, моннан соң арабыз бөтенләйгә өзек булыр.

Безне таныштырган, якынлаштырган һәм мәхәббәт иделенә ыргыткан шаулы шәһәрдән мин инде — еракта.

Монда ни дә булса эзләп килмәдем, нинди дә булса яңа бәхет, яңа эш, яңа мәхәббәт табармын дип уйламыйм. Китүем — синең янда синсез газап чигүне калдыру өчен генә. Һәм сиңа комачау итмәс өчен.

Сигез яшьтә Кама аръягына йөзеп чыкканда ук шушы язмышны сайлагач соң, хәзер инде кемгә үпкәләргә мөмкин? Зарланмыйча түзәргә кала. Зарлану, аһ ору урынына бәлки әле котылгысыз җәзаны аңлы рәвештә кичереп, чиктән уза белү бәхете белән ялгызлыкта горур калу мөмкиндер?

Дөньяда бәхәсле булмаган бәхет юк бит.

Ләкин инде шуны беләм: ялгызлык сагышын дискотекалар шаушуы кумә, җиңә алмый икән — өйдә дә, кичләрдә дә. Үз мисалымда, жаным-тәнем белән тоеп инандым. Шулай булгач, синең мине башка тормышка күчерү өчен булган интегүләрең әрәмгә китмәгәндер. Мин— чынлап та гарип кеше. Гариплегем — программасызлык — эштә һәм тормышта. Сизмәстән сине дә шул хәлгә төшерә яздым шикелле.

Хәтерлисеңдер, гел стресс хәлендә яшәвемнең фәнни сәбәбен син баш миендә гаҗәеп молекулалар — эндорфиннар җитмәве белән аңлаткан идең? Баш миендә эндорфиннар синтезлауның артуы — дөрес тәртип өчен, әйбәт эшләр, гамәлләр өчен бирелә торган бүләк—шатлык, тынычлык, ләззәт тойгысы белән түләү. Акыл без — җәнлекләрне камчылап та, сыйлап та өйрәтә! Ә стресс — эндорфиннарның җиткелекле ясалмавы. Зиһенем әгәр җаныма шундый җәза бирә икән, моңарчы булган тәртибемә (тәртипсезлеккә дисәм, дөресрәктер) бөтен организмым, табигатем каршы килгән диган сүз.

Тикшерә, эзләнә төшсәң, баш миендә эндорфиннарны ясалма рәвештә барлыкка китерә торган препарат эшләп чыгарырга һәм шул дару ярдәмендә вөҗдан җәзасын, уңышсызлыклардан канәгатьсезлек тойгысын җиңеп, гел рәхәтлек, шатлык кичереп кенә йөрергә дә мөмкин булыр иде. Ләкин бу наркотик сыман алама нәрсә — кешелек каршында гафу ителмәслек җинаять булыр иде. Әйе, табигатьне алдарга ярамый, чөнки ул барыбер алдатмый, ахыр чиктә барыбыр үчен ала.

Колакларны томалый алса да, шау-шулар баш миен, вөҗданны алдый, саңгыраулата алмадылар. Инде табигатем белән килешермен, дип ышанам. Әгәр шуңа ирешмәсәм, әйдә, син әйткәнчә булсын, иярә бирсен артымнан ялгызлык — Кара сакал...

Ә син үзеңчә яшә.

Бәхетле бул.

Бәхил бул.

## Кайту

*Бәхетле азак*

Нажарның күп төрле кәгазьләре арасында борын-борыннан, нәселнәсәптән, кардәш-ырудан калган төрле язулар саклана. Аларны укыганда буыннан-буынга күчә килгән тойгылар: ерак аралар, океаннар аркылы кыска дулкыннар аша килгән сәер авазлар: соклану-аптыраулар, уфтану-үкенүләр, чакыру-эндәшүләр, ялвару-пышылдаулар, рәнҗү-үпкәләүләр, табышу һәм югалтышулар җирне ураган радио сигналлары белән кушылып ишетеләләр. Нажар кәгазьләр актарып утырырга, шул авазларны тыңларга ярата һәм бу вакытта аның үз йөрәге дә шундый ашкыну-талпынулар белән тула. Дөнья өстендә ике кеше сөй-

ләшә: ир заты һәм хатын-кыз заты. Соңгы вакытта Нажар бу затларның берсенә Гөлчәчәк, икенчесенә Нажар дигән исем бирде. Ләкин мәңге тынмас тоелган сөйләшүләр аның өчен кинәт өзелде. Аерылышуның гомерлеккә икәнен Нажар бөтен җан тирәнлеге белән тоя хәзер.

Гөлчәчәк бөтенләй юкка чыктымы? Монысы белән Нажар килешә алмас. Нажар белә: бөтенләй үк юкка чыкмады Гөлчәчәк. Ул табигатьнең үзендә калды. Тынлыкта су, яңгыр шыбырдавы, җил белән яфрак очрашуына әверелеп килә дә, үзенең таныш мәгънәләрен кабатлый. Нажар ишетә, Нажар тыңлый, Нажар аңлый. Табигать күп чакта музыка булып ишетелә. Янамы ул, искеме?

Кемдер, үзенең яман табигатен эшкә кушып, яңаны тирги, искене яклаган булып кычкыра, яза. Кемдер исә искене кирәксез, реакцион кодрәт дип, яңа дигәнне дә битәрли. Нажар боларның фәкыйрь үк кешеләр икәнлеген белеп яши. Нажар һәртөрле үзгәрешләргә бармаклары белән кагыла алмаган сурәттә дә күзләре белән, ә күзләре белән барып җитмәсә, акылы белән эзли, таба, тоя, — барысын бөтен итеп күрә һәм ишетә ала. Яшәр көче булган һәр яхшылык дөньяда чик дигән нәрсәне белми, еллар аша алга омтыла, үлде дигән искелек тә бөтенләй үк бетми — алар шулай бергә үрелә-үрелә, киләчәк яктылыгына үрмәли, үсә тора. Нажар аның буынга сикергәнен, үскәнен тыңлый.

Бу мизгелдә каяндыр бик якыннан гына килә ул аваз.

Нинди әсәр әле бу? Дикъкать беләнрәк тыңлагач, авторы, исеме ачыклана. Тик эш исемнәрдә мени! Эш шунда: бу — өр-яңа музыка!

Электр органы — компьютер — тавышы ачык ишетелсә дә, ритм бәйләнчек түгел, йокы дарусы сыман тынычландыра, хәтта оета.

Бүтән төрле поп-музыка әсәрләрендә була торган һәлакәт сиземе, усаллык, агрессивлык шаукымы монда юк — Пинк Флойдка да, бүтән ансамбльләргә дә хас булмаган җинел, тыныч моң. Тыңларга мәҗбүр итсә дә һич ирексезләми: тыңламасаң тыңлама, рәхәт һаваны суламасаң сулама, ул барыбер күңелгә үзе тула — юкка гына «Кислород» дип аталмаган бит әсәр!

Тема акрын үсә. Дүрт бүлек — бөтен бер пластика, вариантлар кушылмасы.

Кайдадыр борынгы орган тавышы — Бах. Тыңлаганда, борынгы стильгә хәзерге заман призмасы аша карыйсың.

Дөнья музыкасы шулай: рәнҗеп, усаллашып кычкыра-кычкыра да арыгач, яңадан Бахка әйләнеп кайта. Ә бүтәнчә булдыра аламыни ул?

Күпмедер буталулар, мәгънәсез сыман шау-шулардан соң дөнья барыбер тынычлана. Тыныч иртәдә чыккан кояшка ияреп, хакыйкать калка.

Көнкүрештәге модерн көче бер ара халык җырларын вакытлыча читкәрәк этәрде. Аларны җырлау модадан чыкты — искерде, кызыксыз... Тавыш-тынсыз гына ята бирсеннәр...

Юк, монысы да икенче төрле булып чыкты. Саф мәгънәсендә моданың соңгы авазы нигезендә пөхтә һәм матур киенеп, халык җыры барыбер үз юлын таба һәм дөньяга чыга — яңа ритмнарда, яңа инструментлар, яңа тавышлар белән үз кинлекләренә әйләнеп кайта.

...Нажар үзенең Гөлчәчәк белән ни сәбәпле очрашканын һәм аерылганда әрәм тоелган вакытның заяга гына китмәгәнлеген кабат төшенә. Яшәүнең гомер озынлыгы белән генә үлчәнмәвен ул болай элек тә аңлый иде шикелле гәрчә.

Шулай да моннан ары ул үз белемәсендә генә гомер сөрер. Читкә чыгуы тик Гөлчәчәк аркасында, аның мавыктыргыч көчендә, кызыктыргыч ирегендә, табигать каннарга үзе салган теләк-таләпләргә бирелүендә, үзенчә саф беркатлылыгында-тилелегендә булгандыр.

Әйе, Нажар моннан соң тыныч, сабыр гына яшәр. Гыйльми совет утырышларының берсен дә калдырмыйча йөреп, өлкән галимнәр белән бер сыйфатта акыллы чыгышлар ясар, һәркемгә билгеле булган, моңарчы банальный дип үзе мыскыл иткән мәсьәләләр буенча бәхәсләр купса да катнашып, озын-озак нотыклар ясар. Көлгәндә дә житди көләр.

Гөлчәчәк хәтерли микән — аның белән дуслашкан, табышкан көннән башлап, Нажарга бер ак чырайлы, дөм кара чәчле, тулырак кына чая кыз гел генә сүз куша, алгысындырырга азаплана иде? Бер елдан артык инде бергә яшәмәгән якын кешеләре янына — хатыны Фәнүзә һәм кызы Энже янына бөтенләйгә савыгып кайтканнан соң һәм ун көн буе тагы авырып ятканнан соң эшкә баргач, Нажарга ул кыз белән баскыч буйлап тагын икәүдән-икәү атларга туры килде. Ләкин ул кыз илтифатсыз гына керфек сирпегәч, Нажарга бүтәнчә күтәрелеп карамады, чөнки ул аны бу юлы танымады.

**1978—1979**

## Укучының күңел дәфтәренә

*Латыш мәкальләре һәм әйтемнәре*

***Һәркем үзен үзе саклый: сыер — сөзә, ат — тибә.***
***Һәр агачтан курай кисеп булмый.***
***Бәп-бәләкәй очкыннан калын урманнар яна.***

*Мари мәкальләре һәм әйтемнәре*

***Берәү таш та кузгаталмый, бергәлек — таулар ишә.***
***Җыйнаулашып сулыш өрсәң, давыл куптарып була.***
***Тәгәрәп таш шомара, яткан ташны мук баса.***
***Якмаган мич җылытмый.***
***Туй узгач чаң сукмыйлар.***
***Тиен өскә, кеше аска карый.***
***Яхшы уңыш кышын хәзерләнә.***
***Ялгыз карлыгач яз ясый алмый.***
***Сатучының начар товары юк.***
***Күтүләрен бүре көтә, сөтләрен мәче саклый.***
***Олыдан тыел, кечедән оял.***
***Кем кулында дилбегә — атны шул кага, суга.***
***Савытыннан эчерә, ә сабы белән кыйный.***
***Зур агачны яшен тизрәк суга.***
***Утта корыч та йомшый.***
***Куркак эт каты өрә.***
***Озын кул гомер кыскарта.***
***Сарык каргышы бүрегә төшми.***

## Ренат Харис

### Йөрәк белән капшап

Аяк белән көпшәк карны капшап,
Йөрәк белән капшап тормышымны
Тотрыклы юл эзлим —
Батасы килми сулы карга,
Каласы килми суыкларда!..
Адым саен
Хыялдагы якын җәйнең,
Җылы җәйнең,
Тыныч җәйнең
Бәһасы арта.
Дуамал күңел дулап тарта —
Ә мин
Аяк белән көпшәк карны капшап,
Йөрәк белән капшап бу тормышны
Тотрыклы юл эзлим...

Һәр яз,
Менә-менә рәхәт җәйгә чыгасың дип,
Сак булырга өйрәтә безне...

### Тып-тын кичләр

Нинди көчләр,
Нинди көчләр бүләге бу тып-тын кичләр?!.

Нинди эшем, казанышым өчен болар? —
Бикләп яшәткәнгәме йөрәгемдә зур давыллар?
Югалтулар кичергәнгәме иреннәрем, кочакларым —
Нинди эшем, казанышым өчен болар?..

Күктә тынлык —
Ни ае юк, ни йолдызы...
Ни сүзләр юк,
Ни күзләр юк —
Бу тынлыкны берни бозмый.

Бары миңа гына
Яшьнәргә дә, күкрәргә дә рөхсәт:
«Булмаса бер давылланып, янып күрсәт!..»

...һәм тын янгын
Бер-беребезнең иреннәрен ялмый...
Һәм тын давыл
Бер-беребезнең чәчләрен тарый...
Һәм бер аваз
Тынлыгын боза тып-тын кичнең:
«Коткармасын,
Коткармасын,
Коткармасын
Бүгенгә безне һичкем!..»

## Моң

— Нәрсә ул моң?
— Ул — җете күз: купшы урман,
Шәрә кыр,
Болытлар томанлы тавыш
Белән җырлый торган җыр.
Кавышу куанычының
Аерылу ачысына
Кушылуыннан килеп чыккан
Гаҗәеп халәт сыман
Бер халәттер.
Аны хәтта
Булмый төгәл билгеләп...
Я аңлатып кара шуны —
Күңел елый, күз көлә...
Нәрсә ул моң?
Ул — кочакта
Елаган сылу ярдыр...
Ә бәлки моннан башка да
Моңның мең яме бардыр...

## Август

Инде август.
Тагын август.
Җәй җиткән ахыр чиккә.
Инде тагын кояш нуры
Яфракка тамып кипкән.
Инде тагын күзгә тула
Купшы, көр, шат чуарлык,
Ә күңелдә төссез уйлар —
Тик теш кысып чыгарлык.
Дөньяда да, күңелдә дә
Борчылу катыш каушау...
Бармаклар да ак чәчләрне
Табалар хәтта капшап.
Китәргә җыенган кошлар
Йөрәккә килеп куна...
Әле август,
Бары август,
Нибары август кына.

●

Көз керә.
Кыз-кыркынга төс керә.
Йөзләренә — көн төсе,
Күзләренә — төн төсе.
Сүзләренә тәм иңә,
Кызыктыргыч ямь иңә.

Көз керә.
Егетләргә көч керә.
Тәннәренә — ир көче,
Аңнарына — җир көче,
Уяу килеш төш күрә,
Туйга охшаш эш күрә.

Көз керә.
Һәм шагыйрьгә шатлыгын
Иленә җиткерерлек
Төгәл, тыгыз сүз керә.
Көз керә.

## Ау чоры

Яфракка сары керде...
Мылтыкка дары керде...
Җитте хушлашу чоры.
Агач — яфрак озатты.
Егылып төште киек үрдәк —
Аучы аңа төз атты.
Үле яфраклар өстендә
Канга буялган киек —
Үлгән фиргавен янында
Япь-яшь хатыны кебек...

●

Оясыннан егылып төшкән кош баласы белән
Шаяра адәм баласы.
Мәхлук кошның каурыйлары сынып беткән.

Оясыннан егылып төшкән адәм баласы белән
Шаяра язмыш.
Ул мәхлукның канатлары нишләр микән?

## Пушкинның гүр маскасы

Гөнаһлыны изге иттерергә
Теләүчеләр әле табылыр.
Тарихның да, безнең колакның да
Ялганнарга сусау чагыдыр.
Пушкин җирләрендә һәр манзара,
Һәрбер адым аһлы, көн аһлы...
Гипс иреннәре ачылыр да,

Пышылдар кук: «Әйе, гөнаһлы...»
Тәне түгел, җаны сызлаганын
Күреп торам гипс аша мин.
...Натальяны мактый: «Ул — гөнаһсыз...»
Мин аңламыйм.
Ахры, шашамын...
Еллар узган саен кан өстенә
Куна, куна тарих сөреме.
Ә шулай да йөрәк белән күрәм
Шагыйрь үлеменең серен мин.
Таш масканың тере газапларын
Карыйм, карыйм ничә кат килеп...
Ядрә генә, Дантес кына түгел,
Гайбәт түгел Пушкин катыйле —
Хыянәттер...
Өмет хыянәте...

## Кайту

Күзләремне йомам да мин
Ике дөньямны кушып күрәм —
Эчкесе белән тышкысын...

Мин аларда күпме каршылыклар,
Тарткалашлар таптым —
Сынып китә язды рухым,
Чак чатнамый калдым теш кысып...

Көннәрдән бер көнне шулай
Күзләремне тышкы яктан нидер какты...
Яшендер дип ачкан идем —
Күзләремә кыю Җәлил кайтты!

Күзләремне йомам да мин
Ике дөньямны кушып күрәм
Ачык итеп, якты итеп...

Икесе дә әлегә бераз өтек,
Икесе дә әлегә бераз китек...
Сынып китә язды рухым...

Көннәрдән бер көнне шулай
Күзләремне эчке яктан нидер какты...
Утлы яшьтер дигән идем —
Күзләремә туры Тукай кайтты!

●

Мин бүген шундый бәхетле —
Бәхетемдә кар агы.
Кар сырган чәчләрен аның
Бармакларым тарады.

Керфегенә кунган карлар
Тамчы булдылар эреп...
Аһ, алар яхшы беләләр
Чын эрүләрнең серен.

Күз яшьләренә кушылу
Сирәк эләгә карга...
Шул карлар күк — мәхәббәттән
Аң җуя белгән ярлар.

Мин бүген шундый бәхетле —
Якты минем бар ягым.
Мин дә ярым күз яшендә
Эреп агып карадым.

●

Мин кичәге көнне кире кайтардым —
Һавасын, җирен, өен, көен, сыен,
Икәү генәлегебезне,
Сине,
Зәңгәр эңгер серен,
Хәтта үземне... нәкъ кичәге килеш.
Барысы да кире кайтты,
Ләкин
Йөрәгемдә кичә булган дулкынлы тибеш
Кайтмады...

## Солтан Шәмси

# БАЛКОНДА

хикәя

I

Бәйрәмнәрне мин нигәдер өнәп бетермим, сәбәбе бәлки буйдак булуымдадыр. Бәйрәм җитте исә үземне диңгез атавында берьялгызым калгандай хис итәм. Мондый шау-шулы көннәр мине эшемнән, күнегелгән гадәтләремнән аера, тормышымның көен боза. Андый чакта мин нишләргә белмичә интегәм, көнем төрле икеләнүләр һәм рухымдагы каршылыклы хисләр тартышуы белән үтә.

Бер яктан, минем дә башкалар кебек дөньямны онытып бәйрәм итәсем килә, икенчедән, җаным моңа нигәдер карыша, бүтәннәр сөенеп кабул иткән бу уенга алай җиңел генә бирелäсем килми.

Шунда берәрсе шалтыратып, килäбез дисә, куана-куана хәзерләнергә керешәм, ләкин андый чаклар бик тә сирәк була...

Бүген бәйрәм. Көн иртәдән үк аяз. Язгы кояш урамга тарта. Иртүк кызыл байраклар, төрле лозунглар, портретлар күтәргән студент халкы шәһәр үзәгенә таба китте, мин аларны тәрәзәдән карап озаттым. Соңрак үзем дә җыенып урамга чыктым. Ашыкмый гына студентлар киткән якка атладым.

Шәһәр бүген гадәттәгедән тынычрак. Хәрәкәт тукталган. Светофорлар онытылган. Чиста урамнарга җәяүлеләр хуҗа. Үзәккә якынлашкан саен, күкрәкләренә медальләр, орденнар таккан картлар күзгә ешрак чалына бара. Өс-башлары пөхтә, йөзләре ачык. Кыяфәтләре белән шактый аерылсалар да, нидер аларны бер-берсенә охшаш итә. Бәлки җыерчыклардыр?!

Мин аларга карыйм да: сугышның бу картларга көче җитмәгән дим. Киресенчә, сугышны үзләре дөмектереп кайтканнар. Аяк-кулларын өздереп булса да кайтканнар дим. Кыйммәткә төшкән ул җиңү...

Мәңгелек ут янына җыелган халык каравыл алышынуын көтә. Кара гранитта кызыл тюльпаннар. Кызлар, тартынып кына килеп, яңаларын өсти.

Монда яшьлек белән картлык аеруча күзгә ташлана. Берәүләре яши генә башлаган, күңелләре саф, дөнья гаменнән ерак. Икенчеләре инде барысын да татыган. Күзләрендә — зирәк моңсулык.

Йөри торгач, күзләрем озын буйлы, чал чәчле бер картка төште һәм... чак кына кычкырып җибәрмәдем. Буын-буын шома таяклы бу карт коеп куйган Кадыйр абый иде. Тик Кадыйр абый урын өстендә дип ишеткән идем бит...

Шул мәлне кызарганымны сиздем. Кайтканыма инде бер ел булып килә. Әмма шушы көнгә кадәр янына кереп хәлен дә белешкәнем юк.

Мин шәһәрнең алар торган ягына төшеп киттем.

## II

Ишекне Гайшә апа ачты. Танымыйча бер мәл аптырабрак торды да, исемен әйтеп исәнләшкәч:

— Карале, Мөнир түгелме соң бу?— дип елмайды һәм ишекне киңрәк итеп ачты. Аяк төбендә кечкенә эт чәңгелдәде.— И ходаем, танырлык та түгел. Үзгәргәнсең.

Ике яктан да мондый очракта әйтелә торган сүзләр әйтелде, мин, плащымны чөйгә элеп, залга уздым.

Гайшә апаны күрмәгәнемә ун еллап бардыр инде. Вакыт аны да үзгәрткән. Мин белгән шат, түгәрәк йөзе суырыла төшкән, яңа җыерчыклар өстәлгән. Зәңгәр күзләрендә елмаюдан гына бетми торган моңсулык.

— Бу квартирыгызда булганым юк бит әле,— дим, шактый яңартылган җиһазларга күз йөгертеп.— Матур торасыз икән.

— Биргәненә шөкер.

Як-ягыма карангалап, Кадыйр абыйны эзлим. Моны күреп, Гайшә апа:

— Кадыйр абыең монда ул,— ди һәм түрдәге ярым ачык ишекне күрсәтә.

Ул мине караватта утырган көе каршы алды. Күргәч, югалып калдым. Аның хәлен ишеткәнем булса да, болай ук дип һич уйламаган идем. Мин белгән мәһабәт гәүдәле Кадыйр абый урынына караватта ике аягы да төптән киселгән кечкенә кешене күрдем.

— Саумы, Кадыйр абый! Бәйрәм белән үзегезне.— Кулымдагы кызыл тюльпаннарны аңа сузам, тик ул чәчәкләргә үрелми.

— Рәхмәт, энекәш. Хәлләр ару гына әле.— Тавышы көчәнебрәк чыкса да, элеккечә көр иде аның. Чәчәк бәйләмен журнал өстәленә куйдым. Килеп, сак кына иңеннән алдым һәм абыйны күкрәгемә кыстым. Яңагындагы чал төкләре битемне чәнчеп алды. Ул тиз-тиз күзләрен йомгалады, күңеле нечкәреп, яшен күрсәтүдән курыкты, ахрысы.

Беразга тынлык урнашты. Кадыйр абый ак майкадан, кара трусиктан. Башы кырылган. Гел өйдә утырганлыктан йөзе аксыл-сары төстә. Миңа ул тынычланган кебек булды. Куе каш астыннан коңгырт күзләрен игътибар белән миңа төбәде һәм көлемсерәгәндәй итеп:

— Үтә диген гомерләр, энекәш, ә?

— Үтә, Кадыйр абый.

— Кайттың инде алайса. — Ул кулларын нык итеп урынга кадады.

— Кайттым. Җитәр.

— Бөтенләйгәме соң?

— Бөтенләйгә. Читтә күп йөрдем, монда төпләнергә исәп.

— Шул хәтле торып, нигә дип кайтырга булдың соң? Анда тормыш итү җиңелрәк диләр ләбаса.

— Анысы дөрес. Китәсемне ишеткәч, дус-ишләр дә тиргәп тә, үгетләп тә карадылар. Туган җир тарта, Кадыйр абый. Җирседем. Үз телемдә сөйләшергә зар булып яши алмадым.

— Алай...— Ул бераз уйланып торды.— Өйләнергә кирәк сиңа, тормыш корырга. Синең ишеләр инде икешәр бала үстерә.

Мин «кирәк тә бит...» дигәнне аңлатып елмайдым гына.

Шул вакыт кыска йонлы кечкенә эт шикләнеп кенә караватастыннан чыкты һәм, миңа кырын карап, ишеккә таба китте. Кухня ягыннан савыт-саба шалтыравы ишетелеп куйды.

Монда килгәндә мин бәйрәм өстәле янына җыелышкан туган-тумачаны, таныш-белешләрне күрермен, барысы белән дә сөйләшермен дип уйлаган идем. Әмма монда тынлык. Бәйрәм бу өйгә кермәгән дә шикелле.

Кадыйр абыйның өстәлдәге чәчәкләргә төбәлгән карашын тотып алдым. Сәерсенеп карый иде ул чәчәкләргә, гүя аларның дөньяда барлыгын да онытткан.

Мине безнең арада урнашкан тынлык борчый иде. Сүзне ничек дәвам итәргә дә белмәдем. Сәламәтлеген сорашсаң, күз алдында, авыру кешенең кәефе кырылыр, әдәп саклар өчен генә сораша дип уйлар.

Шулай утырганда бүлмәгә Гайшә апа килеп керде.

Ул:

— Менә, әтисе, котлыйлар үзеңне,— дип, Кадыйр абый алдына открыткалар китереп салды.— Ә заводныкыларның исе хушы юк.— Тавышында ризасызлык. Миңа борылып сүзен дәвам итте: — Элеграк, елның елында, бәйрәм белән котлыйлар, яисә месткомнан берәрсе килеп китә иде... Менә икенче ел инде оныттылар.. Көне буе шуңа күңелем әрнеп йөри. Күпме эшләп, күпме көч түгеп шул завод өчен...

— Ярар, карчык, сукранма. Беләсең бит, кылны кырыкка ярырдай булып йөриләр.— Ул хатынын тынычландырмакчы булды һәм миңа карап: — Реконструкция бара анда, мәшәкатьле чаклары, — дип өстәде.

Ә Гайшә апаның үз сүзе сүз:

— Эш котлау кәгазендә түгел, онытуларына ачуым килә... Шул инде ул, кеше сәламәт булса гына кирәк, авырып китсәң, я пенсиягә чыксаң, кирәгең бетә.

— Борчылма, Гайшә апа, Кадыйр абыйны оныталармы соң? Котлаулары почтада ята торгандыр,— дидем мин һәм газетада укыган бер кызык хәл турында сөйләп киттем.— Әнә, Көньяк Американың кечкенә бер илендә хат адресатына егерме елдан соң гына килеп җиткән.

Алар икесе дә елмайдылар. Гайшә апа, нидер исенә төшеп, теге якка чыгып китте. Без тагын икәү генә калдык.

Кадыйр абыйның фаҗигасе турында мин хатлардан белә идем. Ләкин ишетеп белү үз күзләреңбелән күрү түгел икән. Бу гаиләгә килгән бәла турында уйлыйм. Кадыйр абый, уйларымны сизенгәндәй, миңа туп-туры карап:

— Менә шулай, энекәш, аякларны кистеләр минем,— диде.

— Ничек алай булды соң әле ул, Кадыйр абый? Сәп-сәламәт идегез бит. Мин әле сезнең газосварщик булып эшләгәнегезне дә хәтерлим.

Ул җанланып китте. Эре кулларына таянып, якынрак, караватт кырыенарак күчте.

— Бер заман минем кислород бетте. Балон инде, үзең беләсең. Өченче катта эшлим, ашыгыч эш. Цех начальнигы сәгать саен белешеп кенә тора... Ну, төштем аска. Балонны арбага салдым да лифт-

ка килдем. Лифт эшләми. Электрик артыннан йөрсәң тагын бер сәгать үтәчәк. Күп уйлап тормастан, мендем дә киттем өченче катка балонны иңгә салып... Ә балонда туксан алты кило.

Ул сүрән генә елмаеп куйды.

— Мин сезнең турыда сөйләп малайларга мактана идем... Хәтерегездәме, Кадыйр абый, ишегалдында стена ишелде. Бер кисәген вата алмый интектеләр. Ә сез тоттыгыз да берүзегез капка төбенә тәгәрәтеп чыгардыгыз.

— Хе-хе-хе.

Кадыйр абый күңелле генә кеткелдәп куйды. Игътибар белән мин аны күзәтәм. Тамырлары бүрткән зур кулларына, чал бөдрәләр каплаган киң күкрәгенә, нык муенына карап, картта әле дә баһадир чалымнарын табарга була иде.

Күрше бүлмәдә чырт-чырт иткән сәер тавышлар чыгарып эт йөргәне ишетелде. Менә эт безнең янга килеп керде. Миңа сагаеп бер карады да, хуҗасына якынаеп, озын тырнаклы тәпиләрен караватк кырыена куйды. (Сәер тавышны озын тырнаклары чыгара икән.) Кадыйр абый аның кара башын сыйпады. Эт койрыгын болгый-болгый, төймә кебек күзләрен җемелдәтеп, хуҗасының бармагын ялап алды.

— Кызым алып кайтты,— диде ул, эткә ымлап.— Апаң эштә чакта күңелсез. Болай, ичмаса, янында җан иясе...

Эт, куанычыннан чинап, караватка сикереп менергә чамалый иде.

— Ярамый, бар уйнап кил,— дип, Кадыйр абый аның башын сак кына читкә этәрде. Эт теләр-теләмәс кенә тәпиләрен идәнгә төшерде, миңа карап алды һәм, буяулы идәнгә чырт-чырт басып, бүлмәдән чыгып китте.

Кадыйр абый гомер-гомергә эт яратты, эт асрады. Бигрәк тә зур овчаркаларны ярата иде ул. Медальле этләренең кайберләрен мин дә хәтерлим әле.

— Кадыйр абый, сезнең Саргон исемле этегез бар иде. Кайда ул хәзер?

— Чик сакларга алдылар. Яраланды ул. Хәзер картайгандыр... Минем шикелле.— Бераз дәшми торганнан соң:— Бәлки үлгәндер дә,— дип өстәде.

— Кызык итте ул мине бер вакыт...— Мин көлә-көлә күптән үткән бер хәлне сөйләп киттем.— Ремеслода укып йөрим. Өстә кара форма, ялтыравыклы тимер төймәләр. Бер көнне ниндидер йомыш белән сезгә килеп кердем. Әле иске квартирда торасыз. Базар янында. Сездә ишек бикләп йөрү юк иде бит. Кердем дә, кеше булмагач, кире чыгыйм дисәм, ишек төбендә бозау хәтле эт. Багана кебек каттым да калдым. Селкендем исә ырылдап куя.

Кадыйр абый елмаеп тыңлый, йөзендәге җыерчыклары тарала. Ул миндәргә сөялебрәк утыра.

— Шуннан... Нәрсә булып бетте соң?

— Сәгатьтән артык Саргонның кызыл теленә карап тордым... Ярый әле Гайшә апа кайтып керде. Аяк тәмам каткан иде инде.

— Акыллы эт иде шул. Аның турында миңа заставадан да яздылар. Мактап.

— Кайдан таптыгыз шундый исемне? Матур бит — Саргон.

— Күрше малае кушты аны. Тарихчы ул. Тупан заманда Саргон исемле патша булган ди. Миңа да ошады.

Ишектә кабат Гайшә апа күренде.

— Әйдәгез, өстәл янына, чәй әзерләдем,— диде ул һәм, картына аркасын куеп, караватк кырыена килеп утырды. Кадыйр абый аны кочаклап алды. Гайшә апа, картын аркасына асып, күрше бүлмәгә алып чыгып китте һәм урындыкка китереп утыртты. Урындыкны мин өстәл янына этәрдем.

III

Чәйдән соң Кадыйр абыйның балконга чыгып утырасы килде. Гайшә апа гардеробны ачты да, медальләре, орденнары зеңелдәп торган карасу-зәңгәр китель тартып чыгарды. Кадыйр абыйның сугышта булып, күп кенә бүләкләр алганын белсәм дә, бу кадәр үк дип уйламый идем. Күбесен беренче тапкыр күрүем.

— Әйдәле, әтисе, кителеңне киеп куйыйк әле.

— Әй, киеп тормыйм ла, карчык, әнә чөйдән пинжәкне генә алып бир дә, чыгыйк.

— Юк, әтисе, киясең, үз бәйрәмеңдә дә кимәгәч, тагын кайчан киярсең?

Гайшә апа кительне җайлап, картына ишарә ясады.

— Әйдә ки, күршеләр алдында минем дә күңелем булыр.

Гайшә апага кушылып мин дә кыстадым.

Кительне киеп, җиз төймәләрен дә эләктереп куйгач, Кадыйр абый үзгәреп китте. Ул орденнарын сыпырып, рәтләп куйды. Безнең сокланып карап торуыбыз күңеленә бигрәк тә хуш килде, ахрысы.

Аны балконга чыгарырга талпынып карасам да, Гайшә апа:

— Юк-юк, Мөнир, мәшәкатьләнмә, мин аңа күнеккән инде,— дип каршы төште. Кунактан күтәртүне яхшысынмадымы, әллә ышанып тапшырырга шикләндеме — аңламадым.

Ул картын баягыча аркасына асып, балкондагы киез түшәлгән урындык өстенә чыгарып утыртты. Мин дә шунда чыктым.

Без чәйләп утырган арада, кояш күтәрелә төшкән. Күкләр аяз. Һавада бөре исе. Ишегалдындагы топольләрдә ямь-яшел яфраклар күренә. Аста чыр-чу килеп бала-чага уйный. Өстәге каттан «Бони М» ритмнары ишетелә. Без Кадыйр абый белән язгы кояшта иркәләнеп тын гына шушы авазларны тыңлыйбыз. Аның сөякчел кулы балкон култыксасында. Күзләре бераз кысылган, йөзендә рәхәт изрәү. Ниләр уйлый икән ул бу минутта? Өч сугыштан исән кайткан солдат бу минутта ниләр уйлый икән? Бәйрәм итүчеләр балконда кояш җылысында таралып утыручы бәхетле картны күрә торганнардыр. Карт исән-сау, күкрәгендә орден-медальләр, димәк, барысы да тәртиптә. Ул лаеклы ялда һәм бу күренеш берәүгә дә сәер тоелмый, берәүне дә сагайтмыйдыр, мөгаен. Ләкин сугышны үткән һәрбер кеше, хәтта ут эченнән исән-имин чыккан очракта да, күңелендә ниләр генә йөртми торгандыр. Мин өметләнеп аның йөзенә карыйм. Ләкин кояшта җылынып утыручы картны гына күрәм. Минем аны сөйләштерәсем, тыңлап утырасым килә. Гомумән, яратам мин картларны тыңлап утырырга. Хикмәтле халык. Тик сөйләштерә генә белмим.

Ул күзләрен ача, изүен чишеп җибәрә. Китель астыннан бинттай пакь күлмәге күренә.

— Көннәрең ничек үтә, Кадыйр абый?— дим, картның ачылып китүенә өметләнеп.— Гайшә апа да эшләгәч, күңелсездер берүзеңә?

— Күңелсез дип... кеше күнегә ул. Апаң да ике-өч сәгатькә генә барып кайта, тулы көн эшләми. Эшләмәскә иде дә бит, гел өйдә утырасы килми торгандыр. Гомер буе кеше арасында эшләп өйрәнгәч, авыр ул өйдә утырулары.

Ул бер араны яшәрә башлаган агачларга карап торды. Аннан авыр сулап:

— Барысы да шул сугыш бәласе,— диде.

— Сез элек бер дә авырып-нитеп йөрми идегез бит, Кадыйр абый?

— Анысы шулай... Сугышта аяк өшеде бит минем.

— Шулаймыни. Ничек булды соң ул?

— Ул, энекәш, Балтик буенда булды. Анда валуннар күп. Белә

торгансыңдыр. Шоп-шома таш, гранит. Мунча хәтлеләре дә, аннан зурраклары да бар.— Кадыйр абый кабат кулларына таянып җайлабрак урнашты.— Нишли фашист? Ташны чокып, эченә пулеметчы урнаштыра. Якын килеп кара син шуннан соң. Валунны бит аны пуля да, гранат та, хәтта снарядың да алмый. Рикошет ясап читкә оча да тора. Менә шунда мине яралады да инде. Ятам. Кыймшанып та булмый. Суык. Пулемет иптәшләрне якын да җибәрми. Безнекеләр килеп алганда аякларны сизми идем инде.

Аста магнитофон акырырга керешге. Үрелеп карасам, подъезд ишегеннән чуар киенгән яшьләр төркеме чыккан да, түгәрәк ясап, киңәшеп торалар. Бераздан, кулларын кесәгә тыгып, ашыкмый гына китеп тә бардылар. Магнитофон тавышы да тоныклана төште.

— Аягыңны ничек саклап калдылар соң?

— Кисмәкче иделәр дә, бирмәдем. Үгетләп тә, ачуланып та карадылар. Барыбер бирмәдем... Уйлыйм-уйлыйм да, күз алдыма Гайшә апаң янына аяксыз кайтып керүем килеп баса. Ну, мәйтәм, бу килеш кайтканчы, ятып калуың хәерле... Рәхмәт врачларга, тырыша торгач, аякка бастырдылар тәки.

— Белмәсәң, бер уйламассың, Кадыйр абый.

— И-и, энекәш, сугышта күргәннәрнең барысын да сөйләп йөреп булмый ул. Үзем шикелле картлар белән гәпләшеп утырганда әллә ниләр хәтергә килә. Үзем дә гаҗәпкә калам...

Шунда сугыш еллары кинохроникасын караганда күземә яшь килеп тыгылганы исемә төште. Экран сугышның кара һәм авыр хезмәтеннән михнәт чигүче гади солдат турында сөйли. Бу газаплар өчен кем орден алган да, кем шөһрәт казанган, дип уйлаганым хәтердә. Ул минутта алар минем өчен чын геройлар иде. Билгесез геройлар...

— Әйе... Менә бүген иртән подъездда күршем Хәмит абыйны очраттым. Карыйм, түше тулы орден-медаль. Шаклар каттым... Мин аны гади бер карт дип йөри идем...

— Гадиләр булдыра да инде аны.

Уйламый әйткәнемә уңайсыз булып китте. Моны Кадыйр абый да сизенде. Киеренкелекне бетерер өчен, ахрысы, сүзен дәвам итте.

— Сугыш ни заманнар үткәч тә китереп суга икән ул. Пенсиягә чыккач, бер уйламаганда сул аяк корый башлады. Бу юлы инде кистеләр. Шунсыз булмый диделәр. Тынычланган гына идем, менә бусы...

Кадыйр абый ботын учлады, угалап йомшарткандай итте.

— Элек борчый идеме соң?

— Һавалар алышынганда гына. Алай зарланырлык түгел. Организм нык булган, энекәш. Көрәшкән, күрәсең.

Без шактый вакыт сүзсез утырдык. Һәркем үз уйларына чумды. Күрше балконда джинсы костюм кигән ике кыз күренде. Чиратлашып сигарет кабыздылар, буйга калкурагы, башын кинәт чайкап, күкрәгенә ишелеп төшкән саргылт чәчләрен артка чөйде. Аннан икесе дә култыксага ялкау гына таянып, нечкә озын бармакларын читкә тырпайткан килеш нәзакат белән тарта башладылар. Бераздан яннарына озын буйлы, ыспай сакаллы акселерант чыкты. Ул уйныйшаяра кызларны билләреннән эләктерде һәм кочаклап алды. Кызлар исә, егетнең аркасына юри генә бер-ике шапылдатып, кулыннан ычкындылар да, кызу-кызу сөйләшергә керештеләр.

Без икебез дә аларны күзәтәбез.

— Син миңа, энекәш, Жуков китабын табып китер әле. Хәзер вакыт күп, укыйсы килә шуны.

Мин китерергә вәгъдә бирдем.

— Урын өстендә утыруның да кызык ягы бар икән. Элек уйла-

мыйчарак яшәлгән, хәзер шуларны кайтарып утырам. Таза, сау чакта артык уйланмыйсың бит аны. Акылны артык җикмисең. Безнең буынга укуы да чамалы гына эләкте. Яшьтән эшкә ябыштык. Шуның белән канәгать идек...

— Сезнең буын күрде инде ул. Сугышы да, башкасы да... Картлар шуңа яшьләрне сүгә торгандыр.

Мин, мәгънәле елмаеп, күрше балкондагыларга ымладым.

— Хе-хе... Сүгәләр дисеңме? Безне дә бит яшь чакта күп сүктеләр. Аңа карап сынатмадык. Вакыты җиткәч, илне дә саклап калдык, тормышны да аякка бастырдык...

Кадыйр абыйга мин сокланып куйдым. Карт башына төшкән сынаулар аның табигатен бер генә дә үзгәртмәгән. Ул һаман да мин белгән Кадыйр абый булып калган. Сүзен төшереп калдырмаска тырышып, аны тыңлыйм.

— Яшь чакта да бер тилереп калмагач, нинди яшьлек ди ул? Эшкә җигелгәч, барысы да үтә. Карт көнеңдә яшьләрне тиргәп утыру да кирәкле нәрсә түгел. Безнеңчә яшәмәсләр бит инде. Аңларга кирәк...

Язгы көнгә хозурланып, без шактый утырдык. Сүзебезне Гайшә апа бүлде. Балкон ишеген ачты да:

— Җитәр, этисе, күп утырдың, җил тия күрмәсен үзеңә. Язгы һава алдаучан була ул,— диде.

Кадыйр абый, нишлисең бит дигәндәй, миңа мәгънәле генә карап куйды. Аннан кулын карчыгына сузды, Гайшә апа аны, баягыча күтәреп, бүлмәгә алып кереп китте.

Миңа кузгалырга вакыт иде. Кадыйр абыйны җилкәсеннән тагын бер сөйдем дә китәргә җыендым.

— Ешрак кил, энекәш.

— Яхшы, Кадыйр абый, килермен.

Саубуллаштык та, чыгып киттем.

Ишегалдына чыккач, борылып, үзебез утырган балконга карадым. Гайшә апаны күреп кул болгадым. Ул да миңа елмаеп кул изәде.

Кадыйр абый янына мин хәзер ешрак керәм. Бигрәк тә күңелем әзләнгән, җаныма тынычлык таба алмаган чакларны кереп утырам мин аның янына. Мине күрүгә, картның җыерчыклары язылып, йөзе ачылып китә, исәнләшергә дип ул миңа зур кулын суза. Без ашыкмый гына чәй эчәбез, дөнья хәлләре турында, узган юлы калдырган китаплар хакында гәпләшәбез. Утыра торгач, минем дә акыртынлап күңелем ачыла, бушанып калам, борчуларым онытылгандай була.

Карт яныннан мин һәрвакыт яктырып чыгам.

## Мәҗит Рафиков

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Онытыма ни бирим?

Йөгерә-көлә уйнарга
Тәти күлмәк бирим,
Балга манып ашарга
Татлы икмәк бирим,
Кеше булып яшәргә
Вөҗданымны бирим,
Эшем белән мактаган,
Канлы яуда саклаган
Ватанымны бирим.

1979

### Гармунчы дус истәлегенә

И клубта яңгырар җырларың ла,
И авылны күмәр моңнарың!..
Тальяныңа картлар таң калды,
Күзләреннән мөлдерәп яшь тамды.

Унҗидедә син дә солдат булдың,
Унсигездә яуда һәлак булдың.
Бер медалең кайткан әйләнеп,
Сүз булмаган бүтән әллә ни...

Авыл гөрли, туган өең имин,
Чал башымның бер сагышы — гел син.
Син әле дә онытылмас җырым,
Күңелемнән мәңге китмәс моңым.

И клубта яңгырар җырларың ла,
И авылны күмәр моңнарың!..

1979

## Ветеран сүзе

Күрмәгәнгә күрсәтмәсен генә!
Газаплары яуның булды күп...
Ятып калган дуслар истә чакта,
Мин батыр, дип уйлау гөнаһ күк.

1979

## Кояшлы давыл

Ветераннар! Авыраймасын әле,
сөрлекмәсен безнең адымнар.
Сугышларны Җирдән себереп ташлар
кояшлы бер шундый давыл бар —
ал байраклы давыл,
өндәүләре:
«Хезмәттәшлек! Дуслык! Иминлек!»
Утка керер чакта без шул хакта
Ватанга ант иткән идек бит.
Җиңел сулап җибәрсен лә иде
Барлык илләр, халык, кавемнәр!..
Тантанасын күреп булмас микән,
яшик әле, шундый давыл бар...

1979

## Әти белән без икәү

Әтием карт чабата тукыган,
Көтү көткән,
Чәчкән, урган, өен бурап кергән,
Сату иткән,

Укытучы, ревизор да булган,
Агитатор...
Пычкы, ышкы, алмазларын әле
Шәп уйнатыр!
Кушсаң әгәр, өч тәүлектә ясап
Бирер сиңа
Космик кораб — тик төрт филтәсенә
Шырпы гына...

Мин, уңмаган, кадак белән бутыйм
Бармак башын.
Кая миңа ышкы, пычкы, алмаз,
Агач-ташы!

Әмма үзем һәрбер яхшы эшне
Зурлыйм, сөям —
Барсын эшлим... кулымдагы шушы
Каләм белән.

1969

## Хыялбай мин...

Хыялбай мин. Кәмитләрем
Бер төрле минем һаман.
Мещан җанлы астыртынга
Яхшы булып алданам.

Әүвәл ул да чын ихластан
Яхшы булып күренә —
Җан атам мин! Ә соңыннан
Гарьләнәм дә көенәм.

Угрыны җан дус итеп
Өйгә алган бәндә мин.
Тумыштандыр — гомерем буе
Шундый кызык хәлдә мин.

Бик беләм лә: юк, килешми
Явызлыкка яхшылык!
Ә гамәлдә өч көн үтми,
Кабатлана нәкъ шул ук...

1977

●

Ерак чикләр аръягында,
әллә кайдадыр
кемдер йөри — әллә өрәк,
әллә шәүләдер...
Абына ул, сөртенә ул
чит-ят чатларда.
Юл табалмый, кайта алмый
туган якларга.
Сынган, сулган... Исеме калыр
шунда адашып...
Тик мәңге әрнер ананың
йөрәк ярасы.

1970

## Мәхәббәтнең ние бар?..

Мәхәббәтнең ние бар?
Уены бар, чыны бар.

Уенына тиң килер
качар-посар юлы бар,
вөҗданыңны кыярга
пычагы бар, кыны бар,
төн йокысыз сыктарга
ятиме бар, толы бар...

Тугрысына тиң килер
татлы кайнар тыны бар,
көн дә җырлап туйгысыз
якты моңлы җыры бар,
шапылдатып сөяргә
кызы бар да улы бар!

1979



*Донбасста тусам да, балачагым республикабызның Балык Бистәсе районы Иске Арыш авылында үтте. 1954 елда шул ук районның Олы Солтан урта мәктәбен тәмамлап, Казанга килдем. Техник училищеда укыдым. Тора-бара төзүче-инженерлар институтына керергә туры килде. Төзелештә мастер, прораб, өлкән прораб булып эшләдем. Хәзерге көндә — баш инженер.*

*Вакыт кытлыгы кичерәм. Әлегрәк языл-ган әйберләрне кабат караштырып чыгасы бар, яңалары да туып тора. Ә тәүлектә бары тик егерме дүрт сәгать...*

## Әхәт Сафиуллин

# ГЕЛ ЗӘҢГӘР БУЛМЫЙ КҮКЛӘР

хикәя

### 1



Иңнәрен алма, чия һәм шомырт чәчәкләре белән бизәп яз да килде. Тәнгә җиңел, күңелләрдә күтәренкелек, һаваның сафлыгыннан башлар әйләнә.

Рафаэль төзетә торган йорттан инде ташчылар китте, хәзер монда штукатурчы кызлар бригадасы эшли, йорт тирәсенә асфальт җәелә, газоннарга куаклар утыртыла.

Иртә белән бу мәһабәт йортка карый-карый эшкә килүе Рафаэль өчен зур шатлыкка әверелде. Беренче «карлыгач»ын дәүләт комиссиясе хөкеменә тапшырырга да күп вакыт калмый бит инде!

Прораб белән вакыт-вакыт сүзгә килсәләр дә, инде аларга да күнегә башлады Рафаэль. «Йортны эксплуатациягә тапшырырга да әкренләп институтка әзерләнә башларга кирәк...»

Иртән эш шундый уйлар белән башланып китте, ләкин күп тә үтмәде, йортта бик каты ухылдау тавышы ишетелде. Рафаэль сискә-

неп куйды, язып утырган «Эш журналы»н өстәлдә калдырып, вагоннан атылып чыкты. «Нинди тавыш бу? Ни булды?»

Аңа таба эшчеләр йөгерә иде. Ул ни булганын сорарга да өлгермәде, штукатурлар бригадиры Аня — үткен булганы өчен аны «пәке тел» дип йөриләр — кабаланып әйтеп салды:

— Тизрәк ашыгыч ярдәм машинасы чакыртыгыз!.. Асия белән Рита кирпеч астында калдылар... Зинһар, тиз булыгыз...

Рафаэль, кире вагонга кереп, калтыранган куллары белән телефон трубкасын эләктерде дә, ашыгыч ярдәм чакыртты, идарәгә шалтыратты һәм кемнедер күрше объектка прораб янына йөгертте. Тик шуннан соң гына этажга менде. Юк, менмәде, очып күтәрелде диярсең...

Күз алдында коточкыч картина иде: түшәм плитәсе урталай сынып төшкән, аның өстендәге бүлем ишелеп, өстәмә авырлыкка чыдый алмыйча аскы катның да өч плитәсе ярылган килеш асылынып тора.

«Әйткән идем бит...» дигән уй Рафаэль башында яшендәй ялтырап алды. Кинәт күз аллары караңгыланды да, ул, егылмас өчен, стенага таянды.

Бүлемне штукатурлаучы кызлардан берсенең аягы сынган, икенчесенең сул кулы имгәнгән һәм битләре җәрәхәтләнеп беткән иде. Аларны, кирпечләр арасыннан алып, зур саклык белән аска төшерделәр һәм больницага озаттылар.

— Әй-йе-е, бу хәл безне бер-ике айга артка чигерде бит әле,— диде прораб, авария картинасын күргәч.— План янды болай булгач...

— Аны һаман план кызыксындыра. Башта яралы кешеләрнең хәлен белешер идегез, Игорь Васильевич?!— дип, ачу белән әйтеп салды шунда «пәке тел».

— Яралы? Кемнәр, ни хәлдә алар?

— Ике кыз иде, больницага озаттык,— диде Рафаэль, дерелдәгән иреннәрен ачар-ачмас кына.

Игорь Васильевич, кырт борылып этаждан ашыга-ашыга төшеп китте. Вагонына Рафаэль кергәндә, ул ике кулын артка куеп әрлебирле йөренә иде.

— Карале, син ашыгыч ярдәмнән башка бер кая да шалтыратмагансыңдыр бит? — диде кинәт.

— Ничек? Идарәгә дә шалтыраттым,— диде Рафаэль, башын гаепле сыман аска иеп.— Шулай кирәктер дип уйлаган идем.

— Алайса ишкәнсең икән ишәк чумарын. Прокурорның үзенә үк шалтыратасың калган?!

Рафаэль бер нәрсә дә аңламыйча гаҗәпләнеп калды.

«Чыннан да, бәлки прорабны котәсе булгандыр... Ялгышлык эшләдем, ахрысы» дип, ул эченнән генә үзен-үзе тиргәп алды.

## II

Шул ук көнне авариянең сәбәпләрен ачыклау өчен төзүче-инженерлар институты профессоры Скворцов җитәкчелегендә комиссия эшли башлады.

Каяндыр килеп чыккан тикшерүче, егерме биш яшьләр тирәсендәге ир-егет, Рафаэльне машинага утыртып алып китте.

— Анда безгә беркем дә комачауламас,— диде ул, машина ишеген ачып һәм кулы белән каядыр ишарә ясады.

«Анда» дигәне район эчке эшләр бүлеге булып чыкты.

— Сез әле ярты ел чамасы гына эшлисез икән,— диде тикшерү-

че, бүлмәсенә кереп утыргач.— Беренче адымнар һәм... авария... Кеше гомерен чебеннекенә саныйсыз мәллә?

Рафаэль бөтен гәүдәсе белән калтыранып куйды, гүя тәнен урак белән сыдырып алдылар.

«Менә мине инде җинаятьче дип саныйлар... Җи-на-ять-че!.. Коточкыч сүз?! Нинди хурлык...»

— Тулы аңлатма язygыз. Искәртеп куям: дөреслек һәм бары тик дөреслек! — дип, тикшерүче Рафаэль алдына берничә бит кәгазь куйды.— Мин бераздан керермен,— диде дә чыгып китте.

Рафаэль, бер алдында яткан ак кәгазьләргә, бер ручкасына карап, уйга калды. «Ничек, нәрсә дип, кайдан башлап язарга?» Шул мизгелдә аның күз алдына объектка беренче мәртәбә аяк баскан, күңелдә зур дулкынлану һәм шатлык тудырган көзге көн килде.

...Җил шашынып-шашынып коелган агач яфракларын куа, ярсулык белән әләктереп ала да, һавага күтәрә, туйганчы бөтерә, аннан кинәт туктап кала һәм яфраклар җиргә төшәргә ашыгалар.

Участок начальнигы белән төзелеш мәйданына килеп җиткәндә, эш күптән башланган иде инде. Көянтәсен югары күтәргән кранның авырлыктан зарлангандай ыңгырашуы, кирпеч салучы ташчыларның җитди йөзләре, сигналчы кызның җитез хәрәкәте — беренче булып Рафаэльнең күзләренә чалынган нәрсәләр шул булды. Туп-туры прораб вагонына керделәр.

— Менә сиңа мастер алып килдем, Игорь Васильевич,— диде участок начальнигы, өстәл артында утыручы утыз биш-кырык яшьләр чамасындагы ир кешегә төбәлеп.— Әле яңа гына техник училищедан — тәҗрибәсе юк. Димәк, аны яхшы мастер итү синең бурыч. Кайра син аны, Игорь Васильевич, шәпләп чарла производство кайрагы белән!

— Үзендә теләк булса, тырышырбыз аны, Александр Борисович,— диде прораб һәм, урыннан торып, Рафаэльгә кулын сузды.— Сүзегездә торганыгыз өчен рәхмәт. Үзегез беләсез, объектлар күп, өлгереп булмый.

Прораб Шестаков — саргылт чәчле, тулы гәүдәле таза ир. Баш түбәсендә, ни сәбәптәндер, чәчләре сирәгәйгән. Ләкин Рафаэльне гаҗәпләндергән нәрсә аның чәче түгел, ә куллары булды: көрәк кебек зур һәм тимердәй каты иде алар.

— Я мастер, бергә эшли башлыйбыз алайса,— диде прораб, участок начальнигы чыгып киткәч.— Хәзер менә шушы йортны төзергә тиешбез.— Ул стенага эленгән фасад сызымына юан бармагы белән күрсәтте.— Менә проекты. Өстәлнең уң ягына өеп куелган кәгазь өстенә сукты.— Өйрән, төшен... Тизрәк булу кирәк — вакыт тар: минем өстә әле тагын ике объект.

Рафаэль проектны кулларына зур дулкынлану белән алды. Альбом итеп теркәлгән бу сызымнарда ул инде төзелеп беткән йортны, аңа күчеп килүче кешеләрнең шатлыгын, ишегалдындагы матур мәйданчыкта чыр-чу килеп уйнаучы балаларны күрде сыман. Проектның яңа битләрен ачкан саен йөзе яктыра барды һәм ул үзен бу төзелештә бик кирәкле кеше итеп сизде.

Әйе, аның беренче эш көне күтәренке күңел белән, матур башланып киткән иде. Әмма моның тикшерүче сораган аңлатмага катнашы юк шул. Аңа бит сынып төшкән плитә турында язарга кирәк.

«Эх, шул чакта плитәне кранга әләктереп үзем генә алып ташлаган булсам...» Шундый үкенечле уй белән Рафаэль әле бер генә сүз дә язылмаган ак кәгазьләрнең берсен алды да, ярык плитә монтажлаган көнне исенә төшереп, аңлатманың беренче юлларын сырлый башлады. Ә ул көн хәтердә бик яхшы сакланган, аңа һаман тынгылык бирми иде.

Ярык плитәне урынында тапмагач Рафаэль туп-туры этажга менде һәм плитәнең инде монтажлап та куелганын күреп, ачу белән бригадир Салаватка дәште:

— Мин бу плитәне менгезмәскә кушкан идем. Ник икәнен дә беләсез — ул ярык. Аңлыйсызмы — ярык. Ниткән башбаштаклык бу?! Хәзер үк кире алып штабельгә төшерегез.

Бригадир исә эре кыяфәт белән, бер дә борчылмыйча тезеп китте:

— Сез киткәч, төшке ашка барышлый монда Игорь Васильевич кергән иде. Мин плитәне күрсәттем, мастер монтажлауны тыйды, дидем. Ә ул монтажларга кушты. Армиядә шундый тәртип бар,— «Минем армиядә булмаганга төрттерә, ахры, бу» дип уйлап куйды Рафаэль — приказның соңгысы үтәлә. Факт. Менә без аны чәпелдәтеп тә куйдык. Ә кире алу мәсьәләсенә килгәндә — безгә бит акчаны эш башыннан түлиләр, ә акчаны безгә, ни әйтсәгез дә, Игорь Васильевич яза. Факт.

«Менә эш нәрсәдә икән,— дип маңгаен кашып куйды Рафаэль,— прораб монтажларга кушкан. Ләкин ул аңларга тиеш иде бит...»

Мәсьәләне ачыкларга прораб янына төшеп китте мастер.

Игорь Васильевич аны сызымнар актара-актара игътибарсыз гына тыңлады. Аннары, башын күтәреп, нindидер кимсетү катыш елмаеп:

— Мин, Рафаэль дус, институт бетергән кеше. Беренчедән, плитәнең аскы өлеше түгел, өсте ярылган. Ә бит, беләсеңдер, плитәнең тотнаклы зонасы —аскы зона. Бу — икенчедән.

— Анысы аңлашыла, Игорь Васильевич, тик ярты кирпеч калынлыгындагы бер бүлем нәкъ шул плитә өстенә туры килә бит.— Рафаэль, сызымны алып, шул бүлемне күрсәтте.— Димәк, өстәмә авырлык дигән сүз. Шулай булгач...

Игорь Васильевич аның сүзен бүлде:

— Эээ, егет. Үз гомеремдә мин аларны — прораб бармагы белән түшәмгә күрсәтте,— күпме монтажлаган инде. Ярыгын да, ярык түгелен дә. Сезгә, яшьләргә, бөтен нәрсә фән буенча булсын... Хәер, баштарак мин үзем дә шундый идем. Ә соңыннан, Рафаэль дускай, план сине әлеге плитә белән ташлар-кирпечләр арасына кыстырып шомарта башлый. Менә күрерсең, бер заман, төзелеш мәйданы сине дә ялтыратып шомартыр әле... Борчылма юкка. Бу төзелеш өчен мин җаваплы, чөнки мин прораб, ә син мастер гына.

Сүз шуның белән бетте дигән мәгънәне аңлатып, Игорь Васильевич кулларын җәеп алды.

## III

Гаять караңгы һәм тынгысыз көннәр башланды Рафаэль өчен. Йокысы качты, объектка күңеле тартмый, киресенчә, әле генә мәет чыккан йортка охшап калды хәзер биш катлы бу йорт. Кая карама, ни турында сөйләшмә, үч иткәндәй, уйлар һаман шул авария тирәсендә бөтерелә дә бөтерелә. Җитмәсә, тикшерүчесе дә еш чакырып кәефне боза...

— Сез аңлатмагызда ярык плитә кую турында язасыз. Моны эксперт комиссиясе дә раслый,— диде ул, өстәлдә яткан йомгаклау актын сузып. Рафаэль җиңелчә калтыранган кулы белән актны алды да йотлыгып укырга керешге. Бер урынга җиткәч, тукталып тагын укыды: «Арматураның инде күгәреп өлгерүе, сынган урынның иске булуын, плитәнең монтажлаганчы ук ярылганын күрсәтә».

— Менә, әйттем бит мин сезгә!..

Рафаэль ниндидер җиңеллек сизеп, җанланып китте. Тик тикшерүче генә аңа бик сәерсенеп карап куйды:

— Аңламыйм, сез нигә куанасыз соң әле? Акт бер дә сезнең файдага түгел бит. Бәхетле очрак аркасында гына ике җан иясен теге дөньяга алып китмәгән, фәкать сезнең эшкә салкын каравыгыз аркасында монтажланган плитә.

Тикшерүче урыныннан торды да, ике кулы белән өстәлгә таянып, гәүдәсен бераз алга иде һәм кискен генә сорап куйды:

— Ул ярык плитәне куярга ярамавын бригадирга һәм прорабка әйтүегезне ничек исбатлый аласыз?

— Бу турыда мин блокнотыма гына язып куймакчы идем дә,— диде Рафаэль, тикшерүчегә туп-туры карап.— Ләкин прораб белән файдасыз сөйләшүләрдән соң «Эш журналы»на искәрмә язып куйдым. Ләкин бераз вакыт үткәч, прораб аны, очраклы рәвештә күреп, сызып ташлады.

Рафаэль, минем сүз бетте дигәндәй, башын аска иде. Тик береаздан бик кирәкле нәрсәне хәтеренә төшергәндәй, башын күтәреп, ашыгып кына өстәп куйды:

— Журналдагы язуны лабораториядә укып була торгандыр бит?

— Журналны вагонда тапмадылар. Минем сезгә ышанасы килә, ләкин...

— Ни-чек тапмадылар?

— Әйе, ул юкка чыккан. Менә бу факт шикләндерә мине.

— Карагыз әле, журнал берничә көн инде күренмәгәч, мин дә прорабтан: «Журнал кайда?» — дип сораган идем, ул: «Милиция алгандыр»,— дип җавап бирде. Шуңа мин аны чыннан да сездәдер дип йөрим бит.

— Юк, журнал бездә түгел.

Бу хәбәр Рафаэльгә аяз көндә яшен суккандай тәэсир итте. Журналны юкка чыгару кемгә кирәк булды икән? Ни өчен? Язманы Игорь Васильевичның сызып ташлавын яхшы хәтерли бит Рафаэль.

...Ул көнне төштән соң вагонга бераз «кәефле» килеп кергән прораб журналдагы язуны күреп кинәт кызарынды һәм өстәлгә сугып куйды.

— Бу нинди фокус тагын? Син архивта эшлисеңме, әллә төзелеш мәйданындамы?

Рафаэль сискәнеп китте.

— Менә монда кара, монда,— дип, прораб юан бармаклары белән журналдагы язуга төртте.— Плитәнең ярык икәнлеген кем яза инде журналга?.. Һәм, кесәсеннән кабалана-кабалана авторучка чыгарып, искәрмәне сызып ташлады.— Синең төзелешкә килгәнеңә күпме соң әле?! Шестаковның кем икәнен монда яхшы беләләр. Ә син кем?..

— Ник кычкырырга, Игорь Васильевич? Бу бит факт. Сезгә әйткән дә идем...

— Син шуны онытма, энекәш: монда мин сиңа әйтәм. Мин сиңа,— ул юан бармагы белән башта үз күкрәгенә төртте, ә аннан соң Рафаэльгә күрсәтте.— Чөнки мин хуҗа. Моннан соң бел аны, зам-полит...

Бу «сөйләшү» вакытында Рафаэль янәшәдә басып торган Салаватка карап алды. «Бәлки ул берәр нәрсә әйтер?» Ләкин бригадир ләм-мим — силикат кирпечен кайчан китерәчәкләрен ачыклады да чыгып китте.

«Соңгы приказны үтәүче» дип, күңелсезләнеп карап калды Рафаэль аның артыннан.

«Чыннан да артык четерекле кеше, ахрысы, мин... Ул бит күп йортлар салдырган инде...» Рафаэль үз-үзен тынычландырырга тырышты.

— Сез миңа башка берәр нәрсә әйтергә теләмисезме? — дип, тикшерүче Рафаэльнең уйларын бүлде.

— Юк, башка бернәрсә дә өсти алмыйм. Минем бит мондый ситуациягә эләккән юк иде, ни дияргә дә белмим инде... Әйткәнемчә, авария көнне сездән кайткач «Эш журналы»н эзләдем, таба алмагач прорабтан сорадым. Ләкин ул миңа көлемсерәп карап торды да, кырыс кына:

— Нәрсә? Авария турында язмакчы идеңме әллә? — дип сорап куйды һәм минем җавапны көтеп тә тормыйча өстәде: — тикшерүче алгандыр...

— Карагыз әле, журнал булмаса, плитә турында прораб белән бригадирның үзләреннән сорап ачыкларга була бит.

Ләкин тикшерүче көлемсерәп кенә куйды һәм салкын гына итеп:

— Кемнән нәрсә ачыкларга икәнен үзебез беләбез,— диде һәм сөйләшүнең бүгенгә беткәнен аңлатып урыныннан торды.

## IV

Тулай торакта яшәүче буйдак егетләр алдына җитди мәсьәлә килеп баса: иртә-кичен кайда ашарга? Моны һәркем үзенчә хәл итә, кайсы ашханәгә бара, кайсысы буфетка гына, өченчеләре кастрюль шалтыратып нәрсә булса да үзләре әмәлләп алалар.

Рафаэль тәмле ис чыгарып торган кастрюлен тастымал белән тотып кухнядан коридорга чыкканда чак кына кешегә бәрелми калды. Караса, Миңнуллин басып тора, аның бригадасыннан.

— Ә-ә-ә, Миңнуллин, пешерә яздым ич үзегезне.

— Исәнмесез, Рафаэль Мингазович.

Болай кинәт кенә очрашудан ул ничектер каушап калды.

— Минә сезгә... килә идем, Мөмкинме?

— Нишләп сорап торасыз. Әйдәгез, әйдә, мактап йөрисез икән әле, менә аш та өлгерде.

Алар бүлмәгә керделәр.

— Шактыйдан күргәнем юк инде сезне, Миңнуллин. Сөйләгез, эшләр ничек бара сезнең яңа объектта?

— Мин бөтенләй башка нәрсә турында сөйләшергә дип кергән идем әле... Эшләр бара... Бер шатлыклы хәбәр ишетеп, сезгә рәхмәт әйтергә дип керүем иде дә, бик уңайсыз хәл килеп чыкты бит: миндә шатлык, ә сездә?..

— Сез ерактан урамагыз әле, Миңнуллин, нинди шатлыгыгыз бар? Нинди рәхмәт ул тагын?

— Миңа квартира бирделәр бит, Рафаэль Мингазович. Чын күңелдән бик зур рәхмәт инде сезгә.

— Шулай диләр аны. Мин бик шат, Миңнуллин. Ләкин монда минем ни катнашым бар?

— Э-э-э, Рафаэль Мингазович, мин барысын да беләм бит. Идарә начальнигы да, постройком председателе дә әйттеләр. Тик шунысы гаҗәп: идарә начальнигы сорый, әллә ул синең туганыңмы? — ди. Кайбер кешеләр яхшылыкны якын туганнары өчен генә эшләнә торган нәрсә дип уйлыйлар. Укымышлы гына кеше үзе.

— Карале, моны ишетүе бик күңелле. Ә минем хәлләр турында борчылмагыз. Намусым чиста.

Бераздан Миңнуллин чыгып китте. Ләкин аның шат йөзе, чандыр гәүдәсе һаман күз алдында тора иде. «Рәхмәт әйтергә кергән. Киң күңелле».

Ә бит Миңнуллин белән беренче очрашу бик күңелле булмаган иде.

— Игорь Васильевич,— дип, зәңгәр комбинезон кигән яшь кенә кыз бусагадан кычкырды. Прорабны күрмәгәч, Рафаэльдән сорады: — Гафу итегез. Прораб кайда?

— Башка объектка китте. Ә нигә кирәк иде ул?

Кыз җавап та бирмичә, дорфа гына борылып, ишеккә юнәлде. Ләкин кызыксынып туктады да сорап куйды:

— Ә сез кем буласыз соң?

— Мин мастер...— диде Рафаэль.— Әле беренче генә көнем.

— Менә нәрсә, иптәш мастер, сез стропильщик Миңнуллинны я хәзер үк өенә кайтарып җибәреп, аның урынына башка кеше куясыз, юкса мин кранда эшләүдән баш тартам.

«Бу кызчык кукташ икән», дип уйлап алды Рафаэль. «Кук» төзелештә кранны аңлата иде. Кеп-кечкенә куллар, тәбәнәк буй, кыска чәч. Кызчык дисәң дә кызчык инде, олан...

— Лаякыл исерек. Берәр бәхетсезлек килеп чыкса, кем гаепле? Күзенә ак-кара күренми — йөк күтәрткәндә читкә китеп тә тормый бит.

«Шул гына җитмәгән иде тагын. Әле мине бер кеше дә белми бит монда. Эшчеләр белән төштән соң таныштырмакчы иде прораб. Беренче сүз каткан эшчең кранчы кыз булса (ә чибәр үзе!), икенчесе исерек булсын, имеш. Прораб та кайтып җитми ичмаса».

— Игорь Васильевич хәзер килеп җитәргә тиеш. Мин аңа әйтермен.

— Ә сез нәрсәдән куркасыз? Мастер ич сез.

Кызчык зур кара күзләре белән тутырып карап торды һәм Рафаэльгә бу караштан уңайсыз булып китте.

Алар контейнерларга кирпеч төйи торган мәйданчыкка чыктылар. Рафаэль Миңнуллинны ерактан ук күреп алды. Кояш астында эшләүдән нык янган йөз, чандыр һәм озынрак гәүдәле берәү контейнерга кирпеч салган саен чайкалып-чайкалып куя иде.

— Иптәш Миңнуллин, күреп торам, болай эшләве авыр бүген. Кайтып ял итегез, ә иртәгә эшкә аек баштан килерсез.

Кулына кирпеч тоткан Миңнуллин кинәт туктап калды. Агарынган күзләре белән сынаган сыман Рафаэльгә карап торды һәм кулындагы кирпечен бик каты итеп өемгә томырды.

— Ә син кем? Ни хакың бар мине эштән куарга? — Ул абынасөртенә Рафаэльгә якынлашты.

Бу минутта Рафаэльнең эшләр шәптән түгел иде. «Чигенергә ярамый, беренче күренгәндә үзеңне ничек куйсаң, шулай китә ул аннары. Әнә бит ничәмә пар күз карый».

Миңнуллин, Рафаэльнең каршына ук килеп басып, чайкала-чайкала «бу нинди малай тагын?» дигән кыяфәт белән шактый озак карап торды.

— Мин сезнең моңа кадәр эчү-эчмәвегезне белмим, ләкин моннан соң,— Рафаэль моңа басым ясап әйтте,— моннан соң болай күрenмәгез.

Миңнуллинга нәрсә тәэсир иткәндер — Рафаэльнең катгый сүземе, әллә үз гаебен аңладымы — кире борылды да, йодрыгын кысып, вагонга таба китте.

Кран тагын ыңгыраша, шыгырдый башлады. Кызыксынып торучылар да эшләренә тотындылар.

«Менә бу танышу... Производстводан аерылмыйча гына» дип иркен сулап куйды Рафаэль.

Икенче көнне вакытын туры китереп, Рафаэль сүз башлады:

— Игорь Васильевич, мин кичә Миңнуллинны исерек булганы өчен эштән кудым.

— Миңнуллин? Кем ул? Киттеме?

— Әйе, стропальщик. Ә сез ник гаҗәпләнәсез?

Прораб, сорауны ишетмәгән сыман, бераз вакыт берни эндәшмичә түшәмгә текәлеп торды да үз-үзе белән сөйләшкәндәй әйтеп куйды:

— Сине тыңлавы гаҗәп Миңнуллинның... Салгалый шул.

— Ә нигә эчә икән ул, Игорь Васильевич?

— И-хх, егеткәй, кем белә аны, алар бит минем объектларда йөз егермедән артык. Ә мин психолог түгел. Минем — план! Аңлашыламы? План! Һәр исерек белән сөйләшергә вакыт юк.

Мәнә сиңа мә!.. Объектта куркынычсызлык техникасын саклау — иң мөһим мәсьәлә дип өйрәттеләр бит Рафаэльне, ә прораб әнә нәрсә ди.

Моңа кагылышлы мәсьәлә берничә көн үткәч үзеннән-үзе ачыкланды.

Прораб вагоннан чыкканда эшчеләр инде кайтып киткәннәр иде. Вагон янында тик Миңнуллин гына тәмәке тартып тора, кемнедер көтә, ахрысы. Яныннан Рафаэль үткәндә, тәмәкесен читкә атты да, каршыга чыгып басты.

— Өйгәме? — дип сорады ул кырыс кына.

— Өйгә дип, гомуми торакка инде,— диде Рафаэль, бераз шикләнә төшеп.

— Алайса юл уңае икән, мин дә шунда торам. Сез беркөн мине эшчеләр алдында хурлыкка калдырдыгыз бит, Рафаэль Мингазович.

— Юк, ялгышасыз, Миннуллин. Сез исерек идегез бит. Эшче намусына тап төшердегез.

— Намус... Эшче... Кайда ул намус дигән нәрсә, ә? Кайда ул? Менә мин хәзер семья янына кайтам. Әйе, эшче мин. Эшче булмасам прораб минем фамилияне бутамас иде... Ә бит семья минем, бала...— Миңнуллин, бер мәл тотлыгып торды да, тагын тезеп китте: — Менә яшәп карагыз әле сез шунда семья белән. Намус бит бөтен кешедә булырга тиеш. Мин кайберәүләрнең ишек бусагасын күпме таптап йөрим инде... Сез яңа кеше әле, белмисез. Алты ел эшлим бит. Һаман сабыр итәргә кушалар, чиге бармы икән ул сабыр итүнең?..

— Квартира мәсьәләсе авыррактыр шул,— дип бүлде аны Рафаэль,— бу турыда мин сезне тынычландыра алмыйм. Ләкин шунысын беләм: эчү белән квартира алу срогын якынайтып булмыйдыр, минемчә.

— Ярдәм өмет итеп сөйләвем түгел, үзем дә белмим, нигәдер сезгә дә әйтеп күңелне җиңеләйтәсе килде. Эчү мәсьәләсендә үзегез хак. Күп уйланам бу турыда. Ташлыйм, бөтенләйгә ташлыйм. Белмим, бәлки шуны аңлатасым килгәндер, чөнки кешене үзегезгә тарта торган ягымлылык бар сездә. Ә миңа квартираны берничә йорттан ышандырдылар. Инде шуңа күрә ышанмый да башладым. Әгәр туптуры менә, иптәш Миңнуллин, сиңа фәлән елда бирәбез, дип кисеп әйтсәләр мин дә гел йөреп аптыратмас идем...

— Мин, кызганычка каршы, бернәрсә дә ышандыра алмыйм шул, иптәш Миңнуллин.

— Юк, юк, мине тынычландырырга кирәкми. Тик теге көн өчен уңайсыз иде. Гафу итегез.

## V

Соңгы чакыртуында тикшерүче Рафаэльгә прорабның аңлатмасын күрсәтте. Анда ярык плитә турында бер сүз дә юк. Тик мастер Рафаэльнең әле тәҗрибәсез булуы, ә үзенең, берничә объекты булып, һәр

мастер артыннан карап йөрергә вакыты җитмәве турында гына язылган иде.

— Я, сезнеңчә ниндиерәк кеше ул Шестаков?— дигән сорау аны гаҗәпкә калдырды.

— Тәҗрибәле, бик күп йортлар салдырган прораб,— дип җавап кайтарды Рафаэль.

— Бу турыда аңа бирелгән производство характеристикасында язылган. Кеше буларак дим мин, кеше буларак. Катлаулы сорау иде бу.

Рафаэль күз алдына прораб белән булган кайбер күңелсез очраклар килеп басты. Бер көнне, моңа ай ярымлап вакыт үтте бугай инде, прораб, идарәгә барып кайткач, Рафаэльдән сорап куйды:

— Син анда теге исерекбаш Миңнуллинга нинди квартира даулап йөрисең?

— Даулап ук түгел инде, Игорь Васильевич, берәр нәрсә кылып булмасмы дигән ният белән хәтеренә төшергәләдем Борис Викентьевичның. Семья белән гомуми торакта яши бит.

— Исерек башка квартира сорап йөрүе үзе үк уңайсыз. Синеңчә без хәзер ниндидер бер ходатайга әйләнергә тиешмени? Аның өчен постройком бар, аңлыйсыңмы,— построй-ком... Ә безнең эш — план!

— Соң, планны шул кешеләр тутыра түгелме соң, Игорь Васильевич?

— Я ходай,— ди шунда прораб,— мастер түгел, ә замполит син...

Бу сөйләшү шуның белән бетте.

Игорь Васильевичның эшчеләргә мөнәсәбәте Рафаэльне торган саен гаҗәпләндерә бара иде. Шул эшчеләр салган йортлар яныннан үткәндә, үзе горурланып: «Мин салган йорт!» ди торгандыр әле. Ә менә кирпечләрен тезгән ташчыларның, буяу эшләрен башкарган чыр-чулы кызларның сөялле кулларын исенә төшерә микән? Юктыр, йортлар өчен үзенә алган премия акчаларын гына исенә төшерәдер кебек тоела Рафаэльгә.

«Исерек Миннуллинга квартира даулап йөрисең».

«Алар бит миндә йөз егермедән артык».

«Син аңла: безнең эш — план!..»

План — аңлашыла. Аны үтәргә кирәк. Ләкин шул планны үтәүчеләр арасында нинди кешеләр бар.

Төзелеш мәйданында репродуктор кую турында сүз чыккач, электрик Санатриев ничек тырышты: эштән калып баганалар өчен чокырын да казыды, төшке ял вакытында чыбыкларын да тартты. Ниһаять, репродуктордан беренче моңнар агылды.

— Менә тәртип!— диде Санатриев, багана башыннан төшкәч, тирләгән, сипкелле битен сөртә-сөртә. — Күптән кирәк иде.

«Күптән кирәк иде!»

Әмма радио көйләү мәсьәләсе җиңел генә хәл ителмәгәнен белми иде Санатриев.

Бу турыда сүз кузгаткач, кырт кисте бит прораб:

— Ансамбль кирәк түгелме сиңа тагын?!

— Миңа түгел, объектта эшләүчеләргә... Хәер, мин үзем дә яхшы җырлар тыңларга яратам,— диде Рафаэль.— Җыр, музыка яңгырап торганда эшләве дә күңелле.

— Моңа кадәр музыкасыз да эшләдек һәм, әйтергә кирәк, начар эшләмәдек. Узган квартал өчен премия алдыкмы? Алдык. Ә син — радио. Җыр, музыка, имеш. Ну, әйтсәң дә әйтәсең инде, зам-по-лит...

Ләкин бу юлы Рафаэль үз сүзендә нык торды. Прораб белән эш пешмәгәч, ул постройкомга мөрәҗәгать итте. Анда Рафаэльнең тәкъдимен куәтләделәр. Соңыннан исә: — Молодец,— диде председатель, Рафаэльнең кулын кысып,— менә бу безнеңчә. Эшче кеше ул үзе ту-

рында кайгыртканны ярата... Яхшылыкны йөрәгенә тирән салып куя.

Радио өчен эшчеләр прорабка рәхмәт әйттеләр.

— Тырыштык инде,— диде ул, елмайган булып, әмма Рафаэльнең күзенә карамады.

— Я, нәрсә уйга калдыгыз? Нindirәк кеше соң ул прораб Шестаков?— дип кабатлады тикшерүче.

— Катлаулы агай, минемчә. Кешеләргә игътибарсызрак дип әйтимме, әллә миңа гына шулай тоеламы... Кыскасы, минем өчен авыр сорау бу.

— Ә бит Шестаков сезнең турыда бик төгәл фикердә: эш белән шөгыльләнәсе урында исерек өчен квартира даулап йөрде, репродуктор мәсьәләсе белән бала-чага кебек мавыкты, ди. Мин аларны, әлбәттә, ачыкладым...

Тикшерүче өстәлдә яткан папканы ачты да, аннан бер бит кәгазь чыгарып бераз карап торды һәм сүзен дәвам итте: — Мин сезнең идарәнең профсоюз комитеты председателе белән сөйләштем. Миңа калса, бик дөрес уйлый ул. Менә сезне, мәсәлән, кеше буларак, яхшы яктан бәяли, борчыла... Ләкин бу әле авариядә гаебегез юк дигән сүз түгел. Моны исбатларга фактлар кирәк, фактлар...

— Ә сез бригадирны чакыртмадыгызмыни?— дигәнен Рафаэль сизми дә калды.

— Монысы инде безнең эш,— диде тикшерүче,— тотынганбыз икән, тикшерербез...— Бу җавап аның үзенә дә корырак булып тоелды ахры. Йомшаграк тавыш белән өстәп куйды:

— Гаеп сездә түгел, борчылмагыз.

## VI

Тикшерүче янына Салават билгеләнгән вакыттан соңгарып килде. Кабинет ишеген ачуга, моның өчен эчкерсез елмаеп гафу үтенде:

— Өс-башны алыштырырга өйгә кергән идем. Факт. Кичерегез.

Ул чыннан да бәйрәмчә киенгән иде: зәңгәр кримплен костюм, зур төенле чуар галстук. Тәкъдим ителгән урынга утыргач, лаклы туфлясы белән нервыланулы тыпырдап алды.

Аның белән сөйләшкән саен гаҗәпләнә төште тикшерүче: әйтерсең прораб Шестаков белән сүз куешканнар. «Эш журналы»ндагы искәрмәне Шестаков сызганын күрмәгән дә, ишетмәгән дә...

— Дөрес, алар ни турындадыр ачуланышып сөйләшәләр иде. Ләкин мин үземә кагылмаган нәрсә белән кызыксынмыйм — хатын-кыз түгел ич. Факт. Мин — рабочий класс, иптәш тикшерүче. Мин түләүне эш башыннан алам. Юк-бар нәрсә тыңлап йөрергә вакыт юк. Факт.

— Туктагыз әле, иптәш Гыйззәтуллин, — дип бүлдерде аны тикшерүче.— Сез Армиядә дә булгансыз, мораль яктан чыныккан кеше. Шуңа күрә намусыгыз кушканны сөйләргә кирәк. Әле тормышын башлап кына җибәргән кешенең юкка харап булуы бар.

— Ә нәрсә намус? Минем намус, тәртиптә. Факт,— дип кызып китте Салават һәм бер мәлгә тавышын әкеренәйтә төшеп, өстәп куйды: — үзара гына әйткәндә, иптәш тикшерүче, акчаны намус өчен түләмиләр, ә эш өчен. Әйе, эш өчен. Факт.

Тикшерүче Салаватка, аны үтәли күрергә теләгәндәй, текәлеп карап торды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Салават чыгып киткәч, тикшерүче авариянең эзләрен бетерүгә кагылышлы расходлар мәсьәләсен ачыклау турында берничә пунктлы план төзеп куйды һәм, лейтенант Айдаровны чакыртып, шуны ачыкларга кушты. Икенче көнне аның өстәлендә тулы мәгълүмат тупланган белешмә ята иде.

«Авариядән җимерелгән урынны төзәтү өчен дүрт кеше алганнар. Берсе — шунда эшләүче, ә өчесе эшкә вакытлыча урнашкан. Эш өчен өч мең сигез йөз сумлык наряд башка объект исәбенә ябылган. Нарядларга прораб Шестаков кул куйган. Ә бит идарәдән авариянең зыяны мең ике йөз сум дигән рәсми белешмә биргәннәр иде. Димәк, чыгым бик азайтып күрсәтелгән... Менә сиңа мә. Тикшерү бетмәгән, ә эш икенче ягы белән дә катлауланып бара».

Кабинетка подполковник Герасимов килеп керде.

— Утыр, утыр,— диде ул тиз генә аягүрә торып баскан тикшерүче Идрисовка.— Аварияне тикшерү кай тирәдә инде сезнең, капитан?

— «Эш журналы»н таба алмыйбыз, иптәш подполковник. Дөрес, ташчылар бригадасыннан Миңнуллин кергән иде. Ул мастерның монтажланган плитәне кире алдырырга боерык биргәнен раслый. Ләкин аның үзен эчкәләүче кеше диләр. Хәзер менә тагын бу мәсьәлә...— Капитан чыгымнар турында белешмәне подполковникка сузды. Аны җентекләп укыгач:

— Менә ничек эшли икән прораб Шестаков. Кызганычка каршы, андый кешеләр кайберәүләргә ошый ул, шуңа күрә яхшы характеристика бирәләр. Безгә аера белергә кирәк: намусы сафмы аның, әллә мүкләнгән, сөрси башлаганмы? — диде подполковник.

Подполковник урыныннан торды һәм ягымлы, җылы күзләре белән Идрисовка карады.

— Димәк, шушы көннәрдә күп нәрсә ачыкланырга тиеш...

— Тырышам инде, иптәш подполковник...

— Миңнуллинның монда килүе әйбәт.

— Соң, ул килде дә китте... иптәш подполковник.

— Килер, капитан, тагын килер. Чын намуслы кеше бүтән кемнең дә булса бәлагә таруын читтән генә карап яталмый. Бу — капитан, тормыш хакыйкате. Эшегездә уңыш телим.

## VII

Комиссия авариянең сәбәбе плитәнең ярык булуы турында үз сүзен әйтте, ләкин моннан Рафаэльгә ни файда?! Прораб үз гаебен танымый, журнал суга төшкәндәй юк булды. Ләкин ул Игорь Васильевич белән күзгә-күз карап тагын бер сөйләшергә булды.

— Сез бит искәрмәне үз кулыгыз белән сыздыгыз, Игорь Васильевич. Хәтерлисезме?

— Э-э-э, замполит, суга төшкәнсең икән, син үзең генә йөзеп чык инде. Бәлә тргансыңдыр, батучыны коткарырга керүчегә сак булырга кушалар, чөнки ул коткаручысына бик нык ябыша икән. Һәм икесе дә буль-буль... Ә кая соң журнал?

— Кызганычка каршы, табылмады.

— Табылмады, имеш. Куркудан тотып аткансыңдыр әле үзен. — Прораб, Рафаэльнең борчулы һәм ачулы йөзен күреп, сүзне тиз генә икенчегә борды.— Курыкма: үлем-җитем булмады, тәҗрибәңнең юклыгын искә алырлар. Ел-ел ярым шартлы срок бирерләр дә вәссәләм...

— Эш андамыни, Игорь Васильевич? Гаепле икәнмен — бирсеннәр. Тик мин үземнең гаепле икәнемне йөрәгем белән аңларга тиеш...

Шул вакыт вагонга ашыга-ашыга капитан Идрисов килеп керде.

— Менә яхшы булды әле бу, икегез дә монда икән. Бүген безгә Гыйззәтуллин бригадасыннан берничә егет килде, ниндидер җыелыш үткәрмәкчеләр. Сезнең икегез белән килүемне сорадылар. Мин сезне алырга дип кердем. Егетләр шәп, үтенечләрен канәгатьләндерми булмый,— диде ул эчтән елмаеп.

Җыелыш бара. Капитан Идрисов тикшерүнең барышы турында сөйләп бирде, кайбер фактларның расланмавы турында әйтеп, шуларны ачыклау кирәклегенә тукталды. Бригада шаулап алды. «Хәзер ачыклыйбыз аны» дигән тавышлар ишетелде. Аннары урыныннан Миңнуллин торды да, иптәшләре тынычлангач сүз башлады:

— Дөресен генә әйткәндә, без инде авария буенча тикшерү эшләре дөрес юл белән барып, бөтен нәрсә ачыкланган дип уйлап йөри идек. Ләкин арабызда «сер саклаучы» кайбер иптәшләр бар икән. Кыскасы, иптәш бригадир, торып бас та, әйдә шуны ачыклыйк!— Прораб күзләре бер мизгелдә Салаватныкы белән очрашып алды.— Монда барыбыз да үз кешеләр, оялма, баштан ук сөйлә,— диде Миңнуллин.

— Ну, прораб әйтте, плитәне салыгыз, диде.

— Юк, юк, баштан ук сөйлә... мин плитә янына килдем диген..: Шуннан...

— Ну, плитә янына килдем, факт. Элэктердем. Кранчы Гөлнур ярты метр чамасы күтәртте. Факт. Мастер дөрес әйткән — плитәне куярга ярамый, ул ярык, диде. Плитәне кире урынына куйдык. Факт. Шунда прораб килеп чыкты. Без аңа әйттек: шулай да шулай, мастер бу плитәне куймаска кушты, ул — ярык, дидек. Факт. Ә прораб, ягъни Игорь Васильевич, плитәне тагын күтәрттереп карады да, аскы зонасы ярылмаган, салыгыз, диде, факт.

— Тукта, тукта,—диде Миңнуллин.— Игорь Васильевич, эш шулай булдымы?

Башын аска иеп, ияген кулларына куеп утырган прораб сискәнеп китте.

— Син... син нәрсә миннән сорау аласың әле?— диде ул, бераздан башын күтәрә төшеп.

— Биредә сорау алучы юк. Кайбер нәрсәләрне генә ачыклау кирәк, чөнки тиешле урында җавап биргәндә сезнең хәтердән кайбер моментлар төшеп калган икән.

— Игорь Васильевич, сүз бик җитди мәсьәлә турында бара, бу чынлап та шулаймы?— дип сорап куйды партоешма секретаре.

— Дөрес,— диде прораб авыр сулап,— дөрес...

— Я, дәвам ит,— диде Миңнуллин, Салаватка ишарә ясап.

— Төштән соң безнең этажга тагын Рафаэль Мингазович менде. Плитәне, кичекмәстән алып, аска — штабельгә төшерергә кушты. Факт. Ләкин монда минем гаеп юк — мин прораб кушканны эшләдем. Әлбәттә, алыштырырга кирәк булган. Кем белгән бит аны... Аннан соң теге көнне чыннан да мин прораб вагонына кергән идем. Факт. Игорь Васильевич мастер белән «Эш журналы»н карап утыра иде. Шунда ул мастер язган искәрмәне күрде дә, ачуланып сызып ташлады... Факт.

— Менә хәзер дөрес,— диде Миннуллин,— хәзер дөрес, чөнки ул бу турыда безгә дә сөйләгән иде.

— Юк, менә монысы инде дөрес түгел,— дип урыныннан сикереп торды Игорь Васильевич,— журнал бик сәер рәвештә, мин әйтер идем, шикле рәвештә юкка чыкты.

— Менә ул миндә!— Миңнуллин газетага төргән «Эш журналы»н баш өстенә күтәрде.

Җыелыштагылар бер мәлгә тын да алмыйча утырдылар. Игорь Васильевич Салават ягына ачулы карады, Салават утырган җиреннән күтәрелеп үк куйды. Миңнуллин дулкынланудан калтыранган куллары белән журналның кирәкле битен ачты.

— Менә ул плитә турында язылган җир, сызылган юллар. Ә журналны мин синең хатыннан алдым, Салават. Дөрес, гомеремдә беренче тапкыр ялганларга туры килде. Салават бер журнал сораган иде, дидем. Тик, Салават, кара аны, хатыныңа тел-теш тиерәсе булма.

Җыелыш беткәч, ташчылар Рафаэльне сырып алды.

## IX

Тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр артта инде. Шул көн-төннәр аркасында язның матурлыгын да сизми калды быел Рафаэль. Ә бит дөнья әнә ничек матур, шайтан алгыры... Яшисе килә, эшлисе килә, урамда очраган һәр кешегә елмаясы килә!

Рафаэль дә төзешкән беренче «йортны» дәүләт комиссиясе «яхшы» билгесенә кабул итте.

Прорабка ике ел бирделәр. Хәер, эш андамыни?

Үзен шактый изалаган бу вакыйгадан Рафаэль бер нәтиҗә ясады: тормыш, кайберәүләр әйткәнчә, шомартмый, ә тәҗрибә, акыл бирә икән. Тәҗрибәле кеше югалмас, ә шома кешенең кайдадыр шуып төшеп калуы бар! Һәм тагын бер хакыйкатьне аңлады Рафаэль: күк йөзе гел зәңгәр генә булмый, ләкин кеше беркайчан да намустан мәхрүм калмасын икән.

## Укучының күңел дәфтәренә

*Молдаван мәкальләре һәм әйтемнәре*

*Дустымны күргәч әйттеләр: моның хәзинәсе бар!*
*Сакчыл кеше кесәсендә йөз тәңкә дә мең хәтле.*
*Ничек ятсаң шулай йоклыйсың.*
*Ашаганда ат кебек, эшләгәндә — тай гына.*

*Мордва мәкальләре*

*Мукшы һәм эрзә телләреннән*

*Төн узмыйча көн килми.*
*Яхшы хуҗаның начар көне юк.*
*Карт агач — урман хуҗасы.*
*Ат авыр эштән курыкмый, начар караудан курка.*
*Йөзәргә өйрәнми торып суга сикереп төшмә.*
*Сынган агачны торгызып булмый, киселгән икмәк кире ябышмый.*
*Кабыгын тешләп ватмасаң — төшен ашый алмыйсың.*
*Сусау су янына илтә.*
*Белмим дисәң — өйрәтерләр, теләмәсәң — мәҗбүр итәрләр.*
*Бердәм булган көтүгә бүре барып керә алмый.*
*Канны кан белән юалар.*
*Ни тартсаң, шуны илисең.*
*Яхшы хәбәр яхшы эштән туа.*
*Буш капчык басып тора алмый.*
*Артыңнан ияреп йөргән — үкчәңне таптар.*
*Ашыгу белән курку — икесе дә бер нәрсә.*
*Кызу барсаң тизрәк туктыйсың.*
*Яхшы кунак — хуҗа мактанычы.*

## Әдхәт Синугыл

# ДАЛА ҖАНЫ

### Уртаклык

*Олжас Сөләймановка*

Ипи-тоздан алып уртак бар да:
Сөйгән кызлар, эчкән кымызлар...
Без бит бар да дала сөте белән
Авызланган егет һәм кызлар.
Иң мөкатдәс саз уйнатып хистә,
Тел, кардәшлек серен бүлешик,
Җәйләүләрдә шаулы табын корып,
Туйлар ясап, кызлар бирешик.
Кем белән кем яуга яуда килгән, —
Аларны без искә төшермик...
Кайгыларын бүлик илнең уртак,
Шатлыкларын татып исерик.
Сабан туйларыбыз алыпларын
Думбрада салыйк җыруга.
Күпме тырышса да ят дошманнар,
Ук аттырмыйк илгә-ыруга.
Дуслык кынамы соң — дошманнар да
Уртак булган гомер-гомергә.
Бер җан булып, бер кан булып тибеп,
Без үч итеп яшик үлемгә!

### Кичер, Заман!

Синең әгәр күп гамәлле
Мәсьәләңне чишәлмәсәм,
Синең зиһен, синең гакыл
Диңгезләрен кичәлмәсәм, —
Кичерәлсәң, кичер, Заман,
Хөкем синең гадел һаман...
Хак эшкә итсәм хыянәт,
Я пакьлеккә пычрак атсам,
Адым саен чордашлардан
Артта торып калсам һаман, —
Хөкем ит мине, кичермә,
Юкка чыккан сана, Заман!

Кылган барлык эшләремнең
Меңнән бере булса яман,
Барлык дөрес эшләремнең
Булса әгәр берсе ялган, —
Ничек туры карармын мин
Синең күзләреңә, Заман?!

## Тарих

Без — тынгысыз, көн-төн казынабыз,
Эзләнәбез безгә кирәкне.
Бик күп китап тавын актарабыз
Аңлар өчен тарих-келәтне.
Берәүләргә Тарих ишек ача,
Берәүләрне ачмый азаплый.
Тирән катламнарда качып ята,
Шунда калыр, белмим, озакмы?
Күпме еллар буе тарихчылар
Омтылалар инде ачарга,
Читен ләкин — үткән гасырларга
Ишек ачкычларын ясарга.
Тарихыбыз су aслары тулы,
Җир аслары... тормый күренеп.
Җир астында гынамы соң тарих?
Өстендә дә ята күмелеп.

## Казагыстан — Даластан...

Казагыстан, гафу әйлә мине —
Күрсәм, танымам дип уйладым;
Йөрәгемдә шаулый далаларда
Дулкынланып үскән кылганың.

Гомеремдә сине бер булса да
Күрсәм иде диеп каңгырдым.
Менә килдем, күрдем инде сине,
Кымызларың татып таныдым.

Җыру катыш думбралар чиртеп,
Йөрәкләрдә утлар кабыздың,
Киң күңелле иркен, киң далаңдай
Карашларың күреп таныдым.

Казакъ иле! Йөрәгемнән ургып
Чыккан җырга сине салырмын,
Кайгыларың синең бармы, белмим...
Шатлыкларың булып яңырмын!..

●

Күзендә моң: тизрәк дагала,
Үткәнемә озат, далага!
С. Хәким

Ана кебек Дала җаны —
Тынычлык юк бер дә аңа,
Давыл купса кәтмәгәндә,
Корбаннарын кәтә Дала.

Дала хәтта йокласа да
Тыныч түгел, күзе уяу...
Миллион еллар буе Дала
Сакта тора әнә шулай.
Кылганнарын җәеп аска,
Дала йоклый төнлә арып,
«Спутник»лар тынгы бирми
Байконурда һава ярып.
Күпне күргән гомерендә,
Дала күзе күргән күп яу...
Әллә шуңа тыныч түгел,
Йокласа да — Дала уяу.

...Дала кебек, безгә дә гел
Уяу булу кирәк, уяу!

## Лена Шакирҗанова

### Атылмыйча калган ук өчен

Дуэльләргә кызлар чакырмаган,
Халык белми андый хәлләрне.
Атылмаган нәфрәт булып җиргә
Очып киткән зәңгәр шәлләре...

Аткан уктай ләкин бәгырьләрне
Уеп кергән йөрәк җырлары.
Нәкышләргә иңеп калган алар,
Өзелсә дә сулыш, тыннары.

Дуэльләргә кызлар чакырмаган,
Намусларын аклар өченгә.
Бәргәләнеп сыкранса да җаннар,
Сулыгып-сулыгып тынган эченнән.

Тамакларда төер булып калган
Соңгы сүзне кайдан эзләргә?!
Киерелгән җәядәге уктай
Төбәлгән ул кара йөзләргә...

Күпме язмышларга батып кергән
Салкын хокуксызлык хәнҗәре.
Эчтән генә тынып калган, димсең,
Зиләйлүкләр, Зөлхиҗәләре?!.

Юк, гасырлар аша килгән бер моң
Адашмыйча, саклап үз көчен,
Кайтарырга теләп гүя үчен
Атылмыйча калган ук өчен...

Дуэльләргә кызлар чакырмаган,
Ул килешми безнең халыкка.
Җырларында дәшә алар һаман
Мәхәббәттәй горур хаклыкка!

## Мин булып

Без дөнья хәлен беләбез,
Дөнья безнекен белә.
Яшь аралаш көнгә карыйм,
Мин булып кояш көлә...

Сүнмә син җилдә, яңгырда,
Ялкыным, дөрлә генә!
Мин булып мәхәббәт кергән
Берәүнең йөрәгенә...

Мин булып җиргә береккән
Мәңгелек сөю кече.
Мин яшим шуның хакына,
Мин шуңа күрә кеше!..

## Хакыйкать

Сулар ага, еллар ага, гомер ага...
Җир үзе дә бер искерә, бер яңара...
Үзгәрәләр кешеләр дә, нигезләр дә.
Сыя алмый бертөрлелек бу дөньяга.
Тик хакыйкать бүленмәгән өлешләргә —
Ваклап булмый аны тәңкә-көмешләргә!

## Чормадагы кече сандыгым

Беркөн шулай чормабызда яткан
Кече сандыгымны хәтерләп,
Менеп киттем. Эзләп таптым үзен —
Тотмаганмын инде кадерләп.
Сөртеп ташладым да еллар буе
Өсләренә кунган тузанын,
Утырдым мин анда шактый озак,
Сизмәдем дә вакыт узганын.
Утырдым мин күрешеп үзем белән,
Яшьлек сәхифәсен актарып.
Искә төште япь-яшь чакларым,
Ниләр генә анда тапмадым...
Үсмер чакның иң саф хатларын,
Күңел дәфтәрләрен, шигырьләрем,
Онытылып беткән эч серләрем,
Яшьлегемнең бөтен ядкарен.
Истәлекләр монда, «тарихлар»,
Кемнәргәдер үпкә сүзләре,
Иң беренче сагыш эзләре...
Яшерен генә гыйшык тотып йөргән,
Утлар йотып йөргән көннәрем,
Үзенә күрә тирән уйлар уйлап,
Йоклый алмый яткан төннәрем...
Чормадагы кече сандыгым!
Яшьлегемне шундый сагындым.
Берсенә дә тимим, изге сандык,
Ертып атып, утта яндырмыйм.
Хисләремне минем кузгатсаң да,
Шул урында сине калдырдым...

## Дәвамы бар...

Кеше белән китмәгәндә очрашу бар,
Күңел тартып вә җан атып дуслашу бар.
Тик бу бәхет купкә түгел, үтеп китә,
Очрашуның яман ягы — хушлашу бар...

Йөрәгеңә оя кора сагыш кошы,
Гаҗәп, ләкин сагышның да бер тәме бар...
Ярый әле бу чирдән дә була терелеп,
Дәвасы шул — һәр дуслыкның дәвамы бар...

Яши кеше тыныч сымак тыштан гына,
Ә эчендә гомер буе бер гаме бар.
Иртәгегә ашкынмаса бүгенгесе,
Бу дөньяның ни мәгънәсе, ни яме бар...

Яши бәхет, яши һаман өметләнеп,
Җирдә әле ризыгы бар, тәгамы бар.
Газап булыр иде яшәү хәтта бер көн,
Ярый әле киләчәге, дәвамы бар...

## Үзгәрү

Үзеңне дә хәтта танымаслык
Итә икән дөнья берзаман.
Гомер баскычларын саный-саный,
Үргә менәм. Туктыйм. Кузгалам...

Үзгәргәнсең, диләр, танышларым
Озаграк күрми торсалар,
Ә мин үзем сизмәгән дә сыман,
Бара бирәм алга, юл салам...

Җирдә кеше төпле үз урынын
Табу өчен яши, эзләнә.
Шуңа, ахры, айлар-еллар аша
Үзенә генә охшап үзгәрә...

## Соңарма!

Житкән!
Күп язылды:
«алсу таңнар,
саф инешләр,
пешкән җимешләр»...
Төптән уйлар вакыт:
барсыннан да
мәхрүм калса кинәт,
Җир нишләр?..
Диңгезләр күп,
әмма янгын чыкса,
сүндерергә суы җитәрме?

Хак сүзләр күп,
әмма тынлык басса
бар дөньяны, көче җитәрме
кыймылдатып телен
Җир-ананың
карт Кояштан гафу сорарга?!.
«Саклый алмадың», дип батса Кояш
һәм онытса кабат чыгарга?..
Кемгә дога укып табыныр Җир,
кемнән шунда шәфкать сорарга?!.
Җавап эзлә! Ашык! Соңарма!

## Рифгать Закиров

### Шигърияткә

Шук язмышым юри усаллашып
Сагышын да өйде, кайгысын да...
Тик күңелдә озак кристаллашып
Әверелде алар татлы моңга.

И шигърият! Шуңа күрә бүген
Колак сал син йөрәк тавышыма:
Тел төбемдә күпме йөргән җырым
Тәнне түгел, җанны ярып чыга!..

### Саубуллашу

...Озаттың бураннарда...
Бер үзеңә күпме аклык
Калдырдым урамнарда!

...Хушлаштык язгы таңда.
Киттем дөньяның бар ямен
Калдырып синең янда.

...Кояшлы, җилле җәйдә
Сиңа калсын дип, гөлләргә
Тимәдем бөтенләй дә!

...Инде озаттым үзем;
һәм син дә калдырып киттең
Бөтен сарысын көзнең...

### Кыр казлары китеп бара...

Кыр казлары очып бара
Киерелгән җәя сыман;
Кыр казлары китеп бара
Ерагайган җәй артыннан.

## Эзләреңне синең җуйсам да

Чәчәк белән бергә йөрәгемне
Бирер идем сиңа мин илтеп,
Керсез яшьне терек суы итеп,
Булса әгәр сине терелтеп.

Тик кабереңгенә кай төштәдер,
Яткан җиреңгенә ничектер...
Ничектерме?! — Ул җирдәге барлык
Пирамидалардан биектер!

Минем моңа шигем югын юк та,
Таба алмам аны чынлыкта:
Син билгесез-гаип булдың, әти,
Зур сугышка куеп чик, нокта!..

Каның кайнарлыгын тоям канда,
Эзләреңне синең җуйсам да.
Сиңа хәләл чәчәкләрне илнең
Кайсы төбәгенә куйсам да...

## Тарихтан бер сәхифә

Ни булгандыр еллар аръягында —
Шаһит бары ялгыз таш пулат...
Бүген гүя ташлар җырлый монда:
«Маллар кыйбат түгел, баш кыйбат».

Тормасын дип, ахры, бөтенләй буш,
Җилләр юлга себереп ком салган.
Җансыз ташка, серле бизәктән тыш,
Күләгәдәй сарылып моң калган.

Гүя эссе ташлар эргәсендә
Күбекләнеп кайный кылганнар...
Ышанмыйча бу көн киләсенә
Кемнәрдер бит монда торганнар!

Кемнәрдер бит шәмдәй янып беткән,
Калган бары шәмдәл-таш пулат.
Һәм бер аваз безгә килеп җиткән:
«Маллар кыйбат түгел, баш кыйбат...»

●

— Кит, — дисең, — син, олак, — дисең,
Бу дөньяның аръягына...
Китәр идем,
Китми йөрим
Мөһим сәбәп барга гына.

Икәү генә булсак, ташлап
Китәр идем еракларга,
Әйтер идем: елап калма!..

Тирәбездә күпме кеше! —
Күңелләре яхшылыкта:
Кулларымнан шулар тота.

Китсәм, кемгә табынырмын? —
Адым саен абынырмын...
Һәм... сине дә сагынырмын.

Менә шуңа күрә генә
Китә алмыйм, син рәнҗемә.

●

«Кем аз күргән, шул күп елый» —
Дип, кем әйткәндер элек?
Кем иң өлгер, шул әйткәндер,
Ләкин әйткәндер белеп!

Кем аз күргән, шул күп елый...
Миңа еларга калса,
Ике тамчы кайнар яшем
Агымсуларга тамса,
Сулар кайнап, бөтерелеп
Ярларын уеп төптән,
Парга әверелеп, кибеп
Бетәрләр иде күптән!

Күпме күрдем? —
Шуны бүген
Килгәнгә белгертәсем,
Йөрмим юкка түгеп яшем,
Һаман да көлеп яшим!

Марсель Зарипов

# МӘҢГЕЛЕК ШӘҺӘР

ОЧЕРК

## Ташландык алтыннар



Боз астыннан балык каптырырга баруыбыз, бер диган балык шулпасы пешерүебез, тик балыгына нефть тәме сеңгәнлеге турында табигатьне саклау буенча баш инженер урынбасары Геннадий Захарович Скрипникка сөйләгәч, (Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсендә шундый урын да бар, алты ак төймәле телефон аппаратына карагаңда, зур әһәмияткә ия булырга тиеш ул):

— Аңлашыла. Тик безнең бернинди дә гаебебез юк, — дип куйды урынбасар.

— Табигатьне корытучылар химиклар, нефтьчеләр икәнлеген кем белми! — дидем мин.

— Нефть белән химия үзләре генә табигатькә файда да, зарар да китерми. Төп сәбәп — алар белән ничек эш итүдә, — диде Геннадий Захарович.

— Бөтен дөньяга билгеле нәрсә, — дидем мин үз сүземне куәтләп, чөнки яңа промыселлар, заводлар барлыкка килгән җирдә күпме елга, күл, урманнар һәлак булганлыгын бик яхшы беләм.

— Без башкалар өчен җавап бирмибез. Безнең суга кадер-хөрмәт зур.

Скрипник минем сорауларыма сабыр гына, ышанычлы, мөлаем бер төс белән җавап бирде. Аның үзен болай тотышы гәптәшемнең эчке табигатен дә, кешеләр, дәүләт алдында, үз намусы алдында җавап бирә торган эшенә мөнәсәбәтен дә күрсәтә иде.

Скрипник өстәлдәге кәгазьләрен җыеп куйды да диспетчердан автобус сорады. Шуннан соң без шәһәр читендәге, реакторлар кулланган суны агыза торган кечерәк бер күлгә киттек. Анда баргач, кармак салып, бакыр төсле кызгылт-сары табан балыклары тоттык, аннары шуларны маргарин салып кыздырдык. Хикмәт түгел диген: бу балыкларда бернинди химия тәме юк иде.

* * *

Берләшмәдә моңа исләре китми, реакторлардан чиста су чыгуын шулай тиешлегә саныйлар. Без Скрипник белән су чистарту станциясенә бардык, гади елга суының технологик системаларга ничек килеп керүен, аппаратларны суытуын, чимал белән

әзер продукцияне ничек юдыртуын, шәһәрне, йортларны җылытуын кәгазьгә сызгалап, өйрәнеп утырдык. Суны кире Камага агызганчы әнә шулай кабат-кабат, илле-алтмыш тапкыр яңадан торбаларга кайтаралар һәм шулай бик күп мәртәбә йөрткәннән соң гына су чистарту станциясенә җибәрәләр, ә станциядә аны елгадагыдан да чистарак итәләр икән. Бездә гади елга суына: «Һи, исең киткән, су!» яки: «Судан да арзан нәрсә юк!» дигән сансызлау гадәте бар. Әнә шул гади суны яңадан чистарту өчен күпме көч-хезмәт сораганын күреп, миндә суга Түбән Кама химикларындагы кебек зур ихтирам хисе уянды.

Су!.. Дөньяда судан да күбрәк, судан да мулрак нәрсә бармы икән? Шәһәрләрдә — кая карама — фонтаннар атып утыра. Кама, Идел дәрьялары, эреле-ваклы тагын бик күп елга-инешләр, буа, күлләр бар, яз көнендә шул елга-инешләр, ташып, буаларны, күперләрне, хәтта йорт, каралты-кураларны да агызып китә, ә шулай да күптәннән инде безнең туган йортыбыз — Җир планетасының ишегеннән шактый зур бер кайгы-мәшәкать шакый башлаган — җир йөзендә суның күпмелегән диңгез, океаннар белән түгел, бәлки литр, йотым, тамчылап исәпләргә кирәк икән... Бигрәк тә үзебезнең тирәдәге инеш-елга, буа, күл суларын шулай исәпләргә кирәк... Суны тереклек чишмәсе дип юкка гына әйтмиләр, күрәсең. Басу-кырларны, болыннарны сугара, шәһәр, авылларны эчертә, реактор һәм мартеннарда эшли, ашау-эчүгә тотыла торган төче су җир йөзендәге барлык суның бер процентыннан да кимрәк икән. Төче суның 55 проценты боз булып каткан. Ә калган процентының биштән бере атаклы Байкалга туры килә, шуннан да калганы инде бөтен планета өлешенә тия.

Суның кадере торган саен арта бара. Кешелек дөньясы иҗтимагый һәм социаль үсеш баскычыннан күтәрелә, тормышы яхшыра барган саен, хәзергә бушка тотыла торган суның бәһасе дә арта бара. Бер тонна корыч кою өчен — ике мең кубометр, бер тонна никел өчен — дүрт мең, бер тонна синтетик җеп булдыру өчен биш мең тонна чамасы су кирәк. Тугыз миллионлы Мәскәү каласы елына кеше башына алтышар йөз литр су тота. Безнең гасырның алтмышынчы еллары уртасында елга, күлләрдән, җир асты чишмәләреннән 3300 куб. километр чамасы су алынган, ә шуның яртысыннан азрагы гына табигатькә кире кайткан. Җәмгыять үсешенә, тормыш кирәк-яраклары җитештерүгә бәйләнешле прогнозлар ике меңенче елда табигатькә кире кайтмый торган суның сигез тапкыр артачагын күрсәтә.

Суны — инеш-елгадан, күлдән булсын, скважина яки коедан булсын, — барысы да алалар. Су тотмаган завод-фабрика, авыл, шәһәр юк. Тукыма, металл, полимер, икмәк, җиләк-җимеш, яшелчә кебек продуктларның составына кермәгән су табигатькә кире кайта. Ләкин бөтен хикмәт нинди су алып, аңа суны нинди итеп кире кайтаруда! Кама елгасына Түбән Кама шәһәре кайтара торган су елгадан ала торган судан чистарак, ул су аркылы көяшны күрергә, ул су белән юынырга, аны эчәргә мөмкин.

Әмма ул су терек су булганчы берничә тапкыр үле суга әйләнеп ала әле. Химик реакторларның һәр кайсы да, нефть эшкәртә торганы бигрәк тә — гаять катлаулы аппарат. Чимал, эреткеч, катализаторлар белән бергә су төрле реакция, үзгәрешләргә катнаша, төрле зарарлы фракцияләргә керә, барлык технологик операцияләрдә төп чистартучы һәм санитар вазифасын үти. Суның да мөмкинлек чамасы бар, бервакыт ул да яраксызга чыга. Аның урынына тотылмаган су җибәрүдән башка чара калмый.

Түбән Кама нефтьче-химиклары исә суны, торбаларда килеш эшкә ярарлык хәлгә китереп, технологик әйләнеш буенча илле-алтмыш тапкыр йөртәләр. Белгечләргә андый технология хикмәтләре әллә кайчан мәгълүм инде, галимнәр ул хикмәтләрне күптән үк ачып, табып, производствога тәкъдим иткәннәр. Бу чараларны һәр җирдә дә моңарчы кулланмаганнар икән — моның сәбәбе су тергезүнең серен белмәүдә түгел, бәлки ул чараларны кулланырга, ягъни мәшәкатьләнергә теләмәүдә генә.

Кирәк булган саен елгадан су ала барсалар, нефтьче химиклар шәһәр һәм производство ихтыяҗына Камадан көн саен 300 мең кубометр су суыртырлар иде, ә хәзер системаларга өстәлә торган су тәүлек буена тотыла торганның ике процентын гына тәшкил итә. Янга калган су башкаларга да — кырларга, заводларга, авыл, шәһәрләргә дә кирәк, алар да Кама суын эчә бит.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китик: Түбән Камадагы эшкә тотылган суны

чистарту станциясе башка производстволардан шактый алданрак эшли башлаган. Нефтьче химиклар беренче продукцияне алтмыш җиденче елның җәендә алган булсалар, су чистарту станциясе 1966 елның 6 октябрендә ук эшкә керешә.

Башта ул зур булмый, шулай да запаслы була, аннан соңгы елларда, шәһәр һәм комбинат үскән саен, ул да арта бара. 1978 елның беренче яртысында станциядә 800 мең сумлык эш башкарырга планлаштырган булсалар, чынлыкта бер ярымга арттырып үтиләр. Тормышта күбесенчә мондый хәлнең киресе була — су тазарту корылмаларын бик зур талаш белән, инспекция, прокуратура, партия һәм совет органнары мәҗбүр иткәч кенә төзергә керешәләр.

Түбән Камада шәһәр белән заводлар су тазарту станциясенә «үле су» кайтаралар, станциядә исә аны яңадан тергезеп, система һәм коммуникацияләргә җибәрәләр яисә Камага агызалар.

Станциянең зур корылмалары арасында йөргән чакта Геннадий Захарович Скрипник болай дип әйтеп куйды:

— Кеше ул табигатьнең баласы да, алласы да, — диде. — Кеше никадәр көчле һәм бөек булмасын, ул барыбер материаль дөнья законнарын узып эш итә алмый, аның кагыйдәләре белән исәпләшергә тиеш ул. Беренче кагыйдәсе шул — табигать бар иткән байлыклардан файдалан, әгәр аны үз файдаңа тотарга көчеңнән килми икән, һич югы, аңа зарар китермәскә кирәк.

— Кагыйдәме бу, әллә программамы? — дип сорадым мин.

— Без бу кагыйдәне программабыз итәргә тырышабыз, — диде Скрипник. — Әлбәттә, академик Несмеянов әйткәнчә эшләү дөресрәк булыр иде; «һава белән суны, чистартудан бигрәк, пычратмаска кирәк», дигән ул. Безнең өчен бу кагыйдә белән бу программа зур бер бурычның ике кисәк өлеше генә. Кайбер нәрсәләр инде кагыйдәгә әйләнде, кайберләре хәл ителеп килә, кайберләре исә хыялда гына яши әле. Хыялдагының чынга ашуы — анысы инде кешенең тырышлыгыннан тора.

— Әлбәттә.

— Зур производство конвейерындагы бик күп кешеләрнең тырышлыгына бәйле, — дип тә өстәде Скрипник. — Борынгы заманнарда бөтен бер кабиләнең тормышы аудагы табышка бәйле булган. Хәзерге заманда исә бер халыкның гына түгел, бәлки бөтен кешелек дөньясының яшәеше таза, бәхетле тормышы — производство калдыкларын җыеп, файдалы эшкә әйләндерүгә бәйле.

*

* *

Гомумән, планетабыз ярлы, ихтыяҗларыбыз бик зур булган бер заманда кешеләр табигать байлыгын иге-чиге юк кебек тоталар. Танылган тикшеренүче галим К. В. Ананичев «Әйләнә-тирә дөнья, энергия һәм табигать байлыгы мәсьәләләре» дигән китабында, безне әлеге ваемсыз юмартлыктан кисәтеп: «Чималны әзер продуктка әйләндергән чагында кеше табигать байлыгының бик күп өлешен әрәм итә, — ди. — Табигать байлыгын чамалап тоту ягыннан, хәзерге производствоның табышы гаять аз, уртача 5—10 процент кына, калган 90—95 проценты исә бөтенләйгә әрәм була»[1], — ди ул.

Түбән Кама нефтьче-химикларының гади суның бер тамчысын да бушка әрәм итмәүләре, аны терелтеп, яңадан елгага кайтарулары аларның эшенә зур ихтирам уята, аларның тырышлыклары, кайгыртучанлыклары — җирдә акыл белән уйлап хуҗалык итүнең бер үрнәге.

Аппаратчыларның тәгәл, пөхтә эшләүләрен күреп сокланасың, әле кичә генә могҗиза булып тоелган гаҗәеп эшләр башкаручы кешеләрдән хәтта көнләшәсең. Шулай да карап-күреп йөри торгач, бу гаҗәп нәрсәләргә дә күнегәсең, күп нәрсәләргә, нефтьче-химиклар кебек, таләпчәнрәк күз белән, җитдирәк карый башлыйсың.

Күккә таба өсләреннән ап-ак пар бөркелеп торган биек-биек градирнялар янынннан узган чакта (пар дигәнебез реакторлардан алынган җылы иде) мин, ихтыярсыздан, бу суны шушы температурага җиткәнче җылыту өчен күпме көч түккәннәр икән дип

[1] Ананичев К. В. «Проблемы окружающей среды, энергии, и природных ресурсов». М., 1975. 40 бит.

уйлап куйдым. Хәзер инде суны «эш эшләрлек хәленә» кайтарырга, артык җылысын киметергә кирәк. Бу градуслар, гомумән, термометр шкаласындагы билгеләр-тамгалар гына түгел, нефть, мазут, газ, күмер, торф, утын,— кыскасы, ягулык ресурслары алар. Бер кубометр суны бер градуска кадәр җылытыр өчен бер мең килокалорий җылы кирәк. Бу кадәр энергияне исә ярты стакан нефть яки 195 грамм күмер яисә 455 грамм утын яндырып кына алып була.

Берләшмә градирналарына тәүлек саен 30—40 градуслы, эшкә тотылган 142 мең кубометр кайнар су кереп тора. Ул суны, егерме градуска киметеп, яңадан системага кайтарырга кирәк, куәтле электр вентиляторлары градирналарга һава өрдереп, әллә ничаклы энергия бәрабәренә алынган бик күп җылылыкны тышка чыгаралар. Әлеге «артык» егерме градус тәүлегенә 272 тонна мазут сорый. Бу саннарны ел исәбенә тапкырласак, эшкә тотылган су аппаратлардан 99 280 тонна мазут алып китә булып чыга!

Ә җылынган суны егерме градуска суытырга кирәк, һава өрдерә торган компрессорлар аны яңадан аппаратларга куганда 1 миллион 95 мең 807 киловатт-сәгать электр энергиясе «ашыйлар». Бер киловат энергиягә 310 грамм шартлы ягулык китә. Димәк, көненә 237 тонна мазут кирәк була. Бер тәүлек эчендә тотылганны 365 көнгә тапкырласак — компрессорлар елына тагын 86 мең тонна мазут «ашый» булып чыга. Ә градирналардан күтәрелгән ак пар белән күккә барлыгы 200 мең тонна мазут китә. Бик гыйбрәтле сан бит бу. Колонналар өстендә гөжләгән факеллар һәм күккә очкан ак парлар күңелдә ике төрле тойгы уята. Беренчесе, иң көчлесе — борчылу-пошыну тойгысы: әлеге ак пар белән кызыл ялкыннарда реакторларга тоташтырылган нефть хәзинәсенең запасы яна бит, кешеләргә «иксез-чиксез байлык» дигәнне искә алып сөйләргә генә кала.

Хәер, реакторлар өстендә факел янып торырга тиеш,— ул реакторлардагы процессларның нормаль хәлдә дәвам итүен күрсәтә, аварияләрдән саклый. Шулай да химия барыбер химия инде ул, бөтен җирдә нефть, газ, хәтта пневматик системаларга да гади һава урынына, инерт, азот тутыралар. Аз гына нормадан читкә тайпылыш булдымы, аппаратларда басым арттымы — клапаннар үзләреннән үзләре артык басымны тышка чыгаралар. Ә ул һаваны кешеләр сулый, монысы инде әйбәт түгел! Менә шунда, биосфераны «агулау»дан саклау өчен, артык газны кабызып яндырып җибәрә торган ут кирәк.

Әмма тормышта бик сирәк очраклар өчен генә дип каралган хәлләр еш кына нормага, кагыйдәгә әйләнеп китә. Кызганычка каршы, гөжләп янган факел ялкыннары бу кагыйдәне раслый гына, башка эффектлырак чаралар табарга мөмкин булганда да артык газны факелларда яндыралар.

Бер уйлаганда, алдан максат куймыйча, үз алдына гына әйләнә башлаган тормыш тәгәрмәче кешеләрне матди дөньяның бик күп законнарын һәм хәлләрен аңлауга-төшенүгә китергән кебек. Кешеләр җир асты утларының серен ачып, ул серне үз файдаларына куллана башлаганнар. Җир өстендә факел ялкыннары дөрли икән (планетабызның биосферасын агулаудан саклау максаты белән), димәк, без әле хуҗалык эшендә бәрәкәтләп тоту дигән нәрсәне уйлап җиткермибез, бик аз нәтиҗәләр белән генә канәгатьләнеп калабыз, югыйсә, эшнең башында ук үз алдыбызга табышлырак һәм отышлырак бурычлар да куярга мөмкин бит!

Монда мин комбинатта факел ялкыннары белән көрәшкә керешүнең башлангыч моментларын гына әйтеп китәм. Анда факеллар котылгысыз кирәк булган сигнал маяклары булып кына кала. Аппаратлардан проектта каралмаган өстәмә коммуникацияләр сузалар, технологик системаларны җылылык челтәрләре белән тоташтыралар, ашык-пошык, төгәлсез эшне факел төзәтер, утта янып бетмәгәнен җил таратыр дигән гадәттән ваз кичәләр. Бу зур һәм катлаулы программаны тормышка ашыруның беренче нәтиҗәләре әнә шундый: производство калдыкларын булдырмаска, табигатьне харап итмәскә. 1977 елда реакторларны бушатып чистартканнан соң ярты миллион тоннадан артык төре фракция алына; шуның дүрттән өч өлеше элекке шикелле факел булып янмый, бәлки шундагы ТЭЦка, үз аппаратларына ягулык итеп тотыла. Урындагы ТЭЦка 4 миллион 395 мең сумлык 200 мең тонна ягулык бирәләр. Файдалы эшкә барлыгы 10 миллион 925 мең сумлык 505 мең тонна калдыкларны яндыралар.

«Яндыралар» сүзеннән куркырга кирәкми. Дөрес анысы, Д. И. Менделеевнең

«нефть яндыру — акча яндыру белән бер» дигән сүзе бар барын. Тик теләк белән мөмкинлек арасында шактый аерма яши шул әле. Дөнья практикасында нефть химиясе калдыкларын яндырып юк итү шактый киң таралган гадәти бер эш. Туп-туры чыгарып ташлауга караганда моның зыяны азрак, билгеле. Махсус белешмәләрдә «артык», «файдасыз» калдыкларны яндыра торган «мичләрнең» сызымнары, схемалары да сызып күрсәтелгән хәтта!

Ярый, ут безне нефть калдыкларыннан коткара торсын. Әмма акыл белән уйлап эш итүче тырыш кешеләр башка идеяләр дә күтәреп чыгалар — нефть калдыкларын мичкә ягарга түгел, бәлки файдалырак эшкә кулланырга кирәк диләр. Ничек итеп? Нәрсә исәбенә? Нинди юл белән?

Мондый сораулар байтак, хәл итәсе мәсьәләләр бик күп. Түбән Кама нефтьче-химиклары, табигатьне саклауга махсус хезмәт итүдән тыш, үзәк фәнни тикшеренү лабораториясе каршында махсус иҗади группа төзегәннәр. Бу группа әлеге «артык», кирәксез һәм зарарлы калдыкларны файдалы продукциягә әйләндерү юлларын эзләү эше белән шөгыльләнә. Бу группага бик тырыш инженер һәм галим Валерий Забористов җитәкчелек итә. Ул, җентекле тәҗрибә эшләре башкарып килү белән бергә, бүгенге көн мәшәкатьләреннән алгарак узып, иртәгәге бурычларны да күрә белә. Кыскасы, бүгенге заман белгече ул, уй-фикергә һәм эш-шөгыльгә җитез-өлгер булган безнең гасыр кешесе! Забористов эшли-эшли укып югары белем ала, комбинатта, үзенең эш урынында, кандидатлык диссертациясе яклый, яңа төр каучук — бутил каучугын күп җитештерү белән бәйләнешле җитди эш башкара. Нефть калдыклары мәсьәләсе сөрелмәгән, кеше кулы тимәгән чирәм җир кебек бер нәрсә булуы, яңа бер эшнең нигезен салу мөмкинлеге белән кызыктырып-мавыктырып алып кереп китә аны.

Забористовның группасы зур түгел — берничә инженер, лаборант. Эшкә моннан бер-ике ел элек кенә керешсәләр дә, кайбер эшләр майтарганнар инде. Стандарт булмаган каучук валчыкларыннан химик яктан чыдамлы түбә материалы «бутизол» ясап була икән. Эсселеккә, салкынга һәм яңгыр суына бирешми торган «поликам» дигән мастика эшлиләр. Идән, нигез, бетон җылыта, ток үткәрә торган келәмгә патент алалар...

Без Забористов белән лабораториядә төрле пыяла савытлар, приборлар, тәҗрибә станоклары һәм аппаратлары арасында сөйләшеп утырдык. Стенада спорт осталарына бирелгән дипломнар төсле аларның ачышларын теркәгән патентлар эленеп тора иде.

Мин, технология процессларының нечкәлекләрен, химиянең эчке хикмәтләрен төпченеп тормастан: «Бу кадәр өстәмә продукцияне комбинат кая куеп бетерә? Беркем тарафыннан планлаштырылмаган әйбер эшләп чыгаруның мәгънәсе бармы? Аның «утәрлек» товармы икәне дә билгеле түгелдер бит әле?» — дип кенә сорадым.

— Нигә «утәрлек» булмасын? — диде Забористов. — Сораучылар бик күп. Мастика бөтенләе белән үзебезнең кирәккә тотыла: тәэминатчылар вагон-вагон буяу кайтаралар иде, менә без хәзер аларны шул мәшәкатьтән коткарабыз. «Поликам»ны Байкал-Амур магистраленнан сорап яздылар: «Булган кадәресен бөтенесен җибәрегез», — диләннәр. «Бутизол» белән башка фәнни тикшеренү институтларында да кызыксыналар. Бөтен кыенлык-соралган кадәрне ничек бирәп җиткерүдә. Эшләнгән чаклысы айсбергның өске өлеше түгел, түбәсендәге бер нокта гына әле. Бу калдыкларны эшкә файдалану өчен зур завод, комбинатлар салырга кирәк, шул чагында аның файдасы да зур булачак.

— Күпме? — дидем мин, кызыксынып китеп.

— Кем санаган бит аны! Егерме миллион сумнан да ким булмас.

Забористов белән Скрипник янынннан мин нефтьче химикларның министрлык буенча оештырылган конкурсының иң кызган чагында кайтып киттем. Табигатьне саклау буенча кем күбрәк эш башкара, кем производство калдыкларыннан яхшырак файдалана белә — әнә шул юнәлештә зур конвейерның барлык участокларында да — завод идарәсе белгечләренең кабинетыннан башлап, аппаратчыларның хезмәт урынына хәтле — бөтен җирдә эш кайный иде. Ярты елдан соң Түбән Камага сөенечле хәбәр килеп төште — нефтьче химиклар, бер миллион сигез йөз унбиш мең сум акчаны янга калдырып, министрлыкта беренче урынны алганнар. Министрлыкның 125 заводында ярты

ел эчендә 17 мең рационализаторлык тәкъдиме булган, шуның ун мең җиде йөз утыз бише эшкә ашкан. Бу вакыт эчендә ташландык суның күләме 38 миллион кубометрга кимегән, нефть һәм аның продукты ташланмалары өч мең тоннага, атмосферага зарарлы матдәләр очыру 114 мең тоннага, чиста су тоту 39 миллион кубометрга азая төшкән.

Ашыгыч конкурс, смотр һәм аврал көннәрендә генә түгел, тоташ еллар буе шулай тырышсак, эшләр нинди шәп булыр иде!

«Айсберг түбәсендәге нокта»ның экономик кереме бик зур икән шул. Производстводагы икенчел ресурсларны эшкә куллану мәсьәләләрен акыл белән төптәнрәк уйлап хәл иткәндә ул күпме табыш-файда китермәс иде икән?!

Бу программаны тормышка ашыруның юллары төрле-төрле. Мин шуларның берсен генә — зур коллективның эзләнү-тырышлык рухын тулыландыра торган административ юлны гына әйтеп китәм.

Комбинатның директоры Николай Васильевич Лемаев яисә баш инженеры Павел Александрович Вернов атнага бер тапкыр завод директорларын, производство җитәкчеләрен һәм белгечләрне, служба, цех, смена башлыкларын летучкага җыеп, эшкә йомгак ясыйлар: бер-берен тетеп тәнкыйть итәләр яки, киресенчә, яхшы эшләүчеләрне мактыйлар. Бер тапкырында әкияттәге толпар ат ялы шикелле җилдә җилфердәп утырган факел ялкыннары турында да сүз була. Генеральный директор таза кулы белән өстәлгә суга-суга:

— Әйдәгез мондый хурлыкны бетерик. Факелга җибәреп кенә котылырга чамалаган кешеләргә ял пособиесеннән башка гына расчет бирәчәкбез. Табигатьне корытучыларны иң югары номенклатура исемлекләре дә, совет суды, демократия терәге — профсоюз да коткарып калмас! — ди.

Бу фикернең әйтелү рәвешенә исегез китмәсен. Летучкалардагы әңгәмәләр кайвакыт аннан да катырак, җиллерәк була. Мине икенче бер уй борчый. Нилектән генеральный директор әйткән кагыйдә һәм кисәтүләрнең тәэсир итү тирәлеге бик кечкенә, нигә комбинаттан тышта да аның көче сизелми икән?!

*
* *

Чыннан да, нигә алай?

Могҗизалар ясаучы химия гыйльменә рәхмәт, галимнәрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә, җир мае — нефть ягулык, моторларның икмәге генә түгел, бәлки иң арзанлы «төзү материалы»на да әйләнде. Дөньяда нефтьтән кырык мең төрдән артык продукт ясыйлар, минем бу язганым укучыга барып ирешкәнче әлеге сан ике-өч тапкырга да артыр, шәт. Шушы бик күп төрле продуктлан, үз нәүбәтендә, тагын ярты миллиард чамасы төрле-төрле, безгә тормыш итү өчен кирәкле әйберләр ясыйлар. Нинди нәрсәләр соң алар? Заманыбызның могҗизасы пластмасса, затлы мех, тукымалар, көн, кием-салым, бик шәп хушбуйлар, мебель, автомобиль, катерлар, кораблар, космик аппаратлар... Тикшеренүче галимнәр озакламый нефтьтән кызыл уылдык белән кара уылдык та ясый башлыйбыз дип вәгъдә итәләр. Электр техникасы промышленностенда барлык продукциянең 80 процентын егерменче гасырның могҗизасы булган полимер кулланып эшлиләр. Киләчәктә пластмасса җитештерү корыч кою белән тигезләшәчәк.

Мин фән-гыйлемнең һәм кешенең мондый эшләргә көче җитәчәгенә шикләнмим. Фәннең кулыннан килмәслек эш юк, мәсьәлә тик вакыт ягында гына — иртәгәме, берсекөнгәме яки бераз соңрракмы — галимнәр иң катлаулы, иң четерекле мәсьәләләрне дә хәл итү юлларын уйлап табарлар. Тик икенче бер нәрсәне дә истән чыгармыйк: нефтьтән кара яки кызыл уылдык ясау технологиясен эшләп җиткергән вакытка җир йөзендә нефть үзе калыр микән?

Кеше дигәнебез табигать хәзинәсеннән бик күп нефть ала, насослар җирнең канын сөлек урынына суыралар, торбалар һәм танкерлар ул нефтьне хәзерге заманның куәтле заводларындагы реакторларга китереп торалар. Болай караганда бу — бик файдалы эш, кешелек дөньясының алга китешенә ярдәм итә, җан башына күпме нефть тотылуын тормыш дәрәҗәсен күрсәтә торган бер билге итеп алырга мөмкин. Әмма нефтьне башлангыч продукт итеп кенә файдаланучыларның үзенә кирәк өлешен генә

алып, чәчәкнең балын гына җыйган бал кортлары кебек, калганын ташландык бер нәрсә дип караулары бик борчылырлык хәл.

Бал кортлары ише җан ияләре үз-үзләрен саклау һәм нәселләрен дәвам иттерү инстинкты белән генә яши. Кешелек җәмгыятенең эш-гамәлен исә акыл идарә итә, шул акылы ярдәмендә кеше бүгенге эшен генә түгел, алдагы көндә ниләр һәм ничек буласын да күреп белә.

Ярый, беренче бишьеллыклар, сугыш алды чорындагы иске завод-фабрикаларда производство ташландыклары күп булсын ди. Ул чагында завод-фабрикалар бүгенге техник үсеш дәрәҗәсеннән бик түбән тора иде. Бүгенге көндә бик күп производство калдыклары бирә торган уникаль комбинатлар һәм комплекслар эшли, аларны башта ук кешелек дөньясының сәләте һәм акылы ирешкән казанышларга, иң яхшы тәҗрибәгә нигезләнеп, килячәккә исәпләп төзиләр. Түбән Кама берләшмәсендә 1978 елның 15 февраленнән 15 октябрена чаклы уздырылган конкурсның махсус темалар исемлегеннән рационализаторлар, уйлап табучылар һәм новаторларга эшкәртү өчен 33 позиция тәкъдим итәләр. Бу исемлектә каучук валчыгы, промышленностьтан чыккан ташландык сулар, эшкә тотылган эреткечләр, катализаторлар, җиңел һәм авыр сумалалар, гексан, изопрен, пиперилен фракцияләре, адсорбент һәм башкалар була.

Баш конвейердагы производство калдыклары — ташландык бер нәрсә түгел, бәлки зур мал-байлык ул. Журналист һәм әдәбиятчылардан бу сүзне әйтүчеләр арасында мин мең дә беренче кешемендер, шәт. Хәзер мин әнә шул мәгълүм мәсьәлә турында уйлыйм, гомуми сызыкларда гына булса да, аны ачыкларга, күз алдына китерергә тырышам: безнең гасырның иң кыйммәтле продукты саналган нефтьне эшкәртү, куллану белән бәйләнешле, заманыбызның иң уникаль завод һәм комбинатларында ни сәбәптән производствочылар алдында әлеге ташландыкларны эшкә файдалану мәшәкатьләре килеп чыга?

Берләшмәнең генеральный директоры Николай Васильевич Лемаев производство калдыкларын файдалы, кирәкле продукциягә әйләндерә торган тәҗрибә участогы төзергә ярты миллион сум акча бирә. Түбән Кама күләмнәре белән чагыштырганда бу — бик аз капитал, билгеле. Бу эш берничди проект һәм планнарда каралмаган, түбәннән килгән инициатива белән генә башланган. Ярты миллионны эшкә тоту да шактый катлаулы мәсьәлә икән!..

Производство калдыкларын файдаланырга кирәклеге үзеннән-үзе аңлашылып торса да, бу мәсьәләне зур дип әйтү генә аз, тау чаклы бер мәсьәлә ул. Аппаратчы, слесарь, машинистларга да, алдагы көн машиналарын һәм заводларын төзүче галимнәргә дә, тырыш хуҗалыкчыларга да, административ, техник, фәнни, әхлак һәм инженерлык идарәсенең җепләрен үз кулларында тотучы министрлык белгечләренә дә уйланырлык нәрсә бик күп монда. Бер очракта производство калдыкларын читкә җибәрергә мөмкин. Түбән Камалылар пипериленны коксохимикларга җибәрә башлыйлар, химиклар реакторларга тутыра торган, эшкә тотылган дизель ягулыгына да ия табыла. Икенче очракта производство калдыгын тагын бер тапкыр эшкәртергә, яңадан аппаратлар аша уздырып, эшкә яраклы продукт алырга мөмкин. Комбинат лабораториясендә пипериленны чистарту әмәлен табалар, шуннан олигомер ясарга регламент алалар. Олиф ясаганда олигомерны үсемлек мае урынына кулланырга мөмкин икән. Бу эшнең экономик нәтиҗәсе миллион сумлап булачак, имеш!..

Производство калдыкларыннан алына торган мондый миллионнар безнең эшләр ал да гөл икән дигән ялгыш фикер уятмасын. Бу бит Түбән Кама! Башка урыннар белән чагыштырганда бирадә мөмкинлекләр дә икенче. Башка төштә хыял булып кына тоелырдай нәтиҗәләрне тагын да зуррак программаларга керешүнең башлангычы итеп карарга кирәк. Производство калдыкларын әрәм итмәү программасы бик кызыклы булса да, ул эш аерым предприятиеләрнең генә хәленнән килер микән? Терәктаяныч ноктаң булмый торып, җирне урыныннан кузгатырга маташу кебек бер эш булыр иде ул. Белгәнебезчә, хәтта Архимед та андый эшне эшли алмаган!

Производство калдыклары бүдырмыйча эшләү өчен кирәштә нәрсәне терәк-таяныч ноктасы итеп санарга соң? Эшне яхшы итеп оештыру: ачык, нигезле итеп уйланган чаралар системасы, бөтен вагы-төягенә хәтле уйлап эшләнгән программа нигезендә берничә тармактагы завод-фабрикаларның көчен берләштерү, фән белән практиканың бергә кушылып эшләве — менә шулар бу эштә таяныч ноктасы була алыр иде. Ярты-йорты гына чараларның уңышы да шул чама гына була!

* * *

Ә киләчәктә хәл ничек булыр соң? Галимнәрнең әйтүенә караганда, җәмгыятьнең житештерү күләме үскән саен, производство калдыклары да арта гына барачак, җир йөзе табигать байлыгын саклаучы хәзинә урыныннан зур бер чүп савытына әйләнәчәк, файдалы эшкә ярардай производство калдыклары дөнья күләмендәге афәткә әвереләчәк.

Безнең буынның күз алдында менә ике дистә ел инде Идел һәм Кама буйларында химия индустриясенең ике зур гиганты — Казандагы «Органик синтез» берләшмәсе һәм Түбән Кама берләшмә заводлары үсеп килә. Баш конвейердагы производство калдыкларын файдага әйләндерү өчен ниләр эшләргә кирәклеге турында меңәр битле калын-калын китапларга да язылмаган. Берәү дә иң зурын максат итеп куймый, күбесенчә иң азы белән генә чикләнергә тырыша. Газ яндыра торган махсус җайланмаларны, торбалардан чыккан ак парларны, реакторлар һәм аппаратлар өстендәге ялкыннарны әйткән дә юк. Бу эшләр нинди генә изге ният белән эшләнмәсен, байлык яндыруны барыбер берничек тә аклап булмый! Атаклы физик Макс Борн: «Күмер белән нефтьне ягу өчен тоту хәтәр эш ул, аны әрәм итү була», дип җир астыннан алынган байлыкның файдалы эшкә — яктылык, җылылык һәм энергия өчен мичтә яндырылуын күздә тотып әйтә. Ә инде нефть-газ яндыруның файдасы нульгә бәрабәр булса, ул чагында нәрсә диярбез?

Иң алдынгы индустрия булган нефть химиясенең дә производство калдыкларыннан тулысынча файдалану ансат эш түгеллеген аңлыйм мин. Бары тик үз эшләрен генә белүче — нефтьтән төрле каучук, пластмасса, ашлама, гербицид, төрле майлар ясаучы галимнәр һәм белгечләргә комплекслы тикшеренүләр башкарырга, халык хуҗалыгының башка өлкәләрендәге белгечләрне эшкә тартырга кирәк. Еш кына шундый комплекслы эш башкару урынына производствочыларга «фән әле нефтьне бөтенләе белән эшкәртү юлларын белү дәрәҗәсенә җитмәгән, производство калдыгы — котылгысыз, аны кабат эшкәртүгә караганда чыгарып түгү файдалырак» дигән фикер белән килешергә тәкъдим итәләр. Бәлки производствочылар бу хәлдән чыгу юлларын үзләре табарлар — тырышсыннар, эзләнсеннәр!

Ә тормышта зур фәнни үзәк галимнәре булдыра алмаган мәсьәләләрне завод лабораторияләрендә хәл итәләр.

Казан «Органик синтез» берләшмәсендә фенол-ацетон аерганда кала торган сумалаларны унбиш ел буе производство калдыгы итеп санап килделәр. Фенол белән ацетон мактаулы сыйфат билгесенә лаек булды, аннан эшләнгән әйберләрнең бәһасе югары күтәрелде, ә калдык сумалаларны Кохтла-Ярвега ягулык сланецларны баетырга җибәргәләделәр яисә тагы да ансатрак эшләделәр — чокырга чыгарып түктеләр. Ә көннәрдән бер көнне завод лабораториясенең өлкән инженеры Валентина Александровна Балатенко шул артык сумалаларны эшкә җигүнең хикмәтен таба!

«В. А. Балантенконың диссертация хезмәтен органик синтез промышленностеның бер тармагындагы производство калдыкларын химиянең икенче бер тармагында — полимер материалларны җитештерүдә рациональ файдалану мәсьәләсенә иҗади килүнең бер үрнәге итеп карарга кирәк,— дип язалар Орехово-Зуеводагы Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы «Карболит»ның белгечләре, — иптәш Балатенко башкарган тикшеренүләр нәтиҗәсендә фенол калдыкларын яңа лак сумалалары һәм шулар нигезендә прессматериаллар җитештерү эшендә файдалануның практик юллары табылган...

Автор тарафыннан эшләнгән рецептура буенча фенолның бер өлешен фенол калдыгына алмаштыру нәтиҗәсендә 1972—74 елларда 640,6 мең сум экономик файда алынган».

Шулай да җир өстен пычратып, аның бөтен ямен җибәреп яткан ташландык сумаладан ярты миллион табыш алу, бик мактаулы эш.

Хәер, өч ел узганнан соң шул ук сумаладан тагын йөз мең сум табыш алалар.

1979 елда «Татколхозстрой»ның Коркачыдагы тимер-бетон конструкцияләр заводында, юктан гына дигәндәй, авыл җирендәге төзү эшләрендә фибралит, пыяла мамыгы, керамзитны алмаштырырлык, бүлмә бүләргә ярарлык плиталәр ясый башлыйлар. Мәсәлән, керамзитның бер кубометры унбер сум торса, әлеге плитә бермә-бер арзан. Аның арзанлыгы шуннан — бу материалны җитештерүдә өч кенә төрле чыгым-

га — амортизация, электр энергиясе һәм хезмәт хакына гына акча тотыла.

«Ә чимал?..» дияр укучы. Хикмәт тә шунда шул — чималы бушлай диярлек — Казандагы электр станцияләре мичennән чыккан көл белән фенол сумалалары...

Мин бу яңа производствоның киләчәге ни дәрәҗәдә өметле булуы белән дә кызыксындым — сатылу-сатылмау ягыннан түгел, сораучылар бик күп,— чимал белән тәэмин итү ягыннан. «Татэнерго» идарәсенең баш инженеры Владимир Федорович Малов болай дип җавап бирде: «Бездә көл дигән байлык җитәрлек. Аны кая куярга белмибез, ташып бетерә алмыйбыз. Елына ике йөз мең тоннага исәп тотсыннар»,— диде.

Тулаем бөтен илдә 1972 елда гына да электр станцияләрендә 79,9 миллион тонна көл һәм шлак җыелган. Ә шуның нибары уннан бере генә файдалы эшкә тотылган, калганы чокырларга чыгарып түгелгән һәм анда ярты миллиард тоннадан артык әлеге чимал өелеп ята[1].

Биредә тагын бер нәрсәне ачыклабрак китик. Плитә заводын, технологик регламентларны, аппарат һәм машиналарны, «Органик синтез»ны эшләгән һәр төрле махсус институтларның катнашыннан тыш — «хуҗалык договоры» буенча төзиләр. Проектны фәннәр кандидаты Сергей Иванович Поликарпов җитәкчелегендә Казан химия-технология институтының берничә белгече эшли. Бу эшнең азагы уңышлы булып чыкса да, кыенлыклары җитәрлек була. Заказчысы акчаны өлешләп-өлешләп кенә түли, эш бер туктала, бер кызып китә, шулай итеп, унынчы ел дигәндә генә чынга ашып җитә. Тик Сергей Иванович Поликарпов һәм аның тырыш хезмәттәшләре миңа үпкәләмәсеннәр — алар бик зур эш башкарып чыкканнар, аларның хезмәтеннән «артык» сумала белән көлне кая куярга белмәгән башка җирләрдә дә файдаланырлар — шулай да икенчел ресурсларны эшкә куллану белән бәйләнешле бер фәнни мәсьәләне ун ел буе тормышка ашыруны уңышлы эш дип санап була микән? Шулкадәр күп вакыт әрәм итүне нинди сәбәпләр белән аклап булыр?

Мине һаман-һаман бер сорау борчый. Нефть химиясе производствосының шулкадәр күп калдык бирүе — бүгенге көндә фән-техниканың үсеш дәрәҗәсенә бәйләнешле котылгысыз бер хәлме, әллә бу эшне оештырып җиткермәү, нефть һәм башка табигать байлыкларыннан файдалануны шул рәвешчә генә күз алдыма китерү нәтиҗәсеме? Кызганычка каршы, соңгысы дөресрәктер. Бүген бөтенесен ук хәл итеп булмаса да, күбесен иртәгә калдырмыйча эшләп була бит.

Химия промышленносте министрлыгының тармак институтында миңа ул — «Органик синтез» берләшмәсенең төп проектчысы проектларның нигезенә производствоны югары табышлы, продукцияне бик яхшы сыйфатлы итә торган алдынгы фикерләр салулары, чит ил фирмалары белән хезмәттәшлек итүләре, үзләре эшләгән предприятиеләрнең «иң шәп» булуы белән горурланулары турында байтак сөйләделәр. Бу предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеге яхшы, цехларында кеше бик аз, анда акыллы автоматлар һәм приборлар эшли, эшләп чыгарылган әйберләренең алтмыш проценттан артыгы Дәүләтнең сыйфат билгесенә лаек булган. Байтак продукцияләре илдә генә түгел, Европада, бөтен дөнья күләмендә иң яхшыдан санала икән!

Мондый сүз ишетү, куен дәфтәренә мондый яхшы мисалларны теркәп кую минем өчен бик күңелле булса да, тагы ике мәсьәләне ачыклыйсы бар. Бүгенге көннең шундый алдынгы производствосында ни сәбәптән калдыклар шул хәтле күп: фенол һәм ацетон җайланмаларында — биш процент чамасы. Ә аны киметер өчен берни каралмаган. Союз күләмендәге институт технология процессларын эшкәртергә илнең иң яхшы фәнни көчләрен катнаштыра. Ни өчен әнә шундый зур дәрәҗәле проект оешмасының бик күп «койрык»лары кала да ул «койрык»ларны башка белгечләр җыештырырга тиеш була? Бу сорауларым нигезлерәк булсын өчен мин сумалалар белән булган баягы ике хәлне мисал итеп китердем.

— Беләсеңме, ул сумалаларның безгә катнашы булмады,— диде институтның баш инженеры вазифаларын үтәүче Э. Р. Адитойс.— Без үзебезгә кушканны гына эшлибез. Сумала мәсьәләсен хәл итәргә дип башта ук әйткән булсалар, без аның юлын тапкан булыр идек. Эшкә яравы яки ярамавы билгеле булмаган проектлар эшләп утырудан ни мәгънә? Юкка акча әрәм итү, көч исраф итү генә була түгелме?

Бәлки, чыннан да, мәгънәсе юктыр, производство калдыкларын кабат эшкәртү, яңа

[1] Дивилов С. «Куда девать отходы». «Наука и жизнь», 1978, № 7, 78 бит.

техник һәм технологик юллар эзләү бик кыйммәткә төшәдер, болар, бәлки, киләчәктә хәл ителәсе эшләрдер, аппаратларда беренчел продуктлар гына алып, калган чималны ташлау файдалырактыр? Өч тиенлек куян — биш тиенлек зыяндыр бәлки?

Ашаган белми, тураган белә дигән мәкальне искә төшереп, проект институтыннан чыгып, башкаланың икенче очына — СССР Министрлар Советының материаль-техник тәэминат буенча Дәүләт комитетындагы нефть һәм нефть продуктларын сату һәм тәэмин итү Баш идарәсенә киттем. Идарәнең башлыгы Александр Александрович Келлер янына кереп, кем булуымны әйткәч, хәлемне сөйләп бирдем: Казаннан, Түбән Кама һәм Мәскәү аша урап, тәэминатчылар янына килүемне, юлда үземне нинди уйлар борчыганлыгын әйттем. Аннары:

— Александр Александрович, нефтьне кабат-кабат аппарат һәм реакторларга кертеп эшкәртүнең мәгънәсе бармы? — дип сорадым.

— Әлбәттә, бар,— диде Келлер, уйлап та тормастан.— Әгәр безнең халык хуҗалыгын беренче буыны нефтьтән торган тоташ производство чылбыры итеп күз алдына китерсәк, бер участоктагы хезмәт һәм тырышлыкның файдасы башка баскычларда да күренә. Мин политэкономия мәгълүматлары сөйлим түгелме?

— Шулайрак...

— Ул чагында үзебезчә фикер йөртеп карыйк.

— Саннар беләнме?— дидем мин, математиканың көченә исәп тотып.

— Саннар белән дә мөмкин. Быел (без 1978 елның башында сөйләшкән идек) нефтьчеләр җир астыннан миллионлаган тонна продукция алачаклар. Гаҗәп зур сан бу, моннан берничә ел элек ул безнең хыялда гына иде әле. Әмма нефтькә, нефтьтән ясалган продуктларга ихтыяҗ шундый зур — без, ресурсларны бүлүче-өләшүчеләр, энергетика һәм чимал байлыгын арттыруга бары тик сөенәбез генә. Бу мәсьәләне хәл итүнең бер юлы — Себердәге яңа промыселлардан, шулай ук Татарстан, Башкортстан, Әзербәйҗан, Төньяк Кавказ шикелле традицион районнардан нефть чыгышын арттыру. Ә тагы да мөһимрәк һәм актуальрәк икенче юл — анысы барлык эшкәртү һәм куллану участокларында — промыселларда, крекинг-установкаларда, химик реакторларда, фабрика һәм заводларда нефтьне ягулык һәм чимал буларак тулысынча файдалану. Мәсәлән, нефтьче химиклар унынчы бишьеллыкның өченче елында югалтуларны 4 процентка киметеп, шул исәпкә 200 мең тонна төрле продукт алырга булдылар. Чимал ресурсларыннан файдалануның отышлырак юлларын табуда нефть эшкәртүчеләр бөтен халык хуҗалыгының файдасын күздә тотып эшлиләр. Мисал итеп, заводларда дизель ягулыгын күкерттән арындыру өчен өстәмә технология чылбырын ясауны китерергә мөмкин. Җир астындагы бик күп нефть ятмаларында күкерт бар, аның бер процентка якыны дизель ягулыгыннан аерылып бетмичә кала. Күкертле ягулык белән эшләгәндә двигательләр берярым, ике мәртәбә тизрәк туза, ягулыкның һәр тоннасына запас частьлар тоту 1,3 сумга арта, ремонтка китә торган чыгымнар 5,8 сумга җитә. Заводлар күкертле дизель ягулыгын 6 процент чамасы эшләп чыгаралар, мондый ягулык куллануның зарары елына 50 миллион сумлап җыела. Өстәмә технология җайланмалары ясауның да чыгымы бик зур, ләкин бөтен халык хуҗалыгына килә торган файда нефть эшкәртүче заводларның бу эштәге чыгымын артыгы белән каплый. Аннан тыш, ягулыктагы зарарлы катнашмаларны киметү двигательләрнең гомерен озынайта, аларны тоту чыгымнарын кимәтә. Өстәмә технология чылбыры бу бишьеллыкта ярты миллион тоннадан артык бик яхшы сыйфатлы күкерт алырга мөмкинлек бирәчәк. Ә бу күкерт исә, үз нәүбәтендә, бер дигән фосфор ашлама булачак. Гадәттә, күкертне рудниклардан, күкертле колчеданнан алалар.

Себердә һәм Ерак Көнчыгышта йөреп кайткан чагында, зур экономик региондагы край, өлкә комитетларының беренче секретарьлары белән сөйләшкәндә Леонид Ильич Брежнев халык хуҗалыгын үстерүнең комплекслы программасын тормышка ашырырга, табигать байлыкларыннан яхшырак файдаланырга кирәклеген басым ясап әйтте. Бу максатларга ирешү өчен технология процессларын камилләштерергә, алдагы эшләр калдыгын чимал итәргә мөмкинчелек биргән чаралар уйлау һәм куллану кирәк. Бу процесслар бер промышленность мәйданчыгында булырмы яки бер-берсе белән бәйле аерым предприятиеләрдә тормышка ашырылырмы — анысы инде, кем әйтмешли, техника эше.

*
* *

Күз алдымда конкрет мисаллар тора — һәр скважина янында дөрләп янган факелларны, нефть крекинг-җайланманың беренче баскычына килеп керү белән мерник, резервуар, торбалардан һавага оча торган җиңел фракцияләр. Болар планда күздә тотылган, элегрәк скважиналарны коргандагы технология кагыйдәләренә сыя торган табигый югалтулардан санала иде. Татарстандагы факелларның сүнгәнлегенә күп вакыт үтте инде. Газның туксан биш процентын файдага тоту — бу тармакта иң зур күрсәткеч. Нефтьне табу һәм озатуны камил итеп оештыру оча торган фракцияләрнең әрәмгә китүен бетерде, әйләнә-тирә мохитны пычратып, агулап, илтеп ташларга урын да булмавы ихтимал калдыклар чималга әйләнеп, Кама белән Идел буендагы ике зур нефть химиясенең реакторларына азык булдылар. Халык хуҗалыгына китергән файдалары аларны эшкәртүгә тотылган чыгымнан артып китте. 1963 елдан башлап Казандагы «Органик синтез»чылар илгә 597 миллион табыш бирде. Түбән Кама нефтьчехимикларының унынчы бишьеллыкның дүрт елы эчендә продукцияне сатудан алган табышлары производство чыгымнарын каплап, бер миллионга арткан. Озакламый бу комплекс халык хуҗалыгына ел саен 900 миллион сум табыш биреп барачак. Бу кадәр байлык Казан кебек бер миллион халкы булган зур шәһәрнең кирәк-ярагына ел буе тотарга җитәчәк...

Ә кешеләр ирешкән белән тынычланып калмыйлар, калдыкларның да калдыкларын файдалану юлларын эзлиләр. Мондый эзләнү тукталмаячак, мәңге дәвам итәчәк, чөнки кеше тормышы — яшәешенең төп кагыйдәсе шундый: бер адым, бер баскыч алга атлаган саен, алдагы яңа баскычлар турында уйлыйсың!

Тел күнекмәгән төшенчәләр, тәгъбирләр белән азаплана-азаплана, үзем өчен әрҗиңа мәсьәләләр белән баш ватып, мәкалә язып утырганда сезнең игътибарны бер генә нәрсәгә — Түбән Камага, социалистик экономиканың үткәндәге казанышларының дәвамы булган, киләчәктә зур казанышлар яулауда үрнәк булачак зур халык хуҗалыгы комплексына юнәлтергә теләдем, артык мактап җибәрүдән тыелып, Түбән Кама нефтьче-химикларының бик зур эш башлаганлыкларын, бу яхшы ниятка булышлык итәргә, эшне тизрәк алга җибәрергә кирәклеген әйтергә тырыштым.

«Түбән Кама белгечләренең тәҗрибәсе — нефть эшкәртүдән калган продуктларны һәр яктан файдалануның беренче карлыгачы ул. Көн тәртибендә калдыксыз эшләү кебек бик өметле технологияне производствога киңрәк кертү мәсьәләсе тора.

Бу эштә нефть эшкәртү һәм нефть химиясе промышленносте министрлыгының һәм башка ведомстволарның актив ярдәме кирәк. Яңа производство комплексларының проектын төзүче фәнни-тикшеренү институтлары да моны онытырга тиеш түгелләр»,— дип язган идем мин «Советская Россия» газетасында. Мәкалә 1978 елның 31 маенда басылып чыккан иде.

Һәр төрле техник, технологик һәм экономик сәбәпләрне сылтау итеп алып, баш конвейердан чыккан калдыкларга кул селтәгәндә, барыннан да бигрәк, халык хуҗалыгы мәнфәгатьләренә каршы килә торган үз ведомстволары максатларын гына күздә тоту да бар. Кабул ителгән карарларның вакытлыча арзанлыгына кызыкмыйча, үз алдыңа аерым-хосусый максат түгел, бәлки комплекслы бурычлар куярга, табигать байлыкларыннан тулысынча файдалануга омтылырга кирәк. Совет илендә нефть чыгарылса да, аның кадерен онытырга ярамый. Баш конвейерның калдыкларын файдалану отышлымы яки отышсызмы? дип буш сүз сөйләгәнче, һәр производство, яңамы ул яки искеме, калдыклар белән эш итүнең анык программасын булдырырга тиеш дигән кагыйдәне гамәлгә кертергә кирәк. Икенче бер урында ул производство калдыгы түгел, бәлки кыйммәтле чимал, дефицит материал лабаса!

Производство калдыклары турындагы мәкаләм әллә нинди сөеррәк хәлгә юлыкты: аны дөрес дип тә таптылар шикелле һәм, шул ук вакытта тиешле тәртип һәм әдәп саклап, шактый шома, оста итеп читләтеп тә үттеләр.

Мәкалә уңае белән, мәсәлән, редакциягә фән һәм техника дәүләт комитеты, Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе промышленносте министрлыгы кебек югарыгы оешмалар җавап язып җибәрделәр. Мәкаләне мактаганнар, «аның төп фикерләрен

яклыйбыз» дигәннәр, аннары инде,—әйтерсең мин «беркем берни эшләми» дип расларга җыенганмын,—кара алтынны комплекслы эшкәртү кирәклеген әйткәннәр, нефть эшкәртү һәм нефть химиясенең калдык продуктларыннан ахыргача файдалану уңае белән бөтен ил күләмендә нинди мәсьәләләр хәл ителүен санап чыкканнар.

Мондый саннар да китерелгән иде: бу бишьеллыкта производство калдыкларыннан файдалана торган 29 (нигәдер 50,100 яки 150 түгел) технология процессы төзеләчәк, 1990 елга кадәр исәпләнгән озак еллык программа эшләнә. Фәнни-тикшеренү институтлары да промышленность калдыкларыннан, икенчел матди ресурслардан файдалануның дәрәҗәсен күтәрү өчен күп эш эшлиләр икән.

Кыскасы, фактлар һәм мисалларына караганда, хәл ал да гөл, ялт итеп тора! Әйтерсең, әйләнә-тирәдә производство калдыклары да өелеп ятмый, факеллар да янмый, торбалар белән градирналар да кешеләр өчен зарарлы агулы төтен-газ чыгармый.

Хакыйкать дигәнең һәрвакыт конкрет була ул. Бөтен кешелек дөньясын яратуы кыен түгел, ә менә аерым-аерым кешеләрне яратуы шактый читен эш. Мәкаләмдә мин конкретрак булырга тырыштым, үзен күреп, белеп, яратып киткән тере кешеләрне күз алдында тоттым, аларның кайгы-борчуларын аңлый башладым, аларның хәлен җиңеләйтергә, үзләренең генә түгел, бөтен дәүләтебезнең, бөтен кешелек дөньясының борчуы булып саналган эшләрендә ярдәм итәргә тырыштым. Кызганычка каршы, редакциягә килгән җавапларда Түбән Кама хакында бер сүз дә әйтелмәгән иде.

Ә Түбән Каманың үзеннән менә мондый җавап язып җибәрделәр:

«Советская Россия» газетасының 1978 ел 31 май санында «Чимал факел булып янсынмы?» дигән мәкаләдә куелган мәсьәлә — бик тормышчан мәсьәлә ул,— дип яза берләшмәнең генеральный директоры Николай Васильевич Лемаев.—Илебезнең бик күп предприятиеләрендә факел итеп яндырыла, чүплеккә чыгарып ташлана, җиргә күмелә, кайвакыт хәтта җир өстендә череп ята торган производство калдыкларыннан рациональ файдаланырга кирәклеге турында мәкаләләр үзәк матбугатта әллә ни өш чыкмый.

Производство калдыкларын файдага куллану, минемчә, өч төрле юл белән барырга тиеш.

Беренчесе, иң арзанлы юлы — производство калдыкларын шул килеш промышленностебызның төрле тармакларында файдалану. Мәсәлән, хәзерге вакытта чүплеккә ташлана торган бик күп төрле катализатор, адсорбент, җылыткычлар утка чыдамлы төрле материаллар ясау өчен кыйммәтле чимал була яисә төрле-төрле төзү материалларына кушыла алалар.

Икенче юлы — производствога яңа технология процессларын кертү, эшкә ярарлык яңа продуктлар ясау. Бездә, мәсәлән, изопренны чистарткannан соң кала торган фулькеннан лак ясалачак.

Өченче юлы — гамәлдәге технология процессларын камилләштерә төшеп, производство калдыкларын әзрәк булдыру. Чыннан да, безнең тәҗрибәне киңрәк тарату хакында сөйләргә хәзергә иртәрәк әле, шулай да без үзебезнең предприятиебездә әле әйтелгән өч юлның өчесен дә кулланырга тырышачакбыз.

Мәсәлән, без элек чүплеккә чыгарып яндыра торган продуктлардан суга чыдамлы буяу белән саф бензин алу җайланмасын үзебез проектлаштырып, үзебез ясадык. Казан химия-технология институты галимнәре белән берлектә уйлап тапкан кокс хасил итү ингибиторын производствога кертеп, без бер тонна продукциягә тотыла торган катализатор белән җылыткычны бермә-бер киметтек, шуның бәрабәренә елына ике миллион чамасы экономия ясадык.

Фәнни-тикшеренү һәм проект оешмаларын үзләренең иске проектларын яңадан карап эшләп җиткерергә, калдык продуктларны файдага тоту юлларын карарга мәҗбүр итәргә кирәк. Министрлыклар андый тәкъдимнәрне эшләп, производствога кертүнең катгый графикларын төзесәләр, бик яхшы булыр иде. Яңа проектларны тикшергән чакта производство циклы тәмамланмаган килеш, ягъни калдык белән эшли торган булса, андый проектларны кабул итмәскә кирәк.

Промышленностьның һәр тармагында бер фәнни-тикшеренү институты баш булып, калдык продуктларны файдага куллануда бөтен эшне юнәлтеп барырга, ә тикшеренүләрне СССР главснабы җитәкләргә тиеш.

Шулай ук икенчел ресурслардан файдалануга бәйләнешле эшләрне финанс белән

тәэмин итүне дә хәл итәргә кирәк дип саныйм, чөнки производство калдыкларын файдалануны, техник яктан тормышка ашырырлык булса да, акча, җиһаз булмау сәбәпле гамәлгә кертеп булмый.

Түбән Кама нефть химиясе берләшмәсе өчен, производствосының гаять зур булуын искә алсак, бу мәсьәләләр беренче дәрәҗәдәге иң төп бурычларның берсенә әйләнәләр. Пиролизның бер продукты пиробензиннан файдалану да бик мөһим мәсьәлә, бу производствода йөз мең тонналап нефть продукты бәрәкәтле файдаланылмый. Без пиробензин эшкәртү өчен махсус завод проектлаштырырга тәкъдим итәбез».

Күрәсез, дәртләнеп-янып эшләүче, яңаны эзләүче производствочыларның хәл итәсе мәсьәләләре, эшкә ашырасы уй-фикерләре бик күп. Кешеләр шундый кагыйдәгә таянып эш итсәләр, без үзебезнең планетабыз өчен артык борчылмабыз. Иң мөһиме шул—мондый эшкә янып керешүчеләр ялгыз калырга тиеш түгел, аларга Ватаныбыз фәненең бөтен көче, илнең экономик һәм техник көче, халык хуҗалыгының планлы эшләве белән ярдәм итеп торырга кирәк.

Түбән Кама берләшмәсе белән шәһәр төзү өчен урын сайлаучылар килеп, биш ел узганнан соң, 1963 елның 3 декабрендә партиянең Үзәк Комитеты Пленумында СССР Фәннәр академиясенең химия физикасы институты директоры Николай Николаевич Семенов илебездә төзелә торган нефть химиясе комплекслары алдына килеп баскан мәсьәләләрне бәйнә-бәйнә итеп сөйләп биргән иде:

«Безнең социалистик илебездә, капиталистик илләр белән чагыштырганда, фән белән производствоның тыгыз бәйләнешын, һәр тармактагы дәүләт комитетлары белән фәннәр академиясенең үзара ярдәмләшеп эшләүләрен күп өлеш ансатрак һәм уңышлырак итеп оештырырга мөмкин. Кызганычка каршы... чын-чынлап планлаштыру һәм фән белән техниканың җанлы бәйләнеше бюрократларча кәгазьдә генә планлаштыру белән алмаштырыла, бу кәгазь эшенең күләме исә искиткеч зурая, үсә бара. Югыйсә бездә социалистик җәмгыятьнең өстенлекләрен бөтен дөньяны шаккатырырлык итеп, бик ачык күрсәткән мисаллар күп.

Мондыйлар итеп, мәсәлән, тиз очышлы авиациядәге, космик ракеталар, еракка очышлы ракеталар, бигрәк тә атом энергиясендәге эшләрне әйтеп китәргә мөмкин.

Безгә эшне шушылай чын-чынлап оештыру тәҗрибәсен нигә дәүләт химия һәм нефть промышленносте комитетында да оештырмаска?

Инде Кама елгасыннан бик күп сулар акты, эшләнәсе бик күп эшләр тормышка ашып килә, көн тәртибендә үткән елларга караганда бик җитди, кискен булып, илнең барлык чимал ресурсларын, шул исәптән, нефть байлыгын да бәрәкәтле файдалану мәсьәләсе тора. КПССның XXV съезды игътибарны бөтен дәүләт күләмендәге бу программаның бик мөһим булуына юнәлтте: «Чи нефтьнең байтак өлеше кыйммәтлерәк ягулыклар, нефть химиясе продуктлары алу, экспорт ресурсларын арттыру өчен файдаланылмыйча, мазут итеп кенә ягылганда аны җитештерүнең файдасы күп булмаячак» [1].

Мин инде шушы җирдә очеркыма нокта да куймакчы идем, шул чагында кулыма атаклы Урал әкиятчесе Бажов бабайның әкиятләре килеп керде дә укырга керештем. Бактың исә, әле борынгы осталар — тауларда, куе чытырманлыкларда алтын, байлык эзләүче кешеләр дә — минем шикелле үк хыялланган булганнар икән.

«Җир байлыклары төрлечә исәпләнә — кешегә күбрәк кирәк нәрсә кыйммәтлерәк санала. Әгәр без бабайлардан калган чүплекне актарып карасак, аннан бик күп файдалы нәрсә табарбыз, ә оныкларыбыз бездән калганны актарып карасалар, безнең иң кыйммәтле нәрсәләрне чүплеккә ташлаганыбызны күреп шаккатырлар. Җирнең байлыгын тауга карап түгел, кешегә карап санарга кирәк: кешеләр нинди байлыкка барып җитсәләр, таудан шуны табарлар» [2] — дигән акыллы киңәшләрен ишетәм мин аларның.

Без мәгъдән эзләүче осталарның беренче буыны түгел, җиденче-унҗиденче буыны оныкларыдыр. Алар бары тик хыялланган гына булсалар, безгә шуны чынга ашырырга вакыт. Калдыкларны актарыр вакыт җитә генә түгел, үтеп бара инде. Бик кадерле, кыйммәтле җир мае — нефтьне ташландык килеш саклана дип әйтеп булмый. Тик без, хезмәтебезне дә, акчабызны да кызганмыйча, аны тизрәк яндырып бетерергә тырышабыз... Юкка...

---

[1] КПССның XXV съезды материаллары, М., 1976, 59 бит.
[2] Бажов П. Сбор. соч. в 3-х томах. 2 том. М., 1976, 136 бит.

## Мәгъсүм Гәрәев

# КАҺАРМАН

ОЧЕРК

### Кеше яши җыр булып

Кич. Салкынча Иж-Буби елгасы буенда йөри идем. Көзге табигатьнең гүзәллегенә хозурланып барганда тонык кына булып бер җыр ишетелеп китте.

**Гөлбакчадай Туган илне**
**Күз нурыдай сакларга,**
**Асаф кебек батыр уллар**
**Бик күп безнең якларда.**

Совет Армиясе сафларына китәргә җыенган авыл егетләре җырлый иде. Бу җыр Әгерҗе якларында ел саен ике мәртәбә яңгырый. Ул Әгерҗе егетләренең Ватанга, халыкка һәм партиябезгә турылыклы хезмәт итеп, туган илебезнең изге чикләрен күз карасыдай сакларга биргән анты сурәтендә яңгырый.

Әгерҗелеләр күңелендә бу җыр сулмас бер чишмә кебек күптәннән яши. Аны Бөек Ватан сугышында зур кыюлык һәм батырлык күрсәткән Иж-Буби авылы егете Асаф Абдрахмановка багышлап чыгарганнар. Көен җирле халык иҗат иткән. Каһарман матрос турындагы җыр олысы-кечесенең теленнән төшми.

Бу каһарман кеше турында күп сүзләр ишеткәнем бар. Үзе белән очрашып танышырга омтылып карадым. Севастопольгә бер баруымда ул Ерак океан суларында йөзә иде; икенчесендә Кисловодскида ялда булып чыкты. Ә хәрби матрослар, зурзур корабль капитаннары риваятьтәгедәй данлы Асафның тормышындагы кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләрне күп сөйләделәр.

Ниһаять, 1978 елның чәчәкле һәм җиңүле май иртәсендә без Асаф Котдусович Абдрахманов белән герой-шәһәр Севастопольдә очраштык.

— Матрос дусларым сөйләгәч, быел, мәйтәм, килми калмас бу дип көттем мин сине, — дип кочаклап алды мине хөрмәтле якташыбыз.

Чыннан да, кыю табигатьле һәм пәһлевандай таза икән ул. Алты дистәне тутырып, чәче чаларса да, яшьләр кебек җиңел, һәм адымнары нык. Ачык күңелле, шат йөзле— алтмышны һич бирмәссең! Кызык язмышлы, сүзгә бик җор, күпне күргән, күпне белә. Ул татар диңгезчеләреннән беренче булып, 1 ранг капитаны дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше, Советлар Союзы Герое.

## Дан шәһәре

Севастополь сүзенең татарча мәгънәсе шушындый. Сапун тавы янындагы Инкерма калкулыгына күтәрелеп, Россия дәүләте императоры Екатерина II 1787 елның кызу июнендә нигез салынган Севастопольгә байтак сокланып карап торган. Ул чорның елъязмасы яңа крепость туган көннәрдә зур хәрби бәйрәм булу турында сөйли. Туплар, аның дөньяга килүен белдереп, көчле салют биргән. Аның исеме Босфордан Ла-Маншка кадәр йөрүче дипломатларны, сәүдәгәрләрне һәм хәрбиләрне үзен олылап баш иярга мәҗбүр иткән. Моннан ике йөз ел элек сызылган география карталары бик төгәл булмасалар да, белгечләр аларда яңа флот шәһәре — Севастопольнең Россия державасының көньяк чикләре өчен нинди әһәмияткә ия булачагын аерым билгеләп куйган. Һәм аларның барысы да Севастопольнең данлы киләчәген дөрес күрә алган.



Инде ике гасыр буена Кара диңгез ярында Севастополь крепосте горур төстә басып тора. Төзелгәндә «Дан шәһәре» дип аталган Севастополь, ватандашларыбызның батырлыгы мәгънәсе буларак, хәзер Җиңелмәс шәһәр, Герой шәһәр дип тә йөртелә. Ул хәрби крепостьлар тарихында үлемсез ике оборонасы белән аерым урын тота. 1854—1855 елларда Төркия, Англия һәм Франциягә каршы Кырым сугышында аның 349 көн дәвам иткән беренче оборонасы Россиянең сугышчан даны елъязмасына алтын хәрефләр белән мәңгегә уеп язылган.

Ул дәһшәтле вакыйгага һәйкәл йөзеннән 1905 нче елның 14 маенда шәһәрдә Севастополь оборонасы панорамасы ачыла. Аның авторы — рус панорама сәнгатенә нигез салган Франц Рубо. Аның эше 1854—1855 елларда Севастополь оборонасында катнашучылар истәлегенә иң зур һәм иң кадерле сәнгать һәйкәлләреннән санала. Автор, сугышның рәхимсезлеген һәм киметмичә, панорамада бәрелешнең иң киеренке күренешләрен биргән. Гаять зур күләмле бу эштә кыю разведчик матрос Кошка, рус солдатларының тоташ каһарманлыгын тасвирлаган күп кенә күренешләр, Кырым сугышының легендар адмираллары В. А. Корнилов, П. С. Нахимов, В. И. Истоминның җанлы портретлары чагылыш тапкан. Аның төп идеясен Ф. А. Рубо бөек рус язучысы Лев Николаевич Толстойның: «Севастопольнең бу эпопеясы Россиядә мәңгегә бөек эзләр калдырыр, чөнки аның герое рус халкы иде» дигән сүзләре аша ача.

Л. Н. Толстой — Севастопольнең беренче оборонасында үзе дә актив катнашкан кеше. Лев Николаевич 11 нче артиллерия бригадасының 3 нче батареясында хезмәт итә. Ай ярым 4 нче бастионда сугыша. Дошманның соңгы штурмын кире какканда биш орудиеле батареяга командалык итүне үз кулына ала. Шуның белән рус сугышчыларының бухта аша кичүен тәэмин итә. Камалган шәһәрдә кырыс, тормышы өчен куркыныч көннәрне үзе кичермәсә, солдат хезмәтенең һәм батырлыгының бөтен тирәнлеген, мәгънәсен хикәяләрендә күрсәтә алмас иде ул.

Шәһәрдә мәшһүр язучыга һәйкәл куелган. Скульптор Н. П. Петрова, аның шушы тәвәккәллеген истә тотып, поручик Л. Н. Толстой бюстын офицер формасы киган итеп сурәтләгән.

Севастопольдә бик күп тарихи вакыйгалар май ае белән бәйле, аларны мәңге-

ләштерүче һәйкәлләр күп. Биредә Бөек Ватан сугышы вакытында 250 көн дәвам иткән икенче оборона да 1944 елның 9 нчы маенда тәмамлана. Беренче бәрелештән соң 86 ел үткәч, ул чор геройларының оныклары һәм оныкларының оныклары, бабаларының батырлыгын кабатлап, гитлерчыларны шәһәрдән өч көн эчендә куып чыгаралар. Әмма фашистлар оккупация чорында зур вәхшилекләр эшләргә өлгерә. Шәһәрдәге 20 концентрацион лагерьда алар Севастопольне үлем, көчләү һәм кан мәйданына әверелдерәләр. Монда калган 112 мең кешенең 2 меңе генә шәһәрне азат итүнең якты таңын күрү бәхетенә ирешә.

Һәйкәлләрнең иң олысы, иң мәшһүре — Дан һәйкәле дошман алдында тез чүкмәгән совет халкының түземлелегенә, каһарманлылыгына дан җырлап тора. Аның мәрмәр плитәләрендә Севастополь өчен сугышларда Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек булган 233 кешенең исеме алтын белән язылган.

Асаф Котдусович Бөек Җиңү көнендә шушы һәйкәл алдында бик озак сүзсез басып тора. Ул бу монументтагы исемлектән Татарстан кешеләре исемнәрен дә укый. Геройларның өчесе безнең республикадан. Пулеметчылар командиры өлкән сержант Гыйльми Абзалович Баһаветдинов (Лениногорск районында туган) һәм орудие командиры өлкән сержант Иван Егорович Кочнев (Алексеевск районыннан) шушы дәһшәтле сугышта дан казана.

Батарея командиры кече лейтенант Габделхак Сәгыйтович Умеркин әле дә исәнсау, Казанда яши, укытучы. Севастопольнең героик оборонасы һәм аны азат итү музеенда Г. С. Умеркинга багышланган өлеш бар. Сугыш чорының күп кенә рәсемнәре аша анда якташыбызның арысландай сугышуы сөйләнә. 134 нче артиллерия полкының Г. С. Умеркин батареясын фашистлар чолгап ала. Хәл гадәттән тыш кыен. Ләкин кече лейтенант солдатлары үзләренең командиры үрнәгендә каһарманнарча сугышалар. Фашистларның ике танкын юк итәләр, җидесен зарарлыйлар. Г. С. Умеркин үзе егермедән артык гитлерчыны юк итә. Командирның кыюлыгы һәм осталыгы белән батарея камалыштан туплары да исән-сау саклап чыга.

Севастополь сугышында мондый батырлык үрнәкләре санап бетергесез. Хәзер барысының да исемнәре мәңгеләштерелгән.

Шәһәрдә күренекле совет язучылары Ленин премиясе лауреаты С. С. Смирнов, М. А. Дудин һәм П. Ф. Нилин да була. Алар һәр һәйкәл, музейдагы һәр экспонат белән җентекләп танышалар. Геройларның исемнәрен мәңгеләштергән Севастополь халкына: «Тормышта һәйкәлләрсез яшәү мөмкин түгел. Аларны булдырып, яшь буында кыюлык тәрбиялвәгез, батырларны онытмаска өйрәтүегез өчен мең-мең рәхмәт сезгә, җиңелмәс севастопольлеләр!» — дип язып калдыралар.

## Кутуй белән очрашу

Кайвакыт кеше тормышта үзе яраткан һөнәрен кыен һәм катлаулы юллар, үзгәрешләр аша үтеп таба. Асаф Котдусович белән дә шулай була. Гади авыл малае, сайлаган һөнәрен кинәт үзгәртеп, тормышта үз урынын, үз бәхетен, сәләтен һәм талантын диңгезләрдә һәм океаннарда таба. Ул авиация техникы һөнәрен диңгезчегә алыштыра, гомеренең иң күп өлешен зур җирдән аерылып үткәрергә карар бирә.

Малай чагында Асафка хәрби диңгезче һөнәре юрамыйлар. Тулы булмаган урта мәктәптә укыганда укытучылар ул я рәссам, я булмаса әдәбиятчы һөнәрен сайлар дип уйлый. Аларның моңа тулы хокуклары була. 12—13 яшендә үк малайга әдәбият-сәнгать «җене» кагыла. Ул шигырьләрне йотлыгып укып кына калмый, үзе дә каләмен тибрәтә. Иж-Буби авылы күренешләрен, табигатен-суын сурәтләгән рәсемнәрен олылар да сокланып карый.

Җиденче классны тәмамлаганда күңелен бөтенләй уйламаган уй биләп ала. Аның хыялы — очучы булу, океан киңлекләрен иңләү.

Асаф үз теләген атасына сөйләп бирә. Өч бала арасында бердәнбер улын туган Иж-Бубиыннан ерак җибәрү авыр булса да, Котдус абый аның хыялына каршы төшми: 15 яшьлек Асаф Казан авиация техникумына китә.

Казан — Асаф өчен бөтенләй икенче дөнья. Студент чорының шау-шулы еллары башлана, тормышка караш киңәя.

Техникумда татар теле һәм әдәбиятыннан беренче дәрестә үк алар алдына Гадел Кутуй үзе кереп баса. Бу язучы Асаф күңеленә генә түгел, башкаларның күңеленә дә кереп урнаша.

Бу көннәрнең якты хатирәсе буларак, миндә Асаф Котдусовичның бер хаты саклана. Ул менә нәрсәләр яза:

**— Утызынчы еллар ахырында мин әле малай-шалай, студент, Казанны да рәтләп белеп бетермим, Бөтенесе белән дә җентекләп кызыксынам. Татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз Гадел Кутуй техникумда безнең өчен иң дәрәҗәле, иң хөрмәтле кеше. Авыл малайларына кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә тырыша иде. Үзешчән сәнгать түгәрәге оештырып җибәрде һәм безне актив эшкә тартты. Сәхнәдә, студентлар белән бергә, күп рольләрне үзе башкара иде. Безнең алда бик еш чыгыш ясый. Маяковский, Такташ һәм, әлбәттә, үз шигырьләрен дә укый иде.**

**Гадел Кутуй студентлар белән иркенләп сөйләшергә ярата. Киң күңелле, көче һәм энергиясе ташып торган кеше. Кешеләрне бик яратты, студентлар белән тыгыз аралашты. Кыен чакларыбызда рухландыра, кирәк икән, бик тиз ярдәм итә. Ул чакларда студентларга материаль яктан аеруча авыр булды. Минем рәсем сәнгатенә сәләтем булганга, лозунглар язам, юлбашчыларның портретларын ясыйм. Мондыйлар техникумда өчәү идек. Оешмалардан һәм кибетләрдән аларны бизәү өчен заказлар ала башладык. Шуның белән стипендиябезне арттыра идек. Гадел Кутуй безне мактый иде. Күп вакытта аннан киңәш сорарга туры килә, ә ул, вакытын табып, ярдәм итә иде.**

**Гадел Кутуй минем күңелемдә киң эрудицияле кеше буларак саклана. Техникумның фәнни һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашты. Дикциясе яхшы, темпераменты чыгышлар ясый. Студентлар аны Маяковскийга охшарга телидер дип уйлыйлар. Үсмерлек елларында, бәлки, без ялгышканбыздыр. Әмма минем күз алдымда бүген дә энергияле, тере Гадел Кутуй басып тора. Шагыйрь булып танылып өлгергәч тә, элекке кебек гади, безнең иң якын дустыбыз булып калды. Шуңа күрә аны һәр студент яратты, үз итте.**

**Кеше абруе үз тирәсендәге кешеләргә мөгамәләсе белән ялана. Ә Гадел Кутуй безнең һәркайсыбызга яхшы мөгамәләдә; ул студентларның укытучысы да, дусты да, киңәшчесе дә иде.**

А. К. Абдрахманов күренекле татар язучысы Гадел Кутуйда 1935—1938 елларда укый. Әдип булачак батырның әдәбият һәм сәнгатькә мәхәббәтен көчәйтүгә зур тәэсир ясаган. Каты сугыш елларында да, аннан соң диңгез-океаннарда йөзгәндә дә Асаф Котдусович шагыйрьләребезнең китапларына күз төшерергә вакыт таба алган.

Бүген ул үзе дә каләм алып иҗат эшенә чумган. Азов һәм Дунай флотилияләренең тарихыннан очерклар китабы яза. Китапны бизәүне дә ул үзе эшли.

## Училищедан — фронтка

Асаф кече яшьтән үк кыю булырга омтыла, батырлыкны һәм тәвәккәллекне фәкать тормышның авыр участокларында гына күрсәтергә мөмкин икәнен яхшы аңлый. Аның хезмәт юлы фабрик-завод өйрәнчекләре мәктәбендә һәм техникумда укыганда, С. Орджоникидзе исемендәге заводта (хәзер С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы) авиация техникы булып эшләгәндә үк корычтай чыныга бара. Кайда авыр, көчле ихтыярлы кешеләр кирәк, аның урыны шунда булырга тиеш. 20 яшьлек Асафның катгый фикере шундый.

1939 елда комсомол егетләрне диңгез училищеларына укырга чакыргач, актив комсомолец Абдрахманов беренче булып гариза бирә. Һәм шул ук елның көзендә Севастопольгә килә.

Булачак офицер диңгезне үз гомерендә беренче тапкыр шунда, исеме диңгез сугышларында данга күмелгән шәһәрдә күрә. Аның алдында инде рәсемнәрдә һәм киноларда гына күргән диңгез түгел, ә очсыз-кырыйсыз Кара диңгез җәелеп ята.

Шаулы да ул, данлы да, шомлы да. Ф. Ф. Ушаков, Д. Н. Сенявин, М. П. Лазарев, П. С. Нахимов, С. О. Макаров кебек атаклы адмираллар шунда чыныгалар, рус флотын җиңүдән-җиңүгә алып баралар.

Рейдларга чыкканда, диңгез Асафны усал каршылый. Бишәр катлы йорт биеклегендәге дулкыннарын җибәреп, аның түземлелеген, кыюлыгын, холкын сыный. Әмма диңгезче булырга ныклы карар биргән егет куркаклардан түгел, аның белән йөзгә-йөз торып көрәшә, ныгый, үзен сәләтле курсантларның берсе итеп күрсәтә.

Укуның беренче ел ярымы ил өчен тыныч шартларда үтсә дә, калганы дәһшәтле сугыш чорына туры килә. Расписаниеләр үзгәрә. Программага күбрәк хәрби тактика кертелә. Занятиеләр дошман авиациясе Севастопольне көчле бомбага тоткан чакларда да туктамый, корабльләрдә дәвам итә.

Комсомол путевкасы белән килгән егетләр уку йортын сугышның икенче елында тәмамлыйлар һәм туп-туры фронтка юнәләләр. Лейтенант Абдрахманов Азов флотилиясенә җибәрелә. Фашистлар ул чакта диңгездә үзләрен иркен тоталар. Корабльләре һәм тиз йөрешле десант баржалары көнен-төнен бөтен юнәлешләрдә йөзә, караваннар гаскәр һәм хәрби йөк ташый.

Азов флотилиясенә Абдрахманов бронекатер командиры итеп билгеләнә һәм аның курку белмәс сугышчан юлы башлана. Корабль үзе дә һәм аның командасы да әллә ни зур булмый булуын. Шулай да ул зур эшләр башкарып, бик тиз танылып өлгерә һәм флотилиянең горурлыгына әверелә бара. Беренче көннәрдән үк катер дошманның яр буе базаларына һәм караваннарына кыю һөҗүм итә, совет судноларын фашист пиратлары һөҗүменнән оста саклый. Абдрахманов матросларын дошман авиациясенең һәм корабльләренең кетмәгәндә ут ачуы да, меңнәрчә миналары да, көчле штормнар да, томанлы салкын төннәр дә куркытмый. Алар бәрысын да кыю җиңәләр, Ватанны гитлерчылардан азат итү көннәрен якынлаштыру өчен тормышларын да кызганмыйлар. Училищеда укыганда иң сәләтле һәм тырыш курсантларның берсе булган яшь лейтенантның командирлык осталыгы көннән-көн арта. Фашистларга каршы сугышта могҗизалар күрсәтүен флотилия газеталары әледән-әле язып тора. Абдрахманов күкрәгендә медальләр балкый башлый.

Бервакыт шулай төнге дозорда торганда офыкта дошман суднолары отряды күренә. Алар унике. Абдрахманов, команданы тревога белән күтәрергә боерык бирә дә, катерны дошманга каршы юнәлтә. Фашистлар, ялгыз корабны күреп, аңа каршы ут ачалар да, бик тиз якынлаша башлыйлар. Дошман снарядлары һаман якынрак ярыла: ләкин бронекатер, маневрлар ясап, алга баруыннан туктамый. Катер гитлерчыларга якыная. Шулчак һавада безнең самолетлар күренә. Алар бик түбәннән очып, дошман корабльләре өстеннән ике мәртәбә үлем чәчеп үтәләр. Матрослар, шуның белән рухланып, фашистларга удар ясыйлар. Немец корабльләре, югалтуларга дучар булып, тизрәк качу ягын карый.

Өч бронекатердан торган кечкенә отрядка берләшеп, Абдрахманов Азов диңгезендә дошманның куәтле базасы булган Мариупольгә төнге һөҗүмдә катнаша. Караңгыда корабльләр портка якынлашып килгәндә, немецлар, моторлар тавышы ишетеп, яр буендагы прожекторларын кабызып җибәрәләр. Ләкин аларның якты нурлары диңгезгә түгел, һавага төбәлә. Дошман прожекторлары самолетлар тавышы ишетелә дип уйлыйлар, күрәсең. Шул арада катерлар, беренче залпларын биреп, порттагы судноларны, складларны яндыралар. Хәлне аңлап алган гитлерчылар корабльләргә ата башлаганда, бурычларын үтәп, алар инде китеп тә өлгерә.

Диңгез буендагы шәһәрләр бер-бер артлы азат ителә. Лейтенант Абдрахманов командалыгындагы катер, армия һәм флот частьлары белән бергә, Таганрог, Темрюк, Осипенко шәһәрләрен азат итү сугышларында катнаша. Күрсәткән кыюлыгы һәм батырлыгы өчен яшь офицер Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

1943 елның декабренда Керчь бугазын кичеп, Кырым җиренә десант төшергәндә лейтенант Абдрахманов аеруча кыюлык күрсәтә. Кичке караңгыда Темрюк ... аның катерлары диңгез пехотачылары десантын кабул итә. Керчь бугазы фашист миналары белән тулып тора. Мондый чакта, аеруча төнлә, хәвеф-хәтәрсез барып җитүе кыен, миналарга эләгеп, безнең кайбер корабльләр бата. Лейтенант Абдрахманов беренче булып үз катерын алып барырга карар итә. Таң атканда Опасный поселогына килеп

җитәләр. Дошман бик мәкерле, безнекеләргә артиллерия, пулемет һәм автоматтан көчле ут ачып каршылый. Ә десантны төшерергә кирәк, боерык шундый. Нәкъ менә шушында инде Абдрахмановның оста командир булуы күренә. Ул үзе утырган корабльнең юнәлешен үзгәртә, ярга килеп туктый. Аның шәхси үрнәге катер матросларын рухландырып җибәрә, үзләре беренче булып суга сикерәләр, алар артыннан диңгез пехотасы десанты төшә. Шулай ундүрт көн һәм төн дәвам итә. Абдрахмановның бу батырлыгы хакындагы хәбәр бөтен Кара диңгездә тарала.

СССР хәрби-диңгез флоты халык комиссары адмирал Н. Г. Кузнецов татар егетенең кыюлыгына үзе дә соклана. Ул, якташыбызны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп, СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе И. В. Сталинга болай дип яза: «Азов хәрби флотилиясендәге 1 нче бронекатерлар отрядының 121 нче бронекатеры командиры Асаф Котдусович Абдрахманов курку белмәс матрос, үз кораблен искиткеч яхшы белә, аңа оста командалык итә. Сугышта инициативалы һәм тәвәккәл... Дошманның артиллерия уты астында, гаять зур салкын канлылык, кыюлык һәм батырлык күрсәтеп, корал һәм сугышчылар төяп 12 рейс ясады...»

Советлар Союзы Герое булу — иң олы хөрмәт ул! Безнең батыр якташыбыз лейтенант Асаф Абдрахманов үзе чыгып киткән Севастопольгә катерын зарарламыйча әнә шундый хөрмәткә ия булып килеп җитә.

Сугыш ташкыны Совет чикләреннән Көнбатышка таба ерагая бара. Абдрахманов катерының гвардияче вымпелы Румыния портларында җилферди, аны Югославия, Венгрия, Словакиянең Дунай буендагы шәһәр һәм авыл кешеләре сәламләп каршылый. Катерның хәрби данлы юлы Австрия башкаласы Вена өчен сугышларда тәмамлана.

Катерның хәрби биографиясенә болай дип языла: дошманның өч кораблен батырды, җидесен зарарлады, утыз сугышчан операциядә катнашты. Командирның үз батырлыгы өчен алган орден һәм медальләр саны дистә ярымнан артып китә.

## Сугыштан соң

Миңа П. С. Нахимов исемендәге Севастополь хәрби-диңгез училищесында кызыклы бер очрашуда булырга туры килде. Хәтердә озак сакланырлык тәэсирле очрашу иде ул.

Курсантлар бронза бюстлар алдына тезелгән. Уникe һәйкәл Бөек Ватан сугышында бу хәрби-диңгез уку йортында тәрбияләнгән уникe кешенең Советлар Союзы Герое исеменә лаек булуы турында сөйли. Училище политбүлеге начальнигы урынбасары II ранг капитаны Лев Александрович Макаров берәм-берәм геройларның исемфамилиясен атап чыга. Беренче булып Асаф Котдусович Абдрахмановны искә ала, капитанның сугышчан юлы турында сөйли...

Аннан курсантлар клубка үтәләр. Президиумда аларны тере герой үзе каршылый. Булачак офицерлар, аның кыюлыгы һәм батырлыгына салют биргәндәй, бер минут тын да алмыйча басып торалар. Аннан каһарман диңгезче курсантлар белән җанлы әңгәмә башлап җибәрә.

Хәзерге заман техникасы белән коралланган бүгенге көн корабльләрендә яшь офицер өчен иң кыйммәтле сыйфатлар нинди? Флотка бүген генә хәрби хезмәткә чакырылган яшьләрдән югары классны белгечләр хәзерләү авыр эшме?...

Флотта тоташтан 35 ел хезмәт иткән, шуның соңгы 26 елында Советлар Союзының иң зур хәрби корабльләрендә хезмәт иткән тәҗрибәле белгечнең яшьләргә сөйләрлек сүзләре, бирәсе киңәшләре җитәрлек. Әңгәмә өч сәгатьләп барды. Ерак океандиңгезгә чыгып киткәч, тиз генә киңәшеп алырлык кеше булмый. Шуңа күрәдер инде курсантлар, бөтенесен дә җентекләп, кат-кат сорашып, «тактик өйрәнүләр» дигән капын дәфтәрләренә язып бардылар.

Бу ел саен шулай икән. Беренче курсны тәмамлаган курсантлар диңгезгә җәйге өйрәнүләргә китәр алдыннан училище командованиесе А. К. Абдрахмановны шундый очрашуга чакыра.

Училищедан китәр алдыннан, хәрбиләр гадәтенчә рөхсәт сорап аның янына ике

курсант килеп керде. Асаф Котдусович аларны куптәнге танышларыдай күреп, бик җылы елмаеп каршы алды. Чыннан да танышлар икән. Татарстан егетләре Рөстәм Бикеев (Казан) һәм Рөстәм Фәйзрахманов (Саба районы) иде алар. Диплом яклап, мөстәкыйль эшкә китәргә җыеналар. Батыр якташыбызның лекцияләрен тыңлаганнар. Бүген үз әтиләре кебек күргән Асаф Котдусовичның үгет-нәсихәтләре бик кирәк аларга.

Диңгез офицерына тыныч көннәр, җиңел көннәр юк. Ул һәрвакыт туган өйдән еракта. Асаф Котдусович нәкъ менә шундый капитан да инде. Әйтик, бер океан крейсерында гына да ул бер елда 32.634 миль йөзә. Бөтен экватор озынлыгына тула язган ич! Йөзүнең соңгы дүрт елында А. К. Абдрахманов җитәкчелек иткән корабльләр океаннарда 886 тәүлек булалар һәм гомуми озынлыгы 115 мең 331 миль булган юл үтәләр. Монысы инде Җир шарын өч тапкыр әйләнеп чыгуга тигез! Космос лачыннарының диңгез корабльләренә караганда меңнәрчә тапкыр тиз очуларын истә тотсак, аларны да көнләштерерлек саннар лабаса. Космос дигәннән, безнең каһарманыбыз аны буйсындыруда үзе дә турыдан-туры катнаша. Ул бер ара СССР Фәннәр Академиясенең гыйльми экспедицияләрендәге корабльдә дә була. Шулчак аңа галәмне иңләүче батырларыбызның океан аша җир белән элемтәсен тәэмин итү бурычы йөкләтелә. Диңгез батырының галәм тавышын беренче булып ишеткән чаклары аз түгел.

*
* *

Китәр көнне без Асаф Котдусович белән Сапун тавына тагын бер кат күтәрелдек. Ул 100 метрга бик аз гына тулмый, тәгәлрәге — нәкъ 92 метр. Ул, ел саен май башында шушында күтәрелеп, 1944 елның 9 нчы маен бирeдән карый кебек, Севастопольне фашистлардан азат итү көнен күзаллый. Түбәндә үскән виноград басуларына сокланырга ярата...

— Виноград куагы — борынгыдан килгән тынычлык мәгънәсе. Ул куаклар ел буена үзләрен карап торуны сорыйлар, игътибар таләп итәләр. Шул вакытта гына виноград бик тә татлы җимеш һәм бөтен кешенең күңеленә хуш килә, җан рәхәте бирә торган тәмле-тәмле ширбәтләр бүләк итә, — дип сөйләп китте Асаф Котдусович Абдрахманов. — Мин моны юкка гына әйтмим. Тынычлыкка да менә шулай игътибарлы булырга, аны сәгать саен, көн саен, ай саен, ел саен туктаусыз саклап торырга кирәк. Шул вакытта гына безнең бүгенге матур тыныч тормышыбыз киләчәктә дә виноград кебек татлы, аның ширбәтләре шикелле тәмле, рәхәт булыр.

*Казан — Севастополь.*

Радик Фәизов

# КҮҢЕЛЛЕ КӨН

НОВЕЛЛА

Бу ниткән сәер исем әле — Таплап? Исем түгел бу, яратып әйткән кушамат кына. Чын исеме Җәлил аның. Ул чатан аякларындагы ямьшек үкчәле сандалилары белән каты-каты басып, ишегалдында тап-лап атлап йөргәндә очраган абый-апалар тотып сөяләр үзен. «Ах, син—Таплап!»—диләр. Кызык өчен генә өстәл астына кереп утырса да, әбисе аны: «Минем Таплап улым кая гына китте икән?» — дип эзләп йөри. «Таплап» дигәнгә беркемгә дә ачуланып тормый Җәлил. Дәү бит инде ул. Киләсе елга аңа алты яшь тула инде.

Инде йокысы бая ук туйса да, Таплап әле һаман да күзләрен ачмаган — юри генә йоклаган булып ята. Шунда тәрәзә пәрдәсен шыпырт кына ачып кояш керде һәм җылы куллары белән аның бер як битен кытыклап алды. Башын читкә борган иде, икенче як битен кытыклады. Инде булмый икән бу — Таплап торып утырды. Әтисе белән әнисеннән инде өйдә ислемай исе, тагын әллә нинди әчкелтем ис кенә калган, әбисе кәнәфидә утыра, тастымалы кулында булса да, әбисенең күзләре рәхәтлектән йомык иде.

Әй күңелле дә бүген! Тәрәзәдән күренеп торган күк тә зәп-зәңгәр, андагы кояш та нәни генә атлап, күченеп йөри кебек. Кичә кич ут яктысында бу идән кызыл иде, бүген ул ап-ак булып ялтырый, кичәге ак, тәбәнәк түшәм дә бүген биек, зәңгәр төстә. Бөтенесе икенче бүген! Ияген тезләренә терәде дә, шуларны рәхәтләнеп карап утырды Таплап.

Беләсезме, нишләп күңелле бүген! Кичә кичен әтисе Таплапка иртәгә мин эштән тизрәк кайтырмын да сине машинага утыртып су коенырга алып төшәрмен, диде! Ай, кичкә хәтле озак, бик озак шул әле...

Әбисе кайчак күзләре йомык килеш тә бик әйбәт күрә. Менә бу юлы да, күзләрен ачмыйча гына:

— Ник иртәдән болай югалып утырасың, улым? Юын, ашарыңа бирәм,— диде.

— Мин югалмадым, әби. Менә бит мин. Син миңа ботканы бик күп итеп бир. Мин бүген бик озак ашыйм.

— Ник озак, улым?

— Озак ашасаң, вакыт тиз үтә. Кич тә тиз җитә. Кич җиткәч, әти дә кайта.

— Аһ, сине... Хәйләкәр Хәйрулла!— дип көлде әбисе.

Ботканы ял итә-итә ашагач, Таплап бер дә ашыкмыйча гына ямьшек үкчәле сандалиларын, сары панамкасын киде дә, озаклап кая барырга икәнен уйлап утырды. Аннары әбисенә:

— Мин, әби, тупылны карап керәм әле,— диде.

— Ишегалдыннан чыгып йөрисе булма. Ишетсен колагың!— диде әбисе усал итеп. Усал итеп әйтсә дә, әбисенең җыерчыклар арасына кереп качкан күзләре барыбер көлеп карый иде. Таплап беразга әбисенә килеп сыенды. Әбинең куллары әнисенеке кебек шома түгел, ак та түгел, бармаклары да кәкре. Ләкин әбинең кулларыннан бик тәмле булып ботка исе, суган, токмач исе килә. Алъяпкычында да шундый тәмле исләр аның.

Бу кулларга, алъяпкычка сыенуы шундый да рәхәт... Ә менә әнисенең кулларына, күлмәгенә сыенуы рәхәт микән? Моны Таплап белми әле. Иртән ул әнисен күрмичә дә кала. Ә кич белән эштән кайткач, я шунда су китерә, я китап укый, телевизор карый әнисе.

Алар ике катлы бик дәү йортның өске катында торалар. Уң кулы белән кутлыксаны сыпырып, баскычтан бик акрын гына төште Таплап. Йорт янында озак тормакчы иде дә, тик кояш әле түбә артыннан башын сузып кына карый, йорт яны күләгә, салкынча иде. Ул ишек алды уртасына, кояшка, җылыга, яшь агачлар янына чыкты. Машиналар йөри торган асфальт буендагы менә бу тупылны алар әле быел язда гына, әтисе белән бергәләп утырттылар. Тупыл ямьяшел, тотсаң кулга ябыша торган яфраклар ярды, ә үзе бер тамчы да үсмәде әле. Таплап кулын күтәрсә, тупылның башына тия.

Озак басып торсаң, аяк арый, чүгәләсәң менә рәхәт. Таплап бик уңайлы итеп чүгәләде дә, кулына бер йомычка алып, тупылның катып беткән төбен йомшарта башлады. Агачның төбен йомшартырга кирәк, шулай иткәндә тиз үсә ул, диде әтисе. Авырмый да, диде...

Аның әтисе үзе дә авырды, бик каты авырды шул. Бик озак авырды. Кич җиттеме иптәшләре аны өйгә кадәр кулыннан җитәкләп алып кайталар. Бу чакта әтисенең бите кып-кызыл була, күзләре уты сүнгән кесә фонаре төсле караңгы була, бер турыга гына карап тик тора, Таплапны да күрми иде. Иптәшләре чыгып киту белән әнисе ишекне шартлатып бикләп ала, әтисе шунда ишек төбендә утырып тәмәке тартып җибәрә, аннары утырган көйгә йоклап та китә. Аннары әнисе әтисен чишендереп караватка илтеп сала, аны бик каты итеп тирги, ә үзе елый иде.

Ә бервакыт төнлә!.. Бервакыт төнлә ул әллә нидән сискәнеп уянып китте дә, әкрен генә урыныннан торып, әтисе яткан карават янына килде. Караса, әнисе тәрәзәдән төшкән ай яктысында ялгызы гына йоклап ята, әтисе юк! Әтисен теге кешеләр алып киткән!.. Бик каты кычкырып җибәрде шул чакта Таплап. Әбисе белән әнисе уянып ут кабыздылар. Әтисе бер кая да китмәгән, ишек төбендә, өстен дә чишенмичә йоклап утыра иде. Шуннан соң Таплап бик озак әллә нинди ямьсез төшләр күрде. Әле дә күргәли, сискәнеп уянып китә...

Чүгәләп утырудан туйгач, Таплап торып басты. Кулларын артка куеп, агачлар арасында йөренде. Инде кояш йортның түбәсенә үк менеп баскан, шәп кыздыра. Таплап тупылның төбен икенче яктан йомшарта башлады.

Бик озак авырды аның әтисе. Аның көн саен иртән утырып китә торган машинасын алдылар. Әтисе әллә кая барып әрҗәләр төяп йөрде. Ә аннары... Таплаплар өендә күңелле көннәр башланды. Өйгә үзе генә кайта иде аның әтисе. Ишектән кайтып керә дә, башын кыңгыр салып, Таплапка карап тора. Үзенең авызы да көлә, күзләре дә көлә! Таплапны менә болай гына итә дә, күтәреп тә ала. Әби-

зе бик курыкса да, әтисе төшәмгә кадәр чөя Таплапны! Әтисе тагын машинага утырып йөри хәзер. Ул бүген Таплапны машинасына утыртып су коенырга алып төшә!

Таплап кулындагы йомычкасын атып бәрде дә, сикергәләп, ишегалды уртасындагы түгәрәк беседка янына килде. Эскәмия астыннан йонлач койрык күренеп тора иде. Ялкау койрыгы бу, ул шулай башын күләгәгә тыгып йокларга ярата. Хәзер тартабыз аның койрыгын... Әй лә, йоклый бирсен. Аның әтисе дә юктыр әле. Аны машинага утыртып су коенырга алып төшүче дә юктыр. Күңелсездер аңа...

Таплап өйгә атлады.

Төшке аштан соң Таплапның авызы үзеннән-үзе бик дәү булып ачыла башлады.

— Мин йоклап торам әле, әби. Бик аз гына, яме?
— Нишләп бик аз, улым? Туйганчы йокла.
— Минем бит әтине алмага чыгасым бар.
— Беләм, балам, беләм.
— Әти авырмый инде ул, әби.
— Авырмый, улым, аллага шөкер.
— Аның инде машинасы да бар!
— Бар, улым, бар.
— Менә шуңа күрә мин аз йоклыйм. Без су коенырга төшәбез.
— Ярый, улым, ярый.

Һәм әбисе аны урынга яткырып, өстенә юрганын япты.

Таплапның битенә йомшак җил, әбисеннән килгән тәмле, рәхәт исләр кагылды. Ул елмаеп куйды һәм шул елмайган көе йоклап та китте.

Йокыдан торып тагын ишегалдына чыкты. Инде кояш каршыдагы йорт түбәсе турысына җиткән, аннан да көчкә генә, башын сузып кына карый иде. Әмма көн бик җылы, су коенырга бик тә рәхәт булачак. Әти генә тиз кайтсын. Мине ишет, әти, кайт! Мине ишет, әти, кайт!

Таплап күзләрен угалап теләк теләгән арада — менә бәхет — әтисенең брезент өсле дәү машинасы ишегалдына килеп тә керде. Таплап, ямьшек сандалилары белән тап-лап атлап, каршыга йөгерде. Ләкин кабинада руль тотып утырган әтисе аны күрмәде. Машина кинәт туктады, артка чигенеп борылды һәм... арты белән алар утырткан тупылга якынайды. Таплап кычкырырга да өлгермәде, машина тупылны каерып сындырды да лып туктап калды. Машина ишеген каерып ачып әтисе чыкты. Аның күзләре тагын уты сүнгән кесә фонаре кебек караңгы, бер турыга гына карыйлар иде... Әтисе, көчкә генә атлап, Таплап янына килде, үзенең дәү, тирләгән учын аның баш түбәсенә куйды, панамкасын йомарлап, башыннан төшереп үк җибәрде, иелмичә генә аңа нәрсәдер әйтмәкче булды, әйтә алмады, аннары бик авырлык белән генә өйгә атлады.

Инде көн җылы да түгел, инде көн бер тамчы кызык та түгел иде. Таплап тупыл янына килде. Агач сынып ук чыккан, аның нәни кәүсәсе җирдә ята, яфраклары сыдырылган, исән калганнары да салкында туңгандай калтырап торалар иде. Таплап чүгәләде, куллары белән дустының шома, салкынча кәүсәсен сыйпады. Тупылның киртләч-киртләч булып сынган төбендә, яшь бөртекләре кебек, чиптиста тамчылар ялтырый иде. Таплап җиң очы белән ул тамчыларны сөртеп алды. Ләкин тамчылар тагын чыгалар, тагын ялтырыйлар иде.

Мөхәммәт Мәһдиев

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ГОМЕР ЙОМГАГЫ

Җыеп караганда алай бик зур
Төсле түгел гомрем йомгагы;
Сүтеп караганда чак күренә
Аның бер ягыннан бер ягы.

Татар һәм башкорт халкының уртак язучысы, күренекле прозаик һәм шагыйрь Мәҗит Гафури үзенең тормыш юлы турында әнә шулай язды.


Галимнәр арасында М. Гафури татар язучысымы әллә башкорт язучысымы дип бәхәсләшергә яратучылар бар. Мондый бәхәснең урынсыз һәм кирәксез икәнен исбат итеп торуга ихтыяҗ юк шикелле. Әмма бу бәхәснең төбендә бик зур һәм әһәмиятле бер мәгънә ята: «безнеке» дип, гадәттә, кыйммәтле, яхшы кеше турында сүз көрәштерәләр. Антик заманнан ук моңа мисал бар: сукыр Гомер бездә туган дип җиде шәһәр дәгъва кылган. Бу бәхәс әле дә хәл ителмәгән. Талантсыз булса Гомер өчен бәхәсләшеп тормаслар иде...

Шагыйрьнең гомер йомгагы. Бу йомгак нинди җепләрдән җыйналды икән соң? Моны сүтеп, тикшереп карау кызыксыз булмас кебек.

Ул 1880 елның августында Уфа губернасы Стәрлетамак өязе Җилем-Каран авылында хәлфә гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Нургали хәлфәнең тормышы шактый авыр була. «Тәрҗемаи халемнән өземтәләр» дигән язмасында Гафури үзе бу турыда болай яза: «Ул вакытларда безнең гаилә тормышы бик авыр һәм өс-башларыбыз сәләмә булуын әле дә исемдә саклыйм. Безнең өйдә арыш икмәге бик кадерле санала, чәй урынына күп вакыт юкә чәчәге яки мәтрүшкә эчелә, җәй көннәре итле аш урынына арыш чумары салган балтырган үрәсе ашала, аның да катыгы иркен тормышлы кешеләрдән алынган була иде. Шуларны искә алсам, хәзерге көндә анкета язганда: «Мин ярлы крестьян баласы...» дип язсам, хаклыдырмын төсле булам...»

Язучының иҗат биографиясенә аның туган ягы, туган туфрагының йогынтысы — бәхәссез. Кырлай урманы Тукайга, Рязань каеннары, Ока буендагы печән кибәннәре Сергей Есенинга нинди илһам биргән булса, М. Гафуригә да Агыйдел һәм Җилем елгалары тирәсендәге сихри табигать балачактан ук поэтик азык биргәннәр. Уралның ерактан күренгән чал кыялары, кыя өсләреннән күккә мәһабәт күтәрелгән бөркетләр, бөдрә куаклар белән чигелгән иксез-чиксез болыннар, әкияттәге серлелеккә ия булган тау куышлары Җилем-Каран авылында туган малайның рухи дөньясына зур тәэсир ясаганнар, сизгер күңелле уйчан малайда акрынлап туган ягына һәм хезмәт кешесенә гашыйк булган шагыйрь өлгереп килгән. Ярлы авыл хәлфәсе улы Мәҗитнең хыялында үз якларының гаҗәеп иркен болыннары, сулары, галибанә табигать матурлыгы белән берлектә халыкның тирән, чал тарихына таба юл сузыла — шундый гүзәл табигать шартларында яшьтән ата-бабаларының борынгы тарихын күз алдына китерү теләге туа.

М. Гафури эшчеләр дөньясы белән бик яшьли таныша. Мәдрәсәләрдә белем күтәрү белән бергәттән, ул сезонлы эшләрдә катнаша. Унсигез яшенә җиткәндә ул инде «Лабашты», «Зигәзи», «Француз» кебек Урал заводларында эшләп зур мәктәп узган егет була.



1898 елда М. Гафури шул чор өчен мәшһүр Троицк мәдрәсәсенә укырга килә. Анда кышын хәллерәк шәкертләргә хезмәт күрсәтеп, җәен алтын приискаларында, разведкада, казакъ һәм рус байларының хуҗалыкларында, тире фабрикаларында эшли.

Троицк мәдрәсәсендә укыганда Гафури зур тормыш мәктәбе уза: җәйләрен ул, казакъ-кыргыз даласына чыгып, бай балаларын укытып йөри. Шул ук елларда язучылык эшенә дә ныклап керешә. «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» хикәясе һәм «Себер тимер юлы» дигән шигыре әнә шул чорда языла. Дөрес, аның бу чорда язылган әсәрләрендә мәгърифәтчелек чикләнгәнлегә үзен бик нык сиздерә. Гафури мәгърифәтнең алга китүе, культураның үсүе белән генә дә кешеләрне бәхетле итәргә мөмкин дип уйлый әле.

Дөньяны инде байтак гизгән Гафуриның суфичылык белән сугарылган Троицк мәдрәсәсеннән күңеле кайта. 1905 елның август аенда ул Иж-Буби мәдрәсәсенә килә, әмма андагы гомуми атмосфераны ошатмыйча (бай балалары күп була) Казанга юл тота. Гафуриның «Мөхәммәдия»дә укыган чоры Казанда революциянең күтәрелгән көннәренә туры килә. Шәкертләр күтәрелү дулкыны, уяну хәрәкәте шагыйрьгә көчле тәэсир ясый һәм ул «Яшь гомерем» исемле шигырь мәҗмугасын тәмамлый. Иҗтимагый-политик тормыштагы һәрбер яңалык бу көннәрдә аңа зур тәэсир ясый. Патшадан ниндидер льготалар көтү һәм 17 октябрь манифестына ышану кебек конституцион иллюзияләрдән ул тиз арына. Шагыйрь революцион көрәшне яклау, дәвам итү, алга таба үстерү позициясенә баса. Аның самодержавие режимына карата мөнәсәбәте «1906 елдан 1907 елга васыять», «Җиденче елның җавабы» шигырьләрендә аеруча ачык чагылган. Бу шигырьләрнең аерым юлларын укып шагыйрьнең кыюлыгына хәйран каласың. Шагыйрьгә мондый кыюлык һәм политик зирәклек каян килгән? Әле күптәнмени, Гафури татар әдәбиятында урын алган дистәләгән үгет-нәсихәтче язучыларның иң беренчесе, иң күренеклесе иде, әле күптәнмени, Гафури татар милләтенең артталыгын халыкның грамотасыз булуыннан һәм халыкның ачлык-ялангачлыгын аның һөнәрсез, культурасызлыгыннан күрә иде.

Ә хәзер... 1906 ел менә ниләр әйтә:

**Искә алдык гаҗиз булган бик күп ачны,**
**Киемнән мәхрүм булган ялангачны,**
**Бер елда ушбу эшләр аз түгелдер,**
**Җиңел түгел тиз аудару зур агачны.**


Әйе, «агач», чыннан да, зур иде, Романовлар династиясе халык канын эчеп, 300 ел буена тәхеттә башбаштаклык итте һәм 1907 ел узган 1906 елга болай дип җавап бирә:

**Сарыф кылдың яхшы юлда бик күп көчне,**
**Моннан соң тапшырдыгыз безгә эшне,**
**Үзегезгә бик мәгълүм зур «кеше»гә**
**Хәл кадәре батырырбыз үткен тешне.**

Шагыйрьнең башына килеп тә карамагандыр: нәкъ дүрт ел үткәч, бу шигырьләр белән жандармерия офицерлары, чиновниклар, цензорлар, губернатор канце-

ляриясе, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр шөгыльләнәчәк. Бу шигырьләр турындагы язмалар белән жандармерия канцеляриясендәге папкалар тулачак, бер оешмадан икенче оешмага кәгазь ташып яшерен почта йөртүчеләр аяктан калачак...

1911 елның 11 февралендә жандармерия Уфадагы «Шәрык матбагасы»нда кинәт кереп тентү уздыра. Тентүне алып барган жандарм офицеры протокол төзегәндә «Чын азатлык кайчан булыр?», «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!», «Халык акчалары кая җыела һәм нәрсәгә тотыла?», Г. Тукай шигырьләренең 4 нче дәфтәре һәм М. Гафуриның «Яшь гомерем» дигән әсәрләрен «аеруча хәтәр китаплар» дип билгели.




*М. Гафуриның Язучылар союзы членлыгы таныклыгы.*
*Аңа А. М. Горький үзе кул куйган.*

Әнә шулай итеп, жандармерия чиновниклары каршында «аеруча хәтәр» бер шәхес — Мәҗит Гафури барлыкка килә.

1911 елның 28 апрелендә Сарапул ротмистры Будагоски Әгерҗе авылы укытучысы Котдус Габдрахмановның (бүген без белгән Советлар Союзы Герое, диңгезче Асаф Габдрахмановның әтисе) өендә тентү уздырып, аның көндәлек дәфтәрләрен протоколга кертә. Ул дәфтәрләргә арест салуның бердәнбер сәбәбе — аларда М. Гафури шигырьләре бар икән. Чиновниклар К. Габдрахманов дәфтәрләрен бик җентекләп өйрәнәләр. Шуның нәтиҗәсе буларак, протоколга М. Гафури шигырьләре теркәлә.

Жандармерия бигрәк тә М. Гафуриның «Алмашыну» һәм «Вакыт җитте» шигырьләренә игътибар юнәлтә. «Алмашыну» шигырендәге «Ясадылар кулны аяк, аякны кул» дигән сүзләр тикшерүчеләргә аеруча хәтәр булып тоела.

Уфадагы «Шәрык матбагасы» патша хөкүмәте алдында шактый кыен хәлдә кала. 1911 елда анда М. Гафуриның «Милли шигырьләр» дигән җыентыгының дүртенче басмасы чыга. Ул вакыттагы тәртип нигезендә, китапны сатуга озатканчы, Казандагы матбугат эшләре буенча Вакытлы комитетка җибәрергә тиеш булалар. Заказлар бик күп булудан файдаланып, барыбер рөхсәт килер әле дип уйлыйлар да, рөхсәт язуы килгәнче үк китапның тиражын Казан, Оренбург, Орск, Троицк кибетләренә озата торалар. Әмма китапка рөхсәт килмәгән, һәм властьлар аны конфискацияләргә карар биргәннәр. Китапның тиражын кире җыеп алалар һәм матбага штрафка тартыла. Гафури үзе исә полиция участогына чакыртыла һәм Уфадан чыгып китмәскә имза бирә. Шулай, полиция күзәтүе астында тормыш башлана...

Әмма бу тентүләр, судлар, күзәтүләр Гафурины каушатмый. Аның халык язмышы, ил язмышы турында уйланулары бу чорда тагы да тирәнәя. Балачактан ук хәтергә уелып калган тәэсирләр аны халыкның, илнең тарихына эчкәрәк керергә чакыралар. Шуның иң матур нәтиҗәсе буларак «Агыйдел буенда» («Хан кызы Алтынчәч») дигән искиткеч легенда языла. «Бер бите ай, бер бите көн кебек» сылу кыз Алтынчәч үзен алырга килгән «җәенке битле Җаек буе яубасарына» барырга

риза булмый гына түгел, ә туган җирен саклау ниятендә, кулына корал тотып, дошманга каршы чыга. Җаек аръягыннан килгән дошман гаскәре Алтынчәчнең туган җирен таптый, Алтынчәч, кулы яраланып, тау куышына чигенә һәм шунда кача. Шуннан соң Алтынчәчнең язмышы мәгълүм түгел. Тик менә аның җәйге матур көннәрдә, шул тау тишегеннән чыгып, теге тау киртләченә утырганын күргән кешеләр бар. Ул, шунда чыгып, үзәнең аякларына төшеп торган озын чәчләренә күмелеп, учына таянып, бик моңаеп тугайга таба карап таң атканчы утыра, ди. Ул борын заманда бик еш күренгән, инде бу көннәрдә аны күргән кеше ишетелми. Тик безнең карт әти кич белән монда кунган вакытта үзәнең Алтынчәчне күргәнен, матурлыгына исе китеп карап торганын сөйли торган иде».

Мәҗит Гафуриның «гомер йомгагы» — ул «иҗат йомгагы». Әйе, гомер буе, бер көн калмыйча, ару-талуны белмичә тудырган иҗат йомгагы. Ул иҗат йомгагына үз Ватанын, үз халкын сөйгән, кулына корал алып дошманга каршы чыккан гүзәл кыз Алтынчәч очраклы рәвештә килеп кермәгән. Алтынчәч образы тормышның үзеннән, тарихтан. Тарих бу легенда туганнан бирле Жанна д'Арк, Зоя Космодемьянская, Лиза Чайкина кебек кызларын күп тудырды...

Халык образы, ил язмышы мәсьәләсе М. Гафуриның бөтен иҗат нигезен тәшкил итте. Гомер йомгагының төп җепләреннән берсе дә әнә шул — Гафуриның үзен ил, халык язмышыннан аерылгысыз каравы.

Гомер йомгагы тагын ниләрдән тора соң?

1912 елның җәендә, казакъ даласына дәваланырга барышлый, Тукай Уфага туктала. Ике шагыйрьнең очрашуы шунда була. Авырлык, авыру, патша Россиясендәге намуслы интеллигенция кичергән хәлләр белән кыйналган ике шагыйрь. Бу очрашу турында тарих безгә бик аз мәгълүмат саклап калдырган. Тукай үзе бу очрашу турында болай искә ала:

«Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мөсахәбәмез күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек — әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек — әле күздән яшемез дә кипкән.

Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән»[1]. Әйе, «хөкүмәт тынычлыгын бозучы» шагыйрьләрне әле генә «язмыш ханым кыйнаган» чор иде бу...

Татар әдәбиятында Октябрьга кадәрге крестьян, һөнәрчеләр тормышының бәхетсез, караңгы чынбарлыгын чагылдырган хикәя-повесть, шигырьләр байтак. Әмма бу темага язылган әсәрләр арасында М. Гафуриның хикәя һәм повестьлары аерым урын алып тора.

...Дөнья әдәбиятында катлаулы язмышлы Кнут Гамсун дигән бер язучы яшәгән. Гамсунның чит илдән салкын якка килеп урнашкан бер рәссам турында язган «Кояш улы» исемле хикәясе бар. Кырыс климатлы бу илдә рәссам — кояшлы ил улы — бервзлексез туңа, урамда салкын, бүлмәдә салкын — аның җаны өши, рухы туңа. Гамсунның бу хикәясен укыганда урамдагы эссе кояшлы көнне дә, бүлмә җылысын да онытасың, кояш та, йомшак җылы җил дә, барысы да чын түгелдер кебек тоела — кыскасы, үзең дә туңа башлыйсың. Кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәтне тасвирлауда хикәянең көче әнә шулай сизелә. М. Гафуриның «Ярлылар яки өйдәш хатын» исемле әсәре нәкъ шундый психологик корылмага ия. Бер дә икеләнмичә әйтергә мөмкин, «Ярлылар яки өйдәш хатын» әсәре фәкыйрьләрне тасвирлау ягыннан Европа һәм бөтендөнья әдәбияты югарылыгында язылган. Әсәр гаҗәп эзлекле, төгәл һәм ышандыргыч. Монда без Виктор Гюгога хас сабырлык һәм эзлеклелекне, тормыш шыксызлыгын тасвирлауда хәзерге заман япон язучысы Кобо

---

[1] Тукай. Әсәрләр, 4 том, 1977, 199 бит. Тукайның бу сүзләре хакында әдәбиятта төрле фикер яши. Соңгы басманы төзүчеләр «Яшебез дә кипкән» сүзен, «елап яшебез калмаган» мәгънәсендә аңларга тәкъдим итәләр. Безгә калса бу — типография хатасы. Ихтимал, сәламәтлеге бик нык какшаган Тукай бу әсәрнең корректурасын үзе укый алмагандыр. Дөресе — «Әле күздән яшемез дә кипмәгән» булырга тиеш. — М. М.

Абэга хас чыдамлылыкны, фәкыйрьлекнең төбенә төшкән кеше рухын сурәтләүдә О'Генрига хас осталыкны күрәбез.

Менә көнлекче Шәриф һәм аның хатыны Бәдри, алардан да бәхетсезрәк Җәмилә... Боларны кешелек сыйфатлары гына түгел, ә актык чигенә җиткән фәкыйрьлек тә берләштерә. Беренче карашка болар — хәерчелекнең иң төбенә төшеп җиткән бәхетсезләр — бөтен төрле кешелек сыйфатларын югалтырга тиешләр иде. В. Гюго әнә шулай ди бит: «Фәкыйрьлекнең мәгълүм бер баскычында хәерче кеше шулкадәр томаналана, ул инде үзенең газапларыннан зарланмый һәм яхшылык эшләгәннәргә рәхмәт әйтми башлый». Әмма М. Гафуриның ярлылары өметсез фәкыйрьлек, ачлык, салкын тырнагы астында бер-берсенә тагын да якынрак килеп сыенырга, тормыш итәргә үзләрендә көч табалар. Әнә шул өметсез, нурсыз хәятта да аларда матур сыйфатлар калкып чыга: ярлылар шатлана беләләр! Очраклы рәвештә килеп кергән 15 тиен акчага ризык алып алар бәйрәмчә табын хәзерли, куана, шөкер итә, өметләнә беләләр. Америка язучысы О'Генриның бер җөмләсе искә төшә: «Ярлы кеше үзенең ертык жилетының чабуына әллә кайчан төшеп югалган чирек долларын тапканда яшәү шатлыгына шундый тирән итеп чума — мондый тирәнлеккә бер миллионер да ирешә алмый».

Фәкыйрьләрдәге иң гади кешелек сыйфатларына контраст итеп, Гафури байлардагы күңел тупаслыгын, кешелексезлекне бирә. Киемсез, ризыксыз, ирсез калган ярлы хатын Җәмиләне бай хатыны өеннән куып чыгара.

«Ярлылар яки өйдәш хатын» повесте үзенең мәгънәсе белән әле дә заманча. Повесть җир шарының почмакларында әле дә яшәп килгән фәкыйрьлек, ачлык афәтенең корбаннарын яклау булып яңгырый, социаль тигезсезлекне гаепли. Бу повесть гуманлы бөек мәгънәгә ия, үзенең идея-эстетик йөге белән ул бер татар әдәбиятының гына түгел, дөнья әдәбиятының да уртак хәзинәсе.

*

* *


Беренче империалистик сугышта күренекле татар язучыларыннан берәү дә катнашмаган. Алар барысы да диярлек — салкын, тузанлы мәдрәсәләрдә унар ел белем алып, кайберләре типографияләрдә кургаш тузанын йотып чир алган кешеләр—армия хезмәтеннән азат ителгәннәр. Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, Г. Коләхметов һ. б. — барысы да авыру булган. М. Гафури да шулай тылда калган.

Хәрби-патриотик рухның беренче дулкыны интеллигенциянең төрле катлавына төрлечә тәэсир ясый. Патша хөкүмәтенең ватанны сакларга чакыруына чын күңелдән ышанып, хәрби-патриотик ялкын белән дөрләп алучылар да була. Ике юл чатында туктап, кулдагы каләмне куеп торучылар, аптырап калучылар да була. Әмма барысы да сизенә: зур вакыйгаларның башы бу.

М. Гафури халыкара хәлләрнең, Россия эчендәге вакыйгаларның барышын зур игътибар белән күзәтә. Интуитив рәвештә ул бер нәрсәне сизә: 1906 елда ауарылмый калган «зур агач» тиздән аварга, самодержавие властена чик куелырга тиеш.

...Безнең гасырның унынчы елларында шигырь язучылар арасыннан чын шагыйрьләрне аерып алырга омтылу модага кергән булган. Кайбер газета, журналлар шул чорның иң күренекле өч шагыйрен, биш шагыйрен атап күрсәтегез, дип анкеталар да тараткannнар. Бу исемлеккә керер өчен тырышып чаралар күрүче шагыйрьләр дә булган. Күпчелек, беренче чиратта, әлбәттә, Тукай исемен атаган. Әмма икенче урынны билгеләү кыенрак булган. Тукайдан соң кемне телгә алырга? Рәмиевнеме, Гафурины, Думавины, Дәрдмәнднеме? Беренче өчлеккә керү турында Зариф Бәшири дә хыялланган.

Анкеталарда Гафурины беренче чиратта атаучылар да була. Бу — кызыклы күренеш, чөнки поэтик осталык ягыннан Тукайның үз замандашы Гафуридан алдарак булуы фәндә беркайчан да бәхәс астына алынмады. М. Гафури шул ук вакытта С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд шикелле «идеаль поэзия» вәкиле дә түгел. Гафури халыктан, шәкертләрдән, фәкыйрь крестьяннардан, һөнәрче эшчеләрдән. Аның шигырьләрендә бәхетсез фәкыйрьләрнең иңрәү авазларын, ачы язмыш ноталарын башка шагыйрьләрнең әсәрләренә караганда ешрак ишетәсең. Халык аһ-зары, халык ың-



*М. Гафури ял иткәндә.*



гырашуы Беренче рус революциясе елларында башка шагыйрьләргә караганда, Гафурида тизрәк революцион рух алды, «зур агач»ны аударырга чакыруга кадәр үсте. Менә бу яктан — политик вакыйгаларга дөрес бәя бирү, кыйбла табу ягыннан караганда — Гафури иҗаты тарихның һәрбер борылышына дөрес юлны башкалар белән чагыштырганда тизрәк табуы белән аерылып тора. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач та нәкъ шулай була.

1913 ел — татар әдәбиятында — торгынлык елы. Ф. Әмирхан моны нәкъ шулай, «уңышсызлык» елы дип атады. Тукай юклыгы сизелә. Г. Коләхметов, Г. Камал авыру. Г. Ибраһимов Казаннан читтә, зур әсәргә керешкән. Ф. Әмирхан үзе дә бу елда аз яза. Әдәбиятта тынлык. 1914 ел августында Россиянең көнбатыш чикләрендә ярылган герман снарядлары бу тынлыкка чик куя. Моны ничек бәяләргә?

Ватанны тышкы дошманнан сакларга чакыру темасы әдәбиятны, публицистиканы басып китә. Күпләр патша хәзрәтләрен, анабыз Ватанны сакларга, Ватан өчен шәһит китәргә өндиләр. Әнә шундый әдәби ташкын эченнән М. Гафури авазы ишетелә. Шагыйрь сугыш афәтен бөтенләй көтмәгән яктан килеп тикшерә: ул аллага мөрәҗәгать итә. Татар әдәбиятында антимилитаристик пропаганданы ул алланың үзен шик астына алудан башлый.

**Юктырсың ла, алла! Әгәр булсаң,**
**Сабыр итмәс идең бу эшкә,**
**Бөтен кодрәтеңне баглап куймас**
**Идең җирдә алтын-көмешкә.**

**Бәндәләрең булды чын бәхетсез,**
**Диннәрең дә файда бирмәде,**
**Тәгълиматың ошбу көнгә чаклы**
**Сәгадәткә [1] ирештермәде.**

[1] Сәгадәт — бәхет.

Кодрәтең там[1] булса, бер фәрманың
Җитмәс идеме соң тыярга!
Чын-чын татулыкны, мәхәббәтне
Мәңге урнаштырып куярга!..

Алланың кодрәте мәсьәләсе татар поэзиясендә беренче мәртәбә өнә шулай шик астына алынды. Монда без Гафуриның дөньяга һәм идея-эстетик карашларында эзлеклелек күрәбез. Канкойгыч сугыш фонында ул кайгы-хәсрәт темасына күчә: тол калган миллион хатыннар исеменнән «сугышта хәбәрсез югалган туганга» мөрәҗәгать итеп шигырь яза. Бу шигырь юлларында бөтен дөньяның ятим солдат аналары, тол солдат хатыннары сөйли. М. Гафури бөтендөнья кайгысы белән кайгыра, бөтенкешелек күз яше белән елый белә иде. Әнә шул бөтенкешелек җәмгыятенең күз яшьләрен күрү аны эзлекле, интуитив рәвештә сугышның империалистик характерын аңлауга кадәр китереп җиткерә — татар шагыйрьләре арасында беренче чиратта сугышның бу сыйфатын М. Гафури аңлый. Шагыйрь үзенең гуманизмы нәтиҗәсе буларак сугышка мөнәсәбәттә нәкъ менә большевиклар позициясенә табигый-стихияле рәвештә килеп чыга. «Империалистлар сугышы корбаннарына» багышлап Гафури 1915 елда — большевиклар сугыш турында резолюция кабул иткәнгә бер ел тулгач— идея ягыннан көчле, тирән мәгънәле «Ул кем?» шигырен яза. РСДРП Үзәк Комитетының сугышка карата кабул иткән Манифестын хәтерлик: анда сугыш чорындагы бик күп бурычлар белән беррәттән сугышучы илләрнең солдатлары арасында туганлашу кирәклеге турында да әйтелә. Швейцариядә В. И. Ленин җитәкчелегендә большевиклар тарафыннан эшләнгән бу документның бер пункты Гафури шигыре аркылы 1917 елда караңгы, ятим татар авылларына килеп җитә. Син кемне үтердең? — дип мөрәҗәгать итә ул солдатка.— Үз туганыңны үтердең. Син бит эшнең асылын аңламыйча үтердең. Сезнең берәр бүләр нәрсәгез бар идеме? Сезнең бит ирегегезне буып шулай бер-берегезне үтерергә куштылар. Сез бит бер-берегезне бөтенләй белми идегез, син — шәрыктән, ул гарептән килде.

Мин сорыйм синнән хәзер: үтереп үч кандымы!
Син аны чәнчеп үтергәч, дөнья бик киң калдымы!
Син шулай коллыкта йөрсәң, дөнья киң булмас сиңа,
Барча эшләрдән элек баш бул, туган, үз иркеңә.
Үз кулыңда саклый алсаң син әгәр хөрриятең,
Бер дә чәнечми дә сыярсың: дөнья киң бит, дөнья киң.

Гафури сугышның мәгънәсез үлем икәнлеген әнә шулай, гап-гади итеп, крестьянча аңлатты. Мондый фикергә килгәнче татар шагыйре, ихтимал, күп уйланулар, эзләнүләр кичергәндер.

Моннан соң инде Гафури вакыйгалар эзеннән атлый. Февраль революциясендә монархияне бәреп төшерү вакыйгасын ул шатланып каршы ала («Хөррият иртәсе»). Дөрес, шигырен әле ул «Яшәсен чын хөррият!» дигән җөмлә белән тәмамлый. Ихтимал, самодержавиене бәреп төшерүне баштарак шагыйрь «чын хөррият» дип кабул иткәндер. Шундый ук аваз аның «Азатлык хөрмәтенә» дигән шигырендә дә сизелә.

Ләкин бу очракта Гафури — 1917 ел җәенең катлаулы политик атмосферасында да — үзенең кыйбласын тиз таба. Вакытлы хөкүмәтнең сугышны дәвам итү политикасы халыкка нинди «хөррият» әзерләгәнен төшенеп алгач, ул поэзиядә турыдантуры сугышка каршы пропаганда башлый. «Бетсен сугыш!», «Хөрриятkә каршы торучыларга» кебек шигырьләрендә Гафури канкойгыч сугышны туктатырга кыю рәвештә өнди, чакыра. Әмма шагыйрьне пацефист булган дип уйларга нигез юк: Корнилов фетнәсе мөнәсәбәте белән язылган «Аждаһа» шигырендә ул хезмәт халкын, кулына корал алып, үз иреге өчен сугышка чыгарга өнди.

Канлы байракларны тәкрар кулга алыйк,—
Ул явыз дошманга каршы кузгалыйк,
Хөррият җырларыны җырлап барыйк,—

[1] Там — тулы.

Әһле хөррият, тагын кузгалыгыз!..
Баш күтәрмәкче була дошманыгыз...

М. Гафуриның «Кызыл байрак» шигыре татар поэзиясе фондына асылташлардан берсе булып кереп калды. Бу шигырь беренче тапкыр патшасыз уздырылган Май демонстрациясе тәэсире белән язылган. Гафури монда эшчеләр сыйныфының кара көчләргә каршы көрәше символы булган Кызыл байракка гимн җырлый. Бары тик шул Кызыл байракта гына чын хакыйкать, чын ышаныч. Әнә шуңа күрә ул башка һәммә байрактан югары күтәрелгән:

Әй, Кызыл байрак,
Нур бир җиһанга!..
Әйдә, эшчеләр,
Алга вә алга!..

М. Гафури әнә шулай — империалистик сугышны кире кагудан эшчеләрнең революцион көрәшен яклау позициясенә килеп чыкты. Октябрь революциясен ул әнә шуңа күрә тарихи барышның табигый бер финалы буларак шатланып кабул итте.

*
* *

Бөек Октябрь социалистик революциясе Мәҗит Гафуриның иҗат чишмәләре өчен искиткеч зур мөмкинлекләр тудыра. Ул, киң колач алып, проза, поэзия, публицистика жанрларына кереп чума, бераздан үзен драматургиядә сынап карый.

Аның Октябрьдан соң язган күренекле әсәрләреннән берсе — «Тормыш баскычлары» повесте.

Гафури, гомумән, үз әсәрләренә бик гади исемнәр куя: «Ярлылар яки өйдәш хатын», «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» һ. б. «Тормыш баскычлары» да шулай — туры мәгънәгә ия. Бу системадан, ихтимал, «Кара йөзләр» исеме генә бераз аерылып торадыр.

Әгәр әдәби әсәр үзенең күтәргән мәсьәләләре буенча (гәрчә ул милли характерлар, милли бизәкләр белән эш итсә дә) теләсә кайсы милләт укучысының күңеленә тәэсир итәрлек икән, әгәр язучы милли характер, милли көнкүреш аркылы гомумкешелек проблемалары күтәрә икән — мондый әсәр теләсә кайсы телдә дә яңгырамыйча кала алмый.

М. Гафуриның «Тормыш баскычлары» дигән повесте белән шулай булды. Рус укучысы «Мәҗит Гафури» диюгә, беренче чиратта, аның «Тормыш баскычлары» дигән повестен телгә ала. Әле күптән түгел генә мәдрәсәнең юаш шәкерте булган Вахит исемле татар егетенең тормыш баскычлары... Мәдрәсәдә вакытта хәлфәләр аңа бик күп тапкыр изге сугыш-газават турында сөйләгәннәр. Вахитка егерме яшь тулганда хәзрәт аңа дәрестән «Китабелҗиһад» укыта башлый. Хәзрәт егетләрнең канын тәмам кыздыра:

— Кяферләр сугыш башласалар, билләһи, башлап үзем китәм! Бу көннән бик шәп чукмар әзерләп куярга кирәк әле, алай-болай була калса, пранме бер-ике кяфернең башын ярып чукындырам! — дип гайрәтләнә Вахит.

Әмма озак та үтми, Вахит наборга эләгә. «Кяфер»-рус егетләре белән бергә ул хәрби комиссия уза, шулар белән бергә армиягә алына. Ә бит болар кяфер! Аларга каршы сугышасымыни инде? Алай дисәң, «кара чикмәнле, ыштырлы рус егетләре» үзләре дә солдатка теләп бармыйлар.

Солдатка киткәндә дә хәзрәт аларны:

— Падишаһ хәзрәтләренә яхшы хезмәт итегез, аның олуг түрәләренә итагатьчел булыгыз,— дип озатып кала.

Менә сиңа мәдрәсә китабы, менә — тормыш!

Вахитның күзе армия хезмәтендә тагы да ачыла. Политик эшчәнлек алып баргән өчен хәрби трибунал тарафыннан суд ясалып өч солдатны строй алдында үлем




*М. Гафуриның беренче сайланма әсәрләренең титул бите. Казан, 1932.*

җәзасына тарталар. Кяферне кяфер атып үтерә. Вахитның рухында бөтен бер борылыш ясала. «Монда кяферлек тә, мөселманлык та юк», дип уйлап куя Вахит шул чакта. Бу инде — Вахит тормышындагы әһәмиятле баскычларның берсе. «Шушы вакыйгадан соң Вахит руслар белән мөселманнар дип бүленүнең урынсыз икәнен, болар арасында байлар һәм алар яклы кешеләр булып, тагын бер төрле халыкның аларга каршы көрәшүен ишетә һәм күрә башлады». Тыныч табигатьле, тыйнак авыл егетендә акрынлык белән генә революционер өлгерә башлый. Әмма аның рухында, гамәлендә бу үзгәрешләр күп баскычлар аркылы ясала. М. Гафуриның реализм көче, әдәби осталыгы да әнә шунда — бер Вахиттан икенче Вахит ясауның эзлеклелеген тормышчан итеп бирә белүдә. Вахит — крестьян улы, мәдрәсә шәкерте. Дини уку йортында тәрбия алган бу егет интернационализмнан бик ерак, хәрби, социаль-политик мәсьәләләрдән бик читтә була. Шуңа күрә повестьта без аның революционлаша баруын гамәлдә түгел, ә уйфикерләрендә күрәбез. Теге шомлы төндә Вахит болай уйлый: «Безгә боларны атарга кушалар икән, туры карап атмаска, пуляны аскарак яки өскәрәк җибәреп, тигезми калдырырга...» Ә инде эшчеләр демонстрациясен таратырга приказ алгач, Вахит конкрет эшкә күчә: бер яралы эшченең баш очында ялтыраган кылычны ул штыгы белән этәрә, эшченең гомерен саклап кала. Монысы — Вахит тормышында яңа, тагын да югары баскыч.

Крестьян егете Вахитның тормыш баскычлары әнә шундый.

М. Гафуриның бу повесте театр, кино һәм телевидение сәнгате өчен искиткеч уңайлы һәм отышлы материал. Сәнгать кешеләре киләчәктә, һичшиксез, бу повесть белән кызыксыначаклар, чөнки монда татар халкының үткәне, рухи тарихы, монда — татар хезмәт ияләренең киләчәккә текәлгән карашлары...

М. Гафуриның Октябрьдан соңгы иҗатында «Кара йөзләр» повесте аерым бер урын алып тора. Идея-эстетик йөге ягыннан, ихтимал, бу әсәр иң тирән фәлсәфи уйлануларны таләп итә торган әсәрдер.

Повесть милли үзенчәлеккә корылган. Хәер, бу әсәрдә дә без Н. Лесков, А. Н. Островский, Г. Успенский, В. Г. Короленко, М. Горький әсәрләрендә чагылыш тапкан патша Россиясендәге башбаштаклык, кыргыйлыкны күрәбез. Бу яктан килгәндә «Кара йөзләр» повесте шулай ук гомуми әдәбиятның бер кисәге. Сюжетның милли үзенчәлеге исә шуннан гыйбарәт: татарлар яшәгән төбәкләрнең бик караңгы почмакларында «уйнаш»та тотылган егет белән кызны яки ир белән хатынны, битләрен корымга буяп, урам йөртү гадәте булган. Моның бөтенесе шәригатькә нигезләнеп эшләнгән. Чөнки шәригать уйнашта тотылган хатын-кызны муеныннан җиргә күмеп, таш ыргытып, үтерергә рөхсәт иткән. Шәригатьнең мондый кыргый законы белән файдаланучылар булгандырмы-юктырмы, тарихта андый истәлекләр калмаган. Әмма йөзләренә кара ягып урамда йөртүләр булган. Башта ук кисәтеп куйыйк: М. Гафуриның бу повестена биргән искәрмәсеннән чыгып («Иске тормышның миллион корбаннарыннан берсе») һәр очрашкан егет-кызның йөзләренә кара ягып урам йөртү татарлар арасында массовый күренеш булган икән дип аңланмасын. Юк, үз хезмәте белән көн күрүче крестьян яшьләре бергә кырда, ындырда эшләгәннәр, өмәләрдә, аулак өйләрдә очрашканнар, сөешкәннәр, хәреф белгәннәре мәхәббәт хатлары язган, кавышканнар, тормыш иткәннәр. Әгәр инде Гафури үзенең Галимәсен «иске тормышның миллион корбаннарыннан берсе» дип атый икән, моны киңрәк аңларга кирәк: патша Россиясендә татар хатыны шундый хурлыклы, газаплы язмышка дучар ителгән иде ки, корбаннар, чыннан да, миллионнар белән исәпләрлек.



*Шагыйрьнең Уфадагы һәйкәле.*

«Кара йөзләр» повесте үзенең сюжет төзелеше буенча «Тормыш баскычлары» повесте белән охшаш. Мондый нәтиҗә беренче карашка сәеррәк тә яңгырарга мөмкин: «Тормыш баскычлары»нда бит солдат язмышы, солдат тормышы; «Кара йөзләр»дә исә вакыйга караңгы татар авылында бара һәм авылның иң матур кызы Галимәнең имгәтелгән тормышы тасвирлана. Ләкин бу әсәрнең нигезенә алынган материаллар аермасы гына. Авторның идеясе, тенденциясе исә һәр ике әсәр өчен дә уртак: Гафури һәр ике повестенда да үз геройларының кадими мәдрәсәдә башларына төягән чүп-чардан әзлекле рәвештә азат булуларын сурәтли. Беренче очракта — Вахит шәкерт. Икенче очракта исә, Гали шәкерт — шулай ук иске мәдрәсә җимеше — үзе ихтирам иткән хәзрәтләр, хәлфәләрнең аның сөекле апасы Галимәне ничек пычратуларын, имгәтүләрен күреп айный башлый, күз алдында булып үткән трагедия аның гына түгел, Галимәнең әти-әнисенең һәм башкаларның да күзен ача.

Кара йөзләр — битенә корым ягылган Закир белән Галимә түгел, кара йөзләр — бөтен мәхәлләнең рухи атасы — карт хәзрәт, Галигә сабак бирүче бозык күңелле хәлфәләр, кыргый инстинктлары уянган, шәригатькә сукырларча ышанган надан мужиклар, куштаннар.

М. Гафуриның Октябрь революциясеннән соң иҗат иткән проза әсәрләре арасында «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1929) дигән автобиографик повесть бар. Әсәрдә XIX йөз ахырларындагы татар-башкорт эшчеләренең коточкыч эксплуатация шартларында тир түгүләре, хуҗаларын баету өчен бил бөгүләре тасвирлана. Зур социаль мәсьәләләр куелып та, художестволы гомумиләштерүнең җитеп бетмәве, әлбәттә, бу әсәрнең кимчелеге иде. Әмма бу әсәрендә дә Гафури каләменә хас булган бер күркәм сыйфат алгы планга чыга: ул — түбән катлау вәкилләрен югары өхлаклы, кешелекле сыйфатлар белән сурәтләү. Эшче Сибгат әнә шундыйлардан.

Егерменче-утызынчы елларда М. Гафури үзенең бөтен поэтик талантын яңа тормышны мактап җырлауга бирде. Бу елларда өлкән буын шагыйрьләреннән социалистик тормышка дан җырлаучы иң актив кеше М. Гафури иде. Аның егерменче-утызынчы еллар иҗатында иске тормышка яңа, азат тормышны контраст итеп алу, чагыштыру иң яраткан алымы булды. Үзенең бөтен иҗаты белән Гафури Октябрь казанышларын сакларга, моның өчен берәзлексез хезмәт итәргә чакырды. Үзе исә азат тормыш шатлыгы белән дулкынланып, җиң сызганып әдәбиятка, культурага хезмәт итте: хикәяләр, повестьлар, поэма, драма, шигырьләр, мәкаләләр язды. М. Гафури Октябрьдан соңгы бөтен гомере буенча социалистик җәмгыять тудырган хөрлек, азатлыкка сокланып туя алмыйча яшәде.

Әнә шуңа күрә татарлар өчен әлегә зур яңалык булган милли опера сәнгатенең беренче адымнарында композиторлар Солтан Габәши һәм Газиз Әлмөхәммәтовлар нәкъ менә М. Гафурига мөрәҗәгать итәләр. Габәши һәм Әлмөхәммәтовларның беренче хезмәте булган «Сания» операсы турында хәбәр бөтендөнья матбугатын шаулата. Бу, әлбәттә, очраклы хәл түгел. Бөек Октябрь революциясен кабул итмичә чит илгә качкан милләтче ак эмигрантлар «большевиклар милли сәнгатьне бетерәләр» дип Харбин, Хельсинки, Париж, Истамбул газеталарында гайбәт сатып яткан арада татарларда беренче милли опера иҗат ителә. Опера сәнгатен тудыру —



*Уфа. 1958 ел. Язучылар Л. Соболев, З. Нури, Г. Кашшаф, Г. Рамазанов, Х. Туфан, К. Мәргән һәм Г. Әпсәләмов М. Гафури кабере янында.*

теләсә кайсы халыкның культура үсеше дәрәҗәсенең күрсәткече. Беренче татар операсы турындагы хәбәрләр Берлин, Рим, Токио матбугатларында басыла. Ак эмигрантларның прогнозлары акланмый. Беренче операны тудыру композиторларны яңа иҗат эшенә дәртләндереп җибәрә. Бу юлы инде сыйнфый юнәлеше, социаль эшчәнлеге ачыграк булган әсәр тудыру турында хыялланалар. Моның өчен М. Гафуриның «Эшче» поэмасы кулай табыла. Автор үзенең поэмасы буенча либретто язарга ризалык белдерә. Шул максатта ул Казанга килә. Бу эшкә композитор В. Виноградов та тартыла[1]. «Эшче» операсын иҗат итү турындагы мәсьәлә партия, хөкүмәт органнары белән берлектә тикшерелә һәм рәсми төс ала. Ул арада матбугатта яңа опера тудыру юлында эш башланды дигән хәбәр дә басылып чыга. Либреттоның нигезенә 1905 ел революциясе чорында татар-башкорт эшчеләренең тормышын, көрәшен алырга тәкъдим ителә. Эшчеләр тормышын өйрәнү, истәлекләр сөйләтү, карт эшчеләр белән очрашу максатында, алар 1928 елда Златоуст заводларына киләләр. Златоуст заводларында, бәхеткә каршы, 1905 ел вакыйгаларын үз башларыннан кичергән карт эшчеләр байтак була. Истәлек сөйләтүләр, язып алулар, әңгәмәләр кыза... Газиз Әлмөхәммәтов үзенең булачак герое эшче Нигъмәткә туры килерлек прототип таба. Шул очрашулар вакытында ук инде аерым фрагментлар туа. Моның өчен уңайлык та бар: Г. Әлмөхәммәтов баш герой Нигъмәт партиясен үзе башкарырга җыена. Авторларга бигрәк тә Нигъмәтнең саубуллашу ариясе зур канәгатьлек хисе бирә. М. Гафуриның үзенә хас булган уйчанлык, тыйнаклык, сагышлылык сыйфатлары, Нигъмәт образына күчеп, Октябрь революциясенә кадәрге татар эшчесенең колоритлы бай образын тудыра.

**Кай диңгезгә барып төшә икән**
**Ашыгып-ашыгып аккан агымсу.**
**Рәхәт иде бергә торган чаклар.**
**Аерылышу бигрәк ямансу.**

Дүрт кешелек «берләшмә» бик уңышлы эшли. Композиторлар һәм башкаручы теләгенә буйсынып, Гафури текстларны эшкәртә, төзәтә; Әлмөхәммәтов, татар-баш-

---

[1] Операның ничек иҗат ителүе һәм сәхнәгә ничек куелуы турында Г. Әлмөхәммәтовның хатыны Мәстүрә ханым Фәйзуллина истәлекләрендә тулы мәгълүмат бар: «Хәтердән чыкмый торган кеше» дигән китапта: Мәҗит Гафури турадында замандаштары, Өфө, 1961, 163—171 битләр.

корт музыкаль фольклорын яхшы белүче буларак, әсәрне халык мелизмнары белән бизи; Виноградов һәм Габәши әсәрнең музыкаль композициясен төзүдә зур осталык күрсәтәләр.

Татарстан АССР хөкүмәте республиканың унъеллык бәйрәмен «Эшче» операсының премьерасы белән билгеләргә карар бирә.

Опера Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә 1930 елның 22 июнендә куела. Уфадан махсус премьерага килгән Гафурины һәм композиторларны һәр пәрдәдән соң көчле алкышлар белән сәхнәгә чакыралар, әсәр шулай зур триумф белән бара.

Сәнгатьнең авыр, катлаулы бер фронтында җиңү яулана. Бу өлкәдә традицияләр булмаган көе социаль эчтәлекле милли опера тудыру М. Гафуриның һәм композиторларның гражданлык батырлыгы иде.

Советлар Союзында культура, әдәбиятның гөрләп чәчәк ата баруына шатланып бетә алмаган Гафуриның гомере кыска була. Шәкерт вакытындагы ачлы-туклы тормыш, шахталарда, прискаларда башкарган газаплы хезмәт, полиция-жандармерия тарафыннан эзәрлекләнү, «язмыш ханым тарафыннан кыйналу» — барысы бергә җыелып илле яшьләренә җиткәндә аның сәламәтлеген какшата. Ул 1934 елда, нибары 54 яшендә, үлеп китә.

*

* *

М. Гафуриның тормыш юлы, аның иҗаты — татар, башкорт халыклары үткән юл, аларның әдәбият-культура тарихлары юлы. Гафури иҗатында татар, башкорт халыкларының көнкүреше, рухи тормышы мәгънәле чагылыш тапты. Гафури иҗатында татар, башкорт хезмәт ияләренең ачлык, коллыктан чыгу өчен бөек рус халкы белән берлектә Октябрь революциясендә катнашулары, революциядән соң зур дәрт белән яңа тормыш төзүләре киң рәвештә яктыртылды. М. Гафуриның бөтен иҗаты — әнә шул бәхетле дәвамы булган авыр көрәш юлының көзгесе.

**Рифкать Әхмәтҗанов,**
филология фәннәре кандидаты

# МИРАСТАН ИКЕ ЭНҖЕ

## «Заятүләк берлә Сусылу»

„Заятүләк белән Сусылу» дастанының М. Гафури язып алган үрнәге башка вариантлардан теленең китапчалыгы белән аерылып тора. Әгәр дә дастанның чәчмә өлеше генә «китапчарак» булса, бер дә гаҗәп булмас иде. Чөнки М. Гафури текстны үзе тапкан берничә язма вариант нигезендә бәян иткән. Әмма дастанның шигъри өлеше анык тугел. Бу хәл «Заятүләк белән Сусылу»-ның башка вариантларында да шул ук яисә шуңа охшаш шигъри юллар булуыннан беленә. М. Гафури вариантындагы шигырьләр традицион китап теленә тартым булулары белән генә аерылып торалар.

«Заятүләк берлә Сусылу» татарча ике тапкыр — 1910 елда Уфада һәм 1927 елда Казанда, латин хәрефләре белән басылып чыга. Шуннан соң ул берничә мәртәбә башкорт телендә басыла.

«Заятүләк белән Сусылу»га багышланган әдәбият шактый күп[1], әмма дастанга әлегәчә фәнни текстологик анализ ясалмаган.

Инде текстка килик.

«Моннан күп заманнар элек, кыргыз илендә, — дип башлый М. Гафури, — Ун сан Уймат диган йортта, Сары Моркас исемле бер хан бар иде». Олы хатынының алты баласы арасына кече хатыннан бер бала — Заятүләк дөньяга килә. Заятүләк һәр эштә, бигрәк тә ханзадәләрнең сөйгән эше — кош чөюдә беренчелек күрсәтә. Бер мәлне агалары ялан-япанда Заятүләкнең аргамагын чатанлатып, йөгәнен алып, үзен куып җибәрәләр. Заятүләк кайту юлында Ачылы күл янына килеп туктый. Шунда су читендә чәчен тарап утырган Сусылуны күрә һәм, әлбәттә, шундук биһуш гашыйк булып, аңар түбәндәге сүзләр белән эндәшә:

**Сәлам бирдем бән сәңа,**
**Айтик күркле йөзеңә,**
**Гашыйк булдым бән сәңа,**
**Көндәй күркәм үзеңә,**
**Хәйран булып калыпмән**
**Бал-шикәрдәй сүзеңә...**

. . . . . . . . . . . . .

**Сәфәр кыйлдык күп кеше,**
**Йөгәнем суйды өч кеше.**
**Атым килә ярашып,**

[1] Мәргән Қ. Қ. Зәятүләк менән һыуһылыу комарткыһы тураһында. «Әдәби Башкортстан», 6 сан, 1960, 87—95 битләр. Киреев А. Н. Башкирский народный героический эпос. Уфа, 1970. Csikai V. Eine unveröffentliche baschkirische Volksmärchen-variante. «Acta oriantalia», t XXVIII, 1. 1971. Башкирский народный эпос. М., 1977. 35—42 бит һ. б.

**Кулым килә карышып.**
**Атым-юлым белмәймән,**
**Җирең-суың белмәймән,**
**Атың әйтче, әй, сылу,**
**Җирең әйтче, Сусылу.**

**Сән, бән, инеп, калыпмән** сүзләре һәм формалары иске нугай-татар төркисеннән килә. **Йөгәнем суйды** (салдырып алды) гыйбарәсе дә казакъ, нугай даирәсенә хас. Әмма китерелгән тексттагы:

**Атым килә ярашып,**
**Кулым килә карышып,**

— дигән юллар бөтенләй урынсыз тоела. Безнеңчә, бирелә хата М. Гафури файдаланган кулъязмалардан ук килә. Төп нөсхәдә:

**Атым килә йер ашып,**
**Кошым килә кыр ашып,**

— булган булса кирәк. «Йер» — нугайча «җир», «ашу» — өстеннән үтү. Нугайча **косым** («кошым) сүзендәге гарәпчә «с» хәрефен М. Гафуригача кадәр күчереп язучыларның берсе «л» дип укыганлыктан, басма текстка ул «кулым» булып килеп кергән. Тик шулай фикер йөрткәндә генә китерелгән сүзләр контекстка яраклаша: Заятүләкнең бар уйлаганы — аты һәм кошы (ак шоңкары), ул шулар белән горурлана, шулар турында күп сөйли (бу «Заятүләк белән Сусылу»ның барлык вариантларында да ачык чагыла һәм нугай дастаннары геройларына гомумән хас нәрсә).

Китерелгән өзектә тагын бер хата — **җирең-суың** сүзе. Дөресе — **җирем-суым:** төрки халыклар эпосында бер-берсенә таныш булмаган ике баһадир очрашса, бер-берсенең атын-юлын әйтешәләр, шуннан соң я дуслашалар, яисә бер-берсе белән «базалар», «баз әйтәләр», ягъни каһарманый бәхәс куптаралар һәм ул бәхәс сугышкөрәш белән тәмамлана («Заятүләк белән Сусылу»ның кайбер вариантларында бу ике каһарман, чынлап та, көрәшә башлыйлар).

Шуннан соң Заятүләк кызга **туганнарымнан бизәйен, сәнең белән булайың... аргамактан бизәйен, сәнең белән булайын** дип сөйли башлый (булайын, беләйен h. б.— нугай язма теленә хас формалар). Кыз аны үзеннән калырга үгетли һәм ахырда йолым биреп котылмакчы була «алтын тарак, ай көзге» тәкъдим итеп карый. Әмма Заятүләк барыбер үзенекен сөйли.

Ахырда Сусылу егетне читкә каратып алдата да, суга чумып китмәкче була. Әмма Заятүләк аның чәченнән тотып өлгерә. Икәүләшеп күл төбенә — су асты патшасы **Чачуар** (кайбер вариантларда **Җаждар,** дөресрәге — Җувдарһа, Җөдар — төрки халыклар, мәсәлән, төрекмәннәр мифологиясендә юха — аждаһаның бер төре[1]) патшалыгына, Сусылуның ак пыяла сарае алдына килеп чыгалар. Төрле вак маҗаралардан соң Заятүләк кызга өйләнә, кәеф-сафада яши. Әмма илен-җирен сагынып саргая, моңлана башлый.

Ә Сусылу һаман элеккечә якты дөньяга — су читенә чыгып йөри икән. Һәм ул Заятүләккә җир өстендә аты белән кошы көтеп торуларын әйтә. Заятүләк аларны үз янына ирештерүне үтенә. Әмма Сусылу моны булдыра алмый:

**Атың синең елмая,**
**Аңа килер юл кая,**
**Ул хезмәтне итәргә**
**Хәлем килми, бай углы.**

---

[1] Каррыев Б. Богатырская свадьба Гер-Оглы. Известия АН Туркменской ССР. Серия общественных наук, 1977, № 3, 43—51 битләр.

Атның «елмаеп» торуы монда урынсыз. Дөресе — нугайча **йелмайа**, казакъча һәм кыргызча **желмая** — җилдән җитез легендар ат, канатлы ат.

Шуннан Сусылуның атасы кияven һәм кызын җиргә чыгарып куя, бик күп мал бирә. Алар Балкантау дигән җирдә яши башлыйлар. Заятүләк шунда шаһ булып китә. Ләкин инде хәзер Сусылу үз туган җирен сагына башлый. Чачуарның җеннәре боларны тагын су асты патшалыгына күчерәләр, хәтта Заятүләк күңелен күреп, аңа Балкантауга охшаш бер тау китереп куялар. Тик Заятүләккә ул ошамый: «Минем тавым түгел бу», — ди.

Дастанның М. Гафури бәян иткән варианты Заятүләк белән Сусылуның кабаттан якты дөньяга чыгып, Балкантауда гомерләрен үткәрүләре белән тәмамлана. Шулай итеп, монда төп конфликт туган якны сагыну белән яр сөю арасында булып чыга һәм ул да шактый «тешсез» хәл ителә. Ләкин, текст белән җентекләбрәк танышканда һәм, бигрәк тә, күп санлы башка вариантларны карап чыкканнан соң, «Заятүләк белән Сусылу»ның безгә билгеле нөсхәләре тирән эчтәлекле зур бер дастанның кызганыч калдыклары гына булуына ышанасың.

М. Гафури текстында байбичә (өлкән хатын) угыллары белән кече хатын углы Заятүләк арасындагы конфликт үстерелми кала. Дастанның безгә килеп җитмәгән төп варианты нәкъ менә шул конфликтка корылган булган. Сусылу белән мәҗаралар — шундагы бер эпизод кына. Ләкин ниндидер бер мохит таләпләре белән дастан социаль мотивлардан махсус рәвештә арындырылган.

Моның шулай икәнлегенә дәлилләрнең берсе — Заятүләк исеменең этимологиясе.

Бу исем ике өлештән тора: Зая һәм Түләк. Күп кенә урыннарда төп каһарман Түләк дип кенә атала. Димәк, Зая исем компоненты түгел, ә үзенчәлекле бер сүз генә. «Зая» дигән сүз нугай телендә азап, газап, газаплану, «зая булу» — шәһит булу, «заялы» — «газаплап үтерелгән» мәгънәләрен аңлата. Бу сүз, һичшиксез, төрки-монгол мифологиясенә хас булган «зая» образына тоташа (билгеле булганча, нугайлар— төркиләшкән монголлар). Төрки-монгол халыкларында **зая** (җая, җаян, җаяга, чая, чаян, йайан, дзаян, заян) — бик үзенчәлекле мифологик образ[1]. (Татар телендә бу образга **чая, шаян, шаяру** сүзләре тоташа). Зая — табигый үлем белән үлмәгән җан ияләренең өрәге ул. Зая — үчле, ачулы, кире җан иясе, ләкин ул торган саен яхшылыкка бара. Тәннән арынган җан (зая) бик актив булып китә: ул кешеләрнең язмышына тәэсир итә. Заялар тере чактагы шикелле тормыш белән яшиләр. Аларның терлеге күп — барлык корбан итеп чалынган терлек заялар кулына керә. Вакытвакыт алар **чоглан** дигән җыелыш җыялар (гомумтөрки **чогула** — «җыелу» сүзеннән, шулай ук татарча **чолан** — «кунак өе, җыелыш өе, ишегалды» сүзе дә шуннан килә) һәм теге яки бу дәүләтнең эшләренә тыкшыну планнарын коралар. Зая эт (үтерелгән этнең өрәге) **имерә** дип атала. Кайчагында имерә кыр буйлап куян куа: аның чапканын үлән-камылларның тибрәнүеннән белеп була... Гомумән, заялар терлекчелеккә химая итәләр: төрек, әзербайҗан телләрендә **зайа, сайа** — терлекчелек алласы[2].

Заятүләк вакыйгасында үтерелгән ханзадәнең (һәм аның аты белән кошының) заясы хәрәкәт итә башлый (М. Гафурида — аягына кадак кагылган ат, Түләк төштә күргән бер кешенең догасы ярдәмендә, аягына баса һәм җилдәй җилеп, чабып китә). «Заятүләк белән Сусылу», шулай итеп, Түләк исемле ханзадәнең заясы турындагы эпос ул. Аның сюжет силәсе — канмаган үчләр, үтәлмәгән теләкләр трагедиясе («үтерелгән ханзадә»нең исеме Түләк, ягъни «бәрән; юаш, мескен, тыныч кеше» мәгънәсендәге сүз булуы да бәлки шуны ассызыклап сайлангандыр).

Барлык китерелгән мәгълүматлар шуны исбат итә: «Заятүләк белән Сусылу» — тептә нугай эпосы. Ул кайчандыр (ихтимал, XVI гасырда хәзерге Башкортстанның көньяк-көнбатышында яшәгән нугайлардан) төрки телгә якынлаштырып язып алынган (нугай, казакъ элементлары чагылган шундый төрки телдә Ә. Курамшинның «Буз

---

[1] Бу образ турында: Хангалов М. Н. Собрание сочинений, т. 2, Улан-Удэ, 1959 (бөтен том «зая»ларга багышланган), Банзаров Р. Собрание сочинений, М., 1955, 56, 63—79, 273—274 битләр. Катанов Н. Ф. Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся во втором томе «Образцов народной литературы тюркских племен» Радлова В. В., СПБ, СПБ, 1888, 22, 79—83 битләр h. б.

[2] Saferoglu A. Zwei schamanen-Gottheiten Astrbaidschans und Anatoliens. Ural-altaische Jahrbücher, m. XXIX, 3—4, 1957, 240.

егет», «Таһир илә Зөһрә» поэмалары да язылган). Шуннан бу дастан башкортлар арасында киң таралган (бу хәл шул тирәдәге нугайларның башкортлар составына керүе яисә нугай телмәрчеләренең татар-башкорт арасында да популяр булуы белән аңлатыла: Татарстанның көнчыгышында туйда кылкубыз-скрипка уйнап, дастан сөйләүчеләрне хәзер дә нугай дип атыйлар).

М. Гафури күргән кулъязма китаплар беренче язма вариантның әллә ничәнче күчермәләре генә булганнар, әлбәттә. Күп тапкыр күчерүләр нәтиҗәсендә дастанга төп вариантта булмаган китаби, дини, сентименталь һ. б. мотивлар өстәлгән. Бу үзгәрешләр нәтиҗәсендә әсәрнең идея йөкләнеше кимегән дә кимегән. М. Гафури вариантында мәхәббәт темасы да гуманистик эчтәлеген югалта төшкән: Заятүләк, эротик хисләр тәэсирендә генә ата-анасын да, илен дә онытырга әзер. Ул, асылда, хәзерге момент белән яши торган, юаш һәм җиңел акыллы, беркатлы үсмер булып гәүдәләнә (В. Преле вариантында ул, күл төбеннән чыккач, агач уенчык — «үртәкәсе» белән уйнап мавыга). Шулай итеп, олы идеяләр оеткысы булган дастан гадәти хыялый әкияткә әверелгән.

## «Замана шигырьләре»

М. Гафуриның «Замана шигырьләре» дип аталып, 1909 елда Уфада нәшер ителгән һәм шуннан соң бастырылмаган әсәре — элекке мәдрәсәләрдә күп укылган «Собат-эл-гаҗизин[1]» дигән дини-дидактик поэмага пародия.

Поэманың кереш бүлекчәсендә лирик герой үзенең бәләкәй чакларында «Собат-эл-гаҗизин»не ничек укыганнарын сөйли:

**Укыймын тотлыгып, туктап вә чак-чак,**
**Бирә хәлфәм ике чикәгә чат-чат...**
**Уку шулай була торгандыр инде,**
**Диеп уйлап, гомер узгандыр инде.**

Балачак заманнарындагы гадәт-йолаларга өстән торып карау геройда яңа, яңача бер китап чыгарырга теләк тудыра:

**Язарга уйладым бер нәрсә мин дә**
**«Собат-эл-гаҗизин»нең эслүбендә.**
**Вәләкин миндә мәсләк башка төлке —**
**Заманага муафикь, чын вә көлке.**

Шуннан соң ул «Собат-эл-гаҗизин»нән алынган башламнар белән атап, әсәрнең төп өлешенә күчә.

«Хәзрәтләр бәянында» дигән бүлекчә типик, гадәти мулла-мәзиннәрне ачы тәнкыйтьләүдән тора. Бигрәк тә руханиларның хәер-садака тамгысы авторны ачындыра.

**Ике тин бирсәң аларга, шунда**
**Бирерләр сигез оҗмах ачкычын да.**

Алдагы бүлекчәләр реакцион руханилар (алар Ишми исеме астында гомумиләштереп бирелә) белән аралашмаска, алар сүзенә карамаска өнди, көрәштә ныклыкка, килешмәүчәнлеккә чакыра.

Әсәрдә шулай ук бай сәүдәгәрләрнең сәүдә афералары, банкротлык игълан итеп, акча үзләштерүләре һ. б. ш. фаш ителә, бу дөнья — байларга оҗмах, ярлыларга тәмуг дигән фикер үткәрелә. Автор үзе шикелле интеллигент яшьләрне байлар алдына барып түбәнсенмәскә өнди, югарырак катлам яшьләргә — «вафалы» мирза балаларына мөрәҗәгать итеп: «Нәсел, мал белән мактанмагыз», — дигән киңәш бирә.

[1] Гомерен Бохарада үткәргән татар шагыйре Аллаһияр суфи (1624—1713) язган дини-дидактик әсәр.

Поэмада төп ике каһарман — лирик герой һәм аның әңгәмәдәше — кордашы. Болардан тыш эпизодик геройлар да шактый (мирза углы, Ишми, Мәкәрҗәдәге татар байлары һ. б.).

Лирик герой өч ракурста сурәтләнә: 1) балачак хатирәләренә чумган егет, 2) шигъри нотыкны сөйләүче үзе, 3) бер үҗәт надан белән конфликтка кергән, яңача киенгән шәкерт. Шулай итеп ул җитәрлек конкретлык белән гәүдәләндерелә.

Шигъри сөйләмнең адресаты исә тышкы яктан ачык сурәтләнми. Чөнки ул гомумиләштерелгән образ. Ләкин аның да рухи һәм социаль тормышы төгәл реалистик детальләр аша бирелгән. Адресат — актив иҗтимагый тормышка килүче яшь егет, түбән катлам кешесе. Аның рухи байлыгы нигездә патриархаль-дини әхлак идеяләреннән генә тора, (шуңа күрә автор аңа мөрәҗәгать итүнең дини-дидактик формасын сайлаган да). Адресатны, бер яктан, изелгән сыйныф вәкиле булу хәле үзенең кешелек хокуклары өчен көрәшкә этәрсә, икенче яктан аңарда «шартларга яраклашу» теләге дә юк түгел. Һәм менә шул — кинәт яктыга чыгып, кая китәргә белмичә каранып, икеләнеп торган яшь кешегә, лирик герой кайнар үгет белән мөрәҗәгать итә.

Поэманың (әсәрне шулай дип атарга була) сатира өлешендә дә, нәсихәт укыган урыннарында да кискенлек, югары идеялелек мотивлары юк шикелле. Бу хәл кайбер тәнкыйтьчеләргә поэманы зәгыйфь әсәр дип билгеләргә урын калдырган. Әмма шунысын исәпкә алырга кирәк: «йомшак» форманы тормышны аңлый гына башлаган әлеге адресы таләп итә, аны шундук ачык сыйнфый көрәшкә өндәп булмый.

Әсәрнең кызыклы моментларыннан берсе шул: лирик герой үзе атеист (югыйсә ул дини әсәргә пародия язарга керешмәс иде), ләкин автор аллага ышанучыларга үзләренчә фикер йөртергә урын калдыра. Әйтергә мөмкин — ул аларга хөрмәт белән карый, рәнҗетмәскә тырыша. Поэмада «Собат-эл-гаҗизин» китабына карата да кимсетү-мыскыллау юк, тик борынгыча язылган дидактик әсәр эчтәлегенә мөнәсәбәтле йомшак юмор гына бар.

Гомумән, сәнгатьчелеге ягыннан бу поэманы М. Гафуриның уңышлы әсәрләреннән берсе дип карарга мөмкин. Поэманың мәгълүм дәрәҗәдә танып белү әһәмияте бар — ул шул заман кешеләренең (демократик интеллигентның, кара халыктан чыгып, яктыга омтылган яшь кешенең һ. б.) реалистик образларын күрсәтә алган әсәр.

# МӘҖИТ ГАФУРИ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘР

*Чын гуманист булган Гафури үзенең бөтен гомерен кеше бәхете һәм хаклык өчен көрәшкә бирүе белән үзенә мәңгелек дан казанды.*

**Павло Тычина**, украин шагыйре, академик.

*Үз халкын һәм шул ук вакытта бөтендөнья хезмәтчәннәрен эксплуататорлар изүеннән азат итү өчен батырларча, аяусыз көрәшкән, хезмәтчәннәрнең тигез хокуклары, халыклар туганлыгы, бөтен кешелекнең якты киләчәге өчен көрәшкән данлы... Мәҗит Гафури.*

**Вилипс**, латыш шагыйре.

*Мәҗит Гафуриның иҗаты безнең әдәбиятыбызны формалаштыруда аеруча зур роль уйнады һәм аның тарихында ул иң күренекле урын алып тора. Без язучының иҗади мирасына зур хөрмәт белән карыйбыз. Гафури үзенең иҗаты белән бүген дә әле республиканың җәмгыять һәм культура тормышында гына түгел, бәлки, әдәбиятка нәтиҗәле рәвештә йогынты ясап, җанлы әдәби процесста да катнаша. Шуңа күрә без аның турында тере кеше турында сөйләгән кебек сөйлибез.*

**Мостай Кәрим.**

*Алыйк, мәсәлән, иҗат юлын үз белемен күтәрү юлы белән үткән Гафурины. Ул Горький белән шәхси бәйләнештә иде. Горький аны да белә иде һәм аның турында: «Гафурида зур әдәбиятның сулышы сизелә»,— дип әйтә торган иде.*

**Александр Фадеев.**

*Гафурины иска алган саен без аның йөрәк җылысын тоябыз. Аның исеме чыккан саен без ул кабызган ялкынның яктылыгын күрәбез.*

**Кирәй Мәргән,** профессор.

*Гафури халык таланты иде, аны халык иң югары дәрәҗәсенә үстерде дә. Халыкның революцион көрәше аның иҗатына яңа эчтәлек бирде. Шагыйрь коммунистлар партиясе күрсәткән коммунизм идеалы яктылыгында яңа эчтәлек материалының поэтик матурлыгын ачты.*

**Хатип Госман,** профессор.

*Гафури иҗатының әһәмияте шунда ки, ул бер минутка да халык интересларын онытмады, беркайчан да үзенең идеологик позициясеннән читкәммәде, үзен пролетариат революциясе белән кандаш итеп бәйләде...*

**Гали Халит,** филология фәннәре докторы.

*Татар һәм башкорт халыклары арасында киң популярлык алган, тирән мәхәббәт казанган, үз иҗат гомерендә өч революцияне башыннан кичергән, саф күңелле, нечкә хисле бу язучы гаять бай иҗат мирасы калдырды.*

**Мөхәммәт Гайнуллин,** филология фәннәре докторы.

*Революциягә кадәр әсәрләрен уку буенча гына аңа күңелемдә хөрмәт саклаган хәлдә, революция чорында үзен беренче тапкыр күргәч, ихтирамым тагын да көчәйде һәм аны күргән саен арта барды. Чөнки бу чорда инде Мәҗит Гафури чын мәгънәсе белән революцион совет шагыйре дәрәҗәсенә күтәрелгән иде.*

**Шәриф Камал.**

**Фоат Галимуллин**

# ИДЕЛ ҖЫРЧЫСЫ

*Гариф Ахуновның иҗат портреты*

Казан арты — татар әдәбиятына элек-электән күренекле шагыйрьләр, язучылар, галимнәр биргән як. Бөек шагыйребез Г. Тукай җырлаган, «җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында яуган» бу төбәкнең игелекле туфрагы әдәбият-сәнгать әһелләрен мул үстерде. Татар совет әдәбиятының танылган әдипләреннән берсе Гариф Ахунов та шушы якларда, Арча районының кечкенә Өчиле авылында дөньяга килгән. Тау башында утырган бу авылның янынннан гына Казан елгасы ага, елга ярларында таллар үсә, таллыкларда кошлар оя ясый, елга буендагы яшел болыннарда бала-чага чыр-чу килә. Гариф та шулар арасында. Җәен урманда каен җиләге, кура җиләге, кара карлыган өлгерә. Гариф иптәш малайлары белән урманнан кайтып керми.

Югары Пошалымдагы Алма апасының гаҗәеп матур итеп сөйләгән әкиятләре, Зәки һәм һидият исемле укытучы абыйларының тирә — юньдәге, беренче карашка гадәти генә булып тоелган күренешләрдән үзләренчә ямь табарга өйрәтүләре малай күңелендә эзсез калмаган, билгеле. Кечкенә Гарифка, гомумән, остазларның әйбәтләре туры килә. Казанбаш урта мәктәбе укытучысы Хәнифә Абдуллина аның язмышын әдәбият белән бәйләүдә зур роль уйный, беренче хикәяләр язарга рухландыручы да ул була. Берничә буын татар балаларына хәреф танытуда тел ачкычы булган «Әлифба» авторлары Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вәгыйзовлар — Арча педагогия училищесы укытучылары — үсмерләргә телебезнең гаҗәеп матурлыгын төшендерәләр, аларның рухын тәрбияләләр. Гарифның шундый кешеләр янәшәсендә бай күңелле, нечкә хисле, нәфис табигатьле булып үсүе гаҗәп түгел.

Шунысын да әйтергә кирәк: язучы булу турында уена да китереп карамаган Гариф кечкенәдән бик нык күзәтүчән, һәрнәрсәне үзе тәфтишләп аңларга тырышучан була. Бу исә аның тумыштан килгән рәссамлык сәләтеннән килә. Әдәби әсәрләрендәге пейзаж күренешләрен һәм персонажларның портретларын сүз мөмкинлекләре белән чигеп бирү осталыгына ия булуда язучыга рәсем сәнгатенә хирыслыгы, төсләрнең хисапсыз күп вариантларын күрә, бәяли белүе дә ярдәм итә.

Кечкенә Өчиле авылы янынннан инеш кенә булып юл алган Казан елгасы, республикабыз башкаласына килеп җитеп, илебезнең төп су артериясенә кушылып, зур бер дәрьяга әйләнгән шикелле, Гариф Ахунов иҗаты да Казанбаш мәктәбендә кульязма журналда катнашудан башланып, татар әдәбиятында лаеклы урын алырлык булып үсте, күп милләтле совет әдәбиятының олы агымына килеп кушылды. Бу иҗат елданел колачын, киңлеген арттыра бара.

Гариф Ахунов исеме әдәбиятта илленче елларда күренә башлый. Яшь каләм язучылар дөньясына артык күзгә ташланып, шаулап түгел, ничектер җай гына, тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе туплый-туплый, үзеннән алда иҗат иткән өлкән әдипләрнең жит-



*Мәскәү. КПССның XXV съезды барган көннәр. Гариф Ахунов танылган башкорт әдибе Мостай Кәрим һәм Яңа Уфа нефть эшкәртү заводы директоры Т. Курамшин белән.*

дилеген, сабырлыгын сеңдереп, әхлакый һәм рухи җитлегеп килә. Мөлаем йөзле, ачык күңелле, кешеләр белән җиңел аралашып китүчән, эрудицияле егет тиз арада язучылар арасында үз кеше булып әверелә. Өметле язучыны укучылар да яратып өлгерә.

Кешеләр күңелен биләп алырлык әсәрләр иҗат итү өчен, тирән белемле булу, тормышны белү генә дә җитми. «Һәркемгә мәгълүм, ямьсез тавышлы кеше атаклы җырчы булып китә алмый. Язучы булачак кешенең дә дөньяны, кешеләрне үзенчә күрү сәләте, үзенчә сурәтләп бирү сәләте булырга тиеш икән... Язучы булу өчен тумыштан ук килгән табигый сәләт тә кирәк, күрәсең»,[1] — ди Ахунов үзе. Әдип булу өчен «кешеләргә ни дә булса әйтәсе килү» теләге һәм шуны үтемле итеп җиткерү өчен тел сәнгатенең нечкәлеген белү, сүз куәтең булу да кирәк, билгеле.

Г. Ахунов, язучы буларак, бервакытта да «ни әйтергә» дип аптырап йөрүчеләрдән түгел. Октябрь революциясеннән соң туып, совет иле белән бергә үскән буын язучыларының башкаларга ишеттерер сүзләре күп. Ә. Фәйзинең «Тукай» романында шундый бер күренеш бар: күренекле мәгърифәтче һәм галим К. Насыйри кечкенә Габдуллага карандаш сыныгы бирә. Бөек шагыйребезнең әдәби эстафетаны К. Насыйри кебек саф күңелле, игелекле кешеләрдән кабул итеп алып, тагын да югарыга алып китүен күрсәтергә ишарәле бу эпизод. Шуңа охшаш вакыйга Г. Ахунов тормышында да бар. Алты яшьлек сабыйның коммунист әтисен кулаклар үтерә. Бу хәл, үсә төшкәч, булачак язучыга зур тәэсир ясаган булырга тиеш, кабат-кабат аның күз алдына тетрәндергеч күренеш килеп баса: моңлы музыка уйный, мылтыклардан атып, саубуллашу салюты бирәләр, йөзләгән халык коммунист якташын соңгы юлга озата. Арча ягына яңа әсәр язу өчен материал тупларга килгән Кәрим Тинчурин малайны җилкәсенә утырткан. Әйтерсең, ул социалистик илебезнең аны ятим итмәячәген әйтә, коммунист әтисе эшенә турылыклы булып үсәргә куша, бала күңеленә мәхәббәт һәм нәфрәт орлыклары сала. Мин үзем моны картинадагыча аермачык итеп күз алдына китерәм һәм, әлбәттә, берәр рәссамыбыз гәүдәләндерүендә күрергә өметләнәм.

Яшүсмер Гарифка һәм аның яшьтәшләренә бик иртә олыгаерга туры килде. Илебезгә немец илбасарлары хыянәтчел рәвештә һөҗүм иткәндә, аңа унбиш яшь була. Кеше тормышының иң саф, иң якты хыяллар белән канатланып яшәү чоры бу, ләкин

[1] Әдәбият. 6 класс өчен дәреслек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1973, 259 бит.

аларга лирика белән артык мавыгырга туры килмәде, тормышның прозасы бөтереп алды үзләрен. Сугыш авырлыгын төпкә җигелеп тарттылар алар. Гариф, җиң сызганып, туган колхозында эшли, яшь беләкләре, арка-җилкәләре йөкнең авырын күтәрәләр. Колхозда сука сукалый, чәчү чәчә, кырчылык бригадасына җитәкчелек итә, клуб мөдире була.

Яшьтән хезмәт сөеп, эшнең рәтен белеп, нык үзәкле булып үсү аңа соңыннан да ярап куя. «Гарифның, эшем бармый әле, туктадым... кәефем юк, дигән сүзләрен бер чакта да ишеткәнем булмады минем. Гариф белән эш, тырышлык, хезмәт янәшә яшиләр»,[1] — ди аның каләмдәше Аяз Гыйләҗев. Чыннан да, кайда гына эшләмәсен, ул үзен тырыш, эшлекле, оештыру сәләтенә ия итеп күрсәтте. 1952 елны Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, Гариф Ахунов «Совет әдәбияты» журналында башта әдәби хезмәткәр, аннары бүлек мөдире, җаваплы секретарь булып эшли. Менә шунда ул әдәби әсәрнең сюжеты-композициясе, характерлары һәм тел мәсьәләләре белән якыннан таныша. Өлкәннәр аны осталыкка, башкаларның әсәрен бәяли һәм редакцияли белергә өйрәтәләр. Журналда алты ел эшләгәч, әдәби иҗатның никадәр катлаулы икәнен, шул эшкә тотынган кешедән нинди зур көч, тырышлык, сәләт һәм фидакарьлек таләп иткәнен аңлагач, ул булачак геройлары — нефтьчеләр белән якыннан танышу, бер һаваны сулау өчен, 1956 елның көзендә Әлмәткә китеп бара. Билгеле булганча, Әлмәт ул елларны Татарстан нефтьчеләренең башкаласы булып үсте. Мондый киң колач, күрелмәгән масштаблар нефть якларында әдәби талантлар үсеп чыгуга да китерде. Әлеге язучыларны бер оешмага туплау зарурлыгы көн тәртибенә килеп баса. Г. Ахунов шушы эшне оештыручыларның берсе була, Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлегенә җаваплы секретарь итеп сайлана. Казанга кайткач, республика Язучылар союзының җаваплы секретаре һәм «Казан утлары» журналының баш редакторы буларак, актив оештыру эшчәнлеген җәелдерә. Татарстан язучыларының сигезенче һәм тугызынчы съездларында идарә председателе итеп сайлана. Ул тугызынчы һәм унынчы чакырылыш СССР Верховный Советы депутаты, Партиянең XXV съезды делегаты, КПССның Татарстан өлкә комитеты члены, ягъни җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе.

Бүген, прозаик буларак, аны илебезнең күп урыннарында беләләр. Мондый биеклекләр үзеннән-үзе генә килмәде, алар — армый-талмый хезмәт итү нәтиҗәсе.

Г. Ахуновның укучыларга барып ирешкән беренче әсәре — «Галләм сорау бирә» хикәясе илленче еллар авыл тормышыннан алып язылган, колхозларны эреләндерү, аларга җитәкчелекне фәнни нигезләргә кую кебек проблемаларны күтәрә. Ләкин әле яшь автор ул чагында үзе күтәргән проблемаларны хәл итүнең дөрес юлларын белгели алмый. Яшьләр инициативасын кысып ятучы председатель Бикбулатов кебекләрнең бер хикәя дәвамында төзәлеп китүе ышандырып бетерми. Шулай да авторның үз чорындагы актуаль проблемаларны тотып ала белүен, аларны кыю рәвештә күтәрергә омтылуын уңай башлангыч итеп бәяләргә кирәк.

Язучының гражданлык өлгергәнлеге, әдәби осталыгы тормыш китереп чыгарган әнә шул актуаль проблемаларны күтәрә белүендә һәм аларны сәнгать чаралары белән ача белүендә күренә дә инде. Бу яктан алганда, 1955 елда язылган «Яшьлек яме» повесте язучының үсә, каләме остара баруын күрсәткән әсәр булды. «Яшьлек яме» повесте белән Гариф үзенең йөрәк серен ачты: яңа язучы пәйда булды»[2].

Студентлык еллары — кеше тормышының иң гүзәл вакыты. Яшьлек хыялларга бай, ул киләчәккә омтылып яши. Нәкъ менә шушы чорда кешенең дөньяга, әхлакый мәсьәләләргә карашы формалаша.

«Яшьлек яме»нең төп геройлары Таһир белән Айрат арасындагы конфликт бу процессның катлаулылыгын раслый. Бер якта — эгоистлык һәм карьера чире кагылган Айрат, Гыйльми, икенче якта — студентлар коллективы. Алар үзара бәрелешәләр. Комсомол оешмасына җитәкчелектәге төрле стиль — әсәрнең конфликтын китереп чыгарган төп сәбәп шушы. Айрат, үзенең шәхесен өстен куеп, башкалар фикере бе-

---

[1] Гыйләҗев А. Безнең замандаш.—Кит.: Г. Ахунов. Хәзинә. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1974, 10 бит.
[2] Гыйләҗев А. Күпне көтәбез. — «Казан утлары», 1975, 9 сан, 63 бит.

лан исәпләшмичә, үз карашын гына үткәрсә, Таһир, иптәшләре белән киңәшеп, эшне коллектив рухта алып бару ягында. Бу сөйкемле егетнең кайбер эш-гамәлләрендә, биографик детальләрендә без авторның үз тормышын төсмерли башлыйбыз. Язучы яшьләрнең характеры формалашу процессын да шактый эзлекле күрсәтә, бу исә әсәрнең ышандыру көчен арттыра.

Әсәрдә вуз укытучысының әхлагы, аның бу эшкә мораль хокукы мәсьәләсе дә кискен итеп күтәрелә. Биредә контрастлыкка Мохтаров белән Сарымсаковлар характерындагы капма-каршылыкны ачып салу юлы белән ирешелә. Мохтаров фәнгә тормыш эченнән килгән. Гаять намуслы, принципиаль. Ул факультетның партия оешмасына җитәкчелек итә, эшнең җанлануына ирешә, фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәлелеге өчен көрәшә. Сарымсаков кебек, фәннең үзен түгел, бәлки фәндә үзләрен яратучыларга карата аяусыз ул. Иң әһәмиятлесе — аңарда кешеләрне тану сәләте көчле. Айрат белән Таһирга дөрес бәя бирүче, кемнең кем икәнен төшенүче дә Мохтаров. Гадел профессор яшь буынны үзенең һәр адымы, эше, сүзе, яшәү рәвеше белән тәрбияли.

Сарымсаков исә вузда укыту кебек изге эшне материаль тәэмин ителү чыганагы итеп кенә исәпли, үз эше белән мавыкмый, чөнки ул аны яратмый. Студентларга да өстән торып кына карый. Әхлак ягыннан да шактый түбән тәгәрәгән бу кеше фәндә урау юллар белән карьерага омтыла, ләкин фаш ителә. Нәтиҗәдә Сарымсаков университеттан куыла. Намусы чиста булмаган кешегә партия яшьләрне укыту эшен ышанып тапшыра алмый.



*1969 ел. Гариф Ахунов һәм Италия язучысы Джанни Родари Ленино-Кокушкинода.*

Шул рәвешле, «Яшьлек яме» повесте үткән проблемалар күтәрә, алар бүгенге көндә дә үзләренең әһәмиятләрен җуймаганнар. Яшь каләм иясе мавыктыргыч сюжет төзүгә һәм үзенчәлекле характерлар тудыруга ирешкән. Әсәр әдәбиятка килүче

Г. Ахуновның беренче уңышы иде. 1955 елның маенда яшь һәм башлап язучылар киңәшендә З. Нури, әлеге әсәрне күздә тотып, башка өметле яшьләр белән беррәттән, Г. Ахуновны да әдәбиятка «ишек шакучы гына түгел, ә әдәби бүлмәгә үтеп кереп, һәм шунда үзләренең эш өстәлләрен куеп, чынлап торып эшли башлаган» язучы дип атый [1].

Г. Ахуновның иҗаты белән ныклап танышкач, бер нәрсә аеруча күзгә ташлана: аның әдәби-иҗат эше һәрвакыт күпьяклы булуы белән аерылып тора. Беренче хикәяләрен, повестен язу белән бергә, әдәбият тарихын, теориясен ныклап өйрәнә. З. Бигиев романнарыннан алып бүгенгә көнгә кадәр иҗат ителгән барлык әсәрләрне яңадан укып чыга, фәнни чыганакларны барлый. Рус һәм чит ил классикасының күренекле үрнәкләрен күздән кичерә. Менә шундый ныклы хәзерлек, әдәбиятны тирән белеп эш итү аңа тәнкыйть өлкәсендә дә үз сүзен әйтү мөмкинлеген бирә. Әле шул елларда ук шагыйрь С. Хәким аны алга таба үсеп китү мөмкинлеге булган тәнкыйтьчеләр рәтендә исәпли һәм аңа олы ышаныч белдерә [2].

Язучы-прозаик булып китүенә карамастан, Г. Ахунов әдәби тәнкыйтьне бервакытта да үги итмәде. Әдәбият үсешенең күп төрле өлкәләренә караган йөзләгән мәкаләнең республикабыз һәм илебез газета-журналларында басылганын искә алсак, бары тик тәнкыйть белән генә шөгыльләнүче кайберәүләр көнләшерлек иҗат активлыгын билгеләргә туры килә. «Әдәби язмышлар», «Без бит Арча яклары» кебек җыентыкларындагы мәкаләләре, күренекле әдипләрнең иҗат портретлары авторның бу өлкәдә дә эрудицияле булуы, мәсьәләләрне тирәннән төшенеп эш итү турында сөйли. Аны прозага тәнкыйть аша килде дисәк, хаклы булырбыз. Гадәттә, күп кенә каләм әһелләре шагыйрьлек стадиясен узалар. Рәсми төстә Г. Ахуновка карата моны әйтеп булмый, чөнки аның шигырьләр бастырганы юк. Әмма шагыйрьлек аның аерылмас юлдашы. Күңелен кузгаткан күп кенә күренешләр, хис-тойгылар башта шигырь булып бөреләнә, соңыннан проза әсәрләренә күчә. Теленең образлылыгы, эмоциональ төсмерләргә бай булуы, гомумән, сүз кадерен белүе шуннан киләдер.

Һәр язучының аеруча үз иткән сурәтләү объекты була. Ләкин Г. Ахунов иҗаты үзенең күп планлылыгы, тематик байлыгы белән характерлы. Без биредә нефтьчеләр, авыл кешеләре, тарихи шәхесләр, интеллигенция вәкилләре белән очрашабыз. Шулай да ул, язучы буларак, иң элек нефтьчеләр темасыннан уңышлы әсәрләр биреп танылды. Авылда туып-үскән Г. Ахунов ни өчен эшчеләр темасы язучысы булып китте соң? Бу сорауга җавап табып була: аны заман таләбе шушы өлкәгә алып килде. Татарстанда бара торган гаять зур үзгәрешләргә битараф булып кала алмады ул. Эшчеләр турында язу өчен безнең әдипләребезнең тәҗрибәсе аз иде, һәртөрле кыенлыкларны җиңәргә сәләтле, әдәбиятта новатор булып күтәрелеп чыгарлык кыю егетләр кирәк иде. Г. Ахунов әнә шундый яңа эшкә алынды, нефтьчегә йөз белән борылды. Баштарак алар тормышына багышланган очерклар, мәкаләләр язылды. «Җир куенында» исемле пьеса язып, уңышсызлыкка очрады. Болар барысы да әдипнең чынбарлыкны өйрәнү процессы, зур әсәр язу өчен хәзерлек чоры иде. Ниһаять, 1963 елда «Хәзинә» дөнья күрде. Роман укучылар тарафыннан җылы каршыланды. Г. Тукай исемендәге Татарстан АССР Дәүләт премиясе язучыга «Чикләвек төше» повесте белән бергә «Хәзинә» өчен дә бирелде. Роман Свердловск киностудиясенең шул исемдәге нәфис фильмы нигезенә ятты. Сценарий авторы В. Потоцкий һәм режиссер О. Воронцов тамашачыларның игътибарын җәлеп итәрдәй фильм эшләделәр.

Тормыш чынбарлыгына тугрылык, игътибарны җитди проблемаларга юнәлтү, йөгерек һәм халыкчан матур теле дә әсәрнең яратып укылуына, уңыш казануына сәбәп булды. Әсәрнең киң танылуы андагы тип-характерларның, кеше язмышларының алгы планга чыгарылуы белән дә бәйләнештә, әлбәттә. Кешеләрнең уй-кичерешләрен, омтылыш-хыялларын производство шау-шуы күмеп китми, тимер салкынлыгы басмый. Монда үзләренең шатлык-кайгылары, уңыш-кимчелекләре һәм хәтта абынып егылулары булган җанлы кешеләр яши. Шул ук вакытта персонажлар хезмәт процессы белән тыгыз бәйләнгәннәр, образ-характерлар производство даирәсендә ачылалар. Г. Ахуновның бу мәсьәләдә карашы ныклы: «Әгәр автор кешене һәм аның эшен бер-

---

[1] «Совет әдәбияты», 1955, 6 сан, 127 бит.
[2] Хәким С. Поэзиябез турында уйланулар. — «Совет әдәбияты», 1955, 4 сан, 119 бит.

дәм итеп күрсәтә алса гына, эштә хезмәт кешесенең характеры ачылса, бүтәннәргә мөнәсәбәте, язмышы билгеләнсә генә, роман, повесть яки пьеса ота, укучының һәм тамашачының күңелен яулап ала [1].»

Үз эшенең бөтен серләрен белүче төпле акыллы Лотфулла Дияров, хезмәткә һәм иптәшләренә туры караучы Арслан Гобәйдуллин, чамадан тыш эшчән, әмма дан артыннан куып һәлак булган Кәрим Тимбиков, бер үк вакытта дуамал да, нечкә күңелле дә Фәйрүзә һәм башка образлар татар әдәбиятында кабатланмас яңа характерлар булып торалар.

Әсәр беренче карашка сәер, көтелмәгәнчә башлана. Төп геройлары нефтьчеләр булган роман безнең төбәкләрдә разведчикларның кара алтын эзләп табулары, беренче нефть фонтаны бәрүе, кешеләрнең бу якларга килүләре яки нефтьчеләр каласын төзергә керешүләре белән башланып китми (сүз уңаенда әйтергә кирәк, автор бу мәсьәләләрне бераз соңрак «Кеше хәзинә эзли» повестенда яктыртты), бәлки, бер уйлаганда, алга таба сюжет үстерүдә һич тә катнашы булмаган Йөзлекәй карчыкның үлемен тасвирлау белән башланып китә. Нәкъ менә Йөзлекәй карчыкка әсәрнең төп идеясен ачуда әһәмиятле урын бирелгән. Өлкән буыннардагы яхшы сыйфатлар яшьләрдә тагын да үстерелеп, безнең көннәрдә дә яши бирә. Арслан, Фәйрүзәләрдәге ныклык, сабырлык, физик сәламәтлек шул йөз яшәр Йөзлекәйләргә барып тоташмыймыни?

Хәзинәнең чын асылын ачуда да Йөзлекәй карчыкка әһәмиятле роль бирелә. Ул гади крестьян кызы, намуслы хезмәт белән көн күргән. Саулык-сәламәтлекне иң олы байлык, ягъни хәзинә дип инанган. Бервакыт аның кулына алтын-көмеш мәгънәсендәге хәзинә килеп керә. Ләкин ул мирза кызы Мәгыйшәнең кайчандыр әтисе кеше талап җыйган хәрам малына кызыкмый, аны төргәге-ние белән янып торган мичкә ата.

Әсәрнең әлеге вакыйга сурәтләнгән урыннары хәзинә турында сүз алып бару өчен экспозиция ролен үтиләр. Романның Йөзлекәй карчыкның гомер юлын искә төшерү белән башлануы да, шул рәвешле, оригинальлек өчен генә түгел, ул аның тукымасына бик нык керешкән, чөнки автор хәзинәнең төп предметын ачыкларга тели. Әсәр, тулаем алганда, шуңа җавап булып тора. Хәзинә турында романда Лотфулла абзыйның да, Арсланның да, Шәвәли картның да үз фәлсәфәләре бар. Шул уйланулар гына да аларның нинди характер иясе булуларын билгеләргә ярдәм итә. Бу өч кешенең хәзинә турындагы фикер агышы бер нәтиҗәгә китерә: иң төп хәзинә — кеше. Кеше дигән хәзинә исән булса, җир асты хәзинәсе чыгачак.

Дилогиянең икенче кисәге булган «Хуҗалар» романы бераз башкачарак язмышка очрады. Ул бәхәс кузгатты. Аңа карата күп кенә тәнкыйть сүзләре әйтелде. Татарстан язучыларының сигезенче съездындагы чыгышыннан күренгәнчә, Г. Ахунов әсәрнең өлгереп җитмәгән булуын үзе дә таный һәм аны камилләштерү эшенә керешкән. Болар язучының, «иҗат кешесе буларак, үз эшенә җитди каравын, тәнкыйть сүзенә колак сала белүен, туктаусыз эзләнүен, тынгысызлыгын раслыйлар» [2]. Ләкин бу әле Г. Ахунов әсәр уңае белән әйтелгән тәнкыйть фикерләренең барысын да төкми-чәчми кабул иткән дигән сүз түгел. Ул аларның үзе дөрес дип тапканнарын, иҗат принцибына туры килгәннәрен генә ала. Мәсәлән, баш герой Арслан нигездә беренче вариантагыча калган. Автор образның характерын билгели торган төп сыйфатларны үзгәртүне кирәк дип тапмаган. Киресенчә, автор Арсланны тагын да күтәрә төшкән. Моңа образның бөтенлегенә зыян китерә, аны кечерәйтә яки ваклый торган аерым эпизодларны кыскарту исәбенә ирешелгән.

Язучы психологик тирәнлекне көчәйтүгә дә игътибар иткән. Сюжет үсешендә артыклыгы күренеп торган урыннар төшереп калдырылган. Элекке басмада буровой эшчесе Буяновның кулак әтисе һәм алтын белән бәйләнгән маҗаралары киң итеп бирелгән иде. Яңасында бу урыннар бөтенләй юк. Без элек Булат Дияровны да, ничектер, каршылыклы, үз кыйбласын табып җиткермәгән кеше итеп күргән идек. Культура үзәкләреннән читтә, буровойда гомер уздыруны мәгънәсезлек дип санауга җиткән Булатның тагын да ерагракка — Себер нефтен үзләштерергә китүе характерның логикасын боза иде. Инде хәзер Булатның әлеге фикер каршылыклары җәелдерелми. Алардан котылып, автор әсәрне кирәкмәгән йөктән арындырган.

[1] Ахунов Г. Дәверләр документы.— «Казан утлары», 1977, 9 сан, 108 бит.
[2] Гыйләҗев А. Безнең замандаш. — Кит.: Г. Ахунов. Хәзинә. 1974, 7 бит.

Әдәби әсәр — гаять катлаулы процесс. Г. Ахунов «Хәзинә»не тәмамланган әсәргә санамый. Икенче китабын, гәрчә аны Мәскәү нәшриятлары кабул итсә дә, бастырырга ашыкмый. Дилогия булып уйланылган бу романның трилогия булып үсеп китү ихтималы да бар. «Азат хатын» журналының 1979 елгы 9 санында басылган «Әлмәт — гомер бишегем» мәкаләсендә ул хакта ачык әйтелә.

Моннан тыш Г. Ахунов нефтьчеләр турында «Хыялый Хәйрүш егетләре», «Артышлы тау буенда» повестьларын, «Утлар яна учакта» пьесасын, хикәяләр һәм күп санлы очерклар иҗат итте. Нефтьчеләр турында балалар өчен проза әсәрләре язуны да ул башлап җибәрде. Тууына илле ел тулу көнендә Г. Ахуновны Әлмәт нефтьчеләренең үз коллективларына «Почетлы нефтьче» итеп алулары бу профессия кешеләренең аны никадәр үз итүләрен әйтеп тора.

Г. Ахуновның әсәрләре арасында темасы һәм оригинальлеге белән аерылып торган бер хикәясе бар. Ул «Соңарып килгән бәхет» дип атала. Хикәянең үзәгенә нефтьче түгел, сәнгать кешесе—балетмейстер Рәхим Собханкулов куелган. Ул инде иллегә якынлашып килә, биюче өчен шактый олы яшь бу. Собханкулов «сәхнә алкышларына, чәчәкләргә кул селтәп» педагоглык эшенә күчкән. Шунысы күңелен тырный, гомере буе сәнгатьтә үз сүзен әйтә алмаган, чын-чыннан иҗат шатлыгы кичермәгән. Аны Әлмәткә нефтьчеләрнең үзешчән коллективына бию куярга җибәрәләр. Теләмичә генә бара балетмейстер, юньле әйбер чыкмаячагына алдан ук күңелен ышандырып куя. Әмма нефтьчеләрне хезмәт урынында күрү, аларның эше сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгәнлеген аңлау аны рухландырып җибәрә, «кинәт балетмейстер үзе куячак биюнең ритмын тойгандай була». Шушы күренештән кабынып китеп, гомерендә беренче тапкыр илһамланып иҗат итә, үз эшеннән канәгать кала, тамашачыларның югары бәясенә лаек була. Собханкулов бәхетле минутлар кичерә. Г. Кашшаф әйткәнчә, «нефть батырлары аңа хезмәт шигърияттен аңларга булыша»[1]. Собханкулов үткән гомерен кызганып куя: «сәнгатьтә дөрес юлны яшьрәк чакта тапкан булса,ниләр генә эшләмәс иде әле ул?»

Әйе, иҗат сукмагыңны иртәрәк табу үзеңә дә, җәмгыятькә дә гаять әһәмиятле. Г. Ахунов исә әдәбиятта дөрес юлны табуда соңармады, геройларына вакытында юлыкты, алар хезмәтендәге шигърияттән илһамлана белде, әдәбиятта үз сүзен кичекмичә әйтү бәхетенә иреште.

Г. Ахунов иҗаты күп тармаклы булуы белән аерылып тора, дидек. 1974 елда ул укучыларга «Ардуан батыр» повестен тәкъдим итте. Бу әсәрендә автор беренче бишьеллык батырларының фидакарь хезмәтен, социализм нигезен салу өчен көрәштә ныклыкларын күрсәтүне максат итте. Шуларның берсенә — Мирсәет Ардуановка әдәби һәйкәл куйды.

Язучының нияте олы һәм изге. Бүген илебездә КамАЗ, БАМ кебек гигантлар төзелә, яшь буын вәкилләре төзелештә могҗизалар күрсәтә. Мондый максатка омтылучанлык һәм ныклыкның чыганагы Ардуановлардан килә дип әйтергә тели автор һәм шушы бөек юлның чишмә башын укучылар күз алдында җанландыруны иҗат максаты итеп куя. Бу повесть та укучылар күңеленә юл тапты. Өлкән әдибебез М. Әмир болай ди: «Беренче бишьеллык чорында Березники химкомбинатын төзүдә катнашкан эшче-бетончы ударник, татар-башкортлардан бригада оештырып, халкыбызның данын арттырган Мирсәет Ардуанов турында документаль повесть. Әйбәт. Кирәкле генә түгел, әдәби осталык белән язылган, рәхәтләнеп укыла, үз халкың өчен горурлык хисләре уята торган әсәр. Мирсәет, Нәфүш-Сайрар кош, Зөлхәбирә шәхесләре хәтердә калырлык әдәби образ итеп эшләнгәннәр. Молодец, Гариф! Тырыш та, яза да белә.

Мирсәетнең, Ленин ордены алып кайткач, бу турыда хатынына әйтергә унайсызланып йөрүе, аннан соң иптәше Николай килеп, бу турыда белгәч, Мәүгыйзәнең бу зур куанычны ничек кабул итүе аеруча оста бирелгән — татарча да, кешечә дә. Художник эше!

Әйбәт, әйбәт!»[2].

Әсәрнең исеме үк аның героеның гадәти генә шәхес булмавына ишарәли. Сүз

---

[1] Кашшаф Г. Ил белән, халык белән.— «Социалистик Татарстан», 1975, 18 сентябрь.
[2] Әмир М. «Укылган әсәрләр» дәфтәреннән. — «Социалистик Татарстан», 1975, 30 март.

какшамас рухлы, пәһлевандай гәүдәле, баһадирдай көчле, шул ук вакытта кешелекле һәм нечкә күңелле эшче кеше турында бара.

Ардуан язмышы — миллионнар язмышы. 1921 нче ачлык елны, күп кенә авылдашлары кебек үк, Мирсәет Ардуанов та эш эзләп чыгып китә. Көч-куәтле һәм гадел табигатьле бу кеше йөкчеләр артеле оештыра. Кайда гына эшләмиләр алар, ниһаять, Пермь шәһәрендә мондый күчмә тормышка чик куела, артель Березники химия комбинаты төзелешенә чакырыла. Шушы көннән башлап ардуанлылар тормышында кискен борылыш башлана: алар утрак тормышка күчәләр, төзүчеләр оешмасы системасына кергән бригадага әвереләләр. Дөрес, моңа кадәр дә аларның коллективлары була, ләкин ул бары тик Мирсәетнең көченә, шәхси авторитетына гына нигезләнә, бу күмәклектә идея мотивы булмый. Ә хәзер алар үзләренең хезмәте яшәү чыганагы гына түгел, бәлки социализм төзелешенә лаеклы өлеш кертү икәнен дә аңлый башлыйлар. Җыйнап кына әйткәндә, алар гадәти сезонниклардан кадровый эшчегә әйләнәләр.

Укучылар алдыннан хезмәт мөнәсәбәтләренең социалистик үзгәрүе нәтиҗәсендә яңа тормышны актив төзүчеләр булып әверелгән байтак кеше уза. Алар: Бәхтияр Гайнуллин, Исәнгул Юлдыбаев, Нәбиулла Фәхриев, Шәмсетдин Сәләхиев һәм, әлбәттә, Мирсәет Ардуанов үзе.

Әсәрнең үзәгендә Ардуановның калку фигурасы тора. «Татарстан АССР тарихы»ннан түбәндәгеләрне укыйбыз: «Татарстаннан килгән Мирсәет Ардуанов бригадасы Березники химия комбинаты төзелешендә дан казанды. 1929 елда ул иң яхшы удар бригадалар сафында Уралның мактау тактасына кертелде».[1] Өстәп шуны әйтергә кирәк: М. Ардуанов илебезнең иң югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнә, гади татар эшчесе СССР Үзәк Башкарма Комитеты члены итеп сайлана, 1936 елда Советларның сигезенче съездында социализмның җиңүен закон тәртибендә беркеткән Яңа Конституциясен яклап кул күтәрә. Үзе үлгәннән соң аңа Березники шәһәрендә һәйкәл куела. Моннан берничә ел элек Пермь өлкәсендә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән алдынгы төзүчеләр бригадаларына ел саен Мирсәет Ардуанов исемендәге премия биреп бару гамәлгә кертелде. Илебез халыкларының какшамас дуслыгы әнә шул фактларда да чагыла.

Г. Ахунов ышандыргыч көч белән бригаданың социалистик идеаллар өчен көрәшүче коллектив булып әверелүен, һәр характерның үсешен логик эзлеклелектә күрсәтә алган. Халкыбызның шундый күренекле вәкиле эзләреннән йөреп, аның турында әйбәт повесть иҗат итүе, һичшиксез, тынгысыз язучыбызның тагы бер җитди казанышы дип саналырга тиеш.

Чыннан да, «Ардуан батыр» повесте «авторның тарихи темага уңышлы бер разведкасы иде»[2]. Озак та үтмәде, Г. Ахунов укучыга халкыбызның үткәнен егерменче гасыр башыннан алып сурәтләүне максат итеп алган «Идел кызы» трилогиясенең беренче китабын тәкъдим итте. Шул рәвешле, язучы данлы тарихыбызның зур катларын актарырга тотынды.

Алдынгы революцион идеяләрнең, аерым шәхесләр күңелендә бөреләнеп, киң социаль җирлектә үзгәрешләр ясарга сәләтле булып үсүен күрсәтүне бөек пролетар язучысы М. Горький башлап җибәрде. Рус совет әдәбиятында М. Шолохов, Г. Марков, А. Иванов кебек язучылар, бездә Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Нәҗмиләр бу эшне уңышлы дәвам иттерделәр. Г. Ахуновның бу әсәре күренекле рус һәм татар язучылары традициясен үстерүнең матур мисалы булып тора.

Әлегә без өч китаптан торырга тиешле зур әсәрнең беренче китабы белән генә таныштык. Шулай да тормыш материалының гаять киң булуын, әсәр геройларының катлаулы, кызыклы язмыш кешеләре икәнен күрергә өлгердек инде. Роман яратып укыла, аның турында бәхәсләшәләр, укучылар аңа карата битараф булып калмадылар. «Һич икеләнүсез әйтергә була: «Идел кызы»—язучының җитди казанышы»[3]. Тормыш чынлыгына турылыклы булуын Ф. Хөсни «авторның батырлыгы»[4] дип атый.

Унтугызынчы гасырның соңгы еллары. Россиянең иҗтимагый тормышында якынлашып килүче революциянең көч-куәт җыйган, әкренләп тернәкләнеп килгән чор.

---

[1] Татарстан АССР тарихы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1970, 444 бит.
[2] Расих А. Прозабыз турында. — «Казан утлары», 1979, 11 сан, 147 бит.
[3] Шунда ук.
[4] Хөсни Ф. Орлыклар кая төшә... — «Казан утлары», 1979, 8 сан, 163 бит.

Шундый көннәрнең берсендә, буранлы таңда романның төп героинясы Нурия дөньяга килә. Бу — Нуриянең тормышы давыллы елларга туры килүенә гомуми ишарә. Һәм әсәрдә ул аклана да. Мулла кызы булып, шау атлас-ефәкләргә төренеп, энҗе калфаклар кадап, беләзек-муенсалар тагып, зиннәтле өйләрдә тук тормышта рәхәт кенә гомер кичерергә дип дөньяга туган Нуриягә дә революция башка язмыш хәзерли. Заман шаукымы, революция дулкыны Кама буенда тын гына яткан Зартугай буйларына да килеп җитә. Яңалык җилләренә сизгер булган Габбас мулла кызын мәхдүмә итеп кенә калдырырга теләми, русча укыта, Алабугадагы земское училищега илтеп бирә. Нурия, совет власте елларында хатын-кызларга бирелгән хокуклардан файдаланып, югары белем алуга ирешә, медицина институтын тәмамлап, врач була, аспирантурада калдырыла. Кыз алдында фән эшлеклесе, галим булу юллары ачыла.

Татар әдәбиятында хатын-кызларның язмышын гәүдәләндергән әсәрләр шактый күп иҗат ителде. Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Бәширов, М. Әмир, Г. Әпсәләмов әсәрләре моның ачык мисалы. Г. Ахунов, шушы традицияне дәвам иттереп, татар хатын-кыз образларының тагын берсен — Нурия язмышын катлаулы хәлләргә куеп күрсәтүне максат иткән.

Кайберәүләр революция һәм шәхес мәсьәләсе уртага куеп сурәтләнгән әсәрнең үзәгенә ни өчен башка берәү түгел, нәкъ менә мулла кызы алынган икән, дип кызыксыну белдерәләр. Ләкин хикмәт кемнең алынуында түгел, ә тормыш материалының нинди, кем позициясеннән торып сурәтләнүендә, проблемаларны кем файдасына хәл итүендә. Нуриянең социаль чыгышы аның тормыш белән конфликтын тагын да үткенләндереп җибәрә, укучының героиня язмышы белән кызыксынуын тагын да көчәйтә төшә. Мәсәлән, рабфакта укыганда аңа үз әти-әнисенә мөнәсәбәтен ачыклау мәсьәләсен хәл итәргә туры килә. Такташ әйтмешли, «матур кызның йөзенә карaудан элек анкетасы каралган» бу чорда Нуриягә дә үз сүзен әйтергә кирәк була. Ул әти-әнисеннән ваз кичә. Әтисенең фаҗигасендә Нурия хәлиткеч рольне уйный. Кызның бу адымы кешелеклелек ягыннан рәхимсезлек булса да, шул заман шартларыннан чыгып, аны да аңларга мөмкин.

Нурия, әсәрнең төп героинясы буларак, романда шактый тулы сурәтләнгән. Шулай да Нуриянең әсәрдәге кылган гамәлләре, язмышы аны романның умырткасы итә алмыйлар әле. Ул, башка образлар янында тонык ук калмаса да, аларны узып китә алмый. Дөрес, бу фикерне әйткәндә, зур әсәрнең бер өлеше турында гына сүз барганлыгын хәтеребездән чыгармыйбыз. Алдагы китапларда Нурия үзенә бирелгән рольне аклар дигән ышаныч бар.

Бәлки, язучының максаты гомумән Идел буе, аерым алганда, татар хатын-кызларының төрле язмышлардан торган җыелма образларын социаль революциягә мөнәсәбәттә бирүдер? «Идел кызы»нда сурәтләнгән шундый хатын-кыз образларының берсе — ярлы Рамазан кызы Хәнифәнең хәле әсәрне укыган кемне генә дулкынландырмады икән? Сөюнең, назлауның нәрсә икәнен аңларга өлгермәгән шушы яшь кызны, байлыгы белән кызыктырып, Габбас мулла үзенә икенче хатынлыкка ала. Әмма мулланың беренче хатыны морза кызы Шәмсениса барында Хәнифәнең исеме генә мулла хатыны булып үзгәрә, асылы шул ук кала — ялчы. Ләкин дөнья аларны да тигезли. Барлык мал-мөлкәтләре, йортлары янып беткәч, Хәнифә үзенең өстенлеген дә сизә.

Хатын-кызлардан Шәмсениса абыстай образы — татар әдәбияты өчен яңалык. Ювелир осталыгы белән сурәтләнгән үтә нечкә характер иясе ул. Байлык тулы йортта ул үзен бәхетсез итеп сизә. Гомумән, бер ирдән, ике хатыннан торган бу семья членнары һәрберсе үзенчә бәхетсез.

Габбас мулла әсәрнең без сүз алып бара торган беренче китабында яши һәм тормышын да чикли. Шуңа күрә аның турында тулырак фикер йөртергә мөмкинлек бар. Гомумән, беренче кисәктә төп фигура булып калкып чыга ул. Зартугай якларында бара торган күп кенә вакыйгаларга аның аек акыллы мөнәсәбәте белдерелә. Габбас мулла үзендә күп кенә каршылыклар туплаган кеше. Бу образ Г. Ахуновның характер тудырудагы осталыгын күрсәтә. Мулла хатынына йортка кереп, социаль асылыннан киткән, ләкин үзләрен өстен, затлы дип атаучы сыйныфта үз кеше үк булып җитә алма-

ган Габбас гомер буе эчке газаплар белән яши. Крестьян хезмәтенә күнегеп үскән куллар эш сорый, файдасыз тук тормыш аны газаплый. Дөрес, ул, муллалыгын ташлап, крестьянча да яшәп карый. Әмма яңа тормыш шулай ук аңа ишегең ачып куймый. «Затлы нәселле» Шәмсенисасы ташлап китә, Нуриясе кабул итми, социаль хәле аңа яңалыкны кабул итәргә комачаулый. Болар бөтенесе Габбасны җәмгыятьнең артык кешесе итә. Ә артык кешенең тәкъдире — кадерсезләнеп юкка чыгу. Габбас үз-үзен юк итү юлын сайлый. Трилогиянең беренче кисәген, хаклы рәвештә, Габбасның трагедиясе дип атарга мөмкин.

Язучы Габбас мулланың фаҗигасенә сизгерлек күрсәтә, әйтергә яраса, аны яратып сурәтли. Габбас, мулла булып исәпләнсә дә, хезмәт халкына җәбер салмый. Шуңа күрә революциядән качып китүче Сөләйман хәзрәтләргә иярми, үз авылында яшәүне артык күрә. Шул ук вакытта большевикларга да симпатия белдерми, урталыкта калырга тели. Мәгълүм булганча, иҗтимагый үсеш урталыкны өнәми. Сәяси идеаллары ачык булмавы, сыйнфый позициясен ахырынача ачыклап бетерә алмавы Габбасны яңа тормышның артык кешесе итә. Дөрес, вакыты-вакыты белән аңарда чорга аек бәя бирү кебек ялтырап киткән фикерләр дә туа. Мәсәлән, Таминдар бай малае Һашим белән туганлашудан баш тарта, чөнки тегеләрнең киләчәге юклыгын яхшы төшенә. Әмма Габбас муллада яңалыкны аңлау эзлекле түгел, бигрәк тә бу юнәлештә практик адымнар ясаудан ул ерак тора. Ниһаять, үзенә караган идея-эстетик вазифаны җиренә җиткереп үтәгәч, әсәрдән төшеп кала.

Габбас мулла кискен сыйнфый көрәш көннәрендә урталыкта калган булса, хәлиткеч бәрелешләрнең полюсларында торучылар да автор тарафыннан шактый җентекле сурәтләнгәннәр. Халык бәхете өчен көрәшче, ленинчы-большевик Мулланур Вахитов, эпизодик образ итеп кенә бирелүенә карамастан, ныклы революцион карашлы, талантлы оештыручы, үткен акыллы пропагандист һәм оста конспиратор булып күзаллана. Шәяхмәтләрдәге идея инанганлыгы, үзләре тоткан юлның иң дөрес булуын төшенү, ныклык М. Вахитовлардан килә. Әсәргә М. Вахитов образын кертеп, автор шундый фикер үткәрә.

Шәяхмәт Айдаров большевик остазларының эшен лаеклы дәвам иттерүче. Ул ярым крестьян һәм ярым пролетариаттан аңлы көрәшче булуга кадәр үсеш юлы үтә, Солтан кебек яшьләрне алдынгы идеяләр белән коралландыручы, юл күрсәтүче һәм тәрбиячегә әверелә. Солтанның, абыйсы эзеннән китеп, Азин дивизиясе сугышчысы булуы очраклы түгел. Ул кечкенәдән сыйнфый тигезсезлекне сизеп, шуңа йөрәге әрнеп үсә. Хезмәт ияләрен изүчеләр аның сыйнфый дошманнарына әйләнә. Менә ни өчен Солтан һич икеләнүсез түбән катлауларның бәхете өчен актив көрәш юлына баса. Солтанны укучы ярата, үз итә. Аның гади бер авыл малаеннан җитәкче кеше булып үсеп җитлегүе ышандыра.

Яшь буында совет патриотизмы, югары гражданлык тойгылары тәрбияләүдә әсәрнең әһәмияте зур.

Революция дошманнары да үз сыйныфларының типик вәкиле итеп сурәтләнгәннәр. Таминдар Тураев, Сөләйман хәзрәт, штабс-капитан Динислам Бохараевлар никадәр тырышмасыннар, халык ташкынына каршы бара алмыйлар, аларга үз ирекләре белән Себергә табан ялтыратудан башка юл калмый.

Язучы әсәрдә тормыш материалын шактый киң планда ала. Вакыйгалар Россиянең үзәге Мәскәүгә дә күчерелә, революция дулкыннарының Әгерҗе якларына, Зартугай кебек авылларга да килеп җитүе күрсәтелә.

«Идел кызы» романы мавыгып укыла, сюжет-композициясе төзек — характерлар үсешенә буйсындырылган, әсәрнең әдәби тукымасы, нигездә, психологик тирән, вакыйгалар үсеше драматик-киеренке. Әмма югары сәнгать законнары нигезендә иҗат ителгән бу әсәрнең журнал вариантында эскиз рәвешендәрәк калган бүлекчәләре дә бар иде. Әйтик, Солтанның гражданнар сугышында катнашуы, партизаннарның Шәяхмәтне үлем баржасыннан килеп коткарулары. Идел-Кама буйларын тетрәтеп яшәгән Таминдар Тураевның революциядән соң совет власте дошманнарыннан контрреволюцион штаб оештыруы, ак генераллар белән качып китүе штрихлар белән генә бирелгән иде. Аерым китап итеп чыгарганда, язучы әсәренә яңадан кайтып шактый күп эшләгән — ул җыйнаклана төшкән, аерым бүлекләр яңабаштан язылган,

тыгызлык арткан. Ләкин әле беренче китапта да эшләнеп бетәсе, ачыкланасы урыннар бар. Мулланур Вахитовның Кремль диварлары буенда аклар тарафыннан атылуы, һәлак булган комиссарлар аерым бүлек итеп алынса, Солтанның Азин дивизиясендә, сугышларда катнашуы конкрет күрсәтелсә, әсәр тагын да отышлырак булыр иде. Документаль төгәллек белән алынган Шәймәрдән Ибраһимовның да образын тулырак күрәсе килә.

Әмма бу хәлендә дә халкыбызның олы үткәне турында киң колачлы роман язарга алынып, Г. Ахунов, әдип буларак, тәвәккәллек күрсәткән, кеше буларак, данлы тарихыбызга мәхәббәтен раслаган дип әйтә алабыз. Бу кыю, киң колачлы эштә аңа зур уңышлар, иҗат илһамы теләргә кала. Укучы әсәрнең яңа китапларын көтә.

Г. Ахунов иҗатында үзенчәлекле урын алып торган тагын бер әсәр бар, ул — «Чикләвек төше» повесте. Автор өчен генә түгел, гомумән, күпне күргән татар әдәбияты өчен дә яңалык булды бу әсәр. «Чикләвек төше» дөньяга килгәнче язучының әдәби-иҗат мөмкинлекләренә ышанып бетмәгән кайберәүләр дә, бу әсәр басылып чыккач, Г. Ахуновның әдәби талантын бәхәссез танырга мәҗбүр булдылар.

Повестьтагы Халикъ Саматов образы совет кешесе характерын художестволы сурәтләүгә кертелгән зур өлеш дип бәяләнде. Илебез кыска гына тарихи чорда нинди зур җиңүләр яулады, экономикада, фән һәм культурада моңа кадәр бер генә халык та ирешмәгән биеклекләргә күтәрелде. Моның сәбәбе нәрсәдә? Әсәрдән әнә шушы сорауга төпле җавап алабыз. Алга куелган якты идеалларга баруда алны-ялны белмәүче, хезмәт иясе мәнфәгатьләрен беренче планга куеп эш итүче, бу изге эшкә комачаулаучыларны аямаучы, бөек планнарны тормышка ашыруга халык массаларын үз артыннан иртәргә сәләтле Халикъ Саматов кебек каһарман коммунистлар җитәкчелегендә генә мөмкин булды мондый могҗиза. Нинди генә урында булмасын, барлык көчен, йөрәк ялкынын салып эшләүче, коммунистик идеалларга турылыклы Саматов образы укучыда хөрмәт, соклану хисләре уята, көчле ихтыяр һәм ныклык сыйфатлары тәрбияли.

Халикъның характеры болай да калку, әмма мещан психологияле Рокыяның үйкичерешләре фонында алар тагын да ныграк күзгә ташланалар. Аңа үз юлында бик күп киртәләрне җимерергә, иңенә төшкән хисапсыз авырлыкларны күтәрергә туры килә. «Әгәр кешенең үзәге чын булса, ягъни чикләвекнең төшенә зыян килмәсә, ул тагын тернәкләнә, тагын яңа үсенте бирә... үзәгемне саклыйм мин, төшемне. Безнең партиянең фундаменты нык, әгәр шушы фундаментка ялгышып кына ватык кирпеч яки черек агач эләксә, ул барыбер фундаментны үзгәртә алмый, чөнки аны алып ташлыйлар» [1].

Рокыя образы үсештә, үзгәрештә бирелүе белән әһәмиятле. Гаиләдә алган тәрбиясе белән гамьсез, муллык эчендә генә яшәргә күнеккән Рокыя көтмәгәндә язмышын Халикъ белән бәйли. Әмма ирен яратса да, үзләре арасында дөньяга караш



*1978 ел. Фрунзе. Гариф Ахунов һәм Чыңгыз Айтматов.*

---

[1] Ахунов Г. Чикләвек төше. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975, 63 бит.

мәсьәләсендә тирән упкын ятуын аңлап ала. Бу исә әсәрнең эчке конфликтын китереп чыгара. Чөнки Рокыяның исәбе, ничек кенә булса, да Халикътан үзе кебек йорт җанлы кеше тәрбияләү. Гомер буе шушы максатын тормышка ашыру теләге белән яши ул. Ләкин соңыннан: «Мин аны түгел, ул мине үз юлы белән алып китте»,— дип, үзенең җиңелүен танырга мәҗбүр.

Кайбер әсәрләрдә персонажның шәхси тормышы аерым, иҗтимагый эшчәнлеге аерым сызыктан бара торган була. Әйбәт эшләүче кешенең гаиләдә бәхетсез булуы, хатыныннан аерылуы шаблонга әйләнгән иде инде. «Чикләвек төше» әсәрендә конфликт үсеше характерлар үсешенә, кешеләр язмышына шулкадәр нык береккән, кайда гаилә, кайда иҗтимагый сфера дигән сорауны куюның үзе үк мәгънәсезлек булыр иде.

Без бу мәкаләдә Гариф Ахунов иҗатына хас тагын бер үзенчәлекне — аның иҗатының ачыктан-ачык публицистик рух белән сугарылуын да билгеләп үтәргә тиешбез. Чөнки ул, Тукай сүзләрен үзгәртебрәк әйтсәк, коеп куйган язучы гына түгел, политик эшлекле дә.

Г. Ахунов илебездә яки республикабызда бара торган бер генә вакыйгага да битараф кала алмый. Тынгысыз каләме, ялкынлы йөрәге белән аларга үз мөнәсәбәтен белдереп бара. Партия съездларымы, илебезнең Төп законы кабул ителүме, Татарстандагы берәр күренекле вакыйгамы — ул үзенең уй-хисләрен шундук укучылар белән уртаклаша. Әдип тормышта килеп туган кыенлыкларга да сизгер. Мәгълүм булганча, 1978 елгы урып-җыю бик кыен һава шартларында алып барылды, көннәр, атналар, айлар буе яңгыр явып торды. Г. Ахунов, каләме белән игенчеләргә ярдәм итү өчен, август аенда колхозларга чыгып китте һәм Куйбышев районыннан язылган хатларын «Социалистик Татарстан» газетасында бастырып барды. Урыннардагы хәлләрне ачыклап, эшлекле тәкъдимнәрен, киңәшләрен оператив төстә республикабыз җәмәгатьчелегенә ирештерде. «Язучы һәм тормыш» рубрикасында аның актуаль проблемалар күтәргән мәкаләләрен шактый еш укырга мөмкин. Аның публицистик ялкыны әдәби әсәрләрендә дә органик төстә урын ала.

Акыл ияләре әдипнең биографиясен аның әсәрләреннән эзләргә кушалар. Бу гаҗәп түгел, чөнки «язучы бөтенләе белән әсәрләрендә бит ул. Анда аның тойгылары, күңел җылысы, хыяллары, дөньяны үзенчә тануы һәм үзенчә бәяли белүе. Шуңа күрә кайберәүләрнең: «Мин ул язучыны күреп беләм», дип мактануына караганда, «Мин ул язучының фәлән әсәрен укып чыктым», дигән сүзе миңа күбрәк ошый»[1]. Шуның кебек мин дә Г. Ахуновны «күреп белүем белән» әллә ни мактана алмыйм, әмма иҗаты белән чынбарлыгыбызның күп якларын аңларга, бәяләргә ярдәм иткән язучыбызга ихтирамым зур.

Г. Ахуновның үзен дә көчле рухлы коммунистлар рәтендә исәпләргә кирәктер. Тормыш юлында аңа да күп кенә катлаулы ситуацияләр эчендә калырга һәм аларны егетләрчә җиңеп чыгарга туры килә, ләкин ул кыенлыклар аны кеше буларак чыныктыралар гына. Шунысын әйтү мөһим: Г. Ахунов күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе була алган икән, болар аның шәхси казанышы гына түгел. Мондый үсеш бары тик совет властеның үз гражданнары турында олы кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә генә мөмкин булды. Бу турыда Гомәр ага Бәшировтан да үтемлерәк итеп әйтеп булмастыр кебек. «Кулаклар синең әтиеңне үтереп, урамга чыгарып ташларга теләгәннәр. Сиздеңме эшләрнең кая барганын? Ялгышканнар бит алар, бик тә каты ялгышканнар... син ач калмадың, ялангач калмадың, ул гына да түгел әле... син, югары белем алып, ил күләмендә китаплар чыгарырлык булып үсеп җиттең. Болар бит берсе дә үзеннән-үзе килгән, күктән төшкән нәрсәләр түгел, болар, тирәнрәк уйлап карасаң, совет властеның хезмәт кешеләренә биргән хокуклары, болар партиянең ленинчыл зирәк сәясәте нәтиҗәләре бит...»[2]. Тагын өстәп шуны әйтергә кирәк: Г. Ахунов, шул хокуклардан файдаланып, илебезнең Яңа Конституциясен кабул иткәндә, меңләгән сайлаучылары исеменнән Кремльдә тавыш бирүдә катнашты.

Г. Ахунов бәхетле — язмыш аны Г. Кашшаф, И. Гази, Г. Бәширов кебек талантлы өлкән әдипләр белән очраштырган, ул алардан иң кирәкле сыйфатны — кешеләрне

---

[1] Ахунов Г. Әдәби язмышлар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1970, 42 бит.
[2] Ахунов Г. Без бит Арча яклары. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979, 9—10 бит.

ярату хисен мирас итеп алган. Чыннан да, һәр язучының уңышлы әсәре аны чын күңелдән шатландыра, өметле каләмнәргә юл ачарга тырыша, уңышсызлыкка очраганнар күңелендә ышаныч кабыза белә. Юк, ул моны Язучылар союзы җитәкчесе булганы өчен генә түгел, кеше буларак эшли. Язучылар эшчәнлегендә килеп чыккан катлаулы мәсьәләләрне гадел итеп, объектив чишә белү осталыгы өчен дә яраталар аны каләмдәшләре. Табигать «аңа кешелекле йөрәк биргән» [1] — ди күренекле рус совет шагыйре М. Львов.

Гомумән, талантлы кешеләргә гашыйк ул. Күренекле сүз остасы Айрат Арсланов та, халык артисты Илһам Шакиров та, театрыбызның горурлыгы Галимә Ибраһимова да, әле генә сәхнә тормышын башлап җибәргән талантлы яшьләр сәнгате дә аны бердәй дулкынландыра, алар иҗаты турында җылы сүзләр әйтергә рухландыра.

Каләмдәшләре аңа тагын да якынрак. Шәйхи Маннур, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Рафаил Төхфәтуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Шәүкәт Галиев, Яхъя Халитов һәм башкалар турындагы мәкаләләрне укыганда бу аеруча нык сизелә. Юк, ул аларга мәдхия җырлап кына утырмый, әйтәсе теләкләрен дә яшерми, кимчелекләрен дә күрсәтә, ләкин кешелекле итеп, үз итеп әйтә.

«Без бит Арча яклары» әсәрендә КПССның Арча райкомының беренче секретаре, Г. Ахунов белән бергә партиянең XXV съездында делегат булып катнашкан Харис Зәйнуллин, яки колхоз председательләре Мирбат Хәстиев, Фәйзи Галиев, Хәммәт Исмәгыйловларны ул үз итеп, яратып сурәтли, алар хезмәтенә ихтирамын белдерә.

Г. Ахунов төрле-төрле җәмәгать эшләре алып бара. Илебез парламенты депутаты вазифалары, Язучылар союзы җитәкчесенең бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре, «Литературная Россия» һәм «Волга» кебек газета-журналларның редколлегия члены булу һәм тагын шуның кебек бурычларны вакытында үтәп бару өстенә ул илебезнең төрле урыннарында булырга, бик күп кешеләр белән аралашырга өлгерә. Аның әле бервакытта да бары тик язучы гына булганы юк, үзенең өч романын, сигез повестен, күп санлы хикәяләрен, драма әсәрләрен, тәнкыйть мәкаләләрен әнә шул күп төрле эшләрне башкара-башкара язды. Р. Тагор, М. Шолохов, А. Макаренко, В. Закруткин, Н. Погодин һәм башкаларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте. М. Шолохов кебек олы язучыларның әсәрләре белән эш итү Г. Ахунов өчен әдәби мәктәп булды. Иҗатында эпик киңлеккә омтылу, психологизм тирәнлеге һәм тормышка тугрылык кебек сыйфатлар шуннан киләдер.

Язучының иҗат планнары тагын да зур: нефтьчеләр турында трилогиясен тәмамлыйсы бар. Ул Түмән нефтьчеләре турында булачак. «Идел кызы»ның икенче һәм өченче китаплары да күңел өстендә тора. Әдип экранда бөек Тукай образын тудыру хакында хыяллана, фәннәр докторы Р. Нәфиков белән бергә, «Атаклы кешеләр тормышы» сериясе өчен Мулланур Вахитов хакындагы китапны әзерли. Болардан тыш тагын күп кенә характерлар һәм сюжетлар туып-өлгереп килә язучының иҗат лабораториясендә. Аларның тизрәк тормышка ашуын гына телисе килә.

Г. Ахунов гомер буе Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Бәширов кебек әдипләрнең иҗатына гашыйк булып яшәде, алардан күп нәрсәгә өйрәнде. Хәер, ул хәзер үзе дә яшьрәк буыннар өчен күп яктан үрнәк булырлык сүз художнигы булып җитеште. Шунысы әйбәт, Г. Ахунов яшьләр белән планнарын, иҗат серләрен бик теләп уртаклаша. Аның «Йолдызлар калка» повесте шул ягы белән кыйммәтле дә. Ул, автобиографик характердагы әсәр булса да, нигездә татар совет әдәбияты үсешен кайгырту, аның күренекле вәкилләрен зурлау нияте белән язылган, анда тугандаш әдәбиятлар дуслыгы һәм хезмәттәшлеге бик матур чагылыш тапкан. Яшь буын язучылар, югары уку йортлары студентлары, укытучылар, гомумән, әдәбият тарихы һәм иҗат процесслары белән кызыксынучылар өчен бай материал тупланган, танып-белү әһәмияте зур булган кирәкле әсәр бу.

Әдәбият дөньясында талантлы авторның пәйда булуын Гариф Ахунов образлы рәвештә күктә яңа йолдыз кабыну белән тиңли: йолдызларның галәм тирәнлегеннән, талантларның халыкның мең еллык тарихыннан тууын әйтә, китапта әнә шундый йолдызларның күбесе турында сүз алып бара. Ул талантларның алга таба да туачагына зур ышаныч белдерә. Без бу фикер белән тулысынча килешәбез.

---

[1] «Литературная газета», 1975, 17 сентябрь.

**Равил Шәрәфи,**
**Рөстәм Мингалим**

# ЭЗЛӘНҮЛӘР ЮЛЫННАН

*Батулла иҗаты турында уйланулар*

Батулла төрле жанрларда иҗат итә.

1966 елда Татарстан китап нәшриятында «Исемем минем Дүрткүз» исемле китап дөнья күрде. Бу яшь автор Батулланың беренче җыентыгы иде. «...Яшерен-батырын түгел, Роберт Батуллинның теле коры, төссез. Аның әле үз ритмы, үз стиле сизелми. Әлегә аның теле тәрҗемә телен хәтерләтә... Күренеп тора, яшь язучының беренче китабы бик үк уңышлы булмаган...» дип язган иде ул вакытта Н. Фәттах. Тәнкыйтьче сүзендә, әлбәттә, хаклык бар. Шулай да повесть күп кенә уңай яклары белән укучы күңелендә җылы урын тапты.

Повесть — Дүрткүз исемле көчекнең ил гизүе, хуҗадан хуҗага күчеп, күп маҗараларга тап булуы, кыенлыклар аша узып, яңадан туган авылына әйләнеп кайтуы турында. Маҗаралар көчекнең үз авызыннан сөйләнә. Мондый алым яңа түгел. Шулай ук ул әсәрнең кимчелеге дә түгел. Повесть җиңел укыла, маҗаралар бербер артлы куера бара, әсәрнең үз ритмы, үсеш тизлеге бар, ул вак-вак бүлекләрдән тора — кечкенә укучы өчен монысы да мөһим. Автор катлаулы, озын җөмләләр кулланмый, тора-бара әсәр үз стиленә ышанырга мәҗбүр итә. Укучы Дүрткүз сөйләгәннәрне күрә, вакыйгаларга инана башлый. Гадәти булмаган сөйләм ысулы лиризмны һич киметми, арттыра гына... «Яңа хуҗаларым» бүлеге — сатирага бай булса, «Мин артист булам» бүлеге — юмор белән сугарылган. Алдагы бүлекләргә контраст буларак, «Ышнаны сагынам» бүлегендә лирика өстенлек итә. Лирика өлешен «Мин хуҗасыз, йортсыз-җирсез калам» дигән кызганыч язмыш алыштыра. Бу ысул жанрлар бутау булып кабул ителми. Повестьның төп каһарманы Дүрткүз төрле хәлләргә куела һәм нәтиҗәдә әсәргә көчле динамика бирелә. Автор яшь укучыны туган җир кадере турында уйландырырга, очраган авырлыкларны җиңүгә дәртләндерергә, бала күңелендә җәнлекләргә карата ярату, кызгану хисе уятырга теләгән. Аның изге теләге «Исемем минем Дүрткүз» повесте булып укучыга җитте.

1967 елның башында ук «Ялкын» журналы аша без «Куян баласы Нуяк» әсәре белән таныштык. Балалар өчен Батулла язган әсәрләрнең күбесенә хас алым тагын кабатлана: бу повестьта да җанварлар кешечә сөйләшә, уйлыйлар... Бу әсәр дә маҗараларга бай, ул маҗаралар лирик буяулар аша бирелә. Куян баласы Нуякның кыен тормышы күз алдыннан уза. Куяннарны этләр куа, төлкеләр, бүреләр сагалап тора, ябалаклар ботарлый. Ләкин яхшы күңелле кешеләр җәнлекләргә ярдәм кулы суза. Аучы булырга хыялланучы Фәйруш повесть азагында олы җанлы, табигать сөюче булып җитешә. Повестька гаять зур тәрбияви фикер салынган. Тик ни сәбәптәндер повесть Батулланың «Куян баласы Наян» җыентыгында[1] бик нык кыскартып басылган, күп кенә бүлекләр бөтенләй төшереп калдырылган һәм әсәрнең эмоциональ куәте кимегән. Укучылар арасында танылып өлгергән каһарман Нуякның исеме «Наян»га әверелгән. Ә «Наян»нар күп булды. Ул яңа әсәрнең исеменә искелек төсмере генә бирә.

Заман әкияте нинди булырга тиеш соң? Бу сорау рәсми җыелышларда көн тәртибенә куелмаса да, үзара сөйләшүләрдә еш кына калкып чыга. Берәүләр, әкият бары тик халык әкиятләре, бәетләр, ягъни гадәти формада булырга тиеш, ди. Икенчеләре, аждаһалар, ханнар, патшалар туйдырып бетерде инде, яңаны уйлап чыгарыр-

[1] Куян баласы Наян. Татарстан китап нәшрияты, 1970 ел.

га кирәк, диләр. Заман әкияте бушлыктан алып язылмас, заман әкияте халык авыз иҗаты нигезендә яңача үсеп чыгарга, яңарырга, алга китәргә тиеш дигән фикерләр дә әйтелә. Татарстан язучылары бу турыда даими рәвештә уйлана, эзләнә. Батулла бу өлкәдә аеруча актив эзләнүче язучы. Алда телгә алынган ике әсәр шул эзләнүләр җимеше, ә аның «Курай уйный бер малай» әсәре — иң уңышлы нәтиҗәләрнең берсе[1]. Автор әсәргә традицион сөйләмне дә, заман элементларын да оста һәм табигый итеп керткән. Әкияттә «неон лампасы» да, «магнитофон» да, курай да, «музыкаль театр» тәгъбире дә бик урынлы кулланылган. Бер үк вакытта Батулла халыкчан такмакларны да шактый урынлы файдалана, алар бәйрәм күренешенә җанлылык, матурлык өсти.

Әкият кечкенә кисәкләрдән тора. Аерым-аерым алганда аларның һәрберсе мөстәкыйль әсәр. һәрберсенең үз максаты, идеясе, әйтергә теләгән фикере бар. Шул ук вакытта алар бер бөтен әсәр кисәкләре булып та тора. Әкиятнең идеясе ачык, гыйбрәтле.

Курайчы малайның апасы Киребеткән музыка яратмый. Ул курайчыны көне-төне эзәрлекли, курайларын берәм-берәм утка ташлый. Апасыннан качып уйнарга мәҗбүр малай, ләкин Киребеткән сагалап торып аның кураен чәрдәкләп ташлый. Малай явыз кызны каргап елый, аның күз яше курай кыйпылчыклары өстенә тама. Шул чак могҗиза башлана: аяз көнне күк күкри — әшәке кыз агач кортына әверелә. Бу беренче әкият эчтәлеге. Үзенә күрә аның фәлсәфәсе бар: музыка сөймәгән, музыка аңламаган, көй-моң яратмаган кеше кеше түгел ул — бөҗәк. Күрәбез ки, бу бүлек аерым әсәр булып яши ала. Кечкенә генә әкият булса да аның сюжеты, үсеше, характерлары, оста тәмамланышы, фикере бар. Әдәби әсәрнең барлык компонентларын җыйган, төгәлләнгән әсәр бу. Автор балалар психологиясен яхшы тоя, укучы күңеленә нәрсә кирәклеген яхшы сиземли һәм тагын берничә әкият өсти.

Курайчы малай көн саен урманга барып апасын эзли, ләкин табалмый. Явыз булса да апа кеше бит. Малай аны яңадан үз хәленә кайтарырга тели. һәр барган саен ул яңа мажарага тап була. һәр мажараның үз гыйбрәте бар. Соңгы әкият азагында курайчы малай апасын таба: «...Киребеткән кызый шул кадәр үзгәргән, бөтенләй танымаслык булып матурайган. Кыз, курайчыны кочаклап елаган да, үз башыннан кичкән хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп биргән: синең каргышың миңа төшкәннән бирле, мин бөҗәк булып яшәдем. Кошлар чукымасын, мине тотып ашамасыннар, дип шуыша-шуыша, үрмәли-үрмәли, кача-поса яшәргә мәҗбүр булдым. Син аланга килеп курай уйный башладың... Шул чакны мин кеше булуның гаҗәп бер кыйммәтен тойдым. Курай моңын тыңлый-тыңлый миңа канатлар үсеп чыкты. Мин күбәләккә әйләндем... Моңсыз, аһәңсез, җырсыз яшәгәнче үлем мең өлеш артык!» — ди кыз. Әкиятнең бу өлеше, бер караганда, примитив акыл сату кебек күренер, ләкин әсәрнең балаларга атап язылган булуын истән чыгармыйк. Әкият азагында бер нәтиҗә ясап, балага сабак алырлык сүзләр әйтәбез икән, бу һич тә зыянга китмәс шикелле. Аның караво, әкият гаять матур, якты тәмамлана: «...Малай кураен алып уйнап җибәргән. Гүзәл кыз чиста, матур, нәфис тавыш белән аңа кушылган. Күбәләк-кыз шулкадәр матур җырлаган, малай шулкадәр оста уйнаган. Ярышта алар беренче урынга чыкканнар...»

һәрберсе лирика, фәлсәфә белән сугарылган шушы бәләкәй генә әкиятләрнең балаларга гына түгел, өлкәннәргә дә тәэсир итәрлек көче бар.

Авторның тагын бер заманча әкияте — «Колакчын Тафи». Кеп-кечкенә әкият. Ләкин фикере, вакыйгалары белән гаять матур, гыйбрәтле әсәр. Үз халкыңны, Ватаныңны хөрмәт итәргә өйрәтә автор. «Колакчын Тафи»да рәхәт тормышка кызыгып, туган илен ташлап, дошман ягына чыккан төлкене дошман үзе үк атып үтерә дә колакчын бүрек тегеп кия.

Әкиятнең яңа формаларын эзләү белән бергә Батулла традицион формада да, халык әкиятләре нигезендә дә күп кенә әсәрләр язды. Моңа «Үлемсез егет», «Тычкан баласы Чикыл», «Йолдызлар һаман исән», «Гөлчәһрә» повестьлары, кече күләмле «Йолдызлар турында әкият» әсәрләрен мисал итеп китерергә була.

«Йолдызлар турында әкият» аерым игътибарга лаек. Автор аны Октябрь Революциясе бәйрәменә багышлап язган. Комсыз Дупмас күктәге йолдызларны урлый. Халык караңгыда кала... Кешеләр сер сандыгы өстендә утыручы Пумпаны бәреп төшерәләр. Халык батырлары йолдызларны азат итә. Йолдызлар дөньяга яктылык сибә. Җир йөзендә Бөек Йолдыз Бәйрәме башлана.

Пионериянең 50 еллыгына атап язылган «Гөлчәһрә» повесте исә формасы белән дә, язылышы белән дә язучының бүтән әсәрләреннән нык аерыла. Ул ике өлештән тора. Беренчесе традицион әкият теле белән язылса, икенче өлеше чынбарлык турында сөйләүче революцион хикәят. Ягъни башта вакыйга әкиятче әби тарафыннан риваять итеп сөйләнә, аннан, Мирасның әнисе авызыннан, реаль вакыйга итеп тасвирлана. Нәтиҗәдә революционерлар Гыйлемҗан белән Гөлчирәнең батырлыгы шигъри әкият дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әсәр бүгенге көн белән тыгыз бәйләнештә. Автор ата-бабаларыбызны үсеп килүче буынга үрнәк итеп куя, революционерларга, гражданнар сугышы батырларына, сугыш корбаннарына булган мәхәббәтне тагы да олырак, яктырак итеп күрергә тели.

Батулла ун ел чамасы инде даими рәвештә телевидение буенча балаларга әкиятләр сөйли. Әйтергә кирәк, бу өлкәдә ул зур эш башкара. Кечкенәләр өчен сөйләгән Мөбәрәк турындагы әкиятләрен

[1] Р. Батуллин. Алтын куллы Гөлчәһрә. Татарстан китап нәшрияты, 1974 ел.

балалар гына түгел, олылар да яратып кабул итте. Иң бәләкәйләр өчен язылган «Салават күпере кайда йоклый», «Тычкан баласы Такыл», «Балавыз», «Куян тотучы Мырый», «Сак белән Сок кавышканда», «Мәрәкәй бабай» әкиятләре — язучының уңышлы әсәрләре.

Автор сигез китап чыгарган. Шуның җидесе балалар өчен. Димәк, Батулланы, икеләнүсез, балалар язучысы диярга тулы хакыбыз бар.

«Тәнкыйтьчеләр һәм педагоглар, балаларга багышланган әдәби әсәр турында сөйләгәндә, бик хаклы рәвештә иң беренче планга тәрбия мәсьәләсен куялар. Әмма тәрбия чаралары балага сиздерми, күренми генә тәэсир итәргә тиеш». Бу сүзләр Батулланың 1969 елда әдәби ел йомгакларында сөйләгән докладыннан китерелде[1]. Яхшы әйтә. Әмма «Каникуллар дәвам итә...» повесте әлеге сүзләрдән ерак тора. Повесть формасы белән дә, теле белән дә, жанры белән дә Батулла иҗатында чит-ят әсәр. Автор бер төркем авыл малайларының җәйге каникул вакытында корыны бушка әйләндереп йөрүләрен яза. Шәһәрдән кайткан Альберт аларны яманлыкка гына өйрәтә. Малайлар мәктәп эшләреннән, походтан качалар һәм шуңа охшаш башка эшләр кылалар. Торабара алар төзәлеп, әйбәт кенә эшли башлыйлар: балык буасы оештырып җибәрәләр... Ә бу процесс повестьта акланмый. Повестьның эзлекле бер сюжеты да юк.

Вакыйгаларның бер өлеше Наилә көндәлеге аша тасвирлана, бер өлеше автор авызыннан сөйләнә. Зур булмаган әсәрдәге мондый сикерешләр авторны таркаулыкка китерә, повестьны уку кыенлаша. Батулла әсәрендәге бүгенге җиденче класс укучыларының сөйләшүен тыңлап, аптырап каласың. Бер карасаң, алар 3—4 нче класс балалары кебек сөйләшә, икенче карасаң, вуз студентларыннан да арттырып җибәрә. Шапшак телләрен төртелә-тәрлә укыйсың. Ясалма тәгъбирләр, аңлаешсыз җөмләләр повестьның һәр битендә диярлек очрый. Яки мондый мәгънәсезлек: «...үги ана яфраклары һәм кыргый үсемлекләр...» (16 бит).

Үги ана яфрагы үзе кыргый үсемлек түгелмени? «Димәк», «чөнки», «әмма», «ләкин», «әлбәттә» кебек сүзләр дә әсәргә дыңгычлап тутырылган.

Язучы китаптан-китапка үсәргә, остарырга тиеш иде, Батулла икенче повестен матбугатка ныклап эшләмичә тапшырган. Нәтиҗәдә — җитлекмәгән китап дөньяга килгән. Шик юк, әлбәттә, автор бу повестенда да мөһим мәсьәлә күзгатырга омтыла — җир-суны, балыкларны, гомумән, табигатьне саклауда пионерлар актив көрәшче булырга тиеш, ди. Тик, Батулланың үз сүзе белән әйтсәк, әсәрдә идея-витамин бар, ләкин витаминны төргән бал юк, ягъни повесть әдәби әсәр була алмаган.

«Каникуллар дәвам итә»нең язмышы авторны ныклап уйландырды кебек. Инде аның теле шомара, әсәрләре камилләшә бара: авторның «Уйларымны кеше белсен...» китабында чыккан хикәяләре моңа ачык дәлил. Бу китапка сигез хикәя, ике очерк кергән. «Офыклар алсу иде»... хикәясе белән ачыла китап. Психологик кичерешләргә гаять бай, ышандыру көченә ия ул әсәр Бөек Ватан сугышы елларында тылдагы картлар, хатын-кызлар, балаларның фидакарь хезмәте турында.

«Соңгы чабыш», «Фасил белән Василә» кебек хикәяләр көчле драматизм белән аерылып торалар. «Шәйдулла абый»да укытучы, колхоз председателе, коммунист Шәйдулланың катлаулы язмышы турында сөйләнелә. 10—15 битлек хикәядә автор повестьлык вакыйганы олы язмышларга туплау осталыгына ирешкән. «Кызыл таң» газетасы оештырган «Коммунист ничек булырга тиеш» конкурсында «Шәйдулла абый» хикәясе беренче урынны алды.

Гомумән, Батулла прозасын бергә җыеп караганда, түбәндәге өч үзенчәлекне аерып күрсәтергә була. Беренчесе, драматизм белән сугарылган психологик хикәяләр: «Офыклар алсу иде...», «Соңгы чабыш», «Мираж», «Шәйдулла абый»... Икенчесе, сатирик-юмористик хикәяләр: «Яшел пакет», «Укалы фәрештә», «Тимерҗан», «Җинаять»... Өченчесе, сәхнә әсәрләренә генә хас элементлардан торган хикәяләр: «Бер юлда», «Көтелмәгән кунак», «Чүгә».

1970 елда, ягъни КамАЗ төзелә башлауның беренче көннәрендә үк язучы комсомолның өлкә комитеты вәкилләре белән бергә Чаллыга барган иде. «Көтелмәгән кунак» шул командировкадан кайткач язылган хикәя. Автор грандиоз төзелешкә карап сөенә, Чаллының зур киләчәген күрә. Һәм шул ук вакытта кыенлыклардан куркып, төзелешкә, үзенә, дусларына хыянәт иткән Зинадан көлә. Бу хикәяне бер пәрдәлек пьесалар рәтенә куеп карасак, әлбәттә, хаклы булырбыз. Вакыйга бер урында, бер сәгать чамасы вакыт эчендә бара, анда бары тик өч кеше катнаша. Шушы вакыт эчендә өч образның характерлары ачылып бетә. Бәхтияр — шофердан инженер дәрәҗәсенә күтәрелгән, һәвәскәр артист Гөлфия (аның хатыны) — музыка укытучысы. Алар кыен чакта Чаллыны ташлап китмәгән. Без аларның бәхетле совет гаиләсе корганнарын күрәбез. Аларга капма-каршы образ Зина (элеккеге Зөлфия) тора: ул җылы урын, җиңел эш эзләп, төзелеш башланганда ук, каядыр чыгып киткән, хәзерге көнгә кадәр үзенә оя кора алмаган бәхетсез кеше.

«Бер юлда»ны да бер пәрдәлек пьеса диярга була. Чөнки ул динамикалы диалоглардан гына тора. Вакыйга бер урында, бер сәгать эчендә бара. Әсәрнең экс-

[1] Р. Батуллин. Витаминнар хакында. Казан утлары, 1969 ел, 8 сан.

[1] Р. Батуллин. Уйларымны кеше белсен... Татарстан китап нәшрияты, 1969 ел.

позициясе дә, үсеше дә, кульминациясе дә, чишелеше дә бар. «Көтелмәгән кунак», «Бер юлда» хикәяләрендәге автор сүзләрен җая эченә алып, һәр туры сөйләм алдында сөйләүченең исемен куйсак, пьеса килә дә чыга. Бу Батулланың күп әсәрләренә хас сыйфат. Аның һәр хикәясендә дә диярлек драматик нигез ята.

«Яшь ленинчы» газетасы, «Ялкын» журналы, «Күңелле сәхнә», «Клуб утлары» җыентыкларында Батулла язган скетчлар, сценарийлар еш кына басыла килә. Ул язган сценарийлар буенча радио һәм телевизион тапшырулар эшләнде. Аның «Пәһлеваннар иле»[1] китабының нигезен курчак театры өчен язылган пьесалар тәшкил итә. Бу китапка кергән «Тылсымчы белән сихерче» әкияте Саратов, Кемерово, Барнаул шәһәрләрендә бүгенге көндә дә бара. Пьесаның Казан курчак театрында куелган нөсхәсе меңгә якын тапкыр уйналды, курчак театрларының Бөтенроссия конкурсында икенче дәрәҗә диплом алуга иреште.

Атаклы Әбугалисина кыйссасыннан файдаланып, автор оригиналь әсәр иҗат иткән. Образлар тулы. Сюжет үткен — маҗаралар белән кайнап тора. Әмма китапка кергән башка пьесалар — «Каһарманнар әкияте», «Курай уйный бер малай», «Үлемсез егет»тә сюжет таркау. Калган өч пьеса да күп сүзлелек, артык персонажлар, күренешләр, сюжет катлаулылыгы, шулар өстенә тел чатаклыгы белән зәгыйфьләнә. Ә үзләрендә күтәрелгән проблемалар мөһим югыйсә, сүз халыклар дуслыгы, ватан азатлыгы өчен корбан булган каһарманнар турында.

Театр сәнгате белән якыннан таныш, Мәскәүдә югары театраль белем алган, режиссура белән дә шөгыльләнгән Батулла өлкәннәр сәхнәсе өчен дә әсәрләр яза. 1974 елда аның берьюлы ике пьесасының премьерасы булды. Республика драма һәм комедия театры сәхнәсендә «Туйлар узгач...» музыкаль комедиясе куелды. Бу лирик комедияне тамашачы шатланып каршылады. Нәрсәсе белән җәлеп итте соң ул тамашачыны? Әсәр бүгенге көн яшьләре турында: бер-берсен өзелеп сөюче Ләйлә белән Мәҗнүн тормыш коралар, ләкин Бибиәсманың (Ләйләнең әнисе) мещанлыгы, Зәйнәпнең (Ләйләнең апасы) тәрбиясезлеге, тар карашлыгы аркасында олы мәхәббәт, яшь гаилә чак кына җимерелми кала. Дуслары белән берлектә яшьләр җиңеп чыга. Шушы җитди мәсьәләне автор мавыктыргыч итеп, көлке дәрәҗәсенә күтәреп хәл иткән.

«Өчәү юлга чыктык» әсәре — драма дип исемләнгән. Ләкин аның Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган нөсхәсен һәм, әлбәттә, әсәрнең үзен дә драма дип әйтүе кыен. Көчле-көчле бәрелешләр булып ала, әмма вакыйгалар драмага кадәр барып җитә алмаганнар.

Беренче пәрдәдә сюжет бар, шул сәбәптәндер, әсәрнең бу өлеше тәгәл генә ритмик үсештә бара, Батулла биредә диалоглар кора белүен дә оста күрсәтә. Ә инде икенче өлештә сюжет сызыгы бөтенләй югала дип әйтерлек. Бу күренеш авторның кимчелегеме, үзенчәлегеме? «Кимчелеге» дияр идең, икенче пәрдәне тамашачы аеруча яратып карый. Зал я тып-тын кала, я дәррәү көлеп җибәрә. Сюжет зәгыйфьләгән авторның «үзенчәлеге» дияр идең, бу драма кануннарына туры килми. Ләкин шунысы кызык, тамашачы «кануннарга туры килми» дип тормыйча, спектакльгә актив йөрде. Хикмәт нәрсәдә соң? Беренче пәрдә әле яңа гына мөстәкыйль тормыш башлап җибәргән өч яшь журналистның бәхәсләшүенә корылган. Производство турындагы специфик сөйләшүләр тамашачының бер өлешенә кызык, икенчесенә — кызык түгел. Ә икенче пәрдә һәркемгә аңлашыла, чөнки автор каһарманнарны гаилә шартларында күрсәтә. Менә Гөлфирә белән Ихлас. Ихласка кыен вакыт, аның мәкаләләрен, хикәяләрен басмыйлар. Ул өзгәләнә, ярсый, тупаслана. Хатыны Гөлфирә шушы вакытта бала көткәнлеген әйтә. Сөенечле хәбәр Ихласка нык тәэсир итә, әле генә балтасы суга төшкән кебек утырган боек кешене алмаштырганнармыни! Кыенлыклар онытыла, без бәхетле гаилә күрәбез.

Морат белән Фатыйма өлешен алыйк. Ни өчен бу күренештә тамаша залында ютәллəү дә, урындык шыгырдату да, конфет кәгазе кыштырдату да ишетелми — тамашачы тын алырга кыймый нәрсә көтә соң?

Фатыйма белән Моратның тормышлары бармый. Тамашачы горур хатынның һәр җөмләсен, һәр сүзен йотып утыра. Тамашачыны Фатыйманың язмышы уйландыра, борчый. Ире Морат нәрсә әйтер, калырмы, әллә ике баласын (Фатыйма бу вакыт икенче бала көтә), хатынын ташлап китәрме? Морат гаиләсенә әйләнеп кайта. Тамашачы иркен сулап куя. Фатыйма роленең ныклы психологик нигезе бар.

Морат белән Фатыйманың драматик өлеше узгач, Мирзахан белән Расиха гаиләсендә вакыйга башлана. Монда авторның сатирик көче тулысы белән сәхнәне дә, тамашачыны да били ала. Шулай да пьесаның бәхәсле яклары ачык сизелә. Темасы татар сәхнәсе өчен яңа булса да, сюжеты шактый иске, күп өлешләре Штейнның «Океан» пьесасын хәтерләтә, ситуацияләр шундый ук дип әйтергә була. Яшь актерларның, артисткаларның яхшы уены, режиссер П. Исәнбәтнең уңышлы режиссурасы гына әсәрнең кимчелекләрен йома алмаган: сюжет таркау, жанры тәгәл ачыкланмаган, финал юк. Мирзахан образы азакка кадәр чишелеп бетми, гомумән, пьесаның ноктасы куелмаган.

Батулланың өлкәннәр өчен профессиональ театр сәхнәсендә барган өченче пьесасы — «Өйләнер чак». Сүз дә юк, спектакльне тамашачы алкышлап каршылады. Рәссам ясаган курчаклар да әйбәт, артистлар да шәп уйный. Спектакльнең идеясе дә ачык: яшьләр, гаилә тормышында бер-берегез белән һәм өлкәннәр белән тупас булмагыз! — ди автор. Ләкин нидер җитми. Сюжет таркаулыгы, жанрда

[1] Татарстан китап нәшрияты, 1977 ел.

эклектика сизелә. Беренче пәрдә — музыкаль комедия. Икенчесе — сатирик драма. Пьесаның, спектакльнең дә финалы, азагы юк. Безнеңчә шулай. Әмма ни генә булмасын, Батулла үзенең драматургия өлкәсендә җигелеп эшләрлек язучы икәнлеген исбат итте. Аның «Кичер мине, әнкәй» драмасы Татар дәүләт академия театрында зур уңыш белән бара. Автор кеше күңелен тетрәндерерлек тема сайлаган. Кем ана булырга хаклы? Баланы тәрбияләгән кешеме? Әллә аны тудырып, сабый чакта ташлап киткән кешеме? Бу сорауга автор үзе үк дөрес җавап бирә. «Сине үстергән кеше ана!» ди ул. Автор әсәрен «трагикомедия» дип ялгыш атаган. Көлке ситуацияләргә, сатирик образларга бай булса да, бу әсәр драма, трагедия түгел.

Республикабыз вакытлы матбугатында Батулла 20 дән артык мәкалә белән дә чыгыш ясаган. Боларның һәммәсен бергә җыеп бер-бер артлы укып карасак, сәеррәк нәтиҗә чыгар: Батулла мактау мәкаләләре генә язарга ярата бугай. Аларның күбесе, бер сүз белән әйткәндә — мәдхия. Дөрес, автор «Вәгъдә һәм омтылыш»та: Г. Рәхим төрле жанрларда эшләргә омтыла, дигәннән соң, «...шагыйрьләр гел шигъри әсәрләр иҗат итү белән генә мәшгульләр. Алар бүтән жанрда эшләргә шүрлиләр һәм күбесе, мин театрны белмим яки мин бит проза яза алмыйм, дип әйтәләр. Шуңа күрә аларның иҗаты бер яклырак», — дип, яшь шагыйрьләргә карата бер тәнкыйть сүзе әйтеп китә. Ләкин автор хаклымы икән? Дөрес, Пушкин да, Маяковский да, Такташ та төрле жанрларда иҗат иткәннәр. — Монысы хак. Ләкин «нигә пьеса язмаган?» дип Тукайны битәрләп булмый бит инде!

«Сәхнәгә яңа көчләр килә» мәкаләсендә дә Батулла мөһим мәсьәлә кузгатырга тырышып карый, ләкин ул тырышу гына булып калган. Автор бу уңай рецензиясендә тәнкыйть сүзе дә әйтә. Әмма аның төгәл адресы юк... Чыннан да, соңгы елларда театрларда телнең сафлыгына, аһәңнең матурлыгына игътибар җитәрлек түгел. Дикция турында әйткән дә юк инде: театрларда сөйләм культурасы түбән. Мәкалә авторы уенчыларның тел кимчелеген бары тик сәхнә теленә өйрәтүче педагоглар өстенә генә аударырга тырыша сыман. Безгә калса, артистларның тел культурасы турында, барыннан да элек, режиссер һәм театрның баш режиссеры үзлексез кайгыртырга тиеш.

Ә инде «Витаминнар хакында» дип исемләнгән мәкалә арада җитдилеге белән аерылып тора. Автор балалар өчен язучы әдипләрнең уңышларына бәя бирү белән бергә, аларның аерым һәм гомуми кимчелекләрен дә оста, кыю итеп ачып салган. Мәкалә дәлилле, тирән язылган. Шунысын да әйтергә кирәк, бу Батулланың беренче мәкаләсе иде. Ни сәбәптәндер, ул моннан соңгы мәкаләләрен үзенә охшаган әсәрләр турында гына яза башлады.

Батулла язган мәкаләләр арасында иң көчлесе, иң матуры, иң образлысы «Гүзәл сәнгать белән очрашу». Аны укыгач, «Галиябану» спектакле тулысы белән күз алдына килеп баса. «Спектакльнең иң тәэсирлесе, иң тетрәндергеч урыны үлем ярасы алган Хәлилнең егыла бару күренешендә, — дип яза мәкалә авторы. — Бөтен сәхнәгә җитә кызыл утлар сирпелә. Әйтерсең лә бөтен кеше ут-хәсрәт эчендә калды. Сәхнә уртасында, менә егылам, дип яралы Хәлил басып тора. Ян-якларда кайгыдан катып калган кешеләрнең шәүләләре. Режиссер кино алымнарын уңышлы кулланган. Егетләр-кызлар туктап калган кинокадрларны хәтерләтә, Хәлил акрынайтылган кинокадрдагы кебек салмак кына, акрын гына шуышып җиргә егыла бара. Оркестр кылларга тияр-тимәс кенә, үзәк өзгеч итеп лейтмотив уйный. Бу күренеш гаять зур тәэсир көченә ия...» Монда автор тарафыннан һич арттыру юк. Талантлы режиссер Рифгать Исрафилов куйган спектакль безне нәкъ мәкалә авторы Батулла сурәтләгәнчә тетрәндерде.

Гомумән, язучы Батулла күп төрле жанрларда эзләнә. Бу сөенечле хәл, әлбәттә. Ләкин киңлеккә җәелеп, кайчакта тирәнлек турында оныткаламыймы икән ул? Кайбер әсәрләрендәге схемачылык, ахырынача төгәлләнмичә калган пьесалар әнә шул жанрдан жанрга сикерү-чәчелү нәтиҗәсе түгелме икән?

Тәнкыйтьчеләргә дә, авторның үзенә дә уйланырлык нәрсәләр бар, безнеңчә.

# ИЛДАР НИЗАМОВ



Илдар Низамов иҗаты белән мин күптәннән таныш. Җитмешенче еллар башында вакытлы матбугат битләрендә басылып чыккан беренче хикәяләрендә үк инде ул үзен әдәбиятка үз темасы һәм язу манерасы белән килүче талантлы прозаик итеп танытты. Аның иҗатында, минемчә, нигездә Идел темасы уңышлы яктыртыла. Татар әдәбияты өчен бу теманың әһәмиятле, бөтен тарихы бәек Идел белән бәйләнгән халык өчен типик, характерлы тема икәнлеген исбатлап торуның кирәге юктыр дип уйлыйм. Ә ул темага бездә шушы көнгәчә мактап телгә алырлык әсәрләр иҗат ителгәне юк. Беренче төп профессиясе буенча елгачы-штурман Илдар Низамовның әдәбиятыбыздагы әнә шул кимчелекне бетерү юлында җиң сызганып эшләү өчен бөтен мөмкинлекләре бар. Киләчәктә ул үзенең укучыларын менә дигән әсәрләр иҗат итеп шатландырыр дип ышанам.

**АТИЛЛА РАСИХ.**

# ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИН



1968 елдан бирле вакытлы матбугат битләрендә һәм яшь шагыйрьләрнең күмәк җыентыкларында катнашып, Зиннур Насыйбуллин үзенең каләмен шактый чарлады, иҗатында җитди «сикереш» ясау өчен көч туплады. Һәм менә шул «сикереш» нәтиҗәсе буларак, аның «Тәлгәш» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Җыентык шунда ук укучыларның игътибарын үзенә җәлеп итте. Һичбер икеләнүсез әйтергә мөмкин: әдәбиятыбызга үзенчә яңгырый торган яңа исем өстәлде.

Әлеге җыентыкка тупланган шигырьләр, барыннан да элек, талантлы язылган булулары белән аерылып торалар. Зиннурның шигырьләренә фикер тирәнлеге, форма гадилеге хас. Дүрт юллык шигырьгә ул бер үк вакытта кисәтә дә, канатландыра да ала торган фәлсәфи фикерне сыйдыра. Фикер алып килүче шигырьләр — аның поэзиясенең асылын кыска гына итеп әнә шулай бәяләргә мөмкин.


Зиннурның гражданлык пафосы яңгыравыклы, бизәкле сүзләргә төренмәгән. Аның шигырьләрендә гражданлык хисе беренче чиратта конкрет нәрсәләрдә чагыла. Шуңа күрә ул шигырьләр күңелдә җуелмас эз калдыра.

Шагыйрь үз теленең бөтен нечкәлекләрен яхшы белә. Ул язган шигырьләрдә мәгънәне ачып бирүгә ярдәм итми торган бер генә буш һәм артык сүз дә юк, шул ук вакытта аның теле саф һәм аһәңле.

Иҗат юлын шундый ышанычлы һәм еметле адымнар белән башлап җибәргән шагыйрьдән киләчәктә безнең берсеннән-берсе уңышлырак әсәрләр көтәргә хакыбыз бар.

**ФАТИХ ХӘСНИ.**

# МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ



Марсель Галиев әдәбиятка шактый нык әзерлек белән килә. Аның кешеләр белән бүлешәсе самими уйлары, дөнья-тормышка әйтер сүзләре, гомумән, шәхес буларак, бай күңеле бар. Шагыйрь язмышының ил-дөнья язмышыннан аерылгысыз икәнлеген искәртеп, аның:

Заман төбәгән бит иң беренче
шагыйрьләргә каршы дуэльдә...
— дөнье очраклы түгел.

Марсель — Азнакай якларыннан, «чал Уралның соңгы дулкыны» булып, «зәңгәр пирамидадай» торган Чатыр таулар төбәгеннән. Биографиясе — заманга һәм үз буынына хас биография — мәктәп, армия хезмәте, университет, редакцияләр...

Марсель Галиевнең беренче шигырьләрен күтәреп, язучыларның Әлмәт бүлегенә килеп йөрүенә дә инде ун еллап вакыт үтте. Бу еллар эчендә матбугатта шактый нәтиҗәле эшләде ул. «Еллар чалымы» исемле шигырь китабы чыгарды. Байтак хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр бастырды. Аның «Март», «Яшел соната» кебек парчалары белән беррәттән «Ак абагалар», «Ул чакта» кебек повестьлары да бар.

Марсель Галиев — интеллектуаль поэзия вәкиле. Шигырьләре рәсемле-сурәтле шигырьләр (...Шүрәлеләр булып каеннарда уйнакладьы учак шәүләсе), уйлыгамьле шигырьләр (...Бу җаныңны чайкап алыр өчен дөнья гүя сулар яраткан).

Ул татар һәм дөнья әдәбиятының яхшы үрнәкләре җирлегендә иҗат итә. Мин аның поэзиябездә булсын, прозабызда булсын, укучыларыбызны сөендерерлек яхшы әсәрләр тудыра алачагына нык ышанам.

**РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН.**

# ӘХМӘТ ГАДЕЛ



Татарстан китап нәшриятында беренче шигъри җыентыгын чыгарганчыга кадәр яшь шагыйрь Әхмәт Гадел бай һәм кызыклы тормыш юлы узды. КамАЗ һәм Түбән Кама нефть-химия төзелешләрендә эшләде, читтән торып М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлады. Шул ук вакытта татар телендә дә, рус телендә дә шигырьләр, хикәяләр язды. Тынгысыз эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, беренче җыентыклары дөньяга килде.

Әхмәт Гаделнең иң әйбәт шигырьләрендә — заманыбызның төрле тавышлы ритмы. Үзенең башланган чишмәсенә — шәҗәрәсенә дә рәхмәт белән борылып карарга онытмый, шул ук вакытта үз милләтенең кабыгы эчендә генә дә чикләнеп калмый. Башка милләт халыкларына ул вакытлыча түгел, җан дусты булып бара, үзе дә байый, аларны да баетырга омтыла.

Әхмәт Гадел үзенең көчен драматургия өлкәсендә дә сынап карый. Беренче драмасына караганда, аның бу өлкәдә дә уңышлы эшләячәгенә ышаныч туа.

Менә бу әйтелгән һәм әйтелмәгән сыйфатларын үстерсә, Әхмәт Гадел безнең әдәбиятыбыз өчен кирәк булган әйбәт әсәрләр тудырыр дигән өметтә калам.

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ.**

# КУЛЬТУРАБЫЗ ҮСЕШЕ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Матбугат әсәрләрен барлау, туплау, тулы исәбен алу һәм аларның елъязмасын чыгарып бару — дәүләт күләмендәге әһәмиятле эш. Татарстан дәүләт китап палатасы илебездәге иң өлкән палаталарның берсе булуына карамастан, республика басмаларының елъязмаларын әзерләү соңгы елларга кадәр эзлекле төс ала алмады. 1925, 1938-1940 еллардагы китапларны теркәгән күрсәткечләрне искә алмаганда, Бөек Ватан сугышыннан соң чыккан басмаларның елъязмалары гына басыла барды. Татар китабының ретроспектив библиографиясен төзүдә соңга калуның үз сәбәпләре бар. Шуларның иң мөһиме — китап палатасының мөстәкыйль учреждение буларак озаграк формалашуы. Аның биографиясе 1920 елда Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге каршында оештырылган библиография бүлегеннән башлана. Тиздән Татарстан дәүләт нәшрияты каршында яңа библиографик бүлек оештырыла, ә 1923 елда Татарстан Халык мәгарифе комиссариаты каршындагы Академүзәктә библиографик бюро ачыла. Бюро кыска гына вакыт эчендә 1917—1925 елларда чыккан татар китапларын туплау белән бергә аның регистрацион күрсәткечен төзү эшенә дә керешә. 1925 елның ахырында Татарстан Халык Комиссарлары Советы әлеге библиографик бюро нигезендә Татарстан дәүләт китап палатасы төзү турында карар кабул итә. Мөстәкыйль учреждение итеп танылса да, үз бинасы булмау һәм финанс яклары акрын хәл ителү сәбәпле, китап палатасы 1927 ел башыннан гына эшкә керешә. Әмма бу юлы да аерым учреждение сыйфатында түгел, ә Татар мәдәнияты йортының бер бүлеге булып кына оеша. Зур авырлыкларга карамастан, китап палатасы үз эшен тиз арада тәртипкә сала, уңышлы гына эшли башлый. Бер ел эчендә революциягә кадәр һәм аннан соң басылган 13 меңлек китап фонды туплый, башка өлкә һәм республикаларда чыга торган татарча басмаларны системалы рәвештә алып баруны җайга сала, 1925—1927 елларда чыккан татар китапларының исемлеген төзи. 1925 елда дөнья күргән басмалар турындагы белешмә басылып та чыга. Татар библиографиясен төзүгә җиң сызганып керешкән палата яңа үзгәрешләргә дучар була, — аны Үзәк Көнчыгыш китапханәсенә кушалар. Тиздән китап палатасы һәм Үзәк Көнчыгыш китапханәсенең төп фондыннан яңа, Академик китапханә оештырыла, китап палатасы чынлыкта эшләүдән туктый. Бу елларда китап продукциясен теркәү эше белән Татарстанны өйрәнү җәмгыяте һәм В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсе бераз шөгыльләнеп ала. 30 нчы елларның икенче яртысында Татарстан китап палатасы яңадан торгызыла. Ләкин бу вакытта аның китап фонды инде таркалган була, картотекалар бутала, китап палатасындагы хезмәткәрләр алышына... Китап елъязмаларын төзү эшенә яңабаштан тотынырга туры килә. Илебезгә фашистлар һөҗүме белән бу эш тагын тукталып кала.

Шул рәвешле, китап палатасының үткәненә кыскача гына күз салып алу бездә регистрацион библиографиянең артка калу сәбәпләрен ачык күрсәтә.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы беренче елларда китап палатасы агымдагы басмаларны исәпкә алу белән шөгыльләнә, 1946 елдан башлап даими рәвештә «Китап елъязма»ларын чыгарып килә. Ләкин элек чыккан китаплар библиографиясен төзү эшенә ныклап торып керешү мөмкинлеге булмый әле. Бөтенсоюз китап палатасы ярдәмендә Татарстан китап палатасы кадрлар белән ныгытылгач кына ретроспектив библиография төзү игътибар үзәгенә куела. 1973 елда шундый хезмәтләрнең беренчесе, 1941—1945 елларда Татарстанда чыккан китапларны теркәгән «Китап елъязмасы» дөнья күрде. 60 нчы еллардан башлап китап палатасы Октябрь революциясеннән алып Бөек Ватан сугышы елларына кадәр илебезнең төрле почмакларында чыккан татар китапларының ретроспектив библиографиясен төзү эшенә тотынган иде. Менә шул хезмәтнең 1917 елның ноябреннән 1929 елның ахырына кадәр чыккан татар китапларын эченә алган өлеше 1979 елның азагында басылып чыкты. «Татар китаплары. Библиографик күрсәткеч. I том» дигән бу белешмәне китап палатасы директоры Ә. Хисамова, библиографлары Ф. Сабитова һәм Р. Сафина төзегән. Белешмәдәге кереш сүздән күренгәнчә, хәзер китап палатасы 1930—1940 елларда чыккан татар китаплары турындагы икенче томын әзерли.

Белешмәнең беренче томында илебез-

нең төрле почмакларында чыккан 4089 татар китабы теркәлгән. Китаплар оригинал телендә библиографияләнгән, тасвирлана торган китапларның исемнәре рус теленә дә тәрҗемә итеп бирелгән. Бу елларда чыккан татар китаплары нигездә гарәп язуы белән басылган. Шуңа күрә аларның исемнәрен гамәлдәге графикада бирү — шактый катлаулы эш, һәм, әйтергә кирәк, төзүчеләр бу бурычны уңышлы башкарып чыкканнар.

Белешмәгә кертелгән китаплар аерым фән һәм темаларга бүлеп системалаштырылган. Меңләгән китапның, кайсы фән һәм темага каравын билгеләү өчен, төзүчеләр һәрбер басманың диярлек эчтәлеген ачыкларга тиеш булганнар. Гарәп шрифты белән басылган меңләгән китапның эчтәлеге белән танышу өчен зур көч һәм күп вакыт сарыф ителгән.

Белешмәдә китапларның библиографик тасвирлану һәм классификацияләнү дәрәҗәсе уңай тәэсир калдыра. Тик шуныһын гына искәртеп үтми мөмкин түгел: күп кенә китапларның кайсы типографиядә басылуы, яки кайсы оешма тарафыннан чыгарылуы турындагы мәгълүматлар тулысынча китерелмәгән. Ә бу мәгълүматлар матбагачылык тарихы өчен гаять әһәмиятле; рус телендәге китапларның ретроспектив библиографиясен төзегәндә, мәсәлән, әлеге мәсьәләгә бик нык игътибар ителә.

Ретроспектив библиография төзү — бик күп көч сорый торган хезмәт. Вакыт үткән саен элек басылган китапларны табу кыенлаша бара. Ә гражданнар сугышы елларында чыккан китапларның күпчелеге инде югалган, вакытында аларны китапханәләргә туплау эше белән шөгыльләнергә мөмкинлек тә булмаган. 1928 елларга кадәр рус булмаган халыклар телләрендә чыккан китапларны исәпкә алу ил күләмендә тәртипкә салынмаган булуын исәпкә алсак, татар басмаларын барлауның никадәр кыен булуы яхшы аңлашыла. Әлеге библиографик белешмәне төзүчеләр Казан дәүләт университеты, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы китапханәләрендә, В. И. Ленин исемендәге Татарстан АССР фәнни китапханәсе, В. И. Ленин исемендәге СССР дәүләт китапханәсе, Бөтенсоюз дәүләт китапханәсендә, Башкортстан китапханәләрендә саклanучы меңләгән басмаларны барлап, тикшереп чыкканнар. Сүз уңаенда әйтеп үтик, Ленинградтагы М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге публичный китапханә фондында саклanучы татар китаплары да барланса, белешмә тагын да тулырак чыккан булыр иде.

Төзүчеләр хезмәтнең кереш өлешендә 1917—1929 елларда чыккан барлык татар басмаларын барлап бетерә алмадык дип искәртеп үтәләр. Моңа, бер яктан, бигрәк тә 1917—1922 елларда чыккан басмаларның күбесе безнең көннәргә хәтле сакланмавы сәбәп булса, икенчедән, бу мораль яктан искергән дип, татар телендәге китапларның бер өлеше 30 нчы еллар башында юкка чыгарылуы белән дә бәйләнгән. Шуның өстенә, төзүчеләр китапханәләрдә сакланып калган барлык басмаларны да табып бетерә алмаганнар. Мәсәлән, Совет властеның беренче декретлары «Җир турында декрет», «Солых турында» декрет басмалары белешмәдә күренми. Алар 1918 ел башында Петроградта татар телендә 100 әр мең тираж белән басылган, хәзер Бөтенсоюз китап палатасында саклана. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе чыгарган китапларның дистәгә якыны шулай ук белешмәгә кермәгән. Һәрхәлдә, төзүчеләрнең белешмәне тагын да тулырак итү өчен бөтен мөмкинлекләрне файдаланып бетерә алмаганлыклары күренеп тора.

Инде әйтеп үтелгәнчә, библиографиягә 4089 басма теркәлгән. Югарыда китерелгән фактлар 1917—1929 елларда чыккан татар китапларының бу сан белән генә чикләнмәгәнен раслый. Илебез тарихының иң авыр елларында да татар матбугатчылыгының шактый зур масштаблар белән үсеп күрәбез. Бу чорда һәр елны уртача 340 лап исемдә 1 миллион 600 мең данә китап чыгып килгән. Илебездә китап басуның торышы турындагы төрле хезмәтләрдә, әлеге елларда татарча китап басу сан ягыннан рус һәм украин телендәге басмалардан гына калышкан, дип искә алына.

Татар телендә совет матбугатына В. И. Ленин да зур әһәмият биргән. Октябрь революциясенең беренче көннәреннән үк татарлар яши торган төбәкләрдә татар совет матбагачылыгы оештырыла, аерым фронтларда татар телендә төрле листовкалар, брошюралар басу җайга салына. Белешмәдән күренгәнчә, 1917—1929 елларда татар телендә китап басу Казан, Мәскәү, Уфада дәвам итә, шуның өстенә Петроград, Самара, Астрахань, Саратов, Екатеринбург (Свердловск), Сембер (Ульяновск), Новосибирск, Томск, Чиләбе, Троицк, Вятка, Стәрлетамак, һ. б. шәһәрләрдә дистәләгән татар китаплары басылып килә. Күп кенә төбәкләрдә татар телендә китап басу Октябрь революциясеннән соң гына башланып китә.

1917—1929 елларда чыккан басмаларның эчтәлеген, тематикасын тикшереп чыгу үзе бер зур хезмәт таләп итәр иде. Без шуны гына күрсәтеп үтәбез: Совет властеның беренче елларында татар телендәге китапларның төп эчтәлеге социалистик революция җиңүләрен яклау, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү, совет хөкүмәте көн тәртибенә куйган бурычларны аңлату, халык хуҗалыгын торгызу кебек темаларны яктыртуга багышланган. Бу елларда В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итеп бастыруга, марксизм-ленинизм тәгълиматын пропагандалаучы әсәрләргә зур урын бирелә. Китап репертуары эчтәлегеннән күренгәнчә, татар совет китабы партия һәм совет органнарының актив ярдәмчесе, пропагандисты ролен үтәгән. Шул ук вакытта дәреслекләр, уку әсбаплары төрле фәнни-популяр, практик китаплар да күп басылган. Бу чордагы басмалар үзләренең эчтәлеге ягыннан күп кырлы, киң тематикалы булулары белән аерылып торалар. Китап репертуарының шактый зур өлешен матур әдәбият әсәрләре, тел һәм әдәбият белеме буенча чыккан басмалар тәшкил итә.

Физика, математика, химия, табигать бе-

леме фәннәре буенча басмаларның күбесе рус теленнән тәрҗемә ителгән, татар авторлары тарафыннан язылганнары да аз түгел. Шунысы кызыклы, марксизм-ленинизм тәгълиматы, партия һәм совет төзелеше, юридик фәннәр, авыл хуҗалыгы, медицина, тарих буенча басмалар арасында авторларның күпчелеге татар зыялылары.

Бу белешмәнең дөньяга чыгуы, басма мирасыбызны барлау юлында зур уңыш булу белән бергә, халкыбызның культура үсешен күрсәткән елъязма да булып тора. Ул киң катлау укучылар, галимнәр, студентлар, китапханәләр өчен кыйммәтле белешмә.

Библиографик күрсәткечнең укучылар өчен тагын бер уңай ягы — аның каталог формасында эшләнүендә, ягъни, анда, китапларның тасвирламалары белән бер рәттән, һәр китапның кайсы китапханәдә һәм нинди шифр астында саклануы турында мәгълүматлар да китерелгән.

Билгеле булганча, Татарстан китап палатасы алдында бөтен татар китабы репертуарын эченә алган күрсәткеч төзү бурычы тора. Инде укучы 1930—1940 елларда чыккан басмаларга багышланган белешмә чыгуын көтә. Шуның белән совет чорында басылган татар китапларын барлау, нигездә, тәмам булачак. Революциягә кадәр чыккан басмалар турындагы белешмә дә зур игътибар һәм фәнни төгәллек белән әзерләнсен иде.

**ӘБРАР КӘРИМУЛЛИН,**
**филология фәннәре докторы.**

# ОЧЛЫ КҮЗ, ҮТКЕН СҮЗ

Китапның тышлыгында — айлы төн рәсемнәре, бер битен ачтың исә — дусларча шарж... Һәммәсе «Чаян» рухындагы көлү булачагын вәгъдә итеп тора. Тагын бер битен ачасың — юморист үзе «күзгә карап» сүзен башлый: «Үзем турында үзем» дип, кем булуын аңлата. Бу «биографиянең» кызык бер хикәят булуын күреп, китапның эчендә тагын да шәп нәрсәләр бардыр әле, дип өметләнеп куясың.

Ике йөз битле китапта 71 юмористик хикәя һәм 8 диалог бар. Автор «күзгә карап»[1], юморга хас булганча, үз итеп көлә. Үз итеп көлсә дә, оялтырлык, кызартырлык көлү бу.

Ф. Шәфигуллин, гомумән, җор табигатьле, каләме белән ут уйнатырга сәләтле язучы. Ул кирәк булганда күкләргә аша, гайре табигый чагыштырулар, күчешләр ясый, бер үк вакытта реаль җирлектә тора, табигый халәтендә кала, ышандыра. Көлә белеп көлү өчен болар бик мөһим сыйфатлар.

Үзенчәлекле эмоциональ тәнкыйть формасы — көлү — комик конфликт нигезендә туа. Комик конфликт үзе вак каршылыклардан — көлке детальләрдән төзелә. Нәкъ менә шул детальләрне бирүдә оттырмаганда гына төп көлү максатына ирешергә мөмкин. Безнеңчә, Ф. Шәфигуллин юморы әлегә киртәне бик җиңел үтә. Әлбәттә, мондый өлгерлек язучының тормыш тәҗрибәсе һәм рухи байлыгы белән нык бәйләнгән.

Китапта беренче хикәя булып килгән «Көмеш лампа»га игътибар итик. Армиядән кайткан егет сөйгән кызының әтисе янына бара. Исәбе — өйләнү ниятен белдерергә. «Ләкин Әбугалинең Сабир картка әйтeләчәк сүзләре поселок читендәге биек капкалы йортка якынлашкан саен азая барды, һәм, капканы шыңгырдатып ачып, каршысында себерке сабына таянып торган усал йөзле Сабир картны күргәч, бөтенләй юкка чыкты.

Сабир картның йөзенә чыккан усаллык гади усаллык кына түгел, ә бәлки кешене кимсетә, үрти, мәсхәрәле торган усаллык иде. Кысылган күзләрен күр син аның! Берсе — ноктага, икенчесе өтергә охшаган.

Күзне-күзгә терәшеп байтак торганнан соң, ниһаять, Әбугали:

— Сабир абзый, — дип мыгырданды да, колак очларына кадәр кызарып, янә сүзсез калды.

— Нучтуж? — дип кукрәде Сабир карт. Читән казыгы кадәр генә гәүдәдән шундый калын тавыш чыккач, Әбугали, дерт итеп, артка тайпылды».

Әсәрдән өзеп алыну сәбәпле, көлү уйнаклавы беркадәр сүрелсә дә, биредә авторның юмористик характерлар иҗат итүдәге осталыгын сизми мөмкин түгел. Менә дигән батыр Әбугали кызның әтисе каршында калтырап тора. Халыкның гореф-гадәтләре кушканча, Сабир карт та горур кылана, эшне бик коры тоткандай итә. Шунысына игътибар итик, биредә ник бер кирәкмәгән деталь булсын да, ник бер урынсыз сүз әйтелсен. Персонажларның сөйләме, образлылык, сюжет-композиция мәсьәләләре ягыннан карасак та, авторның көлү максатын истә тотып, уйлап эш итүен күрербез.

Әсәрдә интонацияләр үзгәреп тора. Менә инде Әбугали «горурланып» күрсәтә, «нучтуж» дип кем булуын сиздерә. Аннары тагын яңалык — Сабир карт йомшый. Ул да усал кеше түгел икән.

«— Сабир абзый!

— Әү, энем!..

— Сөйләшеп утырыйк әле бер, Сабир абзый.

— Нучтуж, энем, мин риза. Толковый егетләрне яратам мин. Тик кайда сөйләшербез икән?.. Бәлкем, безгә кайтып утырырбыз?! Анау гына безнең йорт, какраз чәй дә кайнаган булырга тиеш...»

Менә бит нинди кешеләр икән болар... Кем әйтмәс боларны бүгенге безнең картлар, безнең егетләр, замандашлар дип. Бөтен шуклыклары, җорлыклары белән «бизәп» бирә автор аларны.

---

[1] Шәфигуллин. Күзгә карап. Юмористик хикәяләр. Казан. 1979.

Китаптагы бик күп хикәяләр мәхәббәт темасына карыйлар. Әмма тематиканың шундый беркадәр авышлыгы сизелми диярлек: автор аны тормышның бик күп башка яклары белән бәйләнештә ача. Автор мәхәббәт мөнәсәбәтләре аша, замандашларыбызның гына түгел, үткән буын кешеләренең дә характерларын, рухи дөньяларын бирергә омтыла. Бу яктан «Сафура, Бәкер һәм трактор» хикәясе аерым игътибарга лаек. Ул эпистоляр алымда язылган, геройлар хатлары аша ачылалар.

Тракторын хатынына калдырып, Бәкер сугышка киткән. Ул җир эшеннән ирексез аерылырга мәҗбүр, шуңа күрә уенда һаман да тракторы, «свичәләре». Крестьяннарча эшлекле яшәргә күнеккән бу гашыйкларның хатлары да бик үзенчәлекле: балы-борычы бергә. Болар чынлыкта гаять самими, чын күңелдән сөя белүче батыр кешеләр. Тыштан бераз дуамал, иркитмәгән булып күренү аларның характерына юмористик нур өсти:

«Сагынганга чыдый алмыйча яза икән дип уйлама, җен хатыны, әле берникадәр вакыт чолганышта калып, немецлар белән кетикети уйнап йөрдек. Үзебезнең якка чыккан да бер аягым снаряд кыйпылчыгына бәрелде. Госпитальдә ятып чыктым.

Соңгы көннәрдә борчу басты. Трактор ни хәлдә? Кичә төшемдә бригадир Хөрмәтшаны күрдем: «Трактор хәтле тракторны хатын-кызга ышанып тапшыралармы соң?! Чәч озын, акыл кыска бит аларның», — ди. Ну, кара аны, Сафура, тракторны алай-болай эшләтсәң, кайткач рәхим-шәфкать көтмә миннән! Рәтле генә йөрт. Ремонтлаганда карбюратор белән магнетосына бригадирдан башка орынма»...

Мондый хатларга җавап итеп, Сафура болай яза:

«Сугышуыңны бел! Юк акылың белән кешегә акыл өйрәтеп маташма. «Трактор начар тарта, трактор керосинны күп бетерә», дип зарлануларың исеңдәме? Карбюратор белән магнетоны көйли белмәгәнсең икән шул, җан кисәгем. Трактор сәгать кебек эшли хәзер. Берьюлы ике сабан тагып йөрим!..»

Әйтерсең, чаршау аша гына әйткәләшәләр... Сугыш елларын кичергән кешеләр бик тиз сизәчәк боларның тел төбен. Эчләрендә ут янса да, әнә шулай бер-берсенең күңелен күтәрәләр, бер-берсенең хәленә кереп язалар. Монда ясалмалыкның комизм максатында көчәйтелүен язучы осталыгының бер билгесе буларак бәяләми мөмкин түгел. Башка күп кенә хикәяләрендәге кебек, автор биредә дә публицистик пафосны саклый, үзенең гражданлык сүзен ишетелерлек итеп әйтә, гади генә штрихлар белән совет кешеләренең кызыклы һәм матур рухи сыйфатларын ача.

Дөньяда мәхәббәтнең дә төрлесе бар бит әле. Менә шуларның берсе: «Аерылыштык. Хатын китте. Йокы бүлмәсендә яши. Мин асылынырга бау әзерләп куйдым. Менә әйберләрне бүлешеп бетерәбез дә тәвәккәллим. Суд бүлешкән өчен акча ала, ди. Судсыз гына бүләбез әйберләрне...» («Аерылышу»).

Игътибар итсәк — күрәбез: юморист тагын мәхәббәт турында гына сөйләми икән ләбаса. Әнә берәү... «бау әзерләп куйдым», ди, Ай-чай, «тәвәккәллим» микән бу бәндә, Әйберләр нигә ди аңа теге дөньяда?! Биредә Ф. Шәфигуллин интригалы башламнан уңышлы файдалана: «Аерылыштык (нинди кызганыч хәл!). Хатын китте (ник китте икән?). Йокы бүлмәсендә яши (нәрсә?! Киткән икән җәһәннәмнең артына!)... Кыю арттырулар, көчәйтүләр һәм диспропорцияләр ярдәмендә Ф. Шәфигуллин нәкъ менә шундый гарип күренешләрнең асылын ачып бирә («Җан Али», «Романтика», «Каравылчы», «Әкеринче — кубызчы» һ. б.).

Көлүче юмор объектыннан һәрьяклап югары торырга тиеш дигән закончалык язучы каләме өчен дә мәҗбүри. Ул авторның көлдерергә тырышуын, көчәнүен дә гафу итми. Очлы күз, үткен сүз, үткен акыл, үткен фикер булсын!

«Көзгә карап» китабындагы көлдерми торган кайбер әсәрләрдә авторның әнә шул таләпне үтәп бетерә алмаганлыгы күренеп китә. Төрле хикәяләрдән алынган мондый җөмләләргә игътибар итик: «Галләм шаркылдап көлеп җибәрде». «Кичәдән бирле колагымны тондырып бетергән торба ягына карагач, көләргә тиеш булмасам да, көлеп җибәрдем: баскыч астындагы торбаның бер ягында маңгае күпергән Илсур мүкәләп йөри, ә икенче ягында күреге тишелгән аккордеон тәгәрәп ята иде». Шул рәвешле, «көлү» сүзе «болай гына» әйтелсә дә, авторның укучыны көлдерергә тырышуын сиздереп бара. Тырышу сизелдеме — укучыны көлдерермен димә.

Юмор һәм сатира кыскалыкны ярата. Бу китаптагы әсәрләрнең бик күбесе аз сүзле, әмма бай эмоциональ бизәкле. Мондый текстларда «юл аралары» хисләр, фикерләр белән тулы; алар укучы хыялына киң мәйдан бирәләр. Моны китапка аерым бүлек кертелгән «диалоглар» да раслап тора:

«— Мунчага барасыңмы? — Эһе. — Ә себеркең кая? — Юк. — Нәрсә белән чабынасың? — Чабынмыйм. — Чабынмагач, мунчага баралар димени?! — Бәйләнмәсәнә. — Каен урманы аша үтеп барасың, себерке сындырырга иренәсең...»

Кыскалыкның тагын бер отышлы мисалы итеп «Айлы төндә кызлар белән» дигән диалогны күрсәтергә мөмкин. Автор аны «җиде паузалы трагикәмит» дип тәкъдим итә. Сәхнә әсәре рәвешендә язылган бу «трагикәмит» ике биткә сыйган. Аны укыгач, уйланып куясың: ник әле бу «паузалар»ның авторы бүгенге көнгә водевильләр, музыкаль комедияләр, сәхнә өчен менә дигән сатирик әсәрләр бирми түзеп ята?

Җыентыктагы хикәяләр, диалоглар, берберсен тулыландырып, төрле-төрле типлары, характерлары белән истә калалар. Тулаем алганда, Ф. Шәфигуллинның бу китабы татар әдәбиятында юморның активлашуын, кыюлануын, замандашларыбыз күңеленең тагын да тирәнрәк катламнарын ачарга омтылуын күрсәтә.

**Назыйм ХАНЗАФАРОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**СИБГАТ ХӘКИМ. ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ — ШАГЫЙРЬ ЯЗМЫШЫ.** Әдәби-публицистик мәкаләләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

Сибгат Хәким — барыннан да элек шагыйрь, тирән хисләр, катлаулы кичерешләр дөньясына чумган шагыйрь. Шагыйрьлек аның мәкаләләрендәге бер үзенчәлек булып та сокландыра. Аларның һәркайсы диярлек шигъри күренешләр, образлы фикерләү, тирән хисләр дөньясыннан үсеп чыккан кебек. Чөнки безнең алда — шагыйрь уйланулары, проза теле белән әйтелгән шигъри фикерләр.

С. Хәким китабының эчтәлеге бик бай һәм катлаулы. Анда милли поэзиябез, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйле күп төрле һәм җитди мәсьәләләр күтәрелә. Китаптагы унөч бүлекнең һәркайсында зур темаларга багышланган мәкалә-язмалар урнаштырылган.

Композицион яктан да китап уңышлы төзелгән. С. Хәким — бөек Ленинга багышланган поэмалар, шигырьләр, җырлар авторы. Ленин темасы аның поэзиясенең үзәгендә тора, иҗатының проблематикасын, идеятематик юнәлешләрен билгели. Шуңа күрә шагыйрьнең әдәби-публицистик мәкаләләре җыентыгы да Ленин темасы белән ачылуы бик табигый. Автор «Жирнең иң бөек төшеннән», «Данлы як, бәхетле як», «Мин Ленинның язмаларын укыйм» дип исемләнгән мәкаләләрендә әдип Ленин темасының зурлыгы, тирәнлеге хакында уйлана, үз иҗатында бу теманың ничек ачылуы турында яза.

С. Хәкимнең беренче ике китабы — «Пар ат» һәм «Шагыйрьнең балачагы» Бөек Ватан сугышына кадәр басылып чыга. Билгеле булганча, бу поэмаларның икесе дә Г. Тукайга багышланган. Тукай темасына шагыйрь әдәби-тәнкыйть мәкаләләрендә дә әйләнеп кайта. Алар китапның икенче бүлегендә урын алганнар. Җыентык та шул ук бүлекнең бик мәгънәле исеме белән — «Халык язмышы — шагыйрь язмышы» дип аталган.

«Поэзиядә Тукай кебек, Җәлил кебек юлында мәңге янып торган исемнәр кирәк». — Бүгенге әдәбиятка аксакал әдип әнә шундый таләп куя. Шуңа күрә ул М. Җәлилнең батырлыгы «Моабит дәфтәрләре»ндә гаять югары дәрәҗәгә күтәрелгән шигъри осталыгы хакында да дулкынланып яза. Китаптагы мәкаләләрнең барысын да берләштергән лейтмотив — татар поэзиясенең казанышлары белән горурлык хисе — бередә үзенең иң югары ноктасына күтәрелә: «Мин горур, Муса Җәлил Берлинның «Дуслык йорты»нда дөнья әдәбиятының даһилары булган Гете, Шиллер, Һейнелар арасында утыра», дип яза С. Хәким.

Шагыйрь татар поэзиясенең бүгенге хәле, төп үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре, шигъри осталык, туган тел һәм аның поэтик мөмкинлекләре, классик әдипләр һәм бүгенге шагыйрьләр өчен халык иҗатының роле кебек зур һәм катлаулы мәсьәләләр күтәрә.

«Күңелдән юылмаган эзләр» дип исемләнгән бүлеккә аерым тукталып үтәсе килә. Бередә урын алган материалларның барысын бергә шагыйрь үзе «эзләнү-уйланулар, кыска-кыска язмалар» дип атый. Чыннан да, бүлек махсус исемнәр белән аталган аерым язмалардан тора һәм шагыйрьнең сугышта үткән юлын күз алдына китерә. Монда кайнар публицистика белән сугарылган язмалар да («Сугышның бер көне», «Сугышның дүрт елы...»), моңсу истәлекләр дә («Туй»), үзәк өзгеч күренешләрне сурәтләгән парчалар да («Кунак») бар. Аларның кайберсе үзеннән-үзе шигырьгә, поэзиягә атлыгып тора кебек. Кайбер өзекләр исә шагыйрьнең аерым әсәрләрен, аларның тормышчан нигезен тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Мәсәлән, «Сары капкалы йорт» поэмасы героеның прототибын, «Фронтта беренче көн», «Ржев читендә», «Урман җуйган иске матурлыгын» һ. б. ш. шигырьләрне...

Бер карасаң, бу бүлек җыентыкның гомуми янгырашына, стиленә сыеп бетми кебек. Анда «мәкалә» дип аерып алырдай язмалар юк дәрәҗәсендә... Шулай да бу истәлек-уйлануларын язып, шагыйрь тирән хөрмәткә лаек эш башкарган. Алар поэзиянең көндәлек тормыш белән бәйләнеше, әдәби хәрәкәт, шагыйрьнең иҗат лабораториясе турында мәгълүматыбызны арттыралар, карашыбызны киңәйтәләр.

С. Хәкимнең тәнкыйтьче буларак осталыгы хакында да берничә сүз әйтеп үтәргә кирәк.

Аерым мәкаләләр композицион яктан да шигъри әсәрләрне хәтерләтәләр. Әйтик, «Җирнең иң бөек төшеннән» мәкаләсе Ленино-Кокушкино музеендагы уйланулардан башлана да, татар халкы, бөтен совет

халкы язмышына, дөньякүләм иҗтимагый-политик проблемаларга күчә. Сүзне зур булмаган бер күренештән башлап, тирәнәйтеп, киңәйтеп җибәрү — поэзиядә генә түгел, әдәби тәнкыйтьтә дә, җөмләдән, С. Хәким мәкаләләрендә дә күптән урнашкан уңышлы алым. Ә кайбер язмаларда шигырьгә хас формаль сыйфатлар да (мәсәлән, деталь-мотивлар) күзгә бәрелеп тора.

Шагыйрь аерым әдипләрнең иҗатына, характерына, эш стиленә хас һәм бер тапкыр укыгач та хәтердә калырдай детальләрне бик оста куллана. Тарас Шевченко турында, мәсәлән, ул болай ди: «Шевченко бөтенләе белән моңнан гыйбарәт». Муса Җәлил турында: «Ягымлы, бераз каударлана, күзендә терекөмеш гел җемелдәп тора...» — дип яза. Бер җөмләдә Хәсән Туфанга мондый характеристика бирә: «Куен дәфтәрен, яшел каралы авторучкасын чыгарып, җыелышта, хәтта мунча ишеге төбендәге урындыкта, мәҗлесләрдә гел нәрсәдер язып утыручы фанатик Туфан...»

Мәкаләләрнең исемнәре дә тирән мәгънәле тәгъбирләр, афористик җөмләләр белән аталган: «Шигърияткә — чәчәкләр», «Күңелдән юылмаган эзләр», «Камай чишмәсенең суы җырлата», «Моң барында шагыйрь бетми...» Кайбер мәкаләләрнең төп мәгънәсе, төп идеяләре әнә шундый тирән мәгънәле афоризмнарга йөкләтелгән кебек. Ә инде шагыйрьнең түбәндәге сүзләре бүгенге поэзия турындагы уйлануларына бер сәземтә булып аңлашыла: «Шагыйрь кеше күңеленә юл эзли. Төрле шагыйрь төрлечә эзли. Берәүләр йомгак итеп тәгәрәтә ул юлны. Муса Җәлил шул йомгак буенча барырга кушкан».

Йомгаклап әйткәндә, Сибгат Хәкимнең «Халык язмышы — шагыйрь язмышы» китабын язучылар һәм әдәбият белгечләре генә түгел, киң катлау укучылар да зур кызыксыну белән каршы алгандыр дип уйларга нигез бар.

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ.**

---

**РАДИК ФӘИЗОВ. ЮЛДА.** Хикәяләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

---

Яшь ана биләүсәгә төргән нарасыен йоклата. Сипкеле дә кайтып бетмәгән йөзендә уйчан елмаю, күзләрендә — ниндидер бер сагаю, хәвефләнү бар. Ишегалдында уйнаган малайлар тупны югары чөеп, аның баласы өстенә төшермәсләрме? Әнә теге шаян кызчык ком сибеп, бәбкәсенең күзенә ялгыш кертсә?!

Тормышның үзе кебек барысы да бик гади һәм барысы да бик катлаулы... Дөнья ул кискен, конфликтлы мәлләрдән генә тормый, аның гадәти көннәре, гадәти кешеләре күбрәктер дә әле. Һәм бу чынлыкны йөгерек тасвир, бер күз салу белән генә күрсәтә-аңлата алмыйсың. Шуңа күрә Радик Фәизов ашыкмый-кабаланмый, тәфсилләп яза. Кайбер очракларда ялыктыра төшсә дә, мондый басынкылык, җентекләү барысын да төптән, төрле яктан уйлап карарга, кешеләрне һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләрне төрле бизмәнгә салып үлчәргә мөмкинлек бирә.

...Егерме ел колхозда председательлек иткән Мәрдән җиде төн уртасында уянып, үз-үзен хөкем итеп утыра. Тәҗрибә дә зур, җегәр дә бар әле. Әмма «кулын маңгай өстенә куеп гел киләчәкне күзәткән» Мәрдән — юк! Аның күңелен, рухи картаю шушы микәнни, дигән пошыну били... Биредә ниндидер гайре табигый вакыйга да сурәтләнмәгән, мәгәр ул булса да, хикәя билгеле бер вакыт һәм хәрәкәт кысаларында гына калмас иде, аның хикмәте— күп мәгънәле детальләрдә, кызыклы характерда. Ялангач ботагы белән өй почмагын тырмап утырган каен да тынгы бирми Мәрдәнгә. «Иртәгә үк чабып төшерергә кирәк ул ботакны!» Ләкин тормышта бер селтәнү белән генә барысы да хәл ителми. Картаеп килүче председательнең янында уйнаган давыл да, якыннанрак карасаң, шундый каршылыклар өермәсе бит. Аны җиңел генә таратып-тынычландырып буламы соң? Шуңа күрә эченнән тынарга мәҗбүр Мәрдән, килешергә мәҗбүр: «Кисмәскә ул ботакны, тора бирсен. Аннан гына өй почмагы таралып төшмәс әле...» Хикәядә вәгазь, үгет-нәсыйхәт юк, язучы тормышта үз урыныңны табуның, яшәү мәгънәсенә төшенүнең җиңел булмавын искәртә, шул рәвешле, безне кеше һәм аның тормыш юлы турында уйлануларга алып керә.

Юл образы китапта туры мәгънәсендә дә, символик төшенчә буларак та кабатланып килә. Балалар ерак юлга чыгып, зурлар дөньясының сәер тарафларына күз салалар («Әбигә, кунакка»). Партком секретаре райкомга барганда үзенең һәм башка кешеләрнең тормыш-яшәеш принциплары турындагы уйлары белән күзгә-күз кала («Юлда»). Хезмәт юлына аяк басып кына килгән яшь эшченең ялгышуында тәҗрибәле мастерның кешеләргә булган ышанычы сынала («Үпкә»). Ләкин бу очракларда да хикәянең мәгънәсе ниндидер вакыйгага, фактка гына кайтып калмый, язучы һәр сүзнең, хәрәкәтнең, гамәлнең эчке мәгънәсен табарга омтыла. Ул кешенең зур күңел дөньясын гади һәм табигый сурәтләве белән ышандыра. «Авылым хатлары»н укыганда, бу үзенчәлеккә аеруча игътибар итәсең. Бер-ике штрих белән генә тасвирланган аерым кешеләр аша халыкның рухи хәзинәсе, яшәүчән нигезе ачыла.

Шул ук вакытта арабызда тормышның кадерен белмәүче, матурлыгын күрмәүчеләр дә очрап куя бит. Язучы күңелен аларның язмышы сыкрандыра һәм әлеге борчылу-сыкрану мотивы хикәядән хикәягә күчеп бара.

Әлбәттә, китаптагы барлык хикәяләрнең дә «йөзе килеп» бетмәгән әле. Бигрәк тә тискәре геройларны берьяклырак тасвирлау үзен сиздерә: еш кына аларның эш-хәрәкәтләре психологик яктан нигезләнеп җитмәгән. Әмма «бик кодрәтле, усал хатын» Гатуфә апа, «чуар

йөрәкле», мыштым «Зәхмәтулла»лар ачык дәлил: укучының хәтерендә калырлык җанлы образлар иҗат итәргә көче-мөмкинлеге бар язучының. Ул инде үз юлын табып килә. Ә юлның дәвамы булырга тиеш. Яңа үрләргә илтүче дәвамы.

**ӘНВӘР ХУҖИӘХМӘТОВ.**

●

**И. Г. ГИЗЗАТУЛЛИН. ЗАЩИЩАЯ ЗАВОЕВАНИЯ ОКТЯБРЯ.** М., «Наука», 1979.

1918 елның язында, интервентлар һәм аквардиячеләргә каршы аяусыз сугышлар башлангач, регуляр Кызыл Армия төзү һәм революция дошманнарын тармар итү максатларында күп кенә хәрби учреждениеләр төзелә. Алар арасында Үзәк мөселман хәрби коллегиясе дә була. Коллегия Үзәк мөселман комиссариатының хәрби бүлеге нигезендә 1918 елның 31 маенда оештырыла. Аның председателе итеп күренекле татар революционеры Муллanур Вахитов билгеләнә.

Үзәк мөселман хәрби коллегиясе гражданнар сугышына багышланган китапларның күбесендә искә алына. Ләкин И. Гыйззәтуллин монографиясе — әлеге коллегиянең төзелү тарихын һәм эшчәнлеген бөтен нечкәлекләре белән тикшергән, гомумиләштергән беренче хезмәт.

Китап ике бүлектән тора. Аның беренче бүлеге Кызыл Армиянең милли гаскәри частьларын төзү һәм аңа житәкче кадрлар әзерләү буенча Үзәк мөселман хәрби коллегиясе алып барган эшкә, икенчесе Үзәк коллегиянең политик-агарту эшчәнлегенә багышланган. Документаль чыганакларны яхшы белү һәм тикшеренү темасына кагылышлы әдәбиятны җентекләп анализлау авторга кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек биргән.

Үзәк мөселман хәрби коллегиясе 1918 — 1920 елларда башта Мәскәүдә, аннан Казанда эшли. Гражданнар сугышы барышында аның штаты арта, структурасы ачыклана. Автор коллегиядә политбүлек начальнигы булып эшләгән Камил Якубов, язучы-комиссар Шамил Усмановлар турында яңа, кызыклы мәгълүматлар китерә. Ул елларда коллегия эшендә актив катнашкан башка кешеләр турында да җентекләбрәк сөйләнсә, әлбәттә, тагын да яхшырак булыр иде. Коллегия эшендә актив катнашкан А. Маликов, мәсәлән, күренекле хәрби хезмәткәр булып җитешә. Совет дипломаты һәм язучы Н. Равич үзенең истәлекләр китабында аның турында болай дип яза: «1924 елда А. Маликов Кызыл Байраклы Аерым Кавказ армиясе штабының дүртенче бүлеге начальнигы итеп билгеләнде. Ул Төркияне бик яхшы белә, төрекчә бик чиста сөйләшә, укый һәм яза, чик буендагы һәр ноктаны картага карамыйча да әйтеп бирә ала иде».

Үзәк коллегиянең Кызыл Армия өчен милли частьлар төзүдәге роле аеруча зур. 1918 елның февраль ахырында ук М. Вахитов рус һәм татар газеталары аша «мөселман социалистик армиясенең кызыл әләмнәре астына» чакыру белән чыга. 1918 елның маенда Казанда Нурмөхәммәт Алимов командалыгында беренче социалистик мөселман полкы оештырыла. Озак та үтми, татар хәрби подразделениеләре Совет власте дошманнары белән көрәштә шөһрәт казаналар. Казанны аквардиячеләрдән һәм акчехлардан саклаганда зур батырлыклар күрсәтәләр, татар батальоннары һәркайда тәртипле һәм куркусыз булулары белән аерылып торалар.

Үзәк коллегия Ю. Ибраһимов, М. Крымов, Х. Мәүлетов, Я. Чанышев кебек күп кенә элекке татар офицерларын Кызыл Армиягә хезмәткә тарта һәм, шуның белән бергәттән, Мәскәүдә һәм Казанда мөселман хәрбиләрен әзерләү буенча курслар ача, яңа төзелгән милли частьларда, шулай ук халык арасында эшләү өчен политработниклар әзерли.

Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политик-агарту эшчәнлеге политик, хәрби-агитацион әдәбият, дәреслекләр һәм газеталар бастырып чыгарудан, кызылармиячеләр арасында укыйяза белмәүчелекне бетерү өчен көрәшүдән һәм аларга культура хезмәте күрсәтүне оештырудан гыйбарәт иде, дип билгеләп үтә автор һәм коллегиянең бу юнәлештәге хезмәтләренә җентекләп туктала. Әлеге эшчәнлекнең нинди нәтиҗәләр бирүе дә кыцрак яктыртылган булса, хезмәт тагын да тулырак төс алыр иде.

Тулаем алганда, И. Гыйззәтуллин татар халкының революция казанышларын саклауга керткән зур өлеше, туган ягыбызда ленинчыл милли политиканың гамәлгә ашырылуы турында кирәкле, кызыклы китап язган.

**А. Л. ЛИТВИН,**
**тарих фәннәре докторы, профессор.**

●

**ШАМИЛ МАННАПОВ. ЭТИ УРМАНЫ.** Нәсерләр, парчалар, хикәяләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

Шамил Маннапов — әдәбиятка тормыш тәҗрибәсен шактый туплап килгән автор. Солдат хезмәте, университет, партия югары мәктәбе, журналистлык. Тормышка үз карашыңны булдыру һәм кешеләргә үз фикереңне белдерү өчен «университет»ларның һәртөрлесе дә файдалы.

Шунысы характерлы, соңгы елларда Шамил иҗади эзләнүләрен ике юнәлештә алып бара башлады. Беренчесе аның өчен шактый таныш өлкәдә — поэзиядә булса, икенчесе — кешедән өлгергәнлек, характерның ныгуын таләп итә торган проза өлкәсендә.

Әйе, проза әсәре язар өчен күңелнең бер талпынып алуы гына җитми. Хикәяче вакыйгаларның «мөгезеннән» эләктереп ала белергә һәм вакыйгалар агышында, характерлар бәрелешендә тормыш фәлсәфәсе-

нең бер үзенчәлекле ягын ачарга тиеш.

Ш. Маннаповның «Әти урманы» дип исемләнгән җыентыгына кергән хикәяләр әнә шундый таләпләрне истә тотып иҗат ителгән. Биредә иң элек кыскалыкка, төгәллеккә омтылу күзгә ташлана. Әсәрләрнең күләмендә генә түгел, сюжет җыйнаклыгында һәм фикер ачыклыгында да чагылган бу кыскалык язучының яшен яктысыдай мизгел эчендә укучы күңеленә эстетик ләззәт бирү, укучы аңында тетрәнү яки гаҗәпләнү, соклану яки нәфрәтләнү уяту максаты белән бәйләнгән. Җыентыкны сөйләмнең образлылыгына ирешергә тырышу да бизи. Урынлы китерелгән чагыштыру фикергә үзе бер сафлык өсти: «Безнең якта җир ябага коя башлау белән җитә «Сабан туе», яки: «Рәсәй җире, улым, безнең халык күңеле кебек бит ул, аз гына кагылдыңмы, чишмә булып ургый...» Миңа калса, Шамилнең китапка кергән иң уңышлы әсәрләреннән берсен — «Ялвару» дип исемләнгән нәсерне — чәчмә рәвештә язылган шигырь дияргә мөмкин.

Дөрес, һәр очракта да автор сүзләр белән, тел белән оста эш итә дип булмый әле. Персонажлар теленә ят булган җөмләләр, кытыршылыклар очраштыргалап куя. Бу чатаклыклар хикәяләрнең ышандыру көчен киметә. «Тәмле куллы апа» хикәясендә, мәсәлән, «Аның кояшта янган куллары ипине шундый оста әйләндерә ки, циркттагы жонглер да алай булдыра алмас», дигән җөмлә бар. Сугыш чорындагы авыл баласының «циркттагы жонглер» белән чагыштыруы урынсыз яңгырый. Мондый мисалларны тагын китереп булыр иде.

Беренче хикәяләр җыентыгы белән автор нинди мәсьәләләр күтәрә соң?

Дөресен әйтергә кирәк, хикәяләрнең күпчелеге күңелдә әйбәт тәэсир калдыра. Мәсәлән, «Тәмле куллы апа» хикәясенең сөземтәсен, бер сүз белән, яхшылыкка — яхшылык дип атарга мөмкин. Безнең халыкта ипи гомер-гомергә иң олы байлык саналган. «Ризыктан зур булма», ди ул. Кайчандыр Сәгъдия апа (әлеге хикәянең герое) пешергән ипигә сокланып-кызыгып караган, сирәк-мирәк булса да шул ипинең тәмен татыган малайлар үскәч игенче булалар һәм Сәгъдия апаларына күчтәнәч итеп үзләре иккән ипине алып киләләр. Шушы хәл образларның җанлылыгын һәм кешелеклелеген тагын да көчәйтеп җибәрә.

«Кибән башы» әсәре дә икмәккә, игелеклелеккә мәдхия булу ягыннан әлеге хикәягә аваздаш. Ул кайбер мотивлары белән башка әсәрләрне хәтерләтсә дә, яңача чишелеше белән укучыны җәлеп итә. Бер генә мәртәбә тешләнгән ипи телеме хикәя героеның күңелендә үзенчәлекле ассоциация тудыра. Ул әтисе тешләп киткән «кибән башы»ның авыз суларын китереп, кызыктырып торуы турында сөйли. Ләкин шул ипинең тарту көче әтисен сугыштан исән-сау кайтарсын өчен «кибән башын» ашамый түзә... Еллар үткәч, чүплеккә ташланган ипи телемен күреп: «Ул да үзен ташлап калдыручының яңадан кадерләп кулына алганын көтәдер шикелле тоелды миңа», дигән нәтиҗә ясый. Кырыс, әмма төгәл чагыштыру. Уйландырырлык, гыйбрәтле сүзләр! Икмәк кадере, игенченең авыр һәм мактаулы хезмәте хакында гамь әнә шул рәвешле хикәядән хикәягә күчә. Сугыш елларындагы авырлыкларны искә алу, шуның аша бүгенге көн матурлыкларын күрсәтү алымын сайлау да уртак пафосны, интонацияне ассызыклап бара. Гомумән, Ш. Маннапов үткән белән бүгенгене параллель куеп сурәтләргә ярата. Бу аның язу стилендәге бер үзенчәлек булып төсмерләнә, әсәрләренең актуаль яңгырашын, тәрбияви көчен арттыра.

Сүзне йомгаклап, җыентыкның нигезе өметле хикәяләрдән төзелгән, аларның уңышы — Шамил Маннаповның үзе сурәтләгән мохитне, кешеләрне яхшы белүендә, ятатуында, вакыйгаларга битараф калмыйча үз мөнәсәбәтен белдерә баруында, дип әйтәсе килә. Алдагы әсәрләрендә дә ул әнә шул юнәлештә үсәр төсле тоела.

**ФӘНИС ЯРУЛЛИН.**

# ЯЗУЧЫ ДИЛӘРА ЗӨБӘЕРОВАГА 50 ЯШЬ



*Язучы Диләра Зөбәерова әсәрләре укучыларга яхшы таныш. Бу популярлыкны аңа республика газета-журналларында күп еллардан бирле шактый еш басылып торучы мәкалә һәм очерклары, хикәя һәм повестьлары китерде.*

*Диләра Зөбәерова — Сарман ягыннан. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнан соң ул Татарстан китап нәшриятында, авыл районнары мәгариф системасында, район газетасы редакциясендә эшли. Соңгы унтугыз елда ул — «Азат хатын» журналының бүлек редакторы.*

*Һәрчак юлда, кешеләр арасында, хезмәт коллективларында ул. Тормышның эчендә кайнау иҗат өчен мул материал бирә. Диләра Зөбәерованың язганнары — халыкчан, гади, аерылмый укыла торган әсәрләр. Аның «Кичер, сөеклем», «Кызлар, кызлар», «Яшьләр күңеле» исемле китапларына дүрт повесть, иллеләп хикәя тупланган.*

*Әсәрләрендә авторның туган илне, табигатьне, саф әхлаклы кешеләрне олылавын тоясың, ә дөнья матурлыгына тап төшерүчеләр язучыны хафага сала, ул андыйларны фаш итәргә омтыла, аларга каршы өзлексез көрәшә.*

*Үзенең 50 яшен Диләра Зөбәерова яңа әсәрләр язып каршылады. Арадан берсен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез, кадерле укучылар.*

## Диләра Зөбәерова

# ГАДЕЛ ШЕЛТӘ

хикәя



Нефтебайга автобус әле генә китте,— диделәр миңа вокзалда.

Нәкъ шул чакта каяндыр шылт итеп бер озын гәүдә калыкты:

— Әнә машина! Алып кайтам!

Ул ишарәләгән почмакта соргылт «Жигули» ялтыравыклы маңгаен киереп тора иде. Мин шунда атылдым...

Кайчан да булса бер узылган юл барыбер онытылмый. Күрше республика белән безне аерып аккан Ыкның бу тирәләрендә мин моннан унбиш еллар элек булган идем.— Беренче командировкам иде, ахры.

Нефтебай болай бик зур булмаса да, кара алтынлы кала булып йөри. Атна яңалыкларын хәбәр итеп торучы радиоузелы бар. Шуның микрофонына үрелеп мин дә бер-ике сүз әйткән булдым. Кунак йортына кайтсам, иңенә чуклы шәл салган бер апа көтеп утыра.

— Син Мәлемнекеме әллә, үскәнем?
— Ие!
— Анаң Сармаштан төшкән...
— Ие шул...
— Тач Фахирә икәнсең.
Әнкәмнең исемен ишеткәч әсәрләнеп киттем.
— Анаң белән уйнап үскән Җәннәт тутаңны ишеткәнең булса, мин шул.
Җәннәт апаның бирегә мине радио аша юллап килүе икән. Тик бу танышлык аркасында мин журналист кешегә килешми торган, законлап әйткәндә, җинаять сыманрак нәрсә эшләп ташладым бит, әй.
Бу очрашудан соң күп тә үтми, җәй башлары иде булса кирәк, миңа, калынлыгына чыдый алмый бүселгән, бер хат килеп төште. Бу язма Җәннәт апаныкы булып чыкты. Төче-төче сәламнәрдән соң «бөтен дөньясына аһ орып» зарланырга тотынган. Нинди бәлаләргә юлыккан соң бу дисәм, сигезенчене тәмамлыйсы малаеның классында утырып калу куркынычы бар икән.
«...Ятим башым белән үзем капмый аңа каптырып үстергән бердәнбер бәбкәчем Мотыйгулламны жәллим. Бик тә тырыш, бик тә зиһенле бала бит инде, югыйсә. Менә шуңа кеше төсле генә мәктәбен бетерергә ирек юк, аяк чалалар».
«Аяк чалучысы» математика укытучысы Зәйниева иптәш икән. Малайның бу фәнгә теше бик үтми, күрәсең.
Хатның соңында бу «мәрхәмәтсезлеккә» ул ашыгыч чара күрүемне үтенгән, ялынып сораган.
Мотыйгулла укый торган мәктәпнең телефоны белән тоташтым да Зәйниева белән сөйләштем. Сүз арасында, кайсыдыр педагогтан ишеткән цитатаны кыстырдым: «Өлгермәүче укучылар юк, өлгертмәүче укытучылар гына бар».
Укытучы минем хәлгә кергәнгәме, Мотыйгулла тәки күчкән бит. Ул күчте дә котылды, ә мин тотылдым. Телефоннан сөйләшкәннәр нәкъ кешесенә ишетелгәннәр. «Кешесе» дигәнебез укытучыларның күзгә конференцияләрен генә күтеп торган...
Шелтәнең беренчесен һәм берәгәйлесен алдым. Менә шул вакыйгалардан соң озак кына бу якларга чыгарга кыенсынып йөрдем мин.

*
* *

— Килеп җиттек,— диде шоферым борылып,— Нефтебай — каршыбызда.
— Кунак йортына илтегез.
Шәһәр яшелләнгән, бөтәйгән. Шофер машинасын дүрт катлы коңгырт йорт борынына төртеп диярлек туктатты.
— Һи,— диде ул, ямьшек борынын тагын да киереп,— шулай гына түлисезмени?
Минем әллә оялудан, әллә ачудан аптырап калганымны тойгач «тиешле хакны» кире үземә сузды:
— Мәгез, бу тиеннәрегез белән мондый машинага утырмагыз.
Сабакка гына үскән шайтан таягыдай озын гәүдәле, кешеләрне танып белүдән мәхрүм бу шофер егетне жәлләп кунак йортына күтәрелдем дә администраторның тәрәзә уемына кагылдым.
— Урыннар юк һәм...
Өметсез җаваптан соң аптырап калмадым: булмаган урынны өмет итеп торганчы, тотарга да Җәннәт апаларга туктарга. Кунакка

чакырып язган чаклары күп булды. Фатирлары яңа иде шикелле. Күчмәгәннәрдер, шәт.

Җәннәт апа мине күрү шатлыгыннан нишләргә белмәде, кыстыйкыстый сыйлады, бүлдерә-бүлдерә сөйләде. Мин өчле куйдыртып классыннан күчергән Мотыйгулла да кеше булган. Типсә тимер өзәрлек сау-сәламәт бала икән. Шунысы кызык — һаман да әле «бала» икән.

Җәннәт апа белән хәтсез сөйләшеп утырганнан соң, мендәргә баш төртү белән йоклап кителгән.

Иртән минем торып килүемне күргәч, аяк очы белән генә йөргән хуҗабикәм батыраеп китте. Радионы көчәйтте. Өстенә ак тастымал япкан әзер табынны ачып җибәрде. Үзе сөйләнә-сөйләнә күрше бүлмәгә кереп китте һәм аннан улы белән пышылдап сөйләшүләре ишетелә башлады:

— Һаман тормадыңмыни әле син? Кара әле, гел имгәккә әйләндең бит, ходаем. Төне буе ресторандыр-месторандырда йөри дә... Җитә бит инде бу машина синең башкайларыңа... Шуннан тамган тиеннәргә алданып ташлагансыңдыр эшеңне, ә?!

— Малайны әйтәм, тормый ята, апасын күрми кала бит, раббым...— диде Җәннәт апа аның янынннан чыккач.

Җәннәт апа бу сүзләрне инде ничә мәртәбә кабатлагандыр, икенче чынаягымны каплап өстәл яныннан кузгалыйм дигәндә, ниһаять, ишеккә корылган чаршауны ике якка аерып Мотыйгулла килеп чыкты... Һәм көтелмәгән бу очрашуга әллә ачуы килеп, әллә читенсенеп сыек күзләрен читкә борды.

— Таныш инде, ни карап торасың,— диде Җәннәт апа, улының җилкәсенә төртеп.— Казандагы журналист апаң шушы бит.

— Без таныш инде,— дидем мин көрсенеп кенә,— ялгышмасам, кичә станциядән мин Сезнең машинага утырып кайттым бугай.

— Менәтерәк!— диде Җәннәт апа тагын да чәбәләнебрәк,— әйтми дә торалар тагын. Хәер, бер-берегезне танымагансыздыр инде. Ихи-хих-хи. Аңа ышансаң, хак та түләткәндер әле, акчаны бик ярата ул.

— Бөтен хикмәт тә шунда, түләтмәде шул,— дидем дә үзалдыма елмаеп куйдым: менә ни өчен әләккән икән миңа теге чактагы гадел шелтә. Шушы апаның гаилә бакчасында сабакка гына котыра торган файдасыз үлән үстерешкәнмен ич...

# КӘБИР БӘКЕРНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

*(1880—1941)*

Беренче рус революциясе нәтиҗәсендә туган татар вакытлы матбугаты сәхифәләрендә, Бөек Октябрьга әзерлек елларындагы һәм аннан соңгы әдәбият һәм культурабыз тормышында Кәбир Бәкер билгеле бер эз калдырган әдип. Аның мәкаләләре татар телендә чыккан беренче газета һәм журналларда ук еш күренә башлый. Башта аларда авторның әле эзләнү чорында гына булуы, үз темасын, үз даирәсен әлегә табып бетермәгәнлеге сизелеп тора. Ә инде 1907 нче елларга К. Бәкернең, барыннан да элек, культура һәм әдәбият мәсьәләләренә, бигрәк тә милли театр проблемаларына йөз тоткан автор икәнлеге ачыклана. «Әльислах», «Йолдыз», һәм «Вакыт» газеталарында ул даими рәвештә театрлар репертуарында булган пьесаларга, милли драматургиянең яңа үрнәкләренә рецензияләр язып килә. К. Бәкер театр тәнкыйтьчесе буларак, иң элек, үзенең оперативлыгы һәм объективлыгы, шул чордагы әдәбият һәм культура барышын яхшы тоемлавы белән күзгә ташлана. Аның театр тәнкыйте өлкәсендәге эшчәнлеге замандашлары тарафыннан да (аерым алганда, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һәм Җ. Вәлиди) югары бәяләнә.

Дөрес, Бәкер үзенең рецензия һәм күзәтүләрендә алай артык тирән анализларга тотынмый, культура тормышында вакыйга булырлык олы проблемалар да күтәреп чыкмый. Ләкин, шуңа да карамастан, ул язмалар зур кызыксыну белән укыла, аларда шул чор татар театр сәнгатенең үсеш закончалыклары, уңыш һәм кимчелекләре аермачык итеп күрсәтеп бирелә. Ул язган рецензияләрнең мавыктыргыч әдәби телдә һәм формада язылуы, информация һәм фактларга гаять бай булуы да күзгә ташланып тора. Гомумән, авторның театр тәнкыйтебезнең формалашуына һәм аның тормышчан, халыкчан нигездә үсеп китүенә керткән өлеше аерым игътибарга лаек. 1915 һәм 1916 елгы театр сезоннарына күзәтү рәвешендә язылган күләмле мәкаләләре К. Бәкернең бу юлда очраклы исем булмыйча, күңелен, җанын биреп иҗат иткән фидакарь мөхәррир булуын ачык күрсәтеп тора.

К. Бәкер театр тәнкыйтен һәм журналист эшчәнлеген әдәби иҗат белән дә уңышлы аралаштырып килә. Алдынгы карашлы шәкертләр органы, Ф. Әмирхан җитәкчелегендәге «Әльислах»та беренче хикәясе («Үзгәреш») басылганнан соң, ул алга әйдәгән кыю гына проблемалар күтәреп чыгарга сәләтле язучы буларак та таныла башлый. «Чөн там (яхут татар мәдрәсәсендә атнакич)» комедиясе (1909), «Чын егетлек нәрсәдә» (1909) «Кара тап», «Җанлы курчаклар» хикәяләре үз вакытында әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уяткан әсәрләр. Бу хакта Ф. Әмирханның югарыда искә алынган комедиягә, Г. Ибраһимовның «Җанлы курчаклар» хикәясенә махсус рецензияләр багышлавы да ачык сөйли булса кирәк. Татар әдәбияты классикларының һәр икесе Бәкернең сәләтле һәм заман тормышына йөз тотып, капиталистик чынбарлыкның җитди каршылыкларын кыю рәвештә фаш итеп чыккан үзенчәлекле автор булуын билгеләп узалар. Г. Ибраһимов һәм Ф. Әмирханның уңай тән-

кыйть сүзен кирәксезгә уңга-сулга сибеп йөргән әдипләр түгеллеген искәртеп тору урынсыз булса кирәк.

XX йөз башы татар әдәби процессында игътибарга лаек фигура булган К. Бәкер озак еллар дәвамында халык шагыйре Г. Тукай белән дә, якын мөнәсәбәттә булып, аралашып яши. Бу бигрәк тә Тукай Петербургка килгән һәм аларның икесе дә «Әльислах»та язышкан, эшләгән чорга карый. Соңрак, шагыйрь вафат булганнан соң, К. Бәкер «Тукай Петербургта» дип исемләнгән кызыклы гына истәлек тә язып тәмамлый һәм моның белән ул Тукай турындагы әдәбиятның беренче үрнәкләрен тудыруга үзеннән өлеш кертә.

Оренбургтан ерак түгел генә урнашкан Зубачы авылында нәкъ йөз ел элек дөньяга килеп, татар әдәбияты һәм культурасы үсешенә кулыннан килгән кадәре өлеш керткән тәнкыйтьче һәм язучы Кәбир Бәкер исеме искә алып узуга лаеклы.

## ХАЛИКЪ САДРИНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

*(1890—1955)*

Катлаулы һәм олы тормыш юлы узган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Халикъ Садриның тууына 90 ел. Шул уңайдан көнделәә, ирексездән, аның иҗат һәм тормыш биографиясе белән кызыксыну туа. Ә ул чынлап та бай һәм гыйбрәтле икән.

Габделхаликъ Гариф улы Садриев 1890 елның 4 августында хәзерге Куйбышев өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылында туа һәм Октябрь революциясенә кадәрге чорда Оренбург, Уфа, Баку, Самара шәһәрләрендә завод һәм нефть промыселларында эшләп «тормыш университетларын» уза, патша Россиясендәге гаделсезлекләрне татып, аларның асылына төшенә. Аның яшьли революцион көрәш юлына басуы бер дә гаҗәп түгел. 1917 елда булачак әдип В. В. Куйбышев рекомендациясе белән большевиклар партиясенә кабул ителә һәм гражданнар сугышының башыннан ахырына кадәр совет дәүләтен яклап көрәшә.

Х. Садри Кремльдә уздырылган татар-башкорт коммунистларының беренче киңәшмәсендә катнашып, В. И. Ленин белән очрашу бәхетенә дә ия була. Шул ук вакытта аның Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын оештыру турындагы тарихи закон проектына (1920) кул куйган татар халкы вәкилләренең берсе икәнлеге дә мәгълүм.

Х. Садри Казанда «Спартак» комбинатында директор булып эшли, аннан Бөек Ватан сугышында батальон командиры буларак, үзенең шәхси үрнәге белән сугышчыларны аяусыз көрәшкә рухландыра. Күп кенә орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

Әдәби иҗат эшенә ул Октябрь революциясенә кадәр үк тартылып, шул чорда байтак кына хикәяләр яза. Ә инде революциядән соң аның иҗаты бермә-бер активлашып, тагы да үсеп китә. Ул проза жанрында эшләү белән бергә үзен очеркларда, драматургиядә һәм поэзиядә дә сынап карый. Аның әсәрләре, нигездә, үзенең бай тормыш биографиясеннән аерылгысыз булып, үзара үрелеп бара. «Безнең таң», «Ил батырлары», «Тимерче малае», «Зиятдин балалары» кебек проза әсәрләре һәм «Йөзмә госпитальдә» исемле мемуар очеркы шул хакта сөйли.

Х. Садриның «Идел буенда сугышлар», «Партизаннар» һәм нәни тамашачыларның кайнар мәхәббәтен яулап алган «Камал бабай әкияте» пьесалары үз вакытында республикабыз сәхнәләрендә зур уңыш белән бара. Ә инде аның сүзләренә язылган «Шахтер җыры» (С. Сәйдәшев музыкасы) һәм «Туган илем» (З. Хәбибуллин музыкасы) кебек җырлар бүген дә үзләренең популярлыкларын югалтмаган.

Х. Садриның барлыгы 8 китабы дөнья күрә. Аның аеруча игътибарга лаек әсәрләре 1954 елда басылган «Ил батырлары» исемле сайланма җыентыгында урын алган.

## Иван Крылов

*1769—1844*

*Гаскәри офицер семьясында Мәскәүдә туа, этисе үлгәч кече канцелярист эшенә ялланырга мәҗбүр була. Ундүрт яшендә үзенең «Кофейница» исемле комик опера либреттосы кульязмасын тотып Петербургка килә, Казенный палатада эшли. Шигырьләр, трагедияләр, комедияләр яза, ләкин аларның берсе дә басылмый. 1789 елда «Рухлар почтасы» дигән сатирик журнал чыгара башлап үзен таныта, әмма дворяннар һәм чиновникларга каршы чыгышлары өчен журналны шул ук елда ябалар, ә яшь сатирик үзе провинциягә китеп югала һәм берничә пьеса яза. Бары тик 1806 елда гына башкалага кайтып мәсәлләрен бастыра.*

### Тычкан һәм күсе

«Күршекәй, ишеттеңме син искиткеч яхшы хәбәр?..—
Күсе оясына кереп, Тычкан шуны белдерә. —
Арыслан тырнагына барып капкан ди Мәче!
Димәк, инде безнең тормыш була ал да гөл генә!»
«Юкка куанма, алтынкаем, син, —
Дип өзеп аңа аңлата Күсе. —
Булмас нәрсәгә ышанма бер дә!
Тырнаклар ходка китәләр икән,
Арыслан, димәк, бетте дигән сүз:
Мәчедән көчле ерткыч юк җирдә!»
Мин күпләрне күрдем, сез дә төшенегез,
Шундый була җирдә барча куркак җаннар:
Аның котын алган затны бөтен дөнья
Минем күзләр белән күрә диеп аңлар.

## Александр Измайлов

*1779—1814*

*Владимир губернасында шактый ярлыланган алпавыт семьясында туа. Петербургтагы Тау-кадет корпусында үнике яшеннән башлап белем ала, соңыннан, 1806 елга чаклы, Дәүләт керемнәре экспедициясендә, аннары губернаторлыкта эшли. Петербургта укыта. 1802 елдан башлап «Сүз сәнгате, фәннәр һәм рәссамлык иркәле җәмгыяте»нең башта әгъзасы, соңыннан башлыгы була. «Мәсәлләр һәм әкиятләр» китабы 1814 елда басыла.*

### Ике кысла

«Бөтенегез артка чигенә,
Уйламыйча «кая барам?» — дип.
Бер карт Кысла улын битәрли:

Алга үрлә! Шуыш тик алга!
Юкса хәзер тотып ярам!» — дип.
«Күрсәт, атай, шушы үрнәкне,
Бер булса да күрсәт ичмасам.
Үрлә алга! Сиңа ияриm,
Мин калышмам синнән һичкайчан».

... Кыйный икән барин ялчысын,
эчкән өчен кыйный!
Ялчы курыкмый — чөнки хуҗасы
үзе эчеп туймый.

## Василий Жуковский

*1783—1852*

*Атаклы шагыйрь һәм тәрҗемәче, рус романтизмының әлгәреләреннән берсе. Мәсәл жанрына 1806—1807 елларда, ягъни Крыловның беренче мәсәлләре күренә башлагач, мөрәҗәгать итә һәм язганнарын «Вестник Европы» журналында бастыра.*

### Такыр башлар бәхәсе

Ике пеләш кода атлый бер тар юлдан
һәм ялтырап шунда нидер күренеп китә.
«Нинди бәхет! Без хәзинә таптык бугай!»
«Юк, мин таптым! — ди бер кода, — сиңа иртә!»
«Юләр сатма!» ди яшьрәге кинәт кызып,
һәм тегесен ныклап этә-төртә башлый
һәм... башыннан аның соңгы унлап бөртек
Чәчен өзеп сибә-чәчә җиргә ташлый.
Эш нәрсәдән гыйбарәт соң? Ник кирәкте
Икән шундый чиксез зур бәхәскә керү?
... Нәкъ шул юлда кемдер тарак җуйган икән,
Бәхәс өчен җитә кала шуны күрү.

## Александр Пушкин

*1799—1837*

*Пушкинның үз гомерендә язган бу бердәнбер мәсәле (1829) Н. Надеждинга каршы юнәлтелгән. Чөнки «Вестник Европы» журналында Н. Надеждин «Полтава» һәм «Граф Нулин» поэмаларына, Пушкин, янәсе, эстетик кагыйдәләр белән исәпләшми дип, гадел булмаган һәм урынсыз тәнкыйть яза. Шуңа җавап булганлыктан, әсәр полемик характерда. Аның «Мәзәк» дип билгеләнүе дә шуннан киләдер, бәлки.*

### Итекче

мәзәк

Көннәрнең берендә, имеш, итекче сурәт карый
һәм «туфлие начар чыккан» дигән катгый сүз әйтә.
Ә рәссам исә кулына пумала ала тиз-тиз —
Янәсе, итекче әйткән шул хатаны төзәтә.

Аннары тагын карый да итекче дәвам итә:
«Миңа калса, бу гүзәлнең йөзе кыеграк төсле...
Ә түше, дөресен әйтим, артык шәрәдер кебек»...
Шул чакны Апеллес аны бик кырт кисеп бүлдерә:
«Фикер әйт, ләкин итектән өскәрәк менмә, егет!»
Миңа да таныш шундый бер зат барын әйтим әле:
Белмим аның ни белүен һәм нәрсәне аңлавын,
Тик сизәм җиһан турында сөйләргә хак даулавын,
Әмма күн итек турында берни әйтә алмавын!

## Козьма Прутков

*Козьма Прутков — бертуган Жемчужниковлар: Алексей (1821—1908), Александр (1824—1895), Владимир (1830—1884) һәм танылган язучы Алексей Константинович Толстойның (1817—1875) уртак псевдонимы. Әсәрләре 1851 елдан башлап «Современник» журналының сатира бүлегендә, аннары «Искра» һәм «Свисток»та, «Современник»ның махсус сатирик кушымтасында басылалар. Күпчелек шигырьләре ул чакта инде телдән төшә, бәяләре кими башлаган жанрлар һәм темаларга пародия төсенә язылa һәм теге яки бу конкрет мәсәлгә каршы түгел, ә Крылов эпигоннары моралеңен ялган «зирәклеге» һәм «тирән фикерен»,бу жанрдагы штампларына һәм архаик формаларына каршы юнәлтеләләр. Козьма Прутков әсәрләренең беренче тулы җыелмасы 1884 елда чыга.*

### Ләкләк һәм чабыш арбасы

Чабыш арбасына утырып узганда бер алпавыт
Ләкләк очканны күреп ала күктән.
«Их! Нигә соң Зевс миңа да
Шундый озын тәпиләр бирмәде икән?!»
«Син белмисең, белә аны Зевс үзе!» —
Шундый була Ләкләк әйткән җавап сүзе.
Безнең бу мәсәл күпләргә гыйбрәт булсын:
Тумыштан татар икәнсең, татар бул син;
Мещан калсын әйдә шул ук мещанлыкта,
ә дворянин үз исеменә ябышып ята.
Әгәр дә тимерче кеше барин булырга
Теләсә — булыр иде бик зур хата.
Аны күпләр сантый диеп атар иде,
Бик күпләрнең көлеп эче катар иде.
Кая бирү аңа Ләкләк тәпиен,
Әлбәттә, бирми калырлар иде.
Хәтта ул ясаган чабыш арбасын
Бүтәннәр тартып алырлар иде.

### Корт һәм поп хатыны

Поп хатынының якасыннан
Ниндидер бер корт үрмәләп керә
Һәм ул аны тиз генә тотарга
Үз лакеена катгый әмер бирә.
Ир лакей шунда ук капшый да башлап
Ханымны көтмәгәндә куркыта...
«Нишлисең син, юләр?» — «Корт тотам».

Якасыннан корт кергәннәргә
Без әйтәбез шундый киңәш-фикер:
Түшеңне кешедән капшатма,
Кортны тот та үзең үтер.

## Демьян Бедный

*1883—1945*

*Херсон губернасында ярлы крестьян семьясында туа. Хәрби хезмәттән соң Петербург университетында укый. Беренче шигырьләре белән матбугатта 1899 елда күренә башлап, соңрак большевистик газеталар «Звезда» һәм «Правда»да үзенең шигырьләре, поэмалары, җырлары һәм мәсәлләре белән актив катнашып зур популярлык казана. «Мәсәлләр»е аерым китап булып беренче тапкыр 1913 елда чыга. Бөтен әсәрләренең 8 томлы тулы җыелмасы (1963—1964) илебездә киң яңгыраш тапты.*

### Бунт күтәргән куяннар

Утыз-кырыклап куян бергә
Киңәшәләр үр башында.
Хыяллар да, өметләр дә,
Теләкләр дә күренә шунда:
— Безгә көн юк, агай-эне.
— Болай яшәүдән ни файда?
— Хокук даулап көрәшик без!
— Ирек өчен үлик әйдә!

Кыю бу сүзләрдән хәтта баш әйләнә.
Нотыклар сөйләнелә зур гайрәт белән.
Шул чакны якында кыштырдый бер үлән.
Һәм «азатлык өчен мин баш куям»
дигән бер куян
Беренче булып урныннан куба да кача —
Үрдән шылырга бүтәннәргә юл ача.
Киңәшчеләр бар да бик тиз югала —
Кайсы кая тели, шунда юл ала!

## Самуил Маршак

*1887—1964*

*Атаклы совет шагыйре, Ленин премиясе лауреаты, өлкәннәр һәм балалар өчен бик күп китаплар авторы, танылган тәрҗемәче. Воронежда техник семьясында туа. Острогожск һәм Петербург гимназияләрендә укый. Әсәрләре 1907 елда басыла башлый. Берничә ел Англиядә яши. Бөек Ватан сугышы елларында илебездә иң оста рәссамнарның плакатлары һәм карикатураларына шигъри текстлар, фашист илбасарларны фаш иткән мәсәлләр яза. Балалар өчен китапларында да мәсәлләре күп.*

### Барабан белән быргы

Буп-буш эчле һәм лыгырдык
Барабан — тел бистәсе

Әйтә икән бер быргыга:
— Сыкравымны ишетәмсең?

Синең хәл шәптән — быргычың
Гел ереп кенә тора, —
Яратып үбүен гүя
Белдереп кенә тора.

Минем барабанчым исә
Һич аңламый хәлемне —
Таягы тукмый да тукмый
Авырттырып тәнемне.

— Әйе шул, — ди аңа быргы, —
Синең язмыш—тамаша,
Йөрсәк тә отряд алдыннан
Һәрвакытта янәшә.

Әмма гаеп үзеңдә бит,
Һәм үзең мәңге ачын:
Ник дөбердәргә өйрәндең
Бары тик кыйнагачтын?!

## Сергей Михалков

*1919*

*Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе һәм Дәүләт премияләре лауреаты, академик, шагыйрь, публицист, драматург, күренекле җәмәгать эшлеклесе. 1913 елда Мәскәүдә туа, Пятигорск шәһәрендә урта мәктәп тәмамлый, аннары Мәскәүдә әдәби институтта укый. Үзәк матбугатта 1933 елда басыла башлый. Ватан сугышы елларында, хәрби корреспондент буларак, фронт газетасында һәм Армиябезнең һава көчләре органында эшли. Беренче мәсәлләре сугыштан соң Алексей Толстой киңәшен тыңлап («Фольклордан чыгып, халык юморы җирлегендә иҗат иткәннәрең барыннан да уңышлырак. Сиңа мәсәл яза башларга кирәк түгелме икән ди ул аңа.») матбугатта күренә башлый. Хәзер алар бик күп китаплар булып та, бик күп телләргә тәрҗемә ителеп тә өзлексез чыгып торалар.*

### Бюрократ һәм үлем

Бюрократны алырга үлем килә.
Приемныйда утырып ярты көн көтә,
Приемныйда чират ничек артканын
Карый-карый тагын ярты көн үтә...
Һәм, чираты җиткәнгәчә... үлә ул.

Юк!
Бюрократ көчле түгел үлемнән!
Әмма озак яшәү серен белә ул.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ ЯШЬЛӘРЕ СЕМИНАРЫ

23—26 майда «Идел» халыкара яшьләр лагеренда иҗат яшьләренең VII республика семинары булды. ВЛКСМ өлкә комитеты, ТАССР Культура министрлыгы һәм Татарстан иҗат оешмалары оештырган бу форумда республикабызның төрле төбәкләреннән җыелган яшь язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар, архитекторлар катнашты.

Семинарны ТАССР Культура министры урынбасары, шагыйрь Р. М. Харисов ачты. Аннары ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе Р. А. Җиһаншина, шагыйрь Р. М. Миңнуллин, художник В. И. Рогожин, музыка белгече М. П. Фәйзуллаева, композитор Л. И. Блинов һ. б. иптәшләр сүз алды.

Иҗат яшьләренә идея-әхлак тәрбиясе бирү мәсьәләләренә багышланган доклад белән ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. М. Сафин чыкты.

Өч көн дәвамында «Художник һәм җәмгыять» дигән темага дискуссия уздырылды, империализмның СССРга каршы идеологик диверсияләре, бүгенге халыкара хәл, шулай ук Татарстанның социаль-экономик үсеше һәм унынчы бишьеллыкны тәгәлләү елы бурычлары турында лекцияләр тыңланды.

Бу форумда, идеология һәм культура чаралары белән беррәттән, аерым авторларның иҗатын тикшерүгә багышланган секция утырышлары да уздырылды. Мәсәлән, Рафис Әхмәтов һәм Афзал Нигъмәтуллин (поэзия), Әхәт Сафиуллинның (проза) кулъязма җыентыклары уңай бәяләнде, нәшриятка тәкъдим итәргә мөмкин дип табылды. Әсәрләрне тикшерүдә әдипләрдән Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Равил Кукушкин катнашты.

Иҗат яшьләре семинарында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

## РЕСПУБЛИКА-ЗОНА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Актанышта Минзәлә, Мөслим һәм Актаныш районнарыннан килгән яшь һәм башлап язучыларның республика-зона конференциясе үткәрелде. Анда әдипләрдән Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гатауллин, Габдулла Шәрәфи, Рөстәм Мингалимов, Ринат Мөхәммәдиев, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Мансур Вәлиев, Ризван Хәмид, Госман Садә, Җәүдәт Дәрзаманов, Рәфыйк Юнысов катнашты.

Конференцияне кереш сүз белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателенең яшьләр белән эшләү буенча урынбасары И. Юзеев ачып җибәрде. Партиянең Актаныш райкомы секретаре Р. Ә. Камильянов конференциядә катнашучыларга районның социаль-экономик үсеше, культура учакларының эше, Актанышның киләчәге турында сөйләде. Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Т. Миңнуллин әдәби осталык проблемаларына кагылышлы доклад белән чыкты.

Аннары башлап язучыларның әсәрләре тикшерелде. Мөслимнән Ф. Сафин, М. Әхмәтҗанов, К. Шәйхетдинов, Актаныштан Ф. Дәүләтбаев, Минзәләдән Г. Гимашева әсәрләре вакытлы матбугатка тәкъдим ителде. Конференциядә шулай ук яшь шагыйрә Роза Хәлиуллинаның да иҗаты тикшерелде һәм ул СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителде.

Соныннан язучылар әдәби-музыкаль кичә уздырдылар, группаларга бүленеп, колхозларда булдылар, чыгышлар ясадылар, район хуҗалыклары белән таныштылар.

## ЮГАРЫ ӘДӘБИ КУРСЛАР

СССР Язучылар союзының Югары әдәби курслары быел үзенең беренче чыгарылышының 25 еллык юбилеен үткәрде.

Әдәби курслар бик күп совет язучыларына чын иҗат мәктәбе булды. Алар үзләренең иң күренекле әсәрләрен нәкъ менә шушында иҗат иттеләр. 25 ел эчендә бирегә байтак кына татар язучылары да белемнәрен күтәрде һәм илебезнең төрле милләт әдипләре белән ике ел буе якыннан аралашып иҗат иттеләр. Алар арасында Зәки Нури (1955—1957 еллар), Хәй Вахит, Рафаил Төхфәтуллин, Юныс Әминев, Шәриф Хөсәенов, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Шамил Шагалиев, Мәсгут Шәрифуллин, Шамил Бикчурин, Рәдиф Гатауллин, Илдар Юзеев, Николай Беляев, Диас Вәлиев, Туфан Миңнуллин, Зөлфәт һәм Роберт Батулла, Рөстәм Мингалимов, Рәфкать Кәрами (1977—1979 елларда) кебек язучылар, шагыйрьләр бар. Бүгенге көндә әлеге эстафетаны шагыйрь Гәрәй Рәхим дәвам итә.

## ЯКТАШ ШАГЫЙРЬЛӘР ХӨРМӘТЕНӘ

Башкортстанның Дүртөйле районы, Чишмә авылында күренекле татар совет шагыйре Зыя Мансур укыган мәктәптә ша-

гыйрь истәлегенә мемориаль такта ачу тантанасы булды. Шушындый ук тантана Дүртөйле эшчеләр поселогында да үтте: анда Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрь Бәдрүш Мокамай яшәгән йортка мемориаль такта куелды. Тантаналарда халык депутатларының Дүртөйле район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары К. М. Гарипов, филология фәннәре кандидаты Суфиян Сафуанов, СССР Журналистлар союзы члены Вил Казыйханов һ. б. иптәшләр катнашты.

## ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ДИССЕРТАЦИЯ

Башкорт дәүләт университетының филология факультетындагы гыйльми советта Ош педагогия институтының рус һәм көнбатыш әдәбиятлары кафедрасы мөдире Н. М. Мурадымов «Әхмәт Фәйзи поэзиясендә герой һәм чор проблемалары» дигән темага язылган кандидатлык диссертациясе яклады. Филология фәннәре докторы Гыйлемдар Рамазанов, филология фәннәре кандидаты Тәлгат Галиуллин һ. б. иптәшләр Н. Мурадымовның хезмәтенә уңай бәя бирделәр, диссертациянең язучы иҗатын тикшерүдәге зур адым булуын әйттеләр.

## ОЧРАШУЛАР

Шагыйрьләр Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Роберт Миңнуллин, тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев, драматург Ризван Хәмид Башкортстанның Илеш районында булып кайттылар. Алар партиянең Илеш район комитеты беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое, РСФСР Верховный Советы депутаты Т. Л. Рахманов белән очраштылар, Илеш игенчеләренең эшләре белән таныштылар. Аннары Казан кунаклары район үзәге Югары Яркәйдә, шулай ук Жданов исемендәге колхозның Шәммәт авылында уздырылган сабан туйларында да катнаштылар.

*
* *

Куйбышев шәһәрендәге «Металлург» заводы Культура сарае каршында 1970 елдан бирле «Ялкынлы яшьлек» исемле татар халык ансамбле эшләп килә. Аның чыгышларын шәһәр тамашачылары гына түгел, өлкә районнарында яшәүче хезмәтчәннәр дә бик яратып тыңлыйлар. Репертуары нигездә татар язучылары һәм композиторлары әсәрләреннән торган алтмыш кешелек бу ансамбльне инженер Илгиз Колючев житәкли. Күптән түгел ансамбль үзенең унъеллыгын бәйрәм итте. Бу бәйрәмдә Казаннан композитор Әнвәр Бакиров, язучы Шамил Рәкыйпов, шагыйрьләр Галимҗан Латыйп, Рәшит Гәрәй катнашты.

*
* *

Казанның яңа микрорайонындагы 49 нчы урта мәктәбендә Тукай бүлмәсе ачылды. Аны ачу тантанасында шагыйрьләр Илдар Юзеев белән Рәшит Гәрәй чыгыш ясады.

*
* *

Язучы Марон Хәмидуллин, шагыйрь Хәкимҗан Халиков, Татарстанның атказанган артисты Әзәл Яһудин Чүпрәле районында булдылар. Алар «Ялкын», «Чишмә», Бауман исемендәге һәм Фрунзе исемендәге колхозларның Культура йортларында әдәби-музыкаль кичәләр уздырдылар, Яңа Чокалы, Иске Чокалы, Татар Шатыршаны, Татар Төкесе, Кече Чынлы мәктәпләре укучылары белән очраштылар, терлекчелек фермаларында һәм җәйләүләрдә чыгыш ясадылар.

*
* *

Язучы Ләбибә Ихсанова Кукмара район газетасы каршындагы «Салават күпере» исемле әдәбият түгәрәге утырышында катнашты, түгәрәктә катнашучыларның әсәрләренә анализ ясады. Икенче көнне язучы Балыклы авылында оештырылган «Ләйсән тамчылары» дигән әдәбият түгәрәгендә дә булды. Анда укучы балаларның шигырьләре тикшерелде. Соңыннан «Урал» колхозы эшчәннәре белән очрашулар уздырылды.

*
* *

Шагыйрь Рәшит Гәрәй Минзәлә совхоз-техникумы укучылары һәм укытучылары белән очрашты. Бу очрашуда ул якташларына туган җир, авыл һәм аның кешеләре турындагы шигырьләрен укыды, бирелгән сорауларга җавап бирде, ... язучылар белән әңгәмә уздырды.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешманың чираттагы утырышында язучы Җәмит Рәхимовның «Кыядагы чәчәкләр» исемле романы тикшерелде. Әсәр Обь елгасы буйларыннан Иделгә кадәр нефтьтәргеч торба салучыларның батыр хезмәтләрен чагылдыруны, совет кешеләренең бай рухлы характерларын ачып бирүне максат итеп куйган. Чыгыш ясаучылардан Рафаил Төхфәтуллин, Хәниф Хәйруллин, Гамил Афзал, Шамил Бикчурин, Әдип Маликов, Азат Ганиев, Альберт Хәсәнов, Фәрит Гыйльметдинов, Хава Сафина, Әзһәр Габиди, Разим Вәлиуллин авторга әсәрне тагын да яхшырту юнәлешендә күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр.

*
* *

Лениногорск язучылары Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, Альберт Хәсәнов шәһәрнең нефть техникумы студентлары белән очрашу уздырып, үзләренең нефтьчеләргә багышланган әсәрләрен укыдылар, киләчәктәге иҗат планнары турында сөйләделәр, әдәбиятка кагылышлы сорауларга җавап бирделәр.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешманың «Ләйсән» әдәбият берләшмәсе белән берга уздырылган утырышында яшь прозаик Рафис Сәлимҗановның «Өч көн

яңгыр» исемле повесте тикшерелде. Тормышчан күзәтүләрне, кызыклы һәм гыйбрәтле фикерләрне эченә алган бу әсәр үзенчәлекле формада язылган. Ләкин ул әле чын әдәби калыпка салынмаган: композицион таркаулык үзен нык сиздерә, образлар томанлы, сюжет сызыгы да билгеле бер юнәлештә үстерелми. Тикшерүдә катнашкан Эдуард Касыймов, Нәҗип Мадьяров, Газиз Кашапов, Равил Лотфуллин, Хәниф Хөснуллин иптәшләрнең киңәшләрен искә алып, яшь автор повестьны камилләштерү өстендә ныклап эшләргә тиеш.

*
* *

Түбән Кама шәһәрендәге «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышында яшь прозаик Фәтхулла Абдуллинның хикәяләр һәм очерклар җыентыгы тикшерелде. Тикшерүдә катнашучы Р. Хисмәтуллин, М. Хәбибуллин, К. Зиннәтуллин, Р. Сафин иптәшләр җыентыкның нигезе ышанычлы икәнен, әмма кайбер әсәрләрнең, бигрәк тә хикәяләрнең әдәби яктан әле зәгыйфь булуларын, аларны чын мәгънәдә художестволы итеп эшләргә кирәклеген әйттеләр.

Яшь хикәячеләр Зәбир Ныймаев белән Нәфисә Гафиятованың әсәрләрен тикшерүгә багышланган икенче утырышта яшь авторларга тормышка тирәнрәк, кыюрак үтеп керергә, иҗатта активрак булырга кирәклеге әйтелде.

*
* *

Язучы Эдуард Касыймов һәм шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин Круглое Поле тимер юл станциясендә транспорт милициясе хезмәткәрләре белән очрашу үткәрделәр. Э. Касыймов әле быел гына ачылган Чаллы язучылар оешмасының бурычлары, максаты турында сөйләде, үзенең иҗат юлы, иҗат планнары белән таныштырды, К. Сибгатуллин яңа шигырьләрен укыды.

*
* *

Чаллыда һәм Түбән Камада традицион шигырь бәйрәмнәре һәрвакыт зур күтәренкелек белән уза.

Чаллының «Энергетик» культура сараенда узган быелгы бәйрәм «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән девиз белән үткәрелде. Шигырь кичәсендә шагыйрьләр К. Сибгатуллин, Ф. Хәлиуллина, В. Хәбибрахманова, Я. Игәнәй, Ә. Сабирова, Р. Асылбаева, М. Сафин чыгыш ясадылар, үзешчән композиторлар Х. Булатов, И. Шәфиков, З. Сәгыйтов, җырчылар Р. Мөхәммәтҗанова, Л. Сәгыйтова һәм Х. Шәфиковаларның чыгышларын да тамашачылар яратып тыңлады. Кичәне язучы Эдуард Касыймов алып барды.

Түбән Кама шәһәренең Техника йортында «Язгы сагынулар» исемле әдәби-музыкаль кичә узды. Язучы Рахмай Хисмәтуллин әзерләгән әлеге кичәдә яшь шагыйрьләр Г. Нигъмәтуллин, М. Хәбибуллин, М. Шәйхи, К. Гыйльмуллин, «Яшьлек» җыр-бию ансамбле катнашты. Икенче көнне түбән камалылар Габдулла Тукай һәйкәле янына җыелдылар — шигырь бәйрәме шунда дәвам итте. Аны шәһәр башкарма комитетының культура бүлеге мөдире Ренат Әхмәтҗанов ачып җибәрде. Мәйданда «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе члennары, шулай ук Түбән Кама, Каенлы һәм Шәңгәлче мәктәпләреннән килгән укучылар үз әсәрләрен укыдылар.

*
* *

Чаллы язучылар оешмасы, «Орфей» һәм «Ләйсән» әдәбият берләшмәләре белән берлектә, ТАССРның 60 еллыгына багышланган әдәби кичә үткәрде. Бу очрашуда прозаик Э. Касыймов, шагыйрь М. Газизов, шулай ук әдәбият берләшмәләре члennары чыгыш ясады. Кичәдә Чаллы язучылары китапларын сату оештырылды. Китап сөючеләр Совет Татарстаны язучылары әсәрләреннән төзелгән зур күргәзмә белән дә таныштылар.

## Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ МИРАС КОМИССИЯСЕ

Татарстан Язучылар союзы күренекле татар совет язучысы Габдрахман Әпсәләмовның мирас комиссиясен төзеде. Комиссиягә түбәндәге иптәшләр кертелде: Г. Ахунов (председатель), Ф. Миңнуллин (председатель урынбасары), В. Нуруллин, З. Нури, Н. Юзеев, Л. Ихсанова (секретарь), Ф. Мусин, Р. Сверигин, Ш. Рәкыйпов, М. Әпсәләмова. Комиссия якын арада түбәндәге эшләрне башкарачак: Казанның яңа төзелгән бер урамына Г. Әпсәләмов исемен бирү; әдипнең туган ягында — Мордовия АССРның Рыбкин районы Иске Аллагул авылында — мәктәпкә һәм пионер дружинасына язучының исемен бирү; Г. Әпсәләмовның Казанда торган йортына мәрмәр такта кую; әдипнең язма мирасын тәгәл барлау; Г. Әпсәләмовның иҗаты һәм тормыш юлы турында монография язуны оештыру, замандашлары язган мәкаләләр, истәлекләр китабын төзеп чыгару; язучының 1981 елда булачак 70 еллык юбилеена әзерлек эшләрен башлау.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Совет сынлы сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Харис Абдрахманович **Якуповка** «СССРның халык художнигы» дигән мактаулы исем бирелде. (1980 ел, 13 май).

*
* *

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм житмеш яшь тулу уңаеннан язучы **Нәби Дәүли** «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде (1980 ел, 30 май).

# Шәйхи Маннур



Совет әдәбияты авыр югалтуга дучар булды — 1980 елның 10 июнендә күренекле татар язучысы, үзенчәлекле художник, бөтен тормышын халыкка һәм үзе аның сафларында 40 елга якын член булып торган Коммунистлар партиясенә илһамлы хезмәт итүгә багышлаган Шәйхи Маннур 76 нчы яшендә вафат булды.

Шәйхи Маннур (Маннуров Шәйхи Фәрхулович) 1905 елның 15 январенда Татарстан АССРның Мамадыш районы, Тулбай авылында крестьян семьясында туа. Хезмәт эшчәнлеген ул бик иртә башлый. Себер шахталарында забойщик, металлургия заводында прокатчы, Днепростройда бетончы булып эшли. Совет-партия мәктәбендә укый, ә аннары Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. «Совет әдәбияты» журналының (хәзер «Казан утлары») җаваплы секретаре була. Кызыл Армия сафларында хезмәт итә.

Шәйхи Маннурның беренче шигырьләре 1923 елда күренә башлый. Шул вакыттан бирле ул 46 китап чыгара. Бу китапларда 1917 елгы революцион вакыйгалар, илебездәге гигант үзгәртеп корулар, совет кешеләренең героик хезмәте, аларның сугышчан һәм хезмәт батырлыклары ачык чагылдырыла.

Бөек Ватан сугышы чорында Ш. Маннур «Сугышчан чакыру», «Алга, дошман өстенә», «Ватан намусы өчен» дигән фронт газеталары корреспонденты булып эшли. Газета битләрендә совет сугышчыларының батырлыгы турында шигырьләрен, хикәя һәм очеркларын бастыра.

Сугыштан соңгы елларда язучының таланты яңа көч белән ачыла. Ул «Җир-әнкәнең сылу кызы» дигән шигъри романын иҗат итә, анда Татарстанда беренче булып нефть табучыларның фидакарь хезмәте гәүдәләнә. Муса Җәлил турындагы роман аның иҗатында аерым бер этап булып тора.

Ш. Маннур рус әдәбиятын пропагандалауга зур игътибар бирде. Ул «Игорь полкы турында җыр»ны, А. Пушкин, И. Крылов, М. Лермонтов, С. Михалков һәм башка язучыларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте Ш. Маннурның хезмәтләрен югары бәяләделәр. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы, Кызыл Йолдыз, «Почет билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнде.

Шәйхи Маннур гомеренең соңгы көненә кадәр «Казан утлары» журналының редколлегиясе члены, коллективның якын дусты, киңәшчесе, ярдәмчесе иде.

Күренекле язучы, Совет Ватанының патриоты Ш. Маннурның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Тиздән, гадәттәгечә, вакытлы матбугатка язылу башланачак. Билгеле ки, бездә һәркем үзе теләгән газета-журналга алдан ук язылып куя һәм аңа ел әйләнәсендә шул газеталарны, журналларны китереп торалар. Әмма, укучылардан килгән кайбер хәбәрләргә карагaнда, еш кына көтелмәгән тоткарлыклар килеп чыга. Кызыксына башласаң, барысының да сәбәбе бер генә була: язылу чарасына соңга калып керешкәннәр, укучыларны газета-журналлар белән тәэмин итәргә тиешле «Союзпечать» оешмасы вәкилләре исә үз эшләрен түгәрәкләп куйганнар, планнар үтәлгән, отчетлар бирелгән. Бу очракта журналны алдырырга теләгәннәргә ярдәм итү катлауланa, хәтта бөтенләй мөмкин дә булмый.

Мондый күңелсезлекләр чыкмасын өчен, «Казан утлары» журналына язылуны алдан ук рәсмиләштереп куярга киңәш итәбез. Журнал Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы, ягъни каталогтагы күрсәткеч саны — 73210. Димәк, «Казан утлары»-на илнең теләсә кайсы шәһәр, авылында язылырга мөмкин. Бу эшне почта бүлеге һәм «Союзпечать» агентлыгы хезмәткәрләре башкарырга тиеш.

Урыннарда, нинди дә булса берәр сәбәп табып, журналга яздырмасалар, еллык бәяне түбәндәге адрес белән җибәрә аласыз:

420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. Татарское республиканское агентство «Союзпечать» (для подписки на журнал «Казан утлары»).

Бу очракта да соңга калырга һич ярамый, адресыгызны бик төгәл һәм тулы итеп язарга кирәк.

Журналның еллык бәясе — 6 сум.

«Казан утлары»на язылган укучыны тирән эчтәлекле, чын сәнгатьчә иҗат ителгән берсеннән-берсе кызыклырак, мавыктыргычрак яңа әсәрләр белән танышу шатлыгы көтә. Алар арасында Татарстанның күренекле өлкән әдипләренең дә, урта буын һәм яшь язучыларның да, әдәбиятта әле беренче адым ясаучыларның да язмалары булыр.

Прозаиклардан Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Ш. Бикчурин, М. Юныс, Б. Камалов, М. Хәсәнов һәм башкалар редакциягә кульъязмаларын тәкъдим иттеләр дә инде.

Шигырь сөючеләр яраткан шагыйрьләренең яңа әсәрләрен укып шатланачаклар.

Очерклар бүлеге укучыларны Татарстанның промышленносте, авыл хуҗалыгы һәм культурасындагы проблемалар, алдынгыларның эш ысуллары белән таныштырып торачак.

Әдәби тәнкыйть мәкаләләрен язуга республиканың иң көчле тәнкыйтьчеләре тартылачак.

Җыр яратучыларга республика композиторларының иң матур әсәрләре тәкъдим ителәчәк.

Кыскасы, журналдагы уннарча рубриканың һәркайсы укучыга сөенечле яңалык, рухи байлык алып киләчәк. Укучылар исә танышкан әсәрләргә карата туган уй-фикерләрен шулай ук журналга язып чыга алачаклар. Моның өчен «Укучылар сүзе» исемле махсус бүлек бар.

Редколлегия һәм әдәби хезмәткәрләр журнал алдыручыларны канәгатьләндерү өчен көчләрен кызганмаячаклар.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ